# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Гел сөенче көтәм... *Шигырьләр*. ....................3
Марат ӘМИРХАНОВ. Яугирә. *Роман*. ....................8
Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Күрше хакы – тәңре хакы. *Шигъри дастан*. ....................64
Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Таш Түккән – сихри божра. *Роман*. ....................74
Рәфкать ШАҺИЕВ. Гамәл дәфтәремне тикшерәмен... *Шигырьләр*. ....................137
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Калхуз хикәятләре. ....................141

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Гаврил АНДРОСОВ. Кырыымпа моңнарына тоташ күмелүебез... *Шигырьләр*.
*(Рүзәл МӨХӘММӘТШИН тәрҗемәләре.)* ....................155

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фәгыйлә ШАКИРОВА. Гөлчәчәкнең яңа тормышы. *Хикәя*. ....................159

*Фотоархив:* Ибраһим Нуруллинның тууына – 100 ел.
*(Сәхифәне Айдар ШӘЙХИН әзерләде)*. ....................162

2023 ЕЛ – ДАСТАННАР ЕЛЫ

Илсөяр ЗАКИРОВА.Татарда дастан бармы? ....................164

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Йолдызларга гашыйк шагыйрә (*Рәсимә Гарифуллина иҗатына бер караш)*. ....................171

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Азәрбайҗандагы тукайчы-галим. ....................177
Һүсәйин БАРГАН. Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860–1917 еллар арасында Идел-Урал татар әдәбиятына йогынтысы. *(Төрекчәдән Ринат СӘФӘРОВ тәрҗемәсе)*. ....................181

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Түбәтәйле әдип *(Мәхмүт Хөсәеннең тууына – 100 ел)*. ....................185
Шигырьләре көйгә ятып тора... *(Рамазан Байтимеровның тууына – 100 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара*. ....................186
Рамазан БАЙТИМЕРОВ. *Шигырьләр*. ....................187

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Ландыш НӘСЫЙХОВА. Җиләкле гомер. ....................188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 4 (1206) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.03.2023, график буенча 30.03.2023, басылып чыгу вакыты 05.04.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-0837. Тираж 5690.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Сания
Әхмәтҗанова

# ГЕЛ СӨЕНЧЕ КӨТӘМ...

## Апрель җиле

Туган телем яраланган бер кош сыман,
Талпынса да, чыга алмый читлек ватып.
Дүрт диварга бикләнгәндәй бәргәләнеп,
Янып төшә җаны канап, сыны катып.

Туган телем, бик гайрәтле тоелса да,
Китә алмый үз-үзеннән күпкә ерак...
Иреге дә аның тартып алынмаган,
Сулышын да ала әмма рөхсәт сорап.

Туган телем хаста Тукай хәлендәрәк,
Бәһасез дә үзе, әмма кадерсез дә...
Апрель җиле зәгыйфь курай булып гыжлый:
Калмагыз, ди, туган телсез, бәгырьсезгә...

## Бер ачыклык!

Чытырманлы сукмаклардан барган кебек
Кармаланып юл ерабыз алга таба.
«Менә-менә бер ачыклык күренер» дип,
Нәүмиз өмет алдан чаба... Йөрәк кага...

Хак юл эзләп тәгәрәткән бүз йомгакны
Сүтә айлар, сүтә еллар... Түзем бетә...
Кояш нуры, вак иләктән иләнгәндәй,
Кургашсыман болытларны тишеп үтә.

---

Сания ӘХМӘТҖАНОВА (1962) – *шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Һ.Такташ һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Пар алма», «Гәрәбә», «Язмышлар такыясы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ялгыш сукмак сайландымы юл башында,
Юлбашчыбыз югалттымы җепнең очын?..
Бер тукталып, киңәш-табыш итик мәллә,
Ниятләгән кыйблабызны барлар өчен?

Комсыз бүре майлы калҗа умырганда,
Ач юлчылар тешен-тешкә шыкырдата.
«Сезнең көтү бетү юлын сайлаган» дип,
Козгын сыман кем ул башны тукылдата?

Юнәлешне кирәк, диләр, үзгәртергә,
Чыгар юлны таба алмый адашканда...
Терек-терек теркелдибез күзне йомып,
«Көтү башы» күз дә йоммый алдашканда.

Сирәгәя юлдашлар да тора-бара,
Аксакаллар – зирәк картлар ятып кала.
Шуны көткән ач сыртланнар[1], ыржаешып,
Әлсерәгән баш миенә коткы сала.

Сөйләнәбез: «Без – Ак бүре нәселеннән,
Ак барслы туграбыз» дип мактанабыз.
Ник соң әле кемлегебез раслар чакта
Вакланабыз, акланабыз, сакланабыз?!.

Без иманга ахыргача тугры калыйк,
Бу кавемгә төс булмаган һич качаклык...
...Баш очында кояш тәмам тотылганчы
Талпыныйк та эзләп табыйк бер ачыклык!
Бер ачыклык!

## Уйласам...

Уңышлардан тартынуым түгел,
Бүлешергә никтер кыймасам...
Бәхет күгем кинәт чүгеп куя,
Ил хәсрәтен әгәр уйласам.

Җир-Әнкәнең хәлен күрер идем,
Кош юлларын иңләп-буйласам.
Сулышымнан канатларым көя,
Ил хәсрәтен әгәр уйласам.

«Хәтәрлегем» тыеп калалмам күк,
Гакылымны гына җуймасам...
Көчсезлегем йөзгә төкергәндәй,
Ил хәсрәтен әгәр уйласам.

## Кайда син, Гаделлек?

Кайда син, Гаделлек? Бармы син?
Тукталган тарафың кай якта?!
«Бар ул!» дип, ничәнче мәртәбә
Калырга тырмаштык аякта.

Көч туплап, күкләргә таяндык,
Буынның егәре бетсә дә,
«Бирешәм, бирешәм...» дигән уй
Акылны яшендәй өтсә дә.

Гаделлек син нинди? Ни төстә?
Кем сине хәрамга буяган?
Башыңны ук алып качтыңмы
Бу сатлык һәм денсез дөньядан?

[1] Сыртлан – гиена.

Кизәнә палачлар гөрзие,
Яшькә дә, көчкә дә карамый.
Нәфесе котырган шайтанга
Чик түгел «ярый» һәм «ярамый».

Туктамый тилереп тукмашу,
Тамаша кылыр көч калмады...
Ачкүзле, чаяндай ябышып,
Бәгырьгә тешләрен кадады.

Кем генә чик куяр бу хәлгә,
«Җитте» дип дәшәргә кем кыяр?
Озакмы бергә-бер, йөзгә-йөз
Мәгънәсез мин-минлек кан кояр?

Гаделлек! Син кайда-а? Юктыр син!
Йөрәгең таш мәллә, боз мәллә?!
Комсызлар яңа үч әзерли,
Бугаздан алганы аз мәллә?

Ташламас сөекле бәндәсен,
Саклар Бер Раббысы һәм яклар!
Һәм җиде тарафтан Гаделлек
«Аллаһу әкбәр»ен кабатлар.

## Кыш. 2023

Суык, диләр! Шуннан?! Кирәк икән,
Төренәм мин мамык юрганга.
Туңа калсам, йон оекбаш киям,
Җылымса су салам комганга.

Зәмһәрир кыш миңа кышмыни ул,
Телем бармый өшим дияргә!
Кулны өтә затлы күн перчаткам,
Оят чәшке туным кияргә.

Җылы өйдән торып, тәрәз аша
Кышкы манзараны күзлим мин.
«Минус кырык», диләр. Булса бардыр...
Җаным тоташ утта... Сизмим мин.

...«Урыс кышы» – салкын окопларда
Яткан яугирләргә кыштыр ул...
Кышкы маза[2] – солдат аягына
Берегеп каткан бозлы ыштыр[3] ул.

Автоматның түтәсендә оеп,
Сызлап җан әрнеткән куллар ул!
Соң җылысы кар көртенә уйган
Ләхет эчендәге уллар ул.

Адаштыргыч ялган маягы ул
Хак үлемгә илткән юлларның;
«Урыс кышы» – ачы бәддогасы
Ышанычын җуйган толларның.

...Солдат хатыннарын йокы алмый –
Тәрәзләрдә утлар яналар.
Яшь аралаш догасында көн-төн
Газиз улын көткән аналар.

Якын көндә раска чыкса иде
«Тизрәк узсын!» дигән теләкләр.
«Урыс кышы»н утка тотар булып,
Җанны ягып сыза йөрәкләр.

## Гел сөенче көтәм...

«Апай, шөкер! Сыер бозаулады!» –
Энем иртүк сәлам юллады.
Ил-көннәрдән әле бу арада
Шуннан яхшы хәбәр булмады.

Шуңадырмы, күздән яшьләр килде,
Искә алып туган нигезне...
Аллаһ бөек! Яшәү гаме өстәп,
Дөньяларны шулай тигезли.

...«Числолык»ка яза иде әни:
«Йолдызны[4], – дип, – бүген, йөгерттек...»
Бала акылы белән без ул көнне
Бәйрәм көнгә санап гел йөрттек.

Күз алдыма килә әти, җаным,
«Сөенче!» дип өйгә кергәне.
«Карчык, шөкер, Йолдыз бозаулаган,
Насыйп булгач, безгә биргәне».

Ишле иде гаилә, йортта сыер –
Балаларның тамак туклыгы.
Икмәк белән сөт-катыгың булса,
Кичерелгән башка юклыгы...

---

[2] Маза – монда: борчу, мәшәкать.
[3] Ыштыр – аяк чолгавы.
[4] Йолдыз – сыер кушаматы.

«Сугыш белән ачлык язмасын» дип,
Тели иде һәрчак өлкәннәр.
Башкасына риза-бәхил булып,
Сабыр гына дөнья көткәннәр.

«Сугыш кына була күрмәсен дә,
Ачлык кына, берүк, килмәсен...»
Сыный Аллаһ, кайта-кайта сыный,
Тәүбәләргә килмәс бәндәсен.

«Апай, иртүк сыер бозаулады!» –
Күпме өмет шушы хәбәрдә.
Кеше булмас идек, җан түреннән
Яшәү ямен җуйсак әгәр дә!

...Гел сөенче көтәм... Бу тормышлар
Торса иде имин булыплар!
Кургашындай, дөнья күген сарган
Дары исе килгән болытлар.

***

Мин – мин түгел,
Син – син түгел,
Без – без түгел...
Ни дисәң дә, дөньялыкка баглы күңел.
Барыбыз да башка идек бер кыш элек,
Кешелектән генә язма, әй кешелек!

Нурсыз – күзләр,
Татсыз – сүзләр,
Җансыз – йөзләр...
Түзә йөрәк, түзгән кадәр тагын түзәр.
Язып булмас бу тәкъдирне яңабаштан,
Тик шулай да бер могҗиза көтәм кыштан.

## Кеше булып!

*Бу галәмдә без бик кечкенә шул,*
*Ә яшисе килә зур булып...*
Кадыйр Сибгатуллин

Күз карашым «укый» әңгәмәдәш,
Шикләнгәндәй: дусмы, дошманмы?
Үз фикере микән ми сырында,
Әллә сөйли «зур»лар кушканны?

Сүзен үлчәп кенә ычкындыра,
Юкса мине сатлык саныймы?
«Син хаклы» дип бармак төбәвеме,
Әллә әләк белән яныймы?

Аңлашабыз санлашмыйча гына,
Җитте бигрәк сәер замана.
«Әйт» дигәнгә, «тәйт» дип җавап бирсәң,
Килеп тора бик тә таманга.

«Олы»ларның сүзе һәрчак өстен,
«Кече»ләргә – каршы дәшмисе!
...Бу дөньяда зур йә кече түгел,
Кеше булып килә яшисе!

## Үземә әйтәм, син ишет...

Сүзсез калдың, дисез, бу арада, –
Туктап торып, бер тын алуым.
Юкны сөйләп кәеф китәргәнче,
Хәерлерәк дәшми калуым.

Сүз кадере киткән замана бу,
Чәчкәнне бер булыр җыясы.
Чит авызны томалавы җиңел,
Үз телемне ничек тыясы?

Тел белән без таулар күчерәбез,
Күлне дәррәү күккә асабыз.
Иң кирәк сүз соралганда менә,
Кабырчыкка кереп качабыз.

Уңга-сулга – «уклар» очырабыз,
Җитмәсен тик кеше башына...
Акланырлык сүз табылса ярый,
Баскач беркөн Халикъ каршына.

## Ике азан арасы

Баш түбәмә басып, күкләр ныклыгым сыный тагын...
Җир белән күк арасында адашып йөргән чагым.
Гомернең тәгәрмәченә өстәлде яңа киртек...
Күңелемнең төннегеннән тулган ай бага үртәп.
Шатлык тулы дөньягызга әйтерсең бер мин сыймыйм.
Үземә үзем үги мин, үземне үзем сөймим.
Шәфәкъ учагында ягам тоташ төннең карасын.
Догаларым белән бәйлим ике азан арасын.
Килми туктап каласым...

## Уен-дуен

Гомер юлы язмышына алдан-ала сызылгандыр.
«Көрәшче» дип, ир баланың маңгаена язылгандыр.
Малай-шалай, әсәренеп, «сугыш-сугыш» уйнап үсә.
«Алга!» дигән сүз көченнән яугир рухы аңа күчә.
Ир-егетнең калебендә көрәш уты дөрләп яна.
Илен саклау – җиде буын бабасыннан мирас аңа.
Уен булса кагыйдәсез, уйный торгач, уймак чыгар.
Ил данын да, ир данын да дуен[5]-мәхшәр төптән егар.
Илбасардан илен яклап, Ватан-Ана хакын хаклап,
Гадел көрәш кичсә генә, кайтыр ирләр горур атлап.
...Тәрәзендә уты яна, намазлыкка яше тама.
Хәтәр дуен тынсын, диеп, догасында көн-төн ана.

## Тансык бәхет

Бәхетнең була күрми калганы,
Гомерләр буе көтеп алганы.
Җәйге чилләдә яуган карым син,
Сөеп туялмас тансык ярым син.
Тылсымлы назың дөрләтә канны,
Сөю ширбәтең сугара җанны.

Тартылам утка тартылган кебек,
Сихри төш сыман югалма эреп.
Бу могҗизага ышанмый күңел,
Сине баш җуеп сөймәслек түгел!
Сакласын Күкләр, тимәсен күзем,
Көнлим мин сине үземнән-үзем.

## Яшел туй

Яз учында йоклый бөре кызы,
Ул гөл булып туар таңнарда.
Чык-яшендә тоеп карашыңны,
Сөю хисем дөрләп яңара.

Яз учында йоклый бөре кызы,
Аңа карап дөнья куана.
Сагынуым гөлдән-гөлгә куна,
Сине уйлап күңелем юана.

Яз учында йоклый бөре кызы,
Тибрәнгәләп җилләр куйнында.
Төшләрендә ап-ак күлмәк киеп
Вальс бии Яшел туенда[6].

[5] Дуен – диал. Берәр эшнең, тамашаның иң кызган чагы, өлеше; эшнең, бурычның иң хәтәр, иң авыр өлеше һ.б.
[6] Яшел туй – никах туе.



Марат
Әмирханов

# ЯУГИРӘ

РОМАН

*Болгар – Төркестан шәһәре.*
*Анда гүзәлләр күп.*
Мәүләви әл-Лари

– Алаяк, дим, Алаяк, җүләрләнмә, Силки мәлик алдында мине генә вәгъдәсезгә калдырасың бит, – дип, Бану бикәч чабышкылар сафыннан читкә каерылган җәбә-толпарын тыймак булып, ничек кенә тезгенен тарткаламасын, чаптар баш бирмәде. Әллә нишләде ул, әйтерсең лә, кыргый колан, туктаусыз пошкырына, ике ыргымның берсендә арт санын сикертеп куя, абынып-сөртенеп тә киткәли, кыланышын һич аңламассың.

Кыз мәтәлеп төшмәс өчен атының сыртына бөтен гәүдәсе белән беркеп, куллары белән тузгак ялына уралды.

Алаякны ике яшьлек тай чагында үзе сайлап алган иде. Ул вакытта ук пырдымсыз иде бу кырыкмыш. Актачыга шулай китереп типте ки, бер ай титаклап йөрде бичара. Дөресен генә әйткәндә, аңа әлеге тайның менә ярсу зәһәрлеге ошады да инде. Чөнки үзе дә шундый ук холыклы мыскалга сыймастай назлы вә иркә шәмсия зат ул.

Атасының уены-чыны белән: «Атларым-өйгәннәрем, кызыл бөрлегәннәрем, әнә, күр, карлыгачым, күпме елкының күзләре сиңа төбәлгән, бу имгәк алар янында чүп кенә, тотып алсыннар шуларның берсен», – дигән сүзләренә дә шундый ук кимәлдә җавап кайтарды:

– Бигайбә, атаем-бәк, кошта шоңкар, елкыда толпар асыл, – диде.

Чыннан да, асыл иде сайлаганы: ыспай гәүдәле, озын торыклы, киң күкрәкле. Ә матурлыгы – аякларында. Дөресрәге, бәкәлләрендә. Дүрт аягының да бәкәлләре сөттәй ак төстә иде. Шуңа күрә исемен дә Алаяк дип кушты.

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) – *прозаик; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; Ф.Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты. «Таш һәйкәл», «И кылган догам минем», «Дөя муены» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Әйе, йөгән кигезү, өйрәтү-буйсындыру өчен күп көч түгәргә туры килде. Тайның кыргый дала киңлекләреннән канына сеңгән хөрлеген, бәйсезлеген һич тә җуясы килмәде. Озак тартышты, авырлык белән генә ияләште. Аның урынына, хәзер артыннан чибәр кызларны күзләгәндәй мөкиббән булып карап калалар. Алтын бирмәс йөгерекнең йөгереге. Чабышканда, гәүдәсе су камышыдай сузылып, җиргә ятып бетә, гүя тау хуҗасы бөркет, оча гына...

– Алаяк, дим, Алаяк...

Кыз керфек очыннан гына җыен ягына күз төшереп алды. Карашы әүвәл рәшә ояларыдай тезелешкән тирмәләр арасыннан Силки мәликнең киез өен абайлап алды. Хәер, ул болай да маңгайга бәрелеп тора. Каз канатыдай ап-ак төстәге, күп кеше сыйдырышлы биниһая зур мәһабәт тирмә.

Силки мәлик шулай ел саен җәй уртасында Багы Ирәм гөлбакчасыдай ямьледән-ямьле Солчә елгасы үзәнендә меңләгән иләтен җыеп, бәйрәм үткәрә. Атна буена сузылган әлеге тамаша ат чабышы белән башланып китә.

Мәлик җайдакларны үзе сайлый, чабыш алдыннан очрашып, фатихасын бирә. Бәйгедә егетләр дә, кызлар да бер хокукта катнаша. Шулай да хаким кызларны якынрак күрә иде булса кирәк, әнә, иң беренче Бану каршысына килеп басты да:

– Хәрби һөнәргә һәвәслегең кемнән килә, бикәч? – дип сорады.

– Атаем Бәхтияр бәк кавеменнән, падишаһ.

– Рәхмәт, сөендердең, – диде Силки. – Бәхтияр ыруы – дәүләтебезнең терәге. Шәт, бүген үзең дә сынатмассың.

– Вәгъдә, падишаһ, беренчелек миндә булыр, – диде Бану үз сүзле иркә кызларга гына хас кыюлык вә тәвәккәллек белән. – Нәселебез – җиңүче нәсел!

Силки мәлик башын кыңгыр салып, бүселүле калын ирен очлары белән генә көлемсерәгән хәлдә:

– Ошатам синең кебек ярпачларны, – диде, – яшь чакта үзем дә кизәнгәч, сукмый калмый идем...

– Рәхмәт, пади...

– Кабаланма, әйткәнне тыңлап бетер, – дип бүлде кызны мәлик, – яманатка калганчы яман ярдан оч, дигән бабаларыбыз, чәчрәп чыгу әле ярый, яманатка кала күрмә...

Алаяк янә арт сынын сикертте, Бану мәтәлүдән ялга ябышып кына котылып калды. Ияр булса, бер хәл иде әле, коешканга булса да тотынып идең, ышанычлырак булыр иде. Бәйгенең шартына ияр керми шул, чабышкыларның барысы да бапсыз, дирбиясез, йөгән дә тезген генә.

– Алаяк, дим, Алаяк!

Ә Алаяк, гүя котырык җанвар, күзе-башы тонган, мыш-мыш килеп, гырылдый-гырылдый уйнаклап чабуын гына белә.

– Док-док, док-док...

Алда, әнә, текә яр пәйда булды. Бу фаҗига лабаса!

Бануның колак очында аермачык булып мәликнең кисәтү сүзләре яңгырады: яманатка калганчы ярдан оч...

Яманатка калды инде, анысы хак, кәпәрүле чын ярпач, хурлыгы ни тора: тик бу хурлык гомергә бәрабәрме соң?

– Уф-ф-ф...

Бану уеның очына чыгарга өлгермәде, йөзен икенче бер аргамакның кайнар тыны өттереп алды. Һәм шул ук мизгелдә аны ниндидер сихри дулкын көзге яфрактай очыртып кына үз куенына кертте.

Икенче мизгелдә исә Бану үзенең чит толпар өстендә икәнен төшенеп алды. Алай гынамы, ул бөтенләй чит-ят җайдак кулында иде. Бу, билгеле, аңа ошамады, тыпырчынмак итте, кая ул, әлеге көчле кул тарттырылган элмәктәй отыры кысылды гына.

– Җибәр, җибәр, диләр сиңа, – дип ысылдады кыз.

– Синең чабышкыңны аксыргак төнәтмәсе эчереп агулаганнар, – диде җайдак, элмәген тагын да кыса төшеп, – мин аны бәйгегә тезелеп басканда ук сизеп алган идем. Шуңа күрә артыңнан килдем.

– Кем син?

– Исемем Ярмәк, Бәләнҗәр ыруыннан, мөселман өммәтеннән, мәликнең угланы.

– Ә мин – нократ болгары, барсил кабиләсеннән, – диде Бану тынычлана төшеп, – ыру башыбыз мәшһүр барс-киеккә табынабыз.

– Беләм, – диде углан, – мәлик сезне бик ихтирам итә икән, беренче булып сиңа сүз кушты, барыбыз да көнләшеп тыңлап тордык.

– Мин менә хәзер барыгыз алдында да хурлыкка калдым инде, – диде Бану, – мәликнең күзенә күренергә оят.

Бераз тынып калдылар. Чөнки яннарыннан чабышкы атлары үтеп бара иде.

Йа Хода, манзара дисәң дә манзара! Алда да атлар төркеме, артта да, унда, сулда да... дәрья! Бер мизгелдә тояклар туфракка орынып ала, икенчесендә – өскә ыргыла.

– Дөп-дөп, дөп-дөп...

Дәррәү бер сулыш, дәррәү бер очыш.

Тояк тыпырдауларына җайдакларның түземсез аваз-ымлыклары килеп ялгана:

– Әлләллү-әлләллү...

– Һоппана-һоппана...

Ниһаять, өер артыннан купкан тузан болыты эченнән елмаюлы кояш нурларын сипте. Көн искиткеч матур иде. Күз күреме җитмәс Даланың яшел хәтфәгә төренгән ашлы вә саф-пакь чагы иде. Куе үлән арасыннан аллы-гөлле чәчәкләр дә борыннарын төрткән. Исләре аңкып тора.

Тау читендәге аксыл сыек томан үзенә бер самими аһәң белән әлеге матурлыкка үз бизәген өсти иде.

– Мин сине ошбу ояттан коткару юлын беләм, – дип, иң беренче Ярмәк телгә килде.

– Ничек?

Тик бу сорау җавапсыз калды, чөнки аларны бикәчнең яраннары куып җитте.

– Кәдбану солтания, синең чабышкылар сафында юклыгыңны белеп, Бәхтияр бәк бик борчылды, – диде өлкән яран. – Менә иярле аргамак, атлан, атаеңны тизрәк тынычландырыйк.

– Күреп торасыз, минем ышанычлы булышчым бар, ул ялгыз калдырмас, ә сез яр астыннан Алаякның гәүдәсен эзләп табып, җирләү чарасын күрегез, – дип, бикәч әмиренә боерыгын бирде.

– Җә, углан, тәкъдимең нинди иде? – диде Бану яраннары китеп, үз атын тезгенләгәч. – Тыңлыйм.

Ниһаять, егет белән кызга йөзгә-йөз карап сөйләшү мөмкинлеге туды.

Тууын-туды, тик егетнең теле генә әйләнми, уйлары эздән чыгып, бөтенләй катып калды.

Кыз да кызыксыну хисләре әсирлегендә иде.

Бану коеп куйган чын болгар чибәре икән: гөләндәм буй-сын, анар җимешенә охшаш аксыл йөз, алтынсу-саргылт төстәге калын чәч, ясмык уемлы озынча ияк, төз муен, очар кош канатларыдай як-якка чәчелгән кыйгач кашлар, үзләренә өндәп торучы ымсындыргыч кабарынкы иреннәр...

Бер бите айдай балкыган,
Бер бите көндәй салкыган,
Болгардаен балкыган,
Җофардаен аңкыган
Айтулы ару кыз икән.

Егетләр шулай инде алар, күңелләренә тиң килгән кызларны фәрештә канатларына утыртып, хур кызларны әйләндерәләр. Бануның килеш-килбәтеннән дә җитешсезлекләр табып була иде, әлбәттә. Кемгәдер, әйтик, җәенкерәк борыны ошамас иде, бәгъзеләр буе кыскарак, дияр иде... Ярмәкнең исә шушы бер күз сирпеп алуда күңеле утлы тойгы эченә кереп эреде.

Кыз да егетне сынаулы карашы аша үткәрде. Ул барча белекле угланнар кебек үк мул гәүдәле, эре сөякле, барча күзәнәкләренә кадәр көч-куәт тулышкан әзмәвердәй яугир иде. Тик аның игътибарын исә егет, беренче чиратта, үзгә төсе белән җәлеп итте.

Ярмәк кара тамырдан иде. Чәче кара, күзе кара, кашы кара, йөзе кара. Болгар илендә мондыйлар сирәк. Ә үзе, хакыйкатән, батыр яугир иде, күрәсең. Уң як битеннән буйдан-буйга яугирләр горурлыгы – кызгылт җөй сузылган.

– Бәләнҗәрләрнең барысы да шулай күмердән коелганмы? – дип көлемсерәде Бану. – Төсегезне саклыйсыз икән.

– Безнең кабиләбез ишле түгел, әмма тамырлы кабилә. Ата-бабаларыбыз заманында Хәзәр мәмләкәтендә гомер сөргән. Хәзер менә Болгарда. Кайда да кыйблабызга тугры калганбыз.

– Бабаларыгыз ни сәбәпле күченгән соң? – дип кызыксынды Бану. – Беләсем килә, сөйлә әле.

– Бик рәхәтләнеп, бикәч, – диде Ярмәк. – Үз тарихыбызны без яратабыз, хөрмәт итәбез.

735-736 елларда гарәп – хәзәр мөнәсәбәтләре кискенләшкәч, гарәпләрнең Мәрван исемле гаскәр башлыгы хәзәрләрнең башкаласы Бәләнҗәр – Варачанны басып ала. Бөтен Хәзәрияне, аның белән чиктәш яшәгән болгар кабиләләрен үзенә буйсындыра һәм бик күпләрне әсирлеккә ала. Калган кабиләләр качып котылып, куркынычсызрак урынга, Идел – Чулман елгалары кушылган төбәккә килеп урнаша.

Хикмәт шунда, Хәзәр каханы мөселман диненнән баш тарта. Билгеле, бу гарәпләрнең ачуын китерә. Византиягә шул гына кирәк тә. Бу ил бик

күптәннән хәзәрләрне христиан диненә тарту, үзенә кушу уе белән яна. Ләкин кахан һәм аның якыннары дәүләтнең бәйсезлеген саклау максатында башка дин эзлиләр. Ахырда яһүд диненә тукталалар. Ләкин, асылда, бу динне аксөяк хәзәрләр генә тоткан. Мәҗүсиләрдән кала төп халык, шул исәптән бәләнҗәрләр дә, мөселман булып калган. Шушы җәһәттән, берничә мәзәк-гыйбарә дә сакланып калган. Имештер, хәзәрләр җомгада – мәчеткә, шимбәдә – синагогка, якшәмбедә чиркәүгә йөриләр икән.

Бәләнҗәрләр Болгарда килмешәк түгел, кабилә Болгар дәүләтен төзүдә турыдан-туры катнаша. Иң мөһиме, иң авыр шартларда да мөселманлыктан ваз кичмиләр. Алай гынамы, Болгарда ислам динен тарату безнең тәҗрибәгә нигезләнә дә инде.

Ярмәк әңгәмәдәшенә кыскача шушы мәгълүматны җиткерде. Кыз аны дикъкать белән тыңлады һәм егеткә үзенең дә гыйлемлелеген белдерәсе итте, яттан гарәпле Габид әл-Бәхтәринең шигыреннән бер өзеген исенә төшерде.

– Сөбханалла, – дип, башын иде Ярмәк, – мөхтәрәм гыйлем иясе икәнсең.

– Инде тәкъдимеңне җиткер, углан!

Ярмәк әлегә көтеп-көтеп тә читкә тибелеп килгән кискен җөмләдән югалыбрак калды, аннан төтеннән куркып утка кергәндәй, үзенә бер илгәзәк үҗәтлек белән сүзләрен очырды:

– Бану солтания, мин Силки мәликтән сине сорарга фатиха бирүен үтенергә ният иттем, – диде, – бу сине хурлыктан йолып калачак.

Ул башын кырын салып, җавап көтте. Ничек кабул итүенә карамастан, эчендә җаны булган мәгъсүмәи сөмбелә зат, аның уенча, бу тәкъдимгә, ким дигәндә, мөнәсәбәтен белдерергә тиеш иде.

Күтәрелеп бакты, ә кызның исендә дә юк, куактан куакка кунып куанышучы саргылт түшле тиктормас сандугачларга мөкиббән булып, тик әсәрле халәткә талган.

– Углан, беләсеңме, сандугач нилектән сары? – дип сорады, ниһаять.

– Юк, белмим...

– Их, син, егет, колагыңа киртлә, гыйшкыннан саргайган ул, гыйшкыннан...

Бану бер ыргымда атына сикереп атланды да тезгенен бушатты. Ул инде бөтенләй башка кеше иде. Күзләре нәкъ орышка әзерләнүче яугирләрнекечә очкынланып яна, иреннәре кысылган, йөзе ашкынулы. Менә-менә кыныннан кылычын суырып алыр да яу эченә ыргылыр кебек. Элдертә генә. Ярмәк тә аңа иярде.

Бәйрәм мәйданына җитәрәк, Бану чаптарын тыймыйча гына башын борып:

– Углан, сүзеңдә тор! – дип чыркылдап көлде, – һе-һе-һе...

– Их, бикәч, мин дә хәзер саргайган сандугач инде, – дип пышылдады мәгъшук углан.

***

Быел бәйрәмнең ватылган чүлмәктәй бер чите китек булып, Силки мәликне борчуга төшерде. Ник дисәң, Суар әмире Вираг хаким бәйрәмгә үзе дә килмәде, даирәсен дә җибәрмәде.

Чүп өстенә чүмәлә: тамашаларның иң кызган өченче көнендә иравыл гаскәри башлык күңелсез хәбәр җиткерде:

– Мәлик, суарлылар болгар көтүлекләреннән бик күп мал-туарны куып алып киткәннәр, – диде.

– Сак башлыгы син түгелме соң, ни карадың? – дип, мәлик угланның изүеннән эләктереп алды. – Күземнән югал!

Хаким ничек кенә чыгырыннан чыгып тузынмасын, гаеп сакта түгел, гаеп вазгыятьтә иде. Мәмләкәт мәмләкәт булып туплансын өчен аңа керүче халыкларның бер сулышта яшәве шарт. Ул моны, әлбәттә, бик яхшы белә, әмма үз дигәненә ирешә алмый, таркаулык комачаулый, шуңа өзгәләнә. Хикмәт күрше мал-туарына кул сузуда гына булса икән? Юк шул, барымтага йөрү ул далада күптәннән килә торган гадәти йола, яшәү рәвеше. Болгарлар үзләре дә күршеләрен капшаудан тартынмыйлар. Барсиллар да, бәләнҗәрләр дә, искиләр дә – барысы да.

Югыйсә, сөйләшкән телләре бер, чыгышлары уртак – төркиләр – күбесенең килеш-килбәтләре дә бер-берсеннән әллә ни аерылмый: кызгылт ак йөзле, каты чәчле әкүл вә чибәр кешеләр. Гарәпләр аларны гомуми исем белән сәкалибә-әшкарлар дип саный. Чөнки ил исемен дә, дәүләт исемен дә, башкала исемен дә болгар сүзе белдерә.

Аз санлы бәләнҗәрләрдән аермалы буларак, ишле суарларның үзләрен өскә чыгарасы килә. Бу омтылыш һич тә нигезсез түгел. Ник дисәң, суар кайчандыр Кавказ, Кара диңгез киңлекләрендә дәүләт тоткан гаярь кавем. Ә дәүләти хәтер кан хәтере белән тәңгәл. Ул халык белән туа, халык белән бергә үлә.

*Тарихи белешмә:*

*Күренекле гарәп галиме һәм сәяхәтчесе Ибне әл-Әсир, мисал өчен, түбәндәгеләрне теркәп калдырган. Менә шуннан бер өзек:*

*«Аларның хаканнары бер гаиләдән генә була һәм гаилә эченнән чыкмый. Патшалыкка хуҗа булса да, исеменнән башка бернәрсәсе дә юк. Аннан түбән дәрәҗәдә бер зур хакимнәре бар, аны «мәлик» дип йөртәләр. Хакан янына шул мәлик һәм аннан башка олылардан берничә генә кеше керә ала. Аның алдына кергәч, туфракта ауныйлар – сәҗдә кылалар, аннан аяк өсте басып, хакан янына килергә һәм сүз әйтергә рөхсәт биргәнче көтеп торалар. Хакан үлгәч, аның кабере яныннан хайванга атланган килеш узмыйлар, җиргә төшеп, сәҗдә кылып, кабер күздән югалганчы җәяү китәләр.*

*Әгәр дә берәү үтерелергә хөкем ителсә, ул кеше өенә кайтып, үзен-үзе үтерә. Берәүне патша итеп куярга теләсәләр, сынар өчен, ул кешене тотып бугазыннан буалар. Үләр хәлгә җиткәч: «Дөньяда озак яшисең киләме?» – дип сорыйлар, ни кадәр әйтсә, шул кадәр яши, ә инде әйткән вакыт җиткәндә үлмәсә, халык аны үзе үтерә».*

Силки мәлик шау-гөр килеп бәйрәм үткәргән бер вакытта, Суар хөкемдары Вираг әмир иленең киләчәк язмышына кагылышлы мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган зур утырыш үткәрде.

Мондый очрашулар, гадәттә, мул табын, кәбаб, мәшһүр сөҗү-кәречмә эчемлеге, дум-думбак кагу, кубыз уйнату, субар җырлату кебек күңел ачулар

белән үрелеп бара иде. Даирә шуңа өмет итеп килгән иде дә булса кирәк, тәбәнәк тәгам өстәлләре күренмәгәч, чырайлары сытылды.

Арада иң тәвәккәлләрдән саналган Гыйрфан углан түзмәде, читләтебрәк булса да, ризасызлыгын белдерде.

– Ай-һай, җәнабе гали, буш корсакка ни-нәрсә майтарырбыз икән, ашы юкның, эш юк бит аның, – диде.

Вираг какча гәүдәсен гади парча гына түшәлгән тәхете эченә шудырды да, гадәтенчә, урта бармагын тырпайтты.

– Кайда аш, шунда яраш, – диде, – ә бүген без ярашырга, мактанырга түгел, муафыйк акыл илә киңәш-табыш итешергә җыелдык. Аннан бераз кашларын җыерып торгач өстәде: – Ашъяулык та җәелер, әмма дә ләкин иң әүвәл – гамәл!

– Бисмиллаһи, йә, Ходай, бәрәкәт бир!

Әмир даирәне янә җитди карашы аша үткәрде дә, нотыгын тезеп китте.

– Без хәзерендә Болгар дәүләте әләме күләгәсендә гомер кичерәбез, – диде урта бармагын кылыч рәвешендә селкеп. – Хак, дәгъвам юк, татулык бар, ә уртак куркыныч янаганда, барча кабиләләр җыелышып, бергәләп яу чабабыз. Тик, иманым камил, ахирәткә иңгән шанлы ата-бабаларыбыз безнең кемгәдер баш иеп, буйсынып көн күрүебездән риза-бәхил түгелдер, дип уйлыйм. Ә сез нинди фикердә?

Даирә дулкын өстендәге көймәдәй як-якка чайкалып, гөжләп алды.

Шушы шау-шулы җанлылык шаукымында алдагы рәттә утыручы кәтәнә буйлы юантык Мәгъфур бәк мичкәдәй тәгәрәп кенә уртага чыгып басты да:

– Суар – Раббеле кавем, ә болгар – мәҗүси, потка табына, – дип сөрән салды. – Без алардан өстен!

– Өстен, өстен! – дип күтәрелде даирә.

Бәк тагын да дәртләнебрәк китте, бер мәзәк тә сөйлисе итте:

– Күктән изге китап иңгәндә, мөселман беренчесен, иң хөрмәтлесен, славян икенчесен алган. Фин штырын чолгап, киндерәсен урап барып җиткәнче, аңа дигән китапны сыер ашап киткән...

Даирә галибәнә күтәренкелеккә туры килмәүче бу мәзәкне ошатмады, ярты юлда туктаттылар.

Фикер алышуны Гыйрфан углан башлангыч эзенә кертеп җибәрде.

– Кояш елының өч төрле хисабы бар, – диде белдекле кыяфәттә, – болгарлар «Фарсия хисабы»н, нәсаралар «Румия хисабы»н, без, һәммә мөселманнар белән бергә, «Хәмәл хисабы»н кулланабыз. Күрәсез, монда да суар кавеме аерылып тора.

– Афәрин!

– Хәзер тәкъдимнәрегезне тыңлыйм, – диде әмир. Йөзендә елмаю күренеп тора, даирәсеннән канәгать иде.

– Болгар мәмләкәтенең башкаласын Суар шәһәренә күчерергә кирәк, – дип кычкырды арадан берсе. – Безнең шәһәрне читтән килүче сәүдәгәрләр дә бик хуп күрә, алыш-биреш өчен уңайлы, диләр.

– Ага Базар да Суар юлында, – дип җөпләде аны икенчесе.

– Суарга күчерсәң дә, ул шул ук Болгар дәүләтенең башкаласы булып кала бит инде, безгә моннан ни файда? – дип, Гыйрфан углан тәкъдимгә шик белдерде. – Бу мәсьәләне ярым-йорты гына хәл итү, минемчә.

– Дөрес, – дип күтәреп алды аны әмир, – без мөстәкыйль Суар мәмләкәтен булдырырга тиешбез. Ул дәүләт чынлыкта бар. Мин мөстәкыйльлегебезне игълан итәргә, чит мәмләкәтләр белән илчелек элемтәләре урнаштырырга, аларның яңа дәүләтне рәсми рәвештә тануларына ирешергә вакыт җитте, дип саныйм.

– Болгарлар белән ничек аерылышабыз соң? – диде бер сәүдәгәр борчулы халәттә, – сез ничек, шәхсән мин үзем кан коюны күз алдына да китерә алмыйм. Бер казанда гомер сөр дә орышка чык, имеш...

Бермәлгә тынып калдылар. Тирмәгә аермачык булып пырдымсыз яшь айгыр кешнәгән тавыш үтеп керде. Аңа буылып-буылып өргән чәрелдек эт авазы кушылды. Даирә арасында да арткы рәттән кемнеңдер гырылдаганы ишетелеп китте.

Сәүдәгәр шик-шөбһәле икеләнүләре белән төзәлеп өлгермәгән ярага тоз сипкән иде.

Хак, суарларның бер казанда гомер сөргән болгар дуслары белән орыш мәйданында очрашасы килми, әлбәттә.

Күзләр әмиргә төбәлгән. Соңгы сүз аныкы. Ә ул даирәне тынычландырырга кирәклеген бик тиз аңлап алды һәм:

– Кайсы ыру үчле, канны шул кояр, – диде. – Безнең болгарларга карата бер үчебез дә юк.

***

Суарда Силки мәликнең шымчылары бар иде, билгеле. Атна-ун көннән аңа андагы хәлләр турында тулы мәгълүматны китереп тә җиткерделәр.

– Гаскәр кузгату турында сүз булдымы? – дип белеште мәлик. – Якын арада алардан нинди этлек көтәргә була?

Шымчы бүләк көтә иде, шуңа күрә авызын ачарга ашыкмады, баскан урынында таптанып кына куйды. Мәлик аны аңлады, янында әмер көтеп тораташтай каткан йомышчы угланга ым какты. Тегесе йөгереп кенә шымчыга авызлыклы йөгән китереп тоттырды.

– Аты тышауда, алып китәрсең, – диде.

Шымчының теле ачылды.

– Әлегә бу, мәлик, боламык болгату гына, шау-шу гына, – диде, – әмир бернинди тәгаен гамәл турында сүз алып бармады, ара-тирә шулай яраннарын йокыдан уяткалап, кыздырып алгалый бит инде ул. Шулай да...

– Нәрсә, шулай да, ачыграк сөйлә, – диде мәлик, – җә, көттермә!

– Даирәне таркату мәнфәгатьләрендә яшерен эш алып барулары бик тә ихтимал...

– Ягъни...

– Ягъни, даирәндәге дәрәҗәле суарлар аша. Мисал өчен, Ярмәк углан. Анасының суар ыруыннан икәнен үзең дә беләсең. Атасы – бәләнҗәр токымыннан... Көнче кавем...

– Ярмәк углан – минем иң ышанычлы яугирем.

– Әйттем исә кайттым, бу фәкать фараз гына...

– Тузга язмаган ярым-йорты фаразларың белән башымны әйләндермә, бар, вазифаңда бул, – дип, мәлик шымчыга арты белән борылды. Йомышчы углан аны җилтерәтеп, тышка чыгарып җибәрде.

Кешене чыгырыннан чыгару өчен кайчак бер сүз җитә. Бу нәкъ шул очрак иде. Шымчының фаразы да мәликнең күңеленә корт булып төште. Кымыз китертте, ул да тынычландырмады. Табын кордырды – ризыгы үтмәде. Ахыры тәрәзә янына килеп басты.

Урамда көн бозылырга тора икән. Җил чыккан, агач-куакларны, күк очында оешкан болытларны җепкә элгән кердәй чайкалдырыпмы-чайкалдыра. Ул арада мескен бүрек кадәрле генә бер болыт йомарламы кинәт кенә ыжгырып алга чыкты да кояшны каплап та куйды, дөнья күзсез калды.

Күр, кояш булып кояшны каплау өчен бәләкәй генә бер болыт кисәге дә җитә бит, дип уйлап куйды мәлик, мәмләкәт белән дә шундый ук хәл ләбаса! Вакытында чарасын күрмәсәң, тәхетсез калуыңны көт тә тор. Моның мисаллары бихисап. Бу инде икеләнү-микеләнү генә түгел.

Күп тә үтми, яшен чатнады, күк дөбердәде, коеп, яңгыр ява башлады.

Силки мәлик ни-нәрсә эшләргә кирәклеген белә иде инде.

– Дөрмән бәкне чакырырга куш, – диде ул йомышчы угланга. – Хәзер үк!

– Яңгыр коя анда...

– Тоз түгел, эремәсләр...

Дөрмән бәк – Силкинең кардәше. Бик өлгер һәм булдыклы углан.

Озак көттермәде, төштән соң килеп тә житте.

– Беләм, мине көтелмәгән ашыгыч чакларда гына чакырасың, – диде. – Ни-нәрсә китереп кысты, баш өсте, әзермен.

Гадәттәгечә ул хәрби киемнән иде. Башында көмеш өслеккә асылташлар беркетелгән затлы шишәк, бил каешында хәнҗәр-кылычтан кала, кистән белән чакма тимеренә кадәр тагылган. Тот та яу чабарга җибәр.

– Ерак сәфәр көтә сине, – диде мәлик. – Бик четерекле вә яшерен бирем.

– Кая барырга? – дип, агасына төбәлде Дөрмән.

– Балтыйк диңгезе буена, Вису кабиләләренә, берочтан ясак-сәүдә эшләрен рәткә салырга кирәк.

*Тарихи белешмә: Идел Болгарстаны – Төньяк-Көнчыгыш Ауропаның тәүге феодаль дәүләте. Ул үзенең икътисади-сәяси үсеше ягыннан борынгы ыруглык җәмгыяте дәрәҗәсендә яшәүче күрше кабиләләрдән күпкә өстен булган. Фин телләре төркеменә керүче эргәдәш мажар, ар, чирмеш, буртаслардан кала, болгар җиреннән бер айдан артык юл ераклыгында көн күрүче әлеге Вису кабиләләре дә аңа бәйлелектә булган, ясак түләп торганнар.*

– Бу соң гап-гади бирем ләбаса, моның нинди четереклеге дә, нинди яшеренлеге, – дип, җилкәләрен сикертеп куйды бәк.

– Тишек колак, мин сиңа «бер очтан» дидем.

– Ә-ә, аңладым, ясак-сәүдә сылтау гына, күз буяу...

Мәлик кымыз касәсенә ирennәрен тигезеп куйды да тәрәзә аша урам якка күз төшерде. Анда көн ачылып килә иде инде. Яңгыр туктаган, бүлгәләнгән болытлар арасыннан кояш та күз кыскалап алгалый.

– Сиңа сак вазифасында Ярмәк угланны билгелим, – диде мәлик.

– Башка угланнар да бетмәгән, – дип, йөзен җыерды Дөрмән. – Нигәдер күңелем ятмый шул мокытка.

Таждар янә касәгә үрелмәк иткән иде дә кире уйлады, ахрысы, читкәрәк этеп куйды. Шуннан соң:

– Миңа хәвефле хәбәр ирештерделәр, – диде. – Син мокыт дип атаган Ярмәк угланның Болгарда Суар шымчысы булуы турында фараз бар. Бурычың – шуны ачыклау.

Дөрмән голт-голт итеп, кымызын эчеп куйды да әйтте:

– Моны Висуга бармыйча да ачыклап була, – диде. – Бу – бер, икенчедән, бер карлыгач яз ясамый, diләр.

***

Кәрван шактый ишле иде. Йөргән аякка җим иярә, ди. Күбесе – сәүдәгәр, ниятләре файда итү, кесә калынайту, әлбәттә. Ясакчылар ат менгән, ә болар арбада. Ашап-эчеп, кәеф-сафа корудан да тартынмыйлар.

Дөрмән бәк тә сәфәр чыгуга хәнҗәр-кылычларын салып ташлады, җарияләре белән мәшгуль, аларның күңелен күрә: чырык та чырык.

– Әйдә, минем чатырга, кәнизәкләрнең иң чибәрен алып чыктым, үземә дә, сиңа да җитәрлек, – дип, Ярмәкне дә үз арбасына утыртмак иткән иде дә, углан кырт өзде.

– Бурыч багындыра, ди, бәк, мәликкә биргән антым да гомер бәрабәре...

– Ант, ант, үзең өчен дә яшәргә кирәк, углан, гомер шуның өчен бирелә, – диде Дөрмән.

– Мин башкача булдыра алмыйм, бәк, – диде Ярмәк, – бигайбә.

Ярмәкнең күзе дүрт, тирә-якны карашы белән айкап бара. Ник дисәң, мондый озын койрыклы кәрван үшән була. Юлбасарларга әзер табыш.

Юлның яртысы хәвеф-хәтәрсез генә үтте. Чөнки бу ара тоташ даладан гыйбарәт. Монда җил әвәрәләр тәгәрәтеп уйный. Ерактан ук кемнең кем икәнен абайлап аласың. Шуңа күрә бүре мисаллы залим адәмнәр әлеге ачык җирне хуп күрмиләр, аулак урын сайлыйлар.

Ярмәк – угланның биле юан бишле аргамагы Аҗаган төркемнең алдыннан атлый. Бу андый-мондый көтелмәгән хәл килеп чыга-нитә калса, һөҗүмгә күчү өчен уңай. Кылыч-калкан – билдә, ук-җәяләр – садакта, сөңге-чукмар – кулда.

Төньяк сакалибә җирләрендәге беренче тукталыш урынын шактый озак эзләделәр. Ниндидер юеш, шул ук вакытта сусыз төбәк иде бу. Ә атларга, мал-туарга, кешеләрнең үзләренә, беренче чиратта, су кирәк.

Ниһаять, маңлайбаш яугир уңай хәбәр белән кайтты.

– Бер бик матур түгәрәк күлгә тап булдык, – диде, – тик уңайсызрак җирдә, чытырманлык эчендә.

– Сайланырга чамабыз юк, – диде Ярмәк, – алып барыгыз.

Күккә ашкан алтынсу кәүсәле төз чыршылар кочагында хәтфәдәй яшел алан. Монда ачулы котып җилләре дә, өттергеч зәһәрле салкыннар да үтеп кермәле түгел.

Шулай да, аланның күз явын алырдай матурлыгы – зөбәрҗәт кашлы мөстәна тирән күл иде. Суы көмештәй саф, иртәнге чыктай чиста, төбендәге вак ташларына кадәр энҗе бөртекләредәй җем-җем күренеп тора. Ә тәме, хәтта ару-талуларга да шифа.

– Бу күл, Аллаһының рәхмәте белән, мөгаен, Мәккә шәһәрендәге изге

Зәмзәм коесы белән тоташкандыр, – диде мөселман яугире Әхмәт, – эчеп туеп булмый, үзе ару, үзе дару, әһле кәүсәр.

Кулдашы дустының сүзләрен үз ягына борып җибәрде:

Авызы зәмзәм, ирене кәүсәр, теле гәүһәр
Безгә язган ярларның.

Бу тезем Ярмәкнең дә ләззәтле хатирәләрен яңартып җибәрде. Ә хатирәләр иясе – гүзәлләрдән-гүзәл Бану солтания. Ул аның күңеленнән чыгып тормый, сүнүсез-сүрелүсез янган йөрәге берөзлексез шушы хөсне җәмал бикәч исеме белән тибә.

Бу күрекле алан барысын да әсир итте. Аның матурлыгы белән хозурланып, кояш урман аръягына төшеп, күз бәйләнгәч кенә йокыга талдылар.

– Тыныч, аулак урын, сак куюның хаҗәте юк, яугирләреңә ял бир, – диде Дөрмән бәк Ярмәккә, – үзеңә дә бер иркенләп ял итәргә ярыйдыр.

Бу киңәш кенә иде. Чөнки гаскәри сак белән идарә итү вазифасын мәлик тулысынча Ярмәк угланга йөкләде. Алай да, адәмнең көне адәмнән бит ул, төркем башлыгының бу киңәше аңа да йогынты ясамый калмады.

Чатырына кереп, көбәсен салып ташлады да ятагына ауды. Ә күңеле барыбер урынында түгел иде, эче поша, йөрәге тынычсызлана. Алай да, ята торгач, керфекләре сөрелеп китте үзе, йокымсырап та киткән иде инде.

Тик нindидер яшерен тылсым иясе угланның күзләре йомылуын теләми иде булса кирәк. Һәм ул тылсым иясе аны әйләнеп ятарга мәҗбүр итте. Шунда аркасына ниндидер очлы нәмәрсә килеп кадалмасынмы.

Йокыдан айнуга шул җитте. Сикереп торды да җилкәсенә күлмәген генә элеп, тышка чыкты.

Тышта җәннәт тынычлыгы иде. Тып-тын. Яфрак селкетерлек тә җил исми. Ара-тирә тышаулы атларның гына тонык пошкыру авазлары ишетелеп киткәли.

Җиһанга күк хуҗа. Күккә йолдызлар хуҗа. Күр, әнә, ничек җем-җем җемелдәшәләр. Шунда ук артларыннан якты эз калдыра-калдыра, бер-берсен куышып шаярышалар. Күк аркасы Тимерказык кына уенга бирелми, нурын урынын үзгәртмичә генә сибә. Айга карап адашсаң, атыңны Тимерказыкка бәйлә дип, юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең.

Ярмәк Җидегән йолдызлыгын карашыннан кичерде дә күңеленнән генә җидегә кадәр санады.

Җидегән йолдыз җиде имеш,
Җиде санасаң, савап имеш.

Ул, әлбәттә, төркемне бөтенләй саксыз калдырмаган иде. Күз-колак булырга дип, ике-өч яугирне алмашка куйды. Алар да үз урынында иде.

Юкка гасабиланганмын, шөкер, барысы да тәртиптә дип, җиңел сулап куйды. Хәзер менә ял итеп алу зыян итмәс.

Йоклап китәргә генә өлгермәде, куера гына барган бер мизгелдә аргамагының кешнәвен ишетеп, аягүрә торып басты. Аҗаган тиктомалдан

бимазалана торган ат түгел, кеше акылы анда, чит кешене якын китерми, нидер борчый аны.

Тышта әүвәлге тынлык иде, йолдызлар да баягыча атылып-атылып шаярышалар...

– Ио-һо-һо!

Ярмәк шул якка ыргылды. Ул элек аркаларына хәнҗәр кадалып, кан эчендә җан биреп азапланган өч яугиренә тап булды. Атлар тирәсендә, арбалар янында тавышсыз-тынсыз гына ниндидер ят адәмнәр мәш килә иде. Юк, мәш килмиләр, атларның тышауларын кискәләп, йөгән кигезәләр, арбалардан сәүдә малын капчыкларына тутыралар...

Ярмәк баш бирмичә тыпырчынган толпарын йөгәнләргә маташкан адәмнең гәүдәсен кылычы белән буйдан-буйга ярып төшерде, атына очып кунды.

– Әл-ләл-лү! Әл-ләл-лү!

Йокылы-уяулы яугирләр килә-килешкә кылыч-хәнҗәрләрен кынынарыннан алып, ярдәмгә ашыктылар. Араларында Дөрмән бәк тә бар иде. Күлмәкчән генә, ә кылычын ут уйната.

– Афәрин, бәк! – дип хуплады аны Ярмәк.

Болар мал юлбасарлары иде. Орыш аларның ниятенә керми. Әле дә ничек мыштым гына ябырылган булсалар, шулай ук үлән астыннан шуышкан еланнар кебек мыштым гына юкка да чыктылар.

Төркем, шәһидләрен җир куенына иңдерү белән, иртән иртүк юлга кузгалды. Юлбасарларның мәетләрен җанварларга калдырдылар.

Тагын бер атнадан алар Вису кабиләсе башлыгы Лукомор биләмәсендә иде инде.

Висулылар аксыл чырайлы, кылган чәчле, эре сөякле, баһадир гәүдәле, көчле куллы кешеләр икән. Киң күңеллеләр, көненә ничә тапкыр очрашсаң да, сүзсез генә кочакларын җәеп, исәнләшеп узалар. Кулларында әйбер булса, аны читкә куеп торалар. Бу дустанә мөнәсәбәтнең шарты икән.

– Безнең үз телебездә «алдашу», «урлашу» дигән сүзләр юк, – диде ырубаш, – һәр гамәлебез – күңелебез халәте.

– Мин болай ук өздереп әйтмәс идем, – диде Дөрмән бәк, – безгә юлбасарлар һөҗүм итте, берничә яугиребезне югалттык.

Лукомор зур агач касәсендәге сөҗү хәмерен төбенә кадәр эчеп куйды да авызындагы барча тешләрен күрсәтеп елмайган хәлдә табындагыларны күз уңыннан үткәрде.

– Силки мәликнең бу утлы суы безгә бик ошый, күңелләрне күтәреп җибәрә, – диде, – үзенә дә бик затлы кеш тиреләре әзерләп куйдым. – Аннан Дөрмән бәккә карап әйтте:

– Ул юлбасарлар славян ыруыннан, – диде, – качып-посып, кәрваннарны талыйлар. Аларны күреп тә булмый, ай күрә, кояш ала.

Вису илендә сәүдә алыш-бирешкә корылган, акча әле әйләнешкә кермәгән. Сатулашу да юк.

Алыш-биреш өчен махсус урын билгеләнгән. Үзләре бу урынны Бушлык дип йөртә. Чыннан да, бүрәнәләр өеп ясалган озын, ныклы өстәлләрдән тыш, анда башка бер корылма да юк. Алучы-сатучыларны да күрермен, димә. Базар кешеләре чиратлашып, аерым-аерым билгеле бер вакытта гына булып китәләр икән.

Болгар сәүдәгәрләре таң белән торып басканнар иде инде. Хуҗалар исә кояш төз һәм биек агачларының очына кадәр күтәрелгәч кенә эшмәшәкатьләренә тотындылар.

Бераздан Лукоморның шакмак йөзле, алыптай олуг гәүдәле йомышчысы, кунаклар янына килеп, гадәттәгечә, сүзсез генә колачын җәеп сәлам бирде дә ым какты. Әлеге ым башлагыз, дигән мәгънәгә ия иде. Сәүдәгәрләр алып килгән әйберләрен тезеп чыктылар. Бихисап әйбер: балык тоту өчен гарпуннар дисеңме, уклар, бүрек, көбә дисеңме, хуҗалык кирәк-яраклары, дисеңме, бубеннарга кадәр бар иде.

Эшләрен төгәлләгәч, болгарлар өер-өер бер читкә барып бастылар.

Чират висулыларга җитте. Озак сайланмадылар, бар нәрсәне тын гына кырып-себереп, капчыкларына тутырдылар да китеп тә бардылар. Өстәлдә затлы кеш тиреләре, каклаган балыклар һәм төрледән-төрле диңгез байлыклары гына өем-өем өелеп калды.

Әйе, Вису иле яшәешендә Табигать-ана кануннары хөкем итә, монда барысы да дөньяны бар иткән Бөек Көч тәгаенләгәнчә тормышка ашырыла. Алдашу, урлашу кебек тәрәккыять «казанышлары» әлегә бу җәмгыятькә үтеп кермәгән. Күп җирләрдә бәхәс, хәтта җинаятьчел кимәлдә оештырылучы шау-шулы сәүдә гамәлләре дә тавыш-тынсыз гына башкарыла.

Ярмәк углан моны үзенчә «мыштым базар» дип атады.

– Бу алдым-бирдем базары кагыйдәләрен бозучылар, мөгаен, бардыр, аларга нинди чаралар күрәсез, – дип тә белеште.

– Безнең базарда йөзгә-йөз очрашу юк, шулай булгач, кагыйдәне бозучылар да юк, – дип җавап бирде ырубашның йомышчысы, – үзебез оялмыйча бирәбез дә, оялмыйча алабыз да.

***

Иртәгә юлга кузгаласы кичне Вису ырубаш белән рәсми сөйләшүләр тәмамлангач, Дөрмән бәк Ярмәкне чакыртып алды. Гадәттәгечә, үзенә чак итеп тегелгән кыйммәтле вә ыспай киемнән, башында иң затлы мехлар, асылташлар белән бизәлгән шишәк, ялык-йолык килеп тора. Иңенә кылычын аскан, билендә – хәнҗәр. Әйтерсең лә, яу чабарга әзерләнгән.

Дөресе дә шулай. Мәликнең бирем-әмерен җиренә җиткереп башкарып чыгу яуга бәрабәр ул. Менә хәзер фетнәче үзе дә сизмәстән Дөрмән корган тозакка килеп эләгәчәк.

– Һоп!

Табын мул, чатагында чымыр-чымыр сөҗү чымырдый. Ике генә касә.

Ярмәк як-ягына каранып алды. Чыннан да, алар икәү генә. Кушчыйомышчылар да күренми.

Дөрмән кәефле иде, угланны дустанә кыяфәттә аягүрә каршы алды.

– Әйдә, уз, сәфәребез уңышлы төгәлләнде, инде бераз чишелеп алсак та, урынлы булыр, – дип җайлап-майлап кына, бүрәнә ярыгындагы чөйне какшатырга тотынды.

– Игътибарыгыз өчен рәхмәт, бәк...

– Мин сине бик ошаттым, – дип дәвам итте Дөрмән, – булдыклы, ышанычлы яугир икәнсең, сер дә сыйдырасың булыр, киләчәктә дә аралашып яшәргә язсын.

Шау-шулы күңел ачуларга маһир һиммәтле бәкнең бу ике кешелек касәсе Ярмәктә гаҗәпләнү белән бергә ниндидер аңлаешсыз вә хәвефле уйлар да уятты. Ни өчен әле бу югары даирә түрәсе аны дус итмәкче, серләр бүлешмәкче?

Менә Дөрмән касәсен кулына алды. Ярмәк мәҗлесләрне күп күрми, хәмерле эчемлекләр белән дә дуслыгы чамалы. Шулай да, бу юлы хуҗага иярергә хәл кылды. Хәмер телләрне йозактан ычкындыра бит ул. Ә аның бәк ишарә иткән серне бик тә беләсе килә иде. Дөрмән гыйшык-мыйшык кешесе, сере дә кыз-катыннарга кагылышлы булса кирәк. Бану турында да сүз әйтмәсме? Өстәвенә, юлбасарлар мәрәкәсе вакытындагы кыюлыгын да ошаткан иде.

Дөрмәнгә хәмер килешә икән, төс керде, бит очлары алсуланды, кыяфәте тагын да күркәмләнеп китте. Әйтерең бармы, егет солтаны, юкка гына аны чибәркәйләр үз итми инде. Гәп корырга да ясап куйган кебек, теленә шайтан төкергән.

Ярмәк үзе дәшмеш әле булса шундый җиңел холыклы, аралашучан кешеләрдән көнләшеп яши.

Дөрмән табынга күз салып алды да:

– Бервакыт Мәндине, менә синең кебек, кунакка чакырганнар, – дип сөйләп китте, – китергән ашы күренмәсә дә, хуҗа кунагын:

– Аша, аша, – дип үтереп кыстый икән.

Мәнди моны тыңлап торган-торган да әйткән:

– Ашау синең эшең түгел, минем эш, син алга китереп куюыңны бел, әлегә мин ашар ризык күрмим, – дигән. Шөкер, безнең ризыклар алда, җитеш, кыенсынып утырма.

Башларын артка чөя-чөя көлешеп алдылар.

Дөрмән инде шигъри теземгә күчте.

Алыш булсаң, Ак – Күбәк – ай!
Этеңне бир миңа, алыш – ай!
Этем яхшы, Маңгышым – ай!
Белеквар урманга чипканда
Утыз биш төлке каптырган – ай!
Белеквар ясагын таптырган – ай!

– Мәрхәбә, бәк, – диде Ярмәк, – субра җырлаучыларың бер якта торсын.

Дөрмән каш астыннан гына кунагына күз төшереп алды. Тегесенең авызы ерык, күренеп тора, күңеле чишелгән угланның. Бу – сынау ташларын чәчәргә вакыт дигән сүз иде. Һәм ул тәүге ташын очырды.

– Углан, сине Суар әмирлегең Болгардан аерылып чыгу, мөстәкыйль дәүләт кору хәлләреннән хәбәрдәр дип беләм, – диде җыбыткы бер ваемсызлык белән генә, – нилектән Вираг хаким тәртәгә тибәргә уйлады икән, сәбәбе нидә?

Ярмәкнең шик-шөбһәләре беткән иде инде, җилкәләрен генә сикертеп куйды да:

– Мин яугир, бәк, вазифам сугыш-орыш, калганы мине кызыксындырмый.

– Ә мин беләм, – диде Дөрмән. – Безнең хакимебез Силки мәлик, дөресен әйткәндә, ил белән идарә итә белми, аны тәхеттән куарга вакыт, югыйсә мәмләкәтсез калуыбызны көт тә тор.

Ярмәк ялгышмыйммы, дөрес ишетәмме, дигәндәй, бәккә күтәрелеп карады. Ә Дөрмән һөҗүмен тагын да куерта төште.

– Мин, шәхсән, тәхеткә утырырга риза, бу кануни омтылышымны яугирләр дә яклар дип ышанам. Ә үзеңне сәргаскәр дәрәҗәсенә күтәрермен...

Ярмәк сискәнеп китте, бу соң хыянәт ләбаса, түнтәреш!

Икенче мизгелдә ул аягында иде инде, бер ыргымда бәкне бәреп тә екты.

– Әлләл-лү!

Шундук чатырга яугирләр басып керде.

– Бәкнең аяк-кулларын богауларга! – дип, әмер бирде Ярмәк.

– Углан мине кулга алырга синең хокукың юк, нәсли дәрәҗәң түбән, – дип тибенде бәк.

– Беләм, – диде Ярмәк. – Әгәр бу хыянәтчел коткыны башка кешедән ишеткән булсам, кылычым белән урталай гына ярган булыр идем. Ә сине, алып кайтып, Силки мәлик кулына тапшырам, калганын ул үзе хәл итәр.

Дөрмән хак дөреслекне ачарга уйлаган иде дә, бу уеннан кире кайтты, чөнки шалкан баш яугир аны барыбер аңламаячак.

***

Силки мәлик төн уртасында өнендә уена да кереп карамаган әллә нинди гайре могайяр төш күрүдән уянып китте. Имеш, күз күреме җитмәс дала уртасында басып тора. Җир-су коргаксыган, кар суыннан ары бу җиргә бер тамчы яңгыр төшмәгәнгә охшый. Күрәсең, зәхмәтле урын. Тизрәк таю ягын карарга кирәк.

Мәлик тезгенен бушатты, тик Тарлан Бүз аны тыңламады, гомер булмаганны, нәрсәдәндер өркеп, читкә ыргылды.

Караса, тузан болыты кубарып, янына сыер көтүе якынлаша икән. Пош-пош, борыннары гөбе авызыдай киерелгән. Симезләр, муеннарына муенчак кигезермен, димә.

Ул да булмады, җир куышыннан гына калкып чыккандай, юлларын чем кара төстәге мүкләк сыер төркеме бүлде. Болары санаулы – җиде сыер. Арыктан-арыклар, эчләре эчкә береккән.

Ач хайван ачучан була, ди, болар көтмәгәндә, гүя арыслан-киек, симез сыерларга ташланып, ә дигәнче ботарлап ашап та бетерделәр...

Мәлик, барча мәҗүсиләр кебек үк төшкә ышана иде. Торуга төш юраучыны чакыртып, хәлне сөйләп бирде.

Төш юраучы, күсә сакал-мыеклы, кыссаң суы чыкмастай коры сөяк – ябык кеше, йодрыгы белән шәрә маңгаен ышкый-ышкый уйланып торды да әйтте:

– Падишаһ, Күкләр шуны кисәтә, син якын арада нindидер көтелмәгән хәл-вакыйгага дучар булачаксың, – диде. – Алдан чарасын күреп куярга киңәш итәр идем.

– Юравың рас килерме соң?

– Рас килүе-килмәве, падишаһ, үзең беләсең, Күкләрдән тора, кайвакыт алар андый хәбәрләрне уяулыкны арттыру өчен генә дә җибәргәлиләр.

Төш юраучының, якын арада диюе, якын дәкыйка арасында булып

чыкты. Ул китеп, эзе суынып та өлгермәде, Ярмәк углан авызы томаланган, кул-аяклары богауланган Дөрмән бәкне аның алдына китереп салды.

– Падишаһым-солтаным, менә бу адәм актыгы фетнә оештырып, синең тәхетеңне яулап алмакчы. Ул мине шушы җинаятьчел гамәлендә катнашырга, яугирләрем белән сине кулга алырга өндәде...

Силки таудай юан итчән гәүдәсен бер омтылуда урыныннан очырды да бәбәкләрен уйнатып, әле угланга, әле бәккә текәлеп карап торды. Шулай булмыйча, хәбәре нинди бит, теләсә-нинди хаким өчен хәтта хаклыкка туры килмәгән очракта да, иң үтергеч хәбәр.

– Мин, әгәр ыру-чыгышыма тәңгәл булган булса, урынында ук башын чабып өзә идем, – дип дәвамлады Ярмәк. – Өстәвенә, бәк синең токымнан, язмышын үзең хәл ит. Мин сиңа антлы, ул антыма гомерем буе тугрылыклы калачакмын!

Дөрмәннең күзләре мәликтә, ә мәлик әле һаман яман хәбәр тәэсиреннән арына алмый. Ул хәтта бу мәрәкәне үзе оештырганын да хәтереннән чыгарган иде булса кирәк.

– Китәргә рөхсәт ит, – дип бүлде аның уйларын Ярмәк. – Мин вазифамны үтәдем.

Мәлик кулын гына селтәде.

Ул чыгып киткәннән соң вакыйга нindиерәк юнәлеш алгандыр, монысы караңгы, ә кичке якта мәлик аны үзе янына чакыртып алды. Бәкнең яман нияте буенча өстәмә мәгълүмат кирәктер инде, мөгаен, бирер, ник бирмәсен, барысын да ачыктан-ачык сөйләр. Яугирләрнең иң сөймәгәне – хыянәт. Ә бу хыянәт тә, җинаять тә – баш бәрабәре.

Ярмәк ишекне ачты да баскан килеш мәрткә китте.

– Ләхәүлә...

Силки мәлик белән Дөрмән бәк икәүдән-икәү генә кәеф-сафа корып утыралар иде.

– Әйдә, углан, уз, табынга рәхим ит, – дип, кул изәде мәлик.

Ә Ярмәкнең аңы табынында, күзе күрә, ә башы, гүя буш мичкә, корышып каткан. Шулай булмыйча, падишаһ белән фетнәче дустанә кимәлдә табын корып утырсыннар әле. Бу соң гайре җаиз хәл ләбаса!

Дөрмән бәк аны җитәкләп диярлек үз янындагы урындыкка утыртты да, бер касә сәҗү эчерде. Аннан соң Суар әмирлегендәге хәлләр, мәликнең махсус биреме турында тәфсилләп сөйләп бирде.

Ярмәкнең аңы кайтты, тик ләм-мим сүз әйтмичә утыруында булды.

– Син мине накахка күпме газапларга дучар иттең, – дип көлемсерәде Дөрмән. – Ай буе богауда тоттың, юньле-башлы ашатмадың-эчермәдең, авырлыгын үзем генә беләм...

Ярмәк урыныннан шуып төшеп, мәлик алдына килеп тезләнде дә нindидер ят ялварулы тавыш белән тезеп китте:

– Падишаһым-солтаным, ошбу гамәлең белән мине вәгъдәсезгә чыгардың, – диде, – киләчәктә дә сөткә канымны тамызып эчкән антыма тугры калачакмын, әмма вазифамнан бушат, мин ялганны, ышанычсызлыкны күтәрә алмыйм.

Силки урынына бәк җавап бирде.

– Падишаһ бервакытта да ялгышмый, димәк, шулай кирәк булган, –

диде үзенә бер катгыйлык белән. – Һәм падишаһның гамәле дә, әмерләре дә шәрехләнми, фәкать үтәлә генә. Хәзер үк падишаһтан кичерүен үтен.

– Падишаһым-солтаным...

Ярмәк, бәкнең киңәшенә колак салып, гафу үтенү өчен авызын ачкан идеме, бәлки, үз үтенеч-тәкъдимен куәтләргә теләве булгандыр, моның инде хәзер бер әһәмияте дә калмады, чөнки Силки мәлик сүз арасына кереп, акыллы хакимнәргә генә хас зирәклек белән вазгыятьне тамырдан үзгәртте дә куйды.

– Тышта, әнә, кылычын сөйрәп, кыш бабай килә, һәрвакыттагыча быел да беренче кар төшү хөрмәтенә «Төлке – купшы койрык» тамаша-ау бәйрәмен үткәрәчәкбез, – диде кулына касәсен алып. – Оештыручылар итеп, сезнең икегезне билгелим. Кичекмәстән эшкә тотыныгыз!

***

Мәхәббәт – өермә ул, гарасат. Ә өермә-гарасат эчендә ни булмас? Бану сылуның да көймәсе, һич көтмәгәндә, шушы пырдымсыз зилзилә дөньясына кереп адашты. Моңарчы ул үз-үзенә хуҗа хөр шәхес, ирек иясе яугирә иде. Әле ат менеп чабышка китә, әле кылыч болгау, сөңге тоту, мәргәнлек осталыкларын камилләштерү максатында бәйге-күнегүләрдә катнаша, әле тугрыга кундырып, кош чөя, шоңкарын ау серләренә өйрәтә. Көне шатлыкта-куанычта, яраткан шөгыльләре кочагында үтә иде.

Ә хәзер – гап-гади бер тәнәкә. Күңелен Ярмәк углан биләп алды, һич ычкындырырга теләми. Хәер, аның үзенең дә ычкынасы килми. Чөнки бу татлы да, ләззәтле дә илаһи мәхәббәт тойгысын ул тәүге тапкыр кичерә иде.

Ал төс – җүләр төс. Мәхәббәт тә ал төстә.

Әлеге халәт җилекләренә май тулышкан һәр таифәи туташны сагалап тора һәм бер мизгелдә кочагына тартып кертә дә ут эченә сала.

Бануыбыз да шул халисана халәттә иде. Шөгыльләре дә үзгәрде. Кылыч-калканнарын чөйгә элеп, көбә-шишәкләрен салып ташлады да чин тегүчеләрен чакыртты. Хәзерендә көннәре шулар янында үтә.

Бүген исә алар теккән күлмәкләрне, башка кием-салымны карап, үзенең бәясен бирәчәк.

Әүвәлендә ул якын дусларын да чакырырга, аларның да фикерләрен ишетергә уйлаган иде, тик бу уеннан кире кайтты. Ник дисәң, кайбер таныш-белешләре аша төртмә сүзләр җиткерергә өлгергәннәр иде инде. Имеш, Бану чүпрәк-чапракны яугир мәнфәгатьләреннән өстен күрә икән, шул матур күлмәкләре белән угланнарның башын әйләндермәкче икән...

Бану бу сүзләргә бик гарьләнде, әлбәттә, рәхмәт анасы, Хәдичә бикә тынычландырды. Килешкәне килендә, кызым, көнченең йөрәген ят бәхете яндыра, ди, исең китмәсен, синеке янмый, аларныкы яна, диде.

Чин ир-егетләре бик инсафлы, уңган-булган кешеләр икән, ачык күңеллеләр, бил бөгеп кенә исәнләшәләр, сез дип мөрәҗәгать итәләр. Таң белән эшкә тотыналар, кояш баегач кына энә-җепләрен мендәрчекләренә кадап куялар. Аш-суны да үзләре әзерли, барысына да житешәләр.

Әле дә баш тегүче Чан-шу Бануны идәнгә кадәр иелеп каршы алды.

– Рәхим итегез, туташым-тәнәкә, без күптән әзер, – диде авызындагы

барча тешләрен күрсәтүле елмаюы аша, – шулай да, бер четерекле һөнәри вазифабызны гына хәл итәсе калды...

– Бик рәхәтләнеп, – дип елмайды кыз да үз чиратында, – тыңлыйм.

– Без киемнәрне үзебез тегәбез, үзебез киендерәбез, – диде Чан-шу. – Сез моңа ничек карыйсыз?

– Мин риза, – диде кыз, – тегегез, киендерегез!

Тегүчеләр җиңел сулап, үзләре белән алып йөртә торган биниһая зур җиз көзгеләрен махсус урындыкка урнаштырдылар да Бануны дүрт яктан да ябулы пәрдә эченә алып керделәр. Тотындылар киендерергә, кулларына күз иярми, үз шөгыльләрен ипләп-җайлап, тәнгә кагылмыйча гына, оялтмыйча, кыенсыну тудырмыйча гына башкаралар.

– Туташым-тәнәкә, әйдәгез, үз сурәтегезгә күз салыгыз, – дип, Чан-шу кызны көзге каршына китереп бастырды.

Бану үзен танымады. Көзгедән аңа ниндидер күл камышыдай төз буй-сынлы, озынчарак аксыл йөзле, гүзәлдән-гүзәл әүсафе җәмиләи шаһинә карап тора иде.

Кашларына карасам,
Каләмнән пәйда булгандай,
Күзләренә карасам,
Күгеннән пәйда булгандай,
Буйларына карасам,
Нурдан пәйда булгандай.

Киң итәгенә ике рәт итеп, асыл тасма тотылган ак ефәк күлмәге аякларындагы читек-башмакларын каплап, идәнгә кадәр төшеп тора. Җиңнәре дә озын вә киң. Култык астына тегелгән зәңгәрсу төстәге кештәге дә күлмәгенә үзенә бер купшылык өсти иде.

Ә яка? Тоташ укадан гыйбарәт бу якадан күзне дә алып булмый. Көмештән беркетелгән биш буйлы челтәре, асыл ташлары җем-җем килеп балкый.

Колакларында көмеш алка, беләкләрендә беләзек, бармакларында йөзек, чәчләрендә толым буенча алтын-көмеш тәңкәләр тезелеп төшкән...

– Туташым-тәнәкә, кыз кеше мыскалга салынмаган ак ефәк ул, аның киштәсендә шуңа тиң күлмәк тә булырга тиеш. Әйтик, ошбу күлмәк, – диде Чан-шу балдай татлы елмаю аша. – Рәхим итегез.

Аны элеккечә үк зур саклык белән киендерделәр дә көзге тамашасына куйдылар.

Илаһи кадыйр! Бусысы үзенә бер кабатланмас әһле һөнәри нәфисә. Күккә талпынган аккош канатларыдай купшы, таң җиленнән дә җиңелрәк өрфә күлмәк. Очып кына йөрерлек. Башына уралган өрпәге белән күкрәкчәсе бүтән төстәге чыт-ситсыдан булса да, шундый ук каз мамыгы шикелле үлчәмсез-күләмсез иде.

– Туташым-тәнәкә ошбу зиннәтле күлмәкләрне безнең чин мәмләкәтендә император кәләшләре генә тектерә ала, сез, ничек, ризамы, эшебезгә нинди бәя бирәсез? – дип, Чан-шу аңа текәлеп бакты. – Ошамаган урыннары булса, әйтегез, төзәтергә дә әзербез.

– Мин, мөхтәрәм теүче, мәшһүр тел осталары сурәтләгән көнче җефетләр хәл-халәтендә, – диде Бану, – менә шуларның берсе, тыңлагыз.

Ул хатыннар көрсиләргә утырдылар,
Берәр пычак һәм әфлисун тоттырдылар:
«Әфлисунны турагыз!» – дип боердылар, –
Нәкъ шул вакыт егет-кемсә килеп керде имди.
Кемсә таба борылып бер карадылар,
Гүзәллеген күреп таң калдылар,
Һәммәсе дә күз алалмый карап аңар,
Әфлисун дип бармакларын кисәр имде.

Чан-шу әлеге шигъри тезмәне чынга алды, күрәсең, әйтте:

– Берүк, туташым-тәнәкә бармакларыгызга җәрәхәт ясый күрмәгез, – диде, – андый корбанның хаҗәте чыга-нитә калса, менә, минем кулымны чабып өзәргә әмер бирегез.

– Сезгә кул миңа караганда да кирәгрәк, – дип көлемсерәде Бану, – аңа тисәң, каһәре төшәр.

Асыл затларның ир-егеттә үзен эзәрлекләү теләге уятуы фарыз, дигән бер аксакал. Зәвык белән киенү үзенә бер муаффәкыяти урын били, дип тә шәрехләгән аксакал. Яугирә Бану да, әнә, гыйшкына бәрабәр кием-салым юнәтү белән мәшгуль ләбаса. Сөйгәне бер дә исеннән чыгып тормый: әле хыялында кочагына керә, әле күз суын түгә, әле үпкәли, онытырга ниятли. Янә кайтып төшә, берсеннән-берсе татлы сөю сүзләре пышылдый...

Алар бәйгедәге тәүге очрашудан соң фәкать бер-ике тапкыр гына күрештеләр. Анысы да кеше арасында, әлегә кадәр һич тә икәүдән-икәү генә калып аңлашырга, хисләрен уртаклашырга җай чыкканы юк.

Ярмәк шактый озак вакыт сәфәрдә югалып торды. Кайтканнар икән инде. Тик нигәдер күренми. Күз өстендә кара каш булып буй җиткергән иркә вә нәзберек туташны барыннан да элек егетнең шушы битарафлыгы әрнетә, шуңа күңеле үрсәләнә иде. Нишләмәк кирәк, сөю үзе бер сагышлы авыр чир шул ул.

Булачак булмый калмас, ди. Алар очраштылар. Монысы да көтмәгәндә һәм ат-толпарга мөнәсәбәтле иде.

Бану кешелеккә дигән йөгерек-чабышкыларны үзе сайлый. Аңа Алаяк ише башбирмәс дуамалраклары ошый. Өйрәтүе, кулга ияләштерүе шактый тирләтә-тирләтүен, шулай да, кыю вә тәвәккәл, бернинди киртәләр алдында да югалып калмас куркусыз аргамаклар нәкъ шундыйлар арасыннан табыла.

Бусында ул әйбәт нәселдән тимгел чуар елгырны сайлады.

– Тибенергә бик маһир, сак бул, – дип кисәтте актачы. Аннан, бу ат булганчы, үзен эт булырсың, исәр, дип мыгырданып куйды.

– Бүген-иртәгә муенына арканлы элмәк кигезеп, ике-өч кабат күбеккә батырып арытыгыз да кешәнгә куегыз, нукта кигезегез, – диде Бану. – Берсекөнгә үзем килеп, сыртына утырырмын.

– Безнең үзебезнең арада да бик оста өйрәтүчеләр бар, бәлки, өйрәтүне берәрсенә йөкләргәдер, – дип, бикәчкә карап бакты актачы. – Нигә юкка бимазаланырга?

– Мин үз эшемне үзем башкарырга күнеккән, – диде Бану. – Әйткәнне үтәгез!

– Әйттем исә кайттым, Бану солтания, борчылма, барысын да син әйткәнчә эшләрбез.

Һәм шулай эшләделәр дә. Бикәч тә әйткән көнендә килде. Тимгел чуар

кешәктә иде. Уртлап-уртлап ала да чабып китмәк итә. Әйтерсең лә, җәннәти пырак, үзенә бер күркәм рәвешкә керә. Озынчарак җыйнак гәүдәсе туптай йомарлана, ыспайдан-ыспай туры аяклары сикерергә әзерләнгән арыслан аяклары сыман аз гына бөгелә төшә, муены юлпычка тартым көчле күкрәге өстенә авыша һәм...

Тик кешән нык шул, аны алай гына өзеп булмый. Шуңа йөрәге ярсый.

Бануны да ул каен яфрагына охшаш зур күзләренең агын чыгарып каршы алды. Шулай булмыйча, шушы мәрхәмәтсез кыланчык кыз кисәге аны хөр тормышыннан мәхрүм итәргә җыена лабаса!

Елгыр ачуына чыдаша алмыйча пошкырып җибәрде.

– Кирәкле ат көтүдә, сөекле ат кешәндә, – диде Бану, – тегенең йөзен җиң очы белән корыта-корыта. – Шушы булдымы рәхмәтең?

– Иярлибезме? – дип сорады актачы тирлек җәймәсен кулына алып, – кайберәүләр эчәрге киезе генә сала...

– Берсе дә кирәкми, алар комачаулый гына, үзегез дә миңа иярмәгез, өйрәтүчеләрне җаным сөйми.

– Атаең Бәхтияр бәк рөхсәт итми шул...

– Һәрберегезгә берәр көмеш динар...

– Шушы урыннан күзәтсәк кенә инде, – дип, рәвешен китереп кенә баш түбәсен кашып алды. – Теге... ни... бит...

– Килештек! – дип бәхәскә нокта куйды Бану, – аран авызыгыз төенле, аңладыгызмы?

– Авызда сумала, кәдбану солтания.

Тимгел чуар, барча тайлар кебек үк, урыныннан яшен тизлеге белән кузгалды. Шул рәвешчә җайдакны сыртыннан эшереп төшерергә ниятләде, күрәсең. Ләкин җайдак гүя берекккән, кая ул мәтәлү, һәр хәрәкәтен ул аны гамәлгә ашырганчы ук сиземләп ала да, гәүдәсен шул җайга авыштыра. Тезгенне дә үзе теләгән якка тарттырмак итә.

Бормый гына тор әле, бикәчкәй. Һөнәрләрем бихисап. Менә болай да маташтыра беләм мин, бигайбә.

Тимгел чуар туктаусыз арт сынын сикертергә тотынды.

Бану сөйләнә-сөйләнә, чытырмандай атның муенына беректе.

– Тузынма, бәгырь, барыбер буйсындырам мин сине, буйсындырам булгач буйсындырам...

Тимгел чуар ыжгырып чапкан җиреннән кинәт кенә тукталды да арт аякларына басып, бер мизгелгә тораташ булып катты. Җайдак моны көткән иде, ахрысы, гәүдәсе үзеннән-үзе артка шуышты...

Шулвакыт кемдер пырдымсызга камчысын чирттерде. Ат дүрт аякларына басты, җайдак та урынында калды.

– Әй, актачы, әйттем бит, миңа иярмә дидем, – дип, ачу белән кычкырды җайдак кыз. – Динардан коры каласың болай булгач...

Камчы иясе аның ачулы сүзләренә игътибар итмәде.

– Тезгенеңне бушат, атка чабарга ирек бир, тоткарлама, – диде. – Арыгач, үзе туктый ул.

Дөрестән дә, тезгенен бушаткач, Тимгел чуар үз иркенә чыгып, җилләнә-җилләнә алга ыргылды. Артын да сикертми, җайдакның барын да оныткан, ахры, оча гына.

Шулай шактый ара мыш-мыш килеп барды да, тиргә батып, йөрешен акрынайтты.

– Инде тезгенеңне кыскарт, хәл алсын, – диде камчы иясе, – ул синеке хәзер.

Бану, ниһаять, тавыш ягына башын борды. Ә анда көлеп-елмаеп, аңа Ярмәк углан карап тора иде.

– Котлыйм, – диде, – даланың күрке булырдай бик күркәм толпар, сөлек тә сөлек, ул да сөлек, күр, ничек сузылган.

– Качып-посып артымнан сагалап йөрүчеләрне җенем сөйми, – диде Бану, кашларын җыерып, – бик күрексез гадәт...

Ә үзенең эче-тышы нур белән тулышты.

– Атыма исем табарга булышканың өчен генә гафу итәм. Сөлек – матур исем.

Егет кызның үртәшүен чынга алмады булса кирәк.

– Әйдә, Кыз күле янында туктальп алыйк, атлар да хәл алыр, – диде.

Бану сүзсез генә угланга иярде.

Табигатьнең киләчәк салкыннарны алдан ук өнәмичә, соңгы яфракларына кадәр тартышып өзгәләнергә әзер чагы. Көз әле үтмәгән, кыш җитмәгән. Әмма бу юеш һәм чытык араның үзенә бер матурлыкка ия көннәре дә булгалый. Нindидер кодрәт белән ул вакытта кояш нурга, ай моңга, йолдызлар уйга байый төшә. Җир-ана Күктән ни яуса да, рәхмәтле булып кабул итә.

Бүген дә табигать фасылының гадәттән тыш шундый үзгә бер көне иде. Ул ике яшь җани мәгъшук затны да үз канатының җылысына кертте. Аларның күңеле су төбеннән ялтырап күренеп торган көмеш тәңкәдәй саф вә пакь иде.

Кыз күле – яшьләрнең очрашу-кавышу урыны, исеме риваятьтә мәңгеләштерелгән изге урын ул. Аңа мал-туар да борын тыкмый, урап узалар.

Ә риваять бик тә мәгънәле, бик тә гыйбрәтле.

Борын-борын заманда Кәзкәй бабасы мирас итеп калдырган төшемле иргәсендә байлыкта һәм муллыкта Айтулы исемле яшь кыз көн күрә. Аксакалның оныкчасы да үзе кебек баш июне белмәүче горур вә тәвәккәл, гаярь йөрәкле гали зат булган. Аннан көнләшкәннәр, буйсындырырга, мал-мөлкәтен тартып алырга теләп, сугыш-орыш белән килгәннәр. Аеруча кызгылт көрән чәчле бакырбашлар тынгы бирмәгән.

Сөн елгасы буендагы соңгы яу бигрәк тә фаҗигале тәмамлана. Чибәркәйне бер төркем иярченнәре белән әсир итәләр.

Чирү башы бу курку белмәс болгарларның барысының да башларын кисәргә әмер бирә. Иң соңыннан Айтулы иргәбашны китереп, башыннан яулыгын салдырып алалар...

Һәм чирү башы кызның сылулыгыннан үз башын югалтып, эче-бавыры белән гашыйк була.

– Матур кыз, сине үтертмәем, сине ярлыкаем, минем хатыным бул, – дип, алдына килеп тезләнә.

Ике кашының карасы,
Бармак басым арасы.

Айтулыга тиң булырмы,
Йирдә адәм баласы?

Айтулы уйларга бер тәүлек вакыт сорый.

Чирү башы түзмәгән, төн караңгысы белән чибәркәйнең чатырына кергән.

Хөррә пәрвәр зат халкына, иркенә хыянәт итә ди, көт. Сиздерми генә моның хәнҗәрен суырып алып, күкрәгенә кадый да качып китә.

Тик, ни кызганыч, елга буендагы комда эзе кала. Шул эздән аны куа чыгалар. Айтулы Сөнгә ташлана. Ерак китә алмый, бер-бер артлы ук яудыралар.

Әһле каһарман бикәч суга батып, күздән югала. Ак башлы ярсу дулкыннар гына яулыгын яр читенә кагып чыгара. Кызыл канга буялган бу ак яулыкның бер читендә «Айтулы Кәзкәй онықчасы» дип язылган була.

Сөйгән егете Исәт углан бик кайгыра, канлы яулык белән күз яшен сөртеп, Сөнгә мөрәҗәгать итә:

Ач кочагым, елгам, ярымны күрсәт,
Ак ай бите сулганын күрәем.
Уймак авызын үбеп Айтулымның
Кара чәчен битемә сөртәем.

Углан сөйгәненең үчен кайтарырга ант итеп, кичегеп килүенә бик уфтанып, дошман өстенә ташлана. Ләкин аны да шул ук язмыш көтеп торган икән. Сөн, угланны кочагына алмаска теләгәндәй, гәүдәсен бер батырып, бер калкытып йөртә-йөртә дә бик еракка агызып алып китә.

Тәңре ошбу гаделсезлекне кичерәме соң?

Тиздән елганың чишмәсе корый. Кешеләргә сабак өченгә җиһангир бикәч баткан урында фәкать Үле Сөн генә сакланып кала. Халык аны Кыз күле дип йөртә башлый.

Айтулы барыбер үзен онытырмый, вакыт-вакыт кызыл канга манчылган ярсу дулкыннар әле дә аны яд итә, сагышлана, имеш.

– Ни өчен эзләр мәңгелеккә уелып калмый икән? – диде Бану. – Айтулы кардәшбикәм баскан эзләрен җиргә ятып үбәр идем.

– Эзе калмаса да, җире калган бит, – дип, Ярмәк учына туфрак алды да әүвәл Бануга үптерде, аннан үзе үпте.

– Рәхмәт, – диде Бану, – бөтен үпкәләремне оныттырдың.

Кояш кабарынкы каурый болытларны алсу төскә манып, төнге бишегенә төшеп бара иде инде. Эңгер-меңгер белән бергә җилбикәнең дә җилфердәп аласы килде, күрәсең, әүвәл күл өстенә шадра җыерчыклар сипте, аннан сылукайның йөзенә салкынча тынын өрде.

Кыз калтыранып куйды. Егет сүзсез генә аны кочагына кертте. Ике йөрәк бер сулышта тибә башлады.

Бану күккә, йолдызларга караган кебек, башын чөя төшеп, Ярмәккә текәлгән, ә үзе көзге яфрак кебек дерелдәде. Егет тә өермәдәй хисләрен тыяр хәлдә түгел. Менә ул, өнемме бу, төшемме, дигәндәй сак кына сөйгәненең битен кайнар учларына кертте...

Иреннәр иреннәргә тоташты...

– Син мине яратасың, әйеме? – дип пышылдады Бану. – Назларың шундый ягымлы...

– Кыз күленә шуның өчен алып килдем инде, мин синсез яши алмыйм...

Кызның куллары сөйгәненең изүен ачты...

– Ә кайчан яучы җибәрәсең?

– Мәлик кышкы ау тантанасын оештыруны Дөрмән бәк белән икебезгә тапшырды. Иң әүвәл Силки мәликтән хәер-фатиха аласы бит әле, аннан соң гына атаең Бәхтияр бәк катына барасы. Икесен бергә туры китерсәң, тагын да әйбәтрәк анысы. Һәрхәлдә, тырышырмын.

– Тырыш, җанашыңны саргайтма.

Алар Кыз күленнән бер атка атланып кайттылар.

***

Көз, чыннан да, соңгы яфрагына кадәр көрәште, капкасын җан-фәрман белән йозакта тотарга тырышты. Ләкин табигатьнең үз кануннары, вакыт барыбер үзенекен ала. Хәзер, әнә, бер карыйсың, яңгыр болыты белән генә төшә, җир боламыкка әверелә, икенче карыйсың, җилбикә күкне чистарта, салкын агасына юл ача. Кешеләр ялыктыргыч пычрак көзнең үтүенә сөенешеп, туннарына төренә.

Их, теләк белән чынбарлык гелән тәңгәл килеп торса икән? Юк шул, туннарны салдырып, дөньяны тагын юеш һәм калтыранулы томан биләп ала. Ә бүген халык ниндидер эчке күтәренкелек белән уянып китте.

Таң атып, яңа көн туып килә иде. Җиһан күз явын алырдай якты. Тау-калкулыклар, түбәләренә ап-ак кар бөркәнеп, җем-җем балкыйлар. Күз күреме җиткән төшләрдән аксыл-зәңгәрсу чиксезлек башланып китә, беленер-беленмәс кенә булып ерак галәм шәйләнә.

Шундый килешә икән ак кар дөньяга!

Ярмәк углан куанычыннан яшь кар өстендә ауный-ауный ошбу матур көн белән шатлыгын бүлеште.

– Әл-ләллү! Һәй-һәй-һәй!

Өйлә җиткәнче үк Дөрмән бәк белән икесен Силки мәлик чакыртып алды. Ул инде җәйләүдән кайткан иде. Тәүге кар аның да күңеленә хуш килгән иде, әлбәттә. Йөзе көмеш акчадай балкый, иреннәре елмаюлы.

– Менә, угланнар, сагынып көткән кышкы ау бәйрәме дә килеп җитте, – диде, – вазифагызга керешегез.

– Без, һәрвакыттагыча, эшебезне падишаһ чатырын корудан башлау мәслихәт булыр, дип уйлаштык, – диде Дөрмән бәк, – кунаклар үз чатырларын үзләре корыр, безгә аларның санын да белү кирәк.

– Анысын әле тәгаенләп бетерәсе бар, егерме чатырдан да арттырмабыз, югыйсә, болгавыр була.

– Сак, ашау-эчү, күңел ачу хикмәтләре дә бар бит әле, – дип, сүзгә Ярмәк тә кушылды.

– Ул эшләрнең үз осталары бар, сезнең вазифа турыдан-туры ау оештыру, сез шуңа җаваплы, – дип, мәлик әңгәмәгә нокта куйды.

Ау – падишаһларның буыннан-буынга килә торган күпкешелек күрекле йоласы. Гадәттә ул елга ике мәртәбә үткәрелә: җәй башында – кош авы,

кыш башында – киек-җанвар авы. Билгеле, ау ел дәвамында да дәвам итә. Алары инде рәсми булмаган гадәти аулар.

Ау – беренче чиратта, үзеңнең кем икәнлегеңне башкаларга күрсәтү урыны, олуг күргәзмә.

Силки мәлик ау өчен махсус өйрәтелгән тустыган күзле, чонтык койрыклы мәһабәт акбүз аргамагын иярләгән иде.

Дүртлесендә өйрәткән,
Ефәк нукта сөйрәткән,
Бишлесендә биш бичгә җибәргән,
Алтысында ат иткән.

Аты да үзе кебек эре сөякле, бер-берсенә ярашып, бөтен кырны тутырып торалар. Аннан азга калыбрак даирә тезелешкән. Һәрберсенең янында тазы бурзайларын җитәкләгән аякчылар таптана.

Ау коткысы кергән бурзайларның түземлеге тәмам төкәнгән, муенсаларын өзәрдәй булып өзгәләнәләр, чыелдашалар. Ауның төп хуҗалары нәкъ менә шушы озын торык йөгерекләр. Ау алды ачлыгыннан соң бүген алар да сыйланачак.

– Барысы да әзер, сезнең әмерне көтәбез, – диде Дөрмән бәк, мәликнең сораулы карашына ым кагып, – әле генә Ярмәк углан чабышкысы хәбәр китерде.

Ярмәк атна буе төлке куучылар янында куна-төнә ятты. Ишле вә шөһрәтле ошбу аучылар өчен төлке кирәк, күп кирәк. Ә аларны әрәмәлекләрдән, таш-тау ышыкларыннан, үзәнлекләрдән ике-өч көн буе өннәреннән кубарып, алдан сайланган ачык һәм уңайлы мәйданга куып китерделәр. Хәзерендә, булдыра алганча, читкә качырмыйча камап алдылар. Ә ул мәхлукларның бик буйсынасылары килми, елан урынына шуыша-шуыша шылу ягын карыйлар. Арада бит әле куяннар да бар. Бер-берсеннән өрекмичә-курыкмыйча чабышалар, әйтерсең лә, ахирәти дуслар. Аларны исә кычкыра-бакыра, думбаклар кага-кага һаман куркытып торалар.

– Һайт-һайт!

– Гүл-гүл-гүл!

Силки мәлик, менә күрегез падишаһыгызны, дигәндәй, башын өскә чөебрәк саргылт күн белән тышланган затлы ияренә эленгән укалы канҗагасын, уклар тулы садагын, асылташлар җемелдәгән кынасын, шундый ук сары төстәге йомшак кәҗүл бишбармагы белән җиңел генә сыпыргалап алганнан соң, өзәңгеләренә басып, тирә-якны күзәтеп торды.

Тәүге кар кочагындагы җир әле ныклап катырга өлгермәгән. Тирән чокырлар эченнән, камышлы ергамаклар арасыннан, мул үләнле үзәннәр йоткылыкларыннан чыккан таныш җир исе җәйне искә төшереп, борынны кытыклый. Тау сыртларында, калкулык битләрендә урыны-урыны белән көлсу-күк утраулыклар йөз чөергән.

Офык буйлап сыек тонык томан җәелеп килә. Тагын да арттарак карасу болытлар шәйләнә. Кояш та сүнгән учакка охшабрак тора иде.

Көн бозылу галәмәте, дип уйлап куйды мәлик, башларга кирәк. Ул алты батман чукмарын кулына алды. Шуннан соң ук күз күреме ераклыгындагы Бөркет тавы өстендә учак кабынды.

Дөрмән бәк мәликнең әмерен җиткерде.

– Тезгеннәрне – кулга!

Җәйләүгә язгы ташуны хәтерләткән гөрелте аваз салды. Тора-бара әлеге гөрелте җанвар-киек куучыларның һау-һаулары, думбак дөбертеләре, ярсулы таза этләрнең чинаулары белән кушылып, җир тетрәү рәвешенә охшап калды.

Әнә, беренче купшы койрыклар да күренде. Төлкене койрыгы саклый, дигәннәре хак булса кирәк, күр, ничек боргалыйлар, хәйлә коруларыдыр, мөгаен.

Силки мәлик гәүдәсен турайта төште. Аның бу халәте акбүз атына да күчте. Чонтык койрыгын тырпайтып, тараулы ялларын җилфердәтеп, алга ыргылды. Аның артыннан башкалар. Бурзайлар да урыннарыннан купты.

Чың-чың өзәңгеләр чыңлый, авызлыклар вә түшлекләрдәге көмеш тәңкәләр чылтырый, гөп-гөп тояк тавышлары яңгырый...

Мәлик күз кырые белән генә бер ыргымдарак элдертүче Суар әмире Вираг хакимне шәйләп алды. Аның ауда катнашуына ул бик хәерхаһ иде. Акылына килгән, ахры, дип уйлап алды. Шулай булмыйча, әнә, Исегел әмирдән, Барсил әмирдән үрнәк алырга кирәк, мөгез чыгармый ипләп кенә яшәп яталар бит. Тәртәгә тибеп кенә әллә ни майтарып булмый ул. Ошыймы-ошамыймы, күңеленә ятамы-ятмыймы – дәүләт иләт, мәнфәгатьләре барысыннан да, хәтта дуслыктан да өстен.

Вираг көрән туры атта иде. Сайлый белгән, күр, ничек элдертә, койрыгы дүрт чалуга җитәдер.

Төстән качкан төлке кызыл күренер, ди. Алда шундый шома йонлы, пумала койрыклы мәһабәт кызгылт төлке пәйда булды. Койрыгына ут капкандай ыргылыпмы-ыргыла. Ыргылмыйча теге, бурзайлардан котылу, ай-һай, җиңелләрдән түгел. Кызылкайны да берьюлы ике тазы күреп алды. Шундук ян-ягына да төштеләр, юлын бүлмәк булып, узып китәргә чамалыйлар, күрәсең.

Озын койрыкның хәле мөшкелләнгәннән-мөшкелләнә генә. Нишләмәк кирәк, ау ау инде, кемдер тота, кемдер тотыла. Ләкин төлкенең хәйләкәр дигән даны бар бит әле.

Бәлкем... һәм шулай килеп чыкты да. Төлке атылып чапкан җиреннән кинәт кенә шар кебек тәгәрәп китмәсенме?

Этләр аңа тимичә узып киттеләр. Алар шулай өйрәтелгән, корбанына теш тигезмиләр, тиресен бозмыйлар. Егылган икән, димәк, эләккән. Чөнки бурычлары киек-җанварны мәтәлдерү, калганы – ау-кушчы вазифасы. Тоталар да, аякларын бәйләп, сугымчыларга озаталар.

Ул арада ат тояклары араларыннан арт аякларын сикертә-сикертә, бер куян да килеп чыкты. Хәйләкәр елкылдыкка янә җай килмәсенме, тиз генә сикереп торды да куян күләгәсенә ятты, бергәләп элдерттеләр. Куркыныч янаганда дошманлык та чигенә шул. Ни кызганыч, язмышлары барыбер хәл ителгән иде инде. Бу ишле ау этләренең берсеннән арынсаң, икенчесенә эләгәсең, аннан да ычкынсаң – өченчесенә.

Вираг әмирнең күз алдында әлеге ике бурзай тагын бер төлкегә ябырылдылар. Тик уртак мал мал түгел инде ул – бүлешә алмыйча ырылдаша-ырылдаша талашып ук китте болар.

Әлеге ыспай бурзайларның сөттәй агы Силки мәликнеке, чем карасы әмирнең үзенеке иде.

Вираг, бәладән башаяк, дигәндәй, какча гәүдәсен бер ыргымда ияреннән җиргә очырды да булышчылары башкарырга тиешле гамәлгә үзе кереште, бурзайлар арасына барып кереп, типкәли-типкәли, икесен ике якка аерды.

Моны күрүче, абайлаучы да булмады. Чөнки бу ау үзәнлегенә төлкеләрнең иң күпләп тулган вакыты иде.

Мәйдан каракучкыллы чиллә болытларыннан ишелгән давыллы боз яңгырыдай гөжли башлады. Ат тояклары ташкыны астында җир, думбак каккан кебек, дөбер-дөбер тупырдый, юка кар астыннан балчык кантарлары оча. Җайдакларның һай-һайлавына, акыру-кычкыруларына дәртләнеп, атлар җан-фәрманга сөлектәй сузылып чаба, чаж-чож камчылар сызгыра, тазы этләре чиный...

Кушчыларның борылыр чамасы да юк, төлке арты төлке ава, барысына да кул да җитми, ушлыраклары, әнә, боҗраны кисеп, качарга ук тотындылар. Хәер, бу хәлгә борчылучы да юк, бу әле атналык ауның тәүге көне генә.

Чиллә болытының давылы озакка бармый, шаулап-җилләнеп ала да тынып кала. Төлке авы да шулай. Куып китергән өер узып китүгә, ул да төгәлләнә. Алар менә мин, тотыгыз, дип, күзгә кереп тормый, чабулары чабу. Шул арада эләктереп калырга кирәк. Монысы инде осталыкка, барыннан да бигрәк бурзайларга бәйле.

Кышның сапламы кыска. Кояш инде карлы тауларга бер чите белән генә карап, баеп бара, җиргә салкынча зәңгәр кич томаны җәелеп килә. Даланың акрынлап, үз халәтенә кайтышы. Ара-тирә әле тынычланып җитмәгән толпарларның пошкырулары, ач ау этләренең лык-лык сөяк кимергән ләззәтле чинаулары гына ишетелеп куйгалый.

Дөрмән бәк мәликнең боеруы белән кулындагы ак яулыкны ялт итеп селтәп алды. Шул ук мизгелдә мәйдан думбак авазы белән тулды.

– Дөп-дөп, дөп-дөп...

Ау тәмам. Алда – мәҗлес.

Падишаһ чатырының җиһазлары да затлы иде. Нәфис әрмән паласлары белән уралган тәхет балкый. Һәрвакыттагыча ян-якларында кыска аяклы кече өстәлләр урнаштырылган. Һәр кунакның үз өстәле. Шунда тезләнешәләр.

Өстәлләргә инде ризык-нигъмәтләр куелган. Көйчеләр салмак кына кыл думра чиертә, дәф шөлдериләре шылтырый, субра ераучылары тавышларын көйләү белән мәшгуль...

Һәммәсе әзер. Менә калын гәүдәсен яшьләрчә төзгә катырып, чатырга якын даирәсе белән Силки мәлик килеп керде. Чатыр уптым-илаһи аягүрә басты, бүрекләр очты, башлар иелде. Аннан соң озак кына этенә-төртенә, урыннарын эзләп мазаландылар.

Дөрмән бәк янә ак яулыгын селтәп, һаваны җилләтте.

– Болгар дәүләтенең бөек вә данлы хакиме Силки мәлик сезнең барыгызны да кышкы ау бәйрәме белән тәбрик итә, исәнлек-саулык тели, эчкерсез сәламнәрен җиткерә, – дип оран салды, – инде падишаһның үзен тыңлыйк. Падишаһ үгезне мөгезеннән алды.

– Ашның тәме тоз белән, мәҗлес яме сүз белән, кемнәр хикмәтле сүзгә маһир, күрсәтегез һөнәрегезне, – диде.

Беразга чатырда тынлык урнашты, хәтта тыштагы тазы этләренең тәтегән мул ризыктан ләззәтләнеп чинауларына кадәр ишетелеп торды.

Аңлашыла, сөҗү чатаклары ачылгач, телләр үзеннән-үзе ачыла, аек башка мәгъкуль сүз табуы да җиңелләрдән түгел бит әле ул.

– Җә, көтәм!

Күзләр җыерчыклы йөзендә бер бөртек тә төге булмаган, гәүдәгә малайлар кебек кенә терсәк буйлы Тугача бәккә текәлде. Шома тел кушаматы аңа юкка гына бирелмәгән, сүз куертырга дисәң, аны куш. Әле дә:

– Мөхтәрәм җәнабе гали, мин бүген бер бик хикмәтле хәлгә юлыктым бит әле, – дип, мәликкә мөрәҗәгать итте, – сөйлимме?

– Хикмәтле дә булгач, рәхәтләнеп тыңлыйм, – диде мәлик, – әйдә, сөйлә.

Тугача мут кына елмайган хәлдә әүвәл мәҗлестәгеләрне күз очыннан үткәрде, аннан соң вәкарь белән генә тамагын кыргалап алып сөйләп китте:

– Бүген шулай иртән иртүк тордым да атларым янына чыктым. Карыйм, Мөйтән бәк мине уздырган икән ләбаса, күл буенда атын эчереп тора. Читтән генә күзәтәм моны, кызык бит. Беләсез инде, ул берәгәйле атлар гына тота. Күренеп тора, аргамагы кабыккан, голт-голт эчә. Бераз туктап хәл ала да, тагын эчәргә тотына, тагын, тагын... Мөйтән бәк нигәдер барыбер риза түгел, озын-озын сулыш белән сызгыра-сызгыра атын гелән эчәргә өнди...

Бервакыт җир убылгандай нидер шартлады. Җиле хәтта мине дә аяктан екты. Тузан утыргач, карыйм, ләхәүлә, теге мескен бахбайның корсагы ярылган лабаса!

Тугача башын кыек салып, янә тамагын кыргандай итте дә, хикәятен дәвам итте:

– Мөйтән бәкнең бүген бер төлке дә тота алмавының сәбәбе шунда, җәмәгать. Гарьлегеннән кача-поса өенә үк кайтып китте. Тире салымын ничек түләр, белмим. Җә, шушы да булдымы бәк?

Мәҗлес бер тын шаулашып алды.

– Мин монда, падишаһ, беләсең, Тугача кырык алдар бит ул, – дип, Мөйтән бәк урыныннан калыкты, – бүгенге табышка килгәндә, җиде төлке тиресе иясе мин. Егермедән ким булмас, дип уйлыйм. Салым түләргә дә җитәр.

– Уен уен белән, салым салым белән, – диде мәлик җитди кыяфәттә, – казна кереме – дәүләти гамәл.

*Тарихи белешмә:*

*Алу-сату, түләү берәмлеге саналган акча дигән тылсымлы тәңкәләр әле киң таралмаган бу дәвердә, болгарлар салымны күбесенчә әйбер-нәрсә белән түләгәннәр. Бу X гасыр гарәп сәяхәтчесе Ибне Рус язмаларында да искә алына. «Алар (болгарлар) падишага салымны ат һәм башка терлекләр белән түлиләр», дип язып калдырган ул. Әйе, башлы-күзле булдыңмы – рәхим итеп, җигүле атыңны әзерлә; балаң тудымы – менүле ат; бер-бер һөнәргә тотындыңмы – тиреңне тотып кил... Тире, гомумән, затлылыгы, аңа ихтыяҗ зур булу сәбәпле, салым мәнфәгатендә аеруча мөһим урын*

*били. Ул хәтта вакыт-вакыт акча ролендә дә йөри. Ә менә ашлык салым исемлегенә кермәгән. Дәүләт аны иген игүчеләрдән үзе сатып алган.*

Мәзәк никадәр мәгънәсез булса, аңа ышану да шул кадәр көчлерәк була, диләр. Тугача бәкнең әлеге тозсыз хикәяте дә аучыларга шул кимәлдә тәэсир итте булса кирәк, мәҗлес шундук җанланып китте, бер-берсен бүлә-бүлә, гәпләшә-сөйләшә башладылар.

Мәлик сөҗү чатагын ачтырды. Әчкелтем ис чыгарып, чымырдап торган хәмер касәсенә калын иреннәрен тигезеп куйды да, хөрмәт йөзеннән саркытын Суар әмире Вираг хакимгә тоттырды. Ул да бер йотым гына эчеп, падишаһ касәсен Искел әмиргә сузды.

Мәлик алдындагы зур кисәк иттән бер калҗа кисеп алып, авызына капты.

Шуннан соң гына табынмән үз вазифасына кереште.

– Асулы казан, пешүле ит, падишаһыбыз ризык-нигъмәтенә фатихасын бирә, – дип, чатырны яңгыратты, – авыз ит тә рәхмәт әйт!

Мәҗлес, ниһаять, үз кысасына керде.

Ау мәҗлесе – ир-атлар мәҗлесе. Ауга хатын-кызлар чакырылмый. Әһле мөслимәләргә кан күрү хәрам, имеш, гореф-гадәткә туры килми. Ошбу кысырыклауны чибәр затлар кабул итеп бетерми, билгеле. Дәгъвалары да урынлы, яугир булырга ярый, рәхим ит, орышта кан кайчакта инеш суыдай ага. Хөр йөрәкле чая һәм кыю болгар хәдимәләре Силки мәликне кайбер ташламаларга барырга мәҗбүр иттеләр бит тәки. Менә икенче ел инде ау мәҗлесенең ишеген алар да ачып керде. Дөрес, әлегә субра-җырчы сыйфатында. Башы булгач, бакасы була, ди болгарлар, тиздән аучы дәрәҗәсен дә алырлардыр, мөгаен.

Ә бүген мәҗлеснең яме Ясминә сылу иде. Менә ул күз очлары белән генә көлемсерәп, вак-вак ымсындыргыч адымнар белән горур кыяфәттә уртага чыгып басты. Мәҗлес бермәлгә тынып калды. Ашау-эчү, гәп корулар ярты юлда киселде.

Әйтерең бармы, алтын егач тутый кош.

Болгар кызларының даны болай да бөтен көнчыгыш тарафларына таралган. Гарәп зыялысы Мәүләви эл-Җаминың теземенә генә игътибар итик:

Әгәр күңелдә Болгар гүзәлләренең мәхәббәте булмаса,  
Ике күздән аккан яшьтән чокыр хасил булмас иде.  
Хәким Синаиның тезмәсе дә шул хакта:  
Ул гүзәлләргә теш кырыйларын ай кебек ялтыратып,  
Болай көчле итеп ярату кирәкмәс иде;  
Аларның теш читләренә гыйшык тотудан  
Барысы да иреннәрен тешләргә мәҗбүрләр...

Ясминә шул токымнан. Аның җыруы да ирек сөюче риваяти хөррә пәрвәр Айтулы кыз турында иде.

Дуст булалсаң Айтулыга,  
Күңелең ачып юата.  
Дошман булсаң Айтулыга,  
Кылычын канга буята.

Ватаны юк – җыры юк сандугач. Ә Болгарның җыры бар. Җыры да, сандугачы да.

Бу җыр да мәҗлеснең агышын тирәннән үзгәртеп, бөтенләй икенче юнәлешкә борып җибәрде: әле генә габиданә шәһвәти һәвәс дулкынында ыштан кашагаларын бүрттереп утырган әһле гавәмне, гүя алыштырып куйдылар, авызлар ябылды, иреннәр кысылды, йөзләр җитдиләнде.

Табынмән шундук ошбу омтылыш учагына коры кура өстәргә дә өлгерде.

– Мөхтәрәм падишаһыбыз илебез өчен илсенеп, җиребез өчен җилсенеп, мәмләкәтебезгә ант йөзеннән ак сөткә кан тамызып эчүне мәгъкуль күрә, – дип, тәкъдимен җиткерде.

Вакыт-вакыт кабатланучы бу йоланы бик хуплап каршы алдылар. Һәр барчасы хәнҗәр очы белән бармак битеннән кан чыгарып, сөтле йомрыга тамызды. Дәррәү басып, бер йотымда йомрыларын бушатып та куйдылар. Әлеге йолага үзеннән-үзе икенчесе килеп кушылды.

Болгар җыеннарында, бәйрәмнәрдә дастаннарны тамаша рәвешендә күмәк башкару, җанлы һәм күркәм гадәт буларак, күптәннән яши. Аның һун заманнарыннан килгән күпьеллык тәҗрибә нигезендә тәгаенләнгән үз йөзе, үз аһәңе бар.

Тезелешеп бастылар. Силки мәлик уртада, ян-ягында билек әмирләре.

Иң алга энәдән-җептән генә киенгән мәһабәт гәүдәле тамашамән чыгып басты. Тавышы да килеш-килбәтенә тиң калын һәм көчле иде.

Кил, хәйраным, биләр, сорасаңыз,
Тыңласаңыз да әйтәлең.
Сорасаңыз да ни итсәңез.

Аннан сораулар юллады. Ә җәмәгать аларга шактый көйле тигез тавыш белән җавап җиткерде. Күренеп тора, дастанны алар яттан белә иде.

– Әүвәл башлап ни битте?
– Көн битте дә ай битте.
– Икенчеләй ни битте?
– Тау битте дә таш битте.
– Уртасына ни битте?
– Ирмән, юшыр-ут битте.
– Аны утларга ни битте?
– Кыл койрыклы мал битте.
Аңа ия булсын дип, туфрактан сурәт калдырып,
Адәмгә баш бармакча тән битте.
– Кил, хәйраным, биләр, сорасаңыз,
Тыңласаңыз да әйтәлең!
– Карагай башы ку булыр,
Хан билгесе ту булыр,
Карыдан куәт кайткан соң
Каты ягы тартмак сур булыр,
Карача күздән нур тайган соң
Карап күрү моң булыр.

Бу «Моң» дастаны иде. Аңа Ясминә дә кушылды:

Колак дотуб дыңлаңыз ушбу сүзем, моң-назым...

Дөрмән бәк баядан бирле күз суын корытып, Ясминәгә мөкиббән китеп утыра иде инде, түзмәде, Ярмәкнең колагына үз көен пышылдады:

Бакса, җанны эреткән,
Көлсә канны йөреткән,
Әйтсә, авыру терелткән,
Күзекәдәй сылу кыз –
Йә синек, йә минеке!

– Тулы айдай нур йөзле,
Җәйран-киек саф күзле,

– дип тә өстә инде диде Ярмәк, – әйтерең бармы, кыз сылу.

– Ни кызганыч, углан, мин инде җәмәгатьле, – дип көрсенде Дөрмән, – дус буларак, мин аны сиңа фаразлыйм, башкалар нәфес сузгалаганчы яучыла.

– Минем Бану солтаныма җитәме соң, – диде Ярмә. – Без сүз куештык.

Дөрмән тавышын чыгармый гына көлде. Аннары:

– Аһ, берәүләр сүз куешкан икән, – дип, урта бармагын чигәсе тирәсендә әйләндергәләп торды.

– Әйе, сүз куештык...

– Юкка баш-күз алгансың, углан, – дип бүлде аны Дөрмән. – Син сүз куешкан арада Суар әмире Вираг хаким Бану бичәңне улы Җантимергә яучылады инде.

Ярмәк әлеге хәбәрне шаярту дип кабул итте, көлде генә.

– Синең үзең юкка баш-күз, бәк, һе-һе-һе...

Дөрмән кулдашының бу халәтенә игътибар итмәде, үзенекен тукыды:

– Ул Җантимер кәпринең танавын кыссаң, артыннан тыны чыгарга тора, атасы кебек коры сөяк, Бану бикәч кызганыч, алар һич тә пар түгел, – дип өстәде.

Дөрестән дә, ул әлеге килешүнең шаһиты иде.

Силки мәлик Суар әмире Вираг хакимне аның алдында кабул итте. Бу аларның җәйге уеннар мәрәкәсеннән соң тәүге очрашулары иде. Һәм мәлик моңа бик шат иде. Әмирне хәтта тәхетеннән торып сәламләде, иң дәрәҗәле урынга утыртты.

– Мәрхәбә, әмир, синең ауда катнашуың бик мәслихәт, шәт төлкеләр дә сине үз итәр, – дип шаяртты.

– Төлке җиде бүрене җитәкли, ди, – диде әмир, көлемсерәп. – Аның хәйләсе үзе белән...

Әңгәмә шушы җиңелчә дулкында, көлү-шаяру кимәлендәрәк барды. Ике арада килеп туган киеренкелек, каршылыклар кырына берсе дә аяк басарга кыймады, хәлбуки, ул хәлләр икесенең дә теш арасында иде.

Дөрмән бәк тә ара-тирә мәзәк-хикәятләр белән хакимнәрнең күңелен күреп, күтәренке кәефләренә ялкын өстәштереп утырды.

Әмир юка гәүдәсен кәнәфиенең эченәрәк шуыштырды да, сөҗү касәсен учына йомарлады, әмма эчмәде, кире урынына куйды. Аннан соң:

– Падишаһ, инде төп йомышымны җиткерергә рөхсәт ит, – диде. Мин бу araлapда олы улым Җантимер угланга кәләш сайлау белән мәшгуль, –

диде, – җиргә карар, йөрәкне ягар, ди. Күзебез Болгар әһеле Бәхтияр бәкнең Бану атлы кызына төште, хәер-фатихаңны бирсәң иде.

Силки мәлик күңеленнән генә бу никахның дәүләти мәнфәгатьләргә туры килү-килмәвен тәгаенләп алды да әйтте:

– Бик мәгъкуль, әмир, мин каршы түгел, тик менә Бәхтияр бәк ни әйтер бит әле?

– Тәкъдимемне кире какмас, дип уйлыйм, – диде Вираг зур ышаныч белән, – бу никах бәкнең үзе өчен дә, ыруы өчен дә олы дәрәҗә бит.

Дөрмән бәк шаталаграк кеше, тезгене дә ычкынгалап-ычкынгалап куйгалый, аңа әңгәмәдәшен җирсетү берни тормый, кайчак шыр ялган сүзләр очырырга да күп сорамый. Ләкин әлеге хәбәр падишаһ исеме белән бәйле, монда уен-муен урынсыз гына түгел, абруй бәрабәре.

Ярмәк бәкне кулларыннан эләктереп алды да:

– Бу хәбәр, чыннан да, хакмы? – дип сорады.

– Хак, хак, Ясминәгә яучы җибәрә аласың, – дип елмайды тегесе. – Кара аны, соңлама.

Ярмәк әңгәмәдәшен утлы карашы белән көйдереп алды да атылып диярлек, мәҗлесне ташлап чыгып китте.

Аты аның һәрвакыт иярле. Килә-килешкә ау кошыдай ияренә очып кунуга, коры кура белән аралаш юка кар җәймәсендә тояк эзләрен калдырып, алга ыргылды. Тезгенен тотмады җайдак, үзенең нинди мәсләк белән ат менүен, кая ашкынуын анык кына белми дә иде. Ул бу минутта парын югалтудан зәгъфрандай саргайган ялгыз сандугач кебек бөтенләе белән сагыш йомарламына әверелгән иде.

Аты аны туры Кыз күленә алып килде.

Күл өстендә боз элпәсе. Кошлар да күренми. Ятимлек кочагында тик моңаеп утыра. Ә күк якты, ачык. Йолдызлар, гәрчә еракта, бик еракта булсалар да, учына алып карардай бик якында җемелдәшәләр. Әнә, берсенең читләре көмеш бәс белән акланган, өзелеп төшеп чәчелеп китәр сыман.

– Бануым, сылуым, төшмә, өзелмә, – дип пышылдады иреннәре. – Айтулы язмышына юлыкма.

Әле кайчан гына шушы күл буенда гыйшкын тапкан иде, сөйгәне белән яратышып, сүзләр куешканнар иде. Әйе, аның дөньясын тутырып тора торган нур шикелле йөрәгенә сыеша алмастай иксез-чиксез олуг бәхете бар иде. Бар иде шул. Хәзерендә ул бәхет кара кошка әйләнеп очып китте. Ходай шулай тәгаенләгән, күрәсең, Валлаһе әгъләм биссәваб, дөреслекне Аллаһы гына белә, Аңа сәна вә хәмед!

Хуш, Бану солтаным, минем өчен даның Айтулыга тиң иде. Хуш!

Болгар кызы Айтулы,
Һибә сиңа санайым.
Даның китсен кайтулы,
Чичән урын басарым.

***

Вираг әмирнең Бану бикәчне улы Җантимергә яучылавы турындагы хәбәр әрсез җил тизлеге белән таралып та өлгерде. Кызлы кешеләр көнләште, шулай да арада тиң күргәнне Тәңре сөйгән дип хуплаучылар

да шактый иде. Хәбәр шул ук көнне Бануның үзенә дә килеп иреште. Атасы ауда булганлыктан, кыз үзенең хәл-халәтен иң беренче анасы белән уртаклашты.

– Инәкәй-бикә, мине үземә дә әйтмичә сатып җибәрергә уйладыгызмыни? – дип текәлеп бакты.

– Бу минем өчен дә яңалык әле, кызым, – диде Хәдичә бикә. – Шулай да үзенең иреннәре елмаерга гына тора. Димәк, хәбәр күңеленә хуш килгән.

– Шөкер, бик дәрәҗәле ыру сората, яшегез яшькә, башыгыз башка тиң, – диде.

– Ә минем ризалыгым кирәкмиме?

– Бала өчен ата-ана җаваплы, кызым, бу барыбызның да башыннан үткән хәл, – диде бикә, – сөйгән сигез булса да, язган бер генә була.

– Минем сөйгәнем куенына керәсем килә, башкага ризалыгым юк, – дип, Бану керт-керт басып, өйдән чыгып китте. Аңа иң беренче Ярмәге белән күрешергә, аңлашырга кирәк иде. Ат утарына ашыкты.

Толпары хуҗабикәсен кешнәп каршы алды.

– Рәхмәт, Сөлек, – дип, Бану аның муенына сырышты, ялларын сыйпаштырды. – Безнең хәлләр бик мөшкел, сиңа исем биргән, миңа яшәү дәрте өстәгән Ярмәк углан белән безне аерырга телиләр. Бел, мин бирешмәячәкмен, Ярмәгем генә нык торсын.

Кичен ул Ярмәкне эзләп тапты. Ау көне тәмамланган иде инде, халык күңел ача.

Бану җансакчысын угланны чакырырга җибәрде.

Егет сөйгәнен күргәч, балтасы суга төшкән кешедәй югалып калды.

– Телеңне йотмагансыңдыр бит, углан, – диде кыз. – Әллә комачауладыммы?

– Юк, юк, Бану бикәч, юк, – дип ымлыкларын сипте егет. – Мин... теге... юк-юк...

– Юк икән, әйдә алайса яланга чыгыйк, – дип, Бану атына типке бирде. – Миңа монда күренергә ярамый.

Эңгер-меңгер таралып килә иде инде. Сүнә барган салкын күк читендә кара болытлар укмашып килә, көн бозылмакчы, күрәсең. Әнә, битләрне көйрәтеп, төртмә җил дә исеп куйды.

– Көн бозыла, – дип, Ярмәк тә телгә килде. – Җә, ышыклан миңа, җил тия күрмәсен...

Атлары кабыргага кабырга тезелеп басты. Ярмәк кызны кочагына кертте. Сулышы кайнар иде, Бану балавыздай эреп, сөйгәненә елышты.

– Мин гомерем буе сине шулай назлап, кочагым түрендә генә йөртер идем, – дип пышылдады Ярмәк.

– Йөрт соң, кем сиңа комачаулый, – диде Бану, аның сүзен бүлеп, – мин риза.

– Эх-х, Бану сөеклем...

Ярмәкнең тавышы калтыранып китте, кочагы йомшарды.

– Ни өчен уфтанганыңны мин бик яхшы беләм, – диде кыз, – шуңа күрә сине эзләп таптым да инде.

– Мәлик сүзе катгый сүз, ул шәрехләнми, үтәлә генә, бикәч...

– Аның сүзе әле һавада очкан кош кына, оясына төшмәгән, – диде кыз, – атаем белән бу әле тәгаенләнмәгән, яучылар килмәгән...

– Үзеңә дә мәгълүм, минем ярдәмче-булышчыларым юк дәрәҗәсендә, – диде Ярмәк. – Атаем күптәннән вафат, туганнарым да бармак белән генә санарлык, дәрәҗәләре дә ташка үлчим. Бар көчем – кылычым. Мәликкә шул кылычым белән хезмәт итәм.

– Мин – синең таянычың...

Бану киселеп калды, чөнки алар өстенә туп-туры чиный-чиный куян-төлке өере ябырылып килә иде. Мәхлукларны ау тәмам чыгырыннан чыгарган иде, күрәсең. Пычактан котылып калсалар да, курку өннәрен зәгыйфьләргә өлгергән инде. Әнә, хәзер, аңгыраланган баштан кая төртелергә белмичә, дала буйлап чабышалар.

– Ахры заман, валлаһи, – диде Ярмәк, – төлке белән куян дуслашсын әле.

– Бичарадан ничара, – диде Бану, – болар да безнең мисалда. Ләкин без бу хәлгә төшәргә тиеш түгел. Аңлыйсыңмы, түгел!

Ул өернең кичке томан эченә кереп югалуын карашыннан кичереп, зелпе тамырыдай угланның гәүдәсенә уралды да:

– Мин таптым, таптым! – дип, кайнар тынын өрде.

– Нәрсә таптың? – дип, Ярмәк читкәрәк тайпылды.

– Мәлик вәгъдәсеннән котылу әмәлен таптым!

– Ничек?

– Әйдә, Кыз күленә киттек, зөфаф кичебез шунда булыр, – диде кыз кискен бер тәвәккәллек белән – Җантимер әмирзадә үзеннән-үзе миннән баш тартачак, егет кешегә түш астында булган кәләш фарыз түгел.

Ярмәк беравык телсез-авызсыз калды.

– Җә, тот тезгенеңне, – дип, Бану иярenә тураебрак утырды.

– Ни сөйлисең син, бикәч, – дип, ниһаять, Ярмәк тә айнып китте. – Әйткәнеңне колагың ишетәме?

– Синең минем белән бергә буласың киләме? – дип сорады кыз үз чиратында.

– Әйттем бит инде, гомерем буе кочагым түрендә йөртер идем...

– Шулай булгач?

– Беләсеңме, зина кылуның ахыры ни белән бетә?

*Тарихи белешмә:*
*(Гарәп сәяхәтчесе Ибн Фазлан мәгълүматы)*
*«Аларның (болгарларның) ирләре һәм хатыннары ялангач килеш бергә су коеналар, бер-берсеннән бер дә яшеренмиләр. Суга кергәндә, хатыннар ирләрдән пәрдәләнсеннәр, яшеренсеннәр дип, күпме тырышсам да, теләгемә ирешә алмадым. Аларда зина кылу бер дә юк, әгәр берәү зина кылса, нинди кеше булуына карамастан, дүрт казык кагып, ике кул һәм аягын шул казыкларга бәйләп, ир һәм хатынны муеныннан ботына кадәр балта белән ярып, һәрбер кисәген бер агачка асалар».*

Кыз-хатын хис затыннан. Карар-ниятләре дә хискә корылган. Шуңа күрә аның янында акыл иясе ир-ат булу зарур. Бану бикәч тә никахсыз зөфаф кичәсенең ни дәрәҗәдә гореф-гадәтләргә туры килү-килмәвен бәяләп тормады, күрәсең. Чөнки кыз-хатын ир-атларга караганда күпкә тәвәккәлрәк, күпкә максатчанрак. Ходай аны шулай яраткан.

Бану инде икенче тәкъдимен очырды:

– Алайса, әйдә, Силки мәлик янына барабыз...

– Бану бикәч...

– Карышма, углан, үз бәхетебез өчен без үзебез көрәшергә тиеш.

Бәндәләрнең гомер юлы тау сукмагы кебек бит ул: бер өскә менә, бер аска тәгәри... Мондый чакта терәк зарур.

Мәлик терәк булырмы? Бану никадәр арыслан йөрәкле булып күренергә тырышса да, үзенең дә эче тулы ут иде. Силки янына кергәч тә, алдан килешенгән барча үтенеч-мөрәҗәгать җөмләләре каядыр китеп югалды. Әмма кыз-хатынны теләсә-нинди хәлләрдә дә коткара торган тагын бер тылсымлы көч бар. Ул – күз яше. Аның күңелендә дә үзеннән-үзе шушы көч уянды. Мәликнең аяк астына барып егылды да үксеп еларга тотынды.

Силки кеше хәленә керә белә торган хаким иде, Бануның тынычлануын сабыр гына көтеп торды.

– Инде, бикәч, хәзер йомышыгызны әйтегез, – дип, үзе янында урын күрсәтте.

– Мөхтәрәм падишаһ, безнең никахка хәер-фатиха бирүеңне үтенәбез, – дип, инде алга Ярмәк чыгып басты, – үзара күптән килешкән идек...

Мәлик башын арткарак чөеп, берара уйланыбрак торды. Шуннан соң гына:

– Вираг әмир синнән алданрак җитешкән иде шул, – диде үкенгәндәй. – Соңладыгыз бит, балалар...

– Мин Җантимер бәккә чыкмыйм, мин Ярмәк угланны яратам, – диде Бану яшь аралаш. – Үтерсәгез дә чыкмыйм...

– Чү-чү, бикәч, нинди үтерү?

Бүген ауда янә Вираг әмирнең эте мәлик этенә ташланган иде. Ташлану гынамы, имгәтеп үк еккан. Андый хәлләр булгалый, әлбәттә, әмма әмир авызына су капкандай ләм-мим. Җитмәсә, әле кыз сорап йөри.

Ул аңа үпкәле иде. Шулай да, бу һич тә вәгъдәне бозу өчен сәбәп була алмый. Ярмәк углан да үз кеше, аның да кәефен кырмаска иде...

Мәлик ут белән су арасында калды. Әйе, хәле җилкә кашытырлык иде.

– Балалар, хаким әйткән сүзен боза алмый, – диде озаккарак сузылган тынлыктан соң, – мин сезгә өлкән кеше буларак кына киңәш бирә алам. Әмиргә исә, миннән хәер-фатиха, ә соңгы сүз Бану бикәчнең атасы Бәхтияр бәкнеке, дигән идем. Аларның әле очрашырга вакытлары булмагандыр. Ә сезгә ашыгыч рәвештә Бәхтияр бәккә яучы җибәрергә кирәк. Ашыгыгыз!

– Яучы итеп кемне сайлыйсың? – дип сорады Бану мәлик катыннан чыккач. – Сүзе үтәрдәй кеше булсын. Мин үзем дә хәзер атаем-бәк чатырына китәм.

Ярмәк берара калын кашларын җыерып, уйланып торды да:

– Дөрмән бәктән дә кулайрак кешем юк, – диде, – хәйләкәр дә, булдыклы да, ярдәмчел дә. Пәрәвез корырга да бик маһир.

– Күптәннән Суар әмирен саламга сөяргә җай эзләп йөри идем, бик шәп булды әле бу, – диде бәк. – Вираг әмир җитешмәгән булса, кыз – синеке!

Быел Бәхтияр бәккә чатырын мәлик рәтенә куярга рөхсәт иттеләр. Бу үзе бер күркәм фал, димәк, аны таныйлар, олылыйлар. Өстәвенә ау да шактый табышлы кимәлдә башланып китте. Шуңа күрә кәефе шул уңышларга

тиң иде. Дөрмәнне дә ил-умач әшнәседәй якты чырай белән, мәзәк сөйләп каршы алды.

– Бер болгар угыр кешесе белән белешкән дә, көн дә аңарга килеп, сыйланып китә икән. Тегесе бер көнне:

– Туктале, киләсең дә киләсең, син ни атлы соң? – дип сораган.

– Гелминкил исемле мин, – дигән болгар.

– Сиңа исемне дөрес кушмаганнар, Берминкил-Берсинкил, булырга кирәк иде, – дигән угыр.

Әйдә, бәк, уз, вакыт җитәр, синдә дә сыйланырбыз, шәт.

– Шул исәп белән йөрим дә инде, – диде Дөрмән, авызын ерып, – менә якынлашу ишекләре дә ачылырга тора, тик, ни кызганыч, сезнең тирәдә әтәлге-кош пәйда булган икән.

– Әтәлгеләргә хәерхаһ түгелмен, – диде бәк, – Әтәлге итәк пычратучы кош ул. Яратканым – бөркет.

– Менә-менә, мин сиңа, хөрмәтле бәк, күк кырында мәйдан тотучы Бөркет тәкъдим итәм дә инде, – диде үзенең суарлылардан алдан җитешкәнлеген аңлап алган Дөрмән тагын да батырая төшеп, – гомереңбуе рәхмәт укырсың.

Тугры юк шоңкармын,
Ту җебендә очырмын.
Синдә – Былбыл,
миндә – Бөркет,
бик пар килгәннәр: Бөркет – Былбыл!

– Әйе, Былбылым – асыл кошым, – диде Бәхтияр.

Гөл былбылны сагыныр,
Былбыл гөлгә багыныр.

Бәхтияр бәк тә Дөрмәннең нинди йомыш белән йөрүен бик тиз аңлап алды. Җәмәгате Хәдичә бикә Бануның дәгъвасын җиткерергә өлгергән иде инде.

Бану аның уллары арасында бердәнбер кыз бала иде. Ул аны бик ярата, һәр үтенечен үтәргә әзер иде. Шуңа күрә иң элек кызының теләген ачыклауны кирәк тапты. Чакырып алып:

– Җә, бәләкәчем, үзең ни фикердә? – дип белеште.

Бану шатлыгыннан атасының муенына барып асылынды да:

– Атаем-бәк, яклаучым, Ярмәк угланга ризалыгыңны бирсәң, мин бик бәхетле булыр идем, – диде.

– Кызымның бәхете – минем дә бәхетем!

***

Гыйшык-мәхәббәт дөньясы – үзенә бер кабатланмас могҗизаи дөнья ул. Утлы мәхәббәт кочагында ләззәт кичерүче яшь йөрәкләрнең ошбу илаһи хис-тойгылары һәрвакытта да кавышу белән тәмамланмый. Бу юлда сынау-сыналу киртәләре, үпкә-сүткә хәлләре адым саен очрап кына тора. Бер күренекле шагыйрә хәтта: «Бәхетле мәхәббәт булмый, бәхетле икән, димәк, чын мәхәббәт түгел», – дип әйтеп тә калдырган.

Шөкер, Ярмәк белән Бану өчен әлеге йөзем җимешедәй татлы, зәкъкум җимешедәй ачы катлаулы чор инде артта калды. Күрәсең, бабаларыбыз, сабыр соңында нусрат бар, михнәт соңында рәхәт бар, кайгы соңында шатлык бар, дип, бик белеп әйткәннәр.

Туй көне билгеләнгән, Бәхтияр бәк иртә-кич шушы күңелле мәшәкатьләр эчендә кайный. Бану кием-салым белән мәшгуль, янә таныш чин тегүчеләрен чакырды.

Ярмәк кенә хезмәтеннән бушамый. Яугирләрнең тормышы шулай четерекле инде, кылыч уйнату. Дошман килсә – канга-кан, тыныч вакытта – тоташ күнегү-өйрәнүләр.

Алай да, күрешеп-очрашып торалар. Бану күнегү мәйданында да булгалый, аңарда да яугир каны ага лабаса.

Беркөнне Ярмәк сөйгәне янына үзе килде. Ничектер сәеррәк иде ул. Ашау-эчүдән дә баш тартты, тыныч кына утырып тора алмый, бер торып баса, бер йөрештереп ала, әле тәрәзәгә барып каплана.

– Койрыгы пешкән мәчедәй син бүген, – дип көлде Бану, – бер-бер хәл булмагандыр бит?

Ярмәк сөйгәнен сүзсез генә кочагына кертте дә, калтыранганрак ялварулы тавыш белән:

– Бану, былбылым, туйның вакытын үзгәртәсе иде бит, – диде.

– Ничек?

– Бер ай көтәсе бар бит әле...

Бану бармагы белән егетенең борынына басып:

– Түзәр чамаң калмадымыни? – диде ясалма канәгатьлек белән, – түзгән түш ите йигән, углан, түз. Аннан соң, әле минем күлмәкләрем дә әзер түгел, юк, юк, юк...

Ярмәк янә бер йөрештереп килде дә чын дөресен әйтеп, эчен бушатты.

– Бануым, былбылым, минем котырык ыруым: «Син үзебезгә тиң мөселман кызына өйләнергә тиеш идең, – дип, саруымны кайната, җәтрәк шуларның авызларын каплыйк әле, – диде.

– Без – барслар нәселе, барска табынабыз, – диде Бану уйчан гына, – кешеләрне дингә карап бүлмибез.

– Мин синсез яши алмыйм, – диде Ярмәк. – Моңа бернинди киртәләр дә сәбәп була алмый.

– Минем атаем Бәхтияр бәк анаем-бикәне: «Ир белән хатын – бер җан, бер тән», дип сөя, – диде Бану сүзен дәвам иттереп, – анаем мөселман кавеменнән. Ул мөгаллим чакыртып, мине гарәпчә укырга-язарга да өйрәттерде. Тик мин барыбер атаем-бәк динен үз итәм.

– Туй көнен үзгәртмибез инде алайса?

– Юк, үзгәртмибез, – диде Бану, – шулай да, нинди икән ул мөселман дине, яраткан кешемнең дине, мин моны белергә тиеш.

Бану бикәч якындагы мәчеткә барып, Гарәбстанның үзеннән килгән Хөсәен бине Ибраһим атлы дин әһеленнән, түләү шарты белән, ярдәм итүен үтенде.

– Мөхтәрәм мөслимәнең мәсләге ни-нәрсәдән гыйбарәт? – дип белеште тегесе.

– Мәсләгем ислам дине буенча мәгълүмат өстәү, дамелла, – диде Бану, – әлегә.

Хөсәен бине Ибраһим Болгарда елдан артык яши иде инде. Халык ошата үзен, тиз арада гыйлемлеге белән абруй казанды. Хәлбуки, Болгар – күптин-күп кабилә-кавемнәр иле. Вазгыять катлаулы. Хак дин әле тамырда гына, башлыча мәҗүсилек өстенлек итә. Силки мәлик үзе дә потка табына. Ә гореф-гадәтләр исә мәҗүсилектән дә өстен. Үзләрен мөселман дип атаучы кавемнәр дә исламның үзләренә ошаган якларын гына хуп күрә. Бу, нигездә, садака бирү, корбан чалу кебек гамәли шөгыльләрне үз эченә ала. Намаз уку, ураза тотулар читтәрәк кала бирә.

– Минем анаем Хәдичә бикә мөселман өммәтеннән, – диде Бану, – ул әйтә, кайчандыр безнең борынгы кавемебез Банат әл-Иллаһ кыз-хатын алласын үз иткән, ди. Моны ничек шәрехләргә?

Дамелла күркәм сакал-маекларын сыпыргалый-сыпыргалый, бераз уйланыбрак торды да әйтте:

– Димәк, әлхәмдүллилаһ, анагызның ата-бабалары Көрәеш ыруыннан булган. Хакыйкатьтә, алар кайчандыр Әл-Манат исеме берләштергән Әл-Ләт вә Әл-Гуззә дигән үз аллаларына табынганнар. Хәзерендә көрәешләр Иман юлына басып, шәригать кануннары белән яшәүче кавем, бер Аллалы кавем, дәрәҗәле кавем. Аннан болай, мөхтәрәм бикә, Аллаһының җенесе юк. Аллаһы Тәгалә – туксан тугыз изге исем йөртүче дөньяны бар иткән Бөек зат. Аннан башка Илаһ була алмый. Бәндәгә Аның үзе белдерергә кирәк тапкан сыйфатлары гына мәгълүм. Без – фәкать Аллаһының коллары.

– Шулай да, дамелла, мине кыз-хатыннарның Ислам динендәге урыны күбрәк кызыксындыра. Мәрьям ана турында да ныграк беләсем килә.

– Бик мәслихәт, мөхтәрәм бикә, Мәрьям радыяллаһу ганһә – динебезнең йөзек кашы. Ходай рәхмәте белән сабагыбызны иртәдән үк башлап җибәрик.

– Мин риза, дамелла.

Бану бикәч Хөсәен бине Ибраһим сабакларыннан риза-бәхил калды. Бик дулкынланды, үзенең шәхси фикерләре белән кыйссадан хисса-гыйбрәт алырдай хикәятләрен кәгазенә теркәп куйды.

Беренче хикәят.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай тәкрарлый:

«Мәрьямгә Җәбраил фәрештәбезне җибәрдек, ул Мәрьямгә камил яшь егет сурәтендә күренде».

– Тәкъва булсаң, мин синнән Аллаһы Тәгаләгә сыенамын, тәкъва булмасаң, Аллаһы Тәгаләгә бигрәк тә сыенамын, – диде Мәрьям радыяллаһу ганһә.

Җәбраил галәйһиссәлам:

– Хакыйкатьтә мин синең Раббыңнын илчесе, сиңа ир бала багышларга килдем, – диде.

– Минем балам ничек булсын, хәләллек белән миңа бер ир дә якынлык кылмады, шулай ук никахсыз бозыклык та кылмадым.

– Синең Раббың Аллаһы Тәгаләгә атасыз баланы бар кылу җиңел, бу бала рәхмәте белән килер, – дип, яшь егет сурәтендәге Җәбраил аның күлмәгенә өрде. Һәм мөслимә шундук балага узды.

Мәрьямгә унөч яшь иде.

Гыйбрәт: Ошбу дөньяда балага узган мөслимә – иң бәхетле мөслимәдер. Ярабби, шул бәхетләрне насыйп ит.

Икенче хикәят.

Мәрьям радыяллаһу ганһә нифастан арынып, Гайсә галәйһиссәламне күтәреп, кавеме янына килде.

– Әй, Мәрьям, бик тә мәкруһ эш кылдың, атасыз бала китердең, – дип, борын җыерды кавемдәшләре.

– Бу бала белән үзегез сөйләшегез, аның җавабын ишетегез, – диде Ана.

Кавем гаҗәпкә калды.

– Ничек без бишектәге сабый бала белән сөйләшик? Моңа кадәр бишектәге сабый бала сөйләшә белми иде, – диделәр.

Шунда сабый:

– Хакыйкатьтә, мин– Аллаһы Тәгаләнең колы. Ул миңа китап иңдерде, «Инҗил» дигән китап. Һәм мине пәйгамбәр итте, – диде.

Гыйбрәт: Йәә Мутәкәббир, Йәә Газииз – Бөекләрнең Бөеге, нинди кодрәт иясе Син! Мин – мөкиббән!

Өченче хикәят.

Хак Тәгалә галәмне, ягъни оҗмах, тәмугны, җир һәм күкне, Гареш һәм Көрсине һәм башкаларны яратырга, бар кылырга теләгән заманда, Үз нурыннан бераз нур алып, ул нурга әйтте:

– Хәбибем Мөхәммәд бул, – диде.

Аллаһы Тәгалә гөнаһлы өммәтләре гөнаһысының табибы, пәйгамбәрләр хуҗасы, Кыямәт көненең шәфәгатьчесе, яратканы – хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлламне туу белән шулай сәламләде.

Мөхәммәд анасыннан сөннәтле һәм кендеге киселгән булып туды. Атасы – Габдулла, анасы – Әминә, имезүчесе – Хәлимә.

Җәбраил фәрештә Мөхәммәд хәзрәтләренә кырык яшендә пәйгамбәрлек иңдереп, «Икъра-а би-ис-ми Раббикыл-ләзи халәкә» сүрәсен укып бирде. Беренче булып Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңгән бу сүрә Коръәни Кәримнең тәүге сүрәсе иде. Ул Коръәнне аяте-аяте белән егерме ике ел буе иңдереп торды.

Гыйбрәт: Ләә иләһә илләллаһу Мөхәммәд-әр-Расүлуллаһ.

Ярмәк углан! Кәләшең ихлас күңелдән иман китерде, мөселман булды, сөбхәналлаһи вә биһәмдихи.

***

Бәхтияр бәк яраткан кызының туен моңарчы күрелмәгәнчә, купшы һәм ишле кимәлдә үткәрергә ният итте. Йөзгә якын субра ерау гына чакырган иде. Кунаклар хакында әйтәсе дә юк, болгарның барча шәрәфле кешеләре күптин-күп бүләкләр төяп, ике-өч көн алдан килеп, чатырларын корды.

Болгар туеның төп бизәге – ашау-эчү, табын. Кунак туйдан шар кебек тәгәрәп кайтып китсә генә сыйланган санала. Хәер, моның шулай булачагына шик юк иде, чөнки ашлы көтүлектә бер көтү елкы, бер көтү куй, һәм дә башка аяклы мал түл җыя иде инде. Боларга янә дә алдан тотылып, күлгә җибәрелгән балык, утарда каңгылдашкан йөзләрчә кош-корт та өстәлә. Кыскасы, балталар чарланган, пычаклар кайралган, тәләкәләр асылган иде. Мал суючыларның, пешекчеләрнең, табынчыларның җиңнәре сызганулы, әмер генә көтәләр.

Менә шундый шанлы бәйрәм көтә иде гавамны.

Бу хәбәр Болгар эчендә генә йомылып калмыйча, күрше мәмләкәтләргә дә барып иреште, шул исәптән тернәкләнеп килүче ашкын һәм нәфесле Владимир Русе бакырбашларының да колакларын торгызды. Кемнәрдер сөенде, кемнәрдер көнләште, кемнәрдер, яу чабу өчен менә дигән форсат дип, күңеленә беркетеп куйды.

Күрекле һәм муллыклы Болгар иле дусларының да, көндәш вә дошманнарының да күз уңында иде.

Никах укуны Хөсәен бине Ибраһим дамелла үз өстенә алды. Шартлары да шактый икән. Әүвәл шуларны шәрехләде.

– Инсани кыз үзенең матурлыгына, сафлыгына, уңганлыгына, намуслылыгына вә галимәлелегенә таянып, мәһәрне үзе билгеләргә хаклы, – диде. – Әгәр сораган кадәр бирмәсәләр, ул хәтта никахтан баш тарту хокукына да ия.

Әлеге шарт Бануның күңеленә аеруча хуш килде. Сөйгәненә мут кына карап:

– Минем мәһәр бигадәти мәһәр, мәхәббәтем хакына угланның күктәге айны учыма китереп салуын телим, – диде.

– Ай, мөхтәрәм бикәч, Аллаһы Тәгаләнең биләмәсе, мәһәр була алмый, – дип аңлатма бирде дамелла. – Мәһәр шәхси мөлкәттән гыйбарәт.

– Минем андый мөлкәтләрем юк, – диде Ярмәк. – Атым да кылычым...

– Их, син, мин бит риваяти Айтулы сыңары, мине мөлкәтең кызыксындырмый, мәһәрем син үзең булырсың...

– Тагамул имләк, никах мәҗлесе вәҗиб, тиешле гамәл, – диде дамелла, – ә менә вәлимә, туй мәҗлесе мәҗбүри түгел, үткәрсәң дә, үткәрмәсәң дә, гөнаһы юк. Әлеге җәһәттән ниятегез нинди?

– Бу хакта баш ватасы түгел, дамелла, Болгарда туйсыз кыз бирмиләр, – дип көлде Бану, – үзең әйтмешли, без телибезме-теләмибезме, туй үтәчәк!

– Вәләкин вәлимә шәригать кануннары буенча өч көннән артык сузыла алмый, һәм дә туй хатын-кызлар өчен аерым, ир-атлар өчен аерым үткәрелә. Думбра кагарга...

– Дамелла, – дип туктатты аны Бану. – Бу шарт безгә бөтенләй дә туры килми. Үзең дә беләсең, Болгарда мөселманнар гына яшәми, күбесе мәҗүси, сөҗүне дә бик яраталар, мәҗлесләр дә ике-өч атнага сузыла.

– Ихтыярыгыз.

Никахның икенче көнендә күпләр тилмереп көткән туй башланды.

Башлап, Силки мәлик яшьләрне котлап тәбрик сүзе әйтте, аннан соң, кагыйдә буенча Ярмәк үз гаиләсе исеменнән хакимгә өйләнешкән затларга фарыз булган дәүләт салымы исәбенә ике толпарның бизәкле каеш йөгәнен тапшырды. Атларын да күрсәттеләр. Берсе чем кара, икенчесе сөттәй ап-ак төстә иде.

– Афәрин!

Шушы арада мәликнең тәхете алдына йөзбашы килеп тезләнде.

– Падишаһ, бакырбашлар яу белән килә, чапкын сүзләре буенча чиккә җитеп киләләр икән инде, – дип, күңелсез хәбәр ирештерде.

Силки кулындагы тустаганын өстәлгә куеп, кашларын җыерган хәлдә уйланып торды да янында утырган Дөрмән бәккә төбәп әйтте:

– Туйны өзмибез, бәк, сине сәргаскәр итеп билгелим, хәзер үк вазифаңа кереш, – диде. – Әле туйга да җитешерсең.

– Баш өсте, падишаһ.

***

Кирәк тирәкне ега, ди. Дөрмән бәк эшне коры тотты. Кичкә яугирләрен җыеп бетергән иде инде.

Бу күрексез хәбәрне туй җәмгысенә җиткерергә теләмәсәләр дә, чатнаулы чатактан саркыган сары бал кебек бик тиз исләнеп, таралырга да өлгерде. Ярмәкнең яугирәи каны да тамырларын бүрттереп, уйнаклап алды. Ләкин Силки аңа туйны ташлап китәргә ирек куймады.

– Кәләшең янында гына утыр, Дөрмән бәк синнән дәрәҗәлерәк тә, тәҗрибәлерәк тә, – диде.

Төн юлда үтте. Инде яңа көн туып килә. Җир өстенә, әнә, әкрен-әкрен үрләр, уйсулыклар калкып чыга, дала киңлекләре киңәйгәннән-киңәя бара.

Дөрмән учын каш өстенә куеп, дикъкать белән тирә-юньне күзәтеп торды да кулдаш угланга әйтте:

– Тау ышыгында учак күмерләре пыскый, бакырбашлар төнне шунда уздырганнар булыр, аларны бирҙә каршыларбыз, – диде.

– Орыш өчен бу урын ясап куйган кебек, – дип хуплады углан сәргаскәрнең карарын.

– Мин бу төбәктә шактый илбасарларны тукмадым инде, – диде Дөрмән бәк үзенә бер сәмави канәгатьлек белән. – Потларым – ак барс белән ак бүре – шәт, бүген дә ярдәмнәреннән калдырмас. Ашыт тавы да, Кәркерәү елгасы да безгә хәерхаһ.

Ул берара саргылт күбекләрен чәчрәтә-чәчрәтә йолкынган су тавышына колак салып торды. Иртәнге тынлыкта шыбырдаган су челтерәве аеруча аһәңле булып ишетелә иде.

Ул арада гаскәри башлыклар да җыелып бетте.

– Бакырбаш – үҗәт орышчы, – диде сәргаскәр, һәрберсен кырыс карашы аша үткәреп. – Кирәкме-кирәкмиме, алдын-артын уйлап тормый, котырган эт кебек кем туры килә, шуңа ташлана. Воеводалары да: «Безнең кылыч ике җәпле, дөнья безгә буйсынырга тиеш», – дип тәкрарлый икән.

Ә безнең төп өстенлегебез – тизлек. Бакырбашлар, гадәттә, өер булып атылалар. Бу очракта мин билгеләгән төркем чөй рәвешендә рәт эченә ерып керә, калганнар сул һәм уң канаттан аларны бoҗрага алырга тиеш. Минем яндагы яугирләр исә кайда хәл катлаулана, шунда атылачаклар. Бу – сыналган алым. Аңлашылгандыр, дип уйлыйм.

Менә дала очында бакырбашларның кара-саргылт шәүләләре пәйда булды. Барысы да ияр өстендә. Пошынмыйча, атларын салмак кына атлатып киләләр, әйтерсең лә, сәхрә манзара кылырга чыкканнар. Үзләрен калкулык артында тау итәгенә ышыкланып, болгар яугирләре сагалап торганын башларына да китермиләр, күрәсең. Шулай булмыйча, болгарларның шәрәфле туй вакыты лабаса, зур тантана вакыты, башка мәшәкатьләрнең онытылган чагы.

Бакырбашлар гүя казанга салынган балыклар, чупырдашыпмы-чупырдашалар. Тик казан эчендә чупырдаштың ни дә чупырдашмадың ни, хикмәте аз.

– Сабли на гола! – дип кычкырды воевода үзен-үзе белешмичә. – Сабли на гола!

Дөрмән бәк орышка ошамаган бу күрексез буталышны калкулык өстеннән күзәтеп торды да угланга әйтте:

– Бар, воеводаны сакла, тимәсеннәр, мин аны үзем әсир итәм, – диде.

Атлар кешни, кычкырыш-сүгенүләр яңгырый, тәүге яралыларның йөрәк өзгеч ялварулары колакларны ярып керә.

Үзәнлеккә төчкелтем кан исе таралды. Бу инде орыш иде. Үзенә үлем янавын аңлаган орышчы ерткыч җанварга әйләнә. Курку хисе үч хисенә әверелә. Бакырбаш җирәнсакаллар әнә шундый хәлдә иде.

Дөрмән бәк бу утлы божрадан воеводаны кысрыклап чыгару нияте белән үзе дә яу кырына керде.

Табигать-ана да читтә калырга теләмәде, күрәсең, кабалана-кабалана ашыккан җил даладан ургылып килде дә, коры кураларны әрле-бирле буташтыра-буташтыра, тау ышыгындагы ялгыз карагайга сугылып, үләнле сукмак буенча өермәләнеп узды.

Шул мизгелдә күктән түбәнгә чытыр-чытыр яшен уты сызылып төште. Аннан чатнатып, күк күкрәде, шыбыр-шыбыр яңгыр яварга тотынды. Җил тузгыткан карагай ябалдашлары өзгәләнепме-өзгәләнә. Әле кыеклап, әле чәнчә коелган яңгыр үҗәтләнә генә бара.

Яу кыры боламыкка әверелде. Атлар абына, тая, егыла, җайдаклар иярләреннән мәтәлә. Алдан тәгаенләнгән «уң-сул канатлар», «чөйләр» инде онытылды, йөзгә-йөз, йодрыкка-йодрык, күзгә-күз орышы башланды.

Дөрмән бәк воеводаны карашыннан ычкындырмый, тик янына гына барып җитә алмый, һаман юлын бүләләр. Сагы да ишле, бу хәлдә сак комачаулык кына тудыра. Шуңа күрә ул ым кагып кына, җан сакчыларын тынычландырды да бакырбашлар төркемен ерып, воевода әләме янына якынлашты. Уйнаклапмы-уйнаклый булат кылычы. Әледән-әле җирәнчәчләрнең башына килеп эләгә: селтәнә тора, егыла торалар. Менә бу орыш ичмасам.

– Һоп-һоп!

Коңгырт чырайлы, кызгылт сакал-мыеклы, түмәрдәй юан җәяүле яугир бу үтергеч селтәнүләрне күзәтеп торды-торды да үзенә куркыныч янамавын аңлап алгач, ярсу сәргаскәргә сөңгесен очырды.

Кулы туры да, көчле дә икән. Сөңге бәкнең нәкъ калак сөяге арасына кадалып, күкрәген үтәли тишеп чыкты, көн яктысын сүндерде.

– Ах!

Җан сакчылары килеп җитте-җитүен, тик соң иде инде.

– Сәргаскәрне үтерделәр! – дип оран салды углан.

Бу ачыну набат булып яңгырады.

– Үч! Үч! Үч!

Таулар бәрелешкәндәй, туктаусыз күк күкри, як-якка чәчри-чәчри, яшен яшьни. Бу шашкын манзарага кылыч чыңгары, сүгенү, үлем авазлары кушыла.

Мәхшәрнең мәхшәре.

Бераздан каудар җил болытларны таулар артына куып алып китте. Яңгыр туктады.

Болгарлар бер әсир дә алмады, бөтен бакырбаш явы юешкә манчылган үзәнлектә аунап калды. Үзләре дә шактый югалтуларга дучар иде. Сәргаскәрдән кала, барысын да тау итәгендә җирләделәр.

Күктә гомерлек орыш юлдашлары – козгыннар пәйда булды.

Шәһидләрне юмыйлар, каннары да сөртелми. Кабергә төшергәндә, аяк киемнәреннән башка киеме дә салдырылмый. Фәкать коралы гына алына.

Дөрмән бәк исә, орышларда теләп катнашса да, угланлык, төп һөнәре түгел иде. Икътисад кешесе иде ул. Шуңа күрә аны җир куенына мәҗүсиләр йоласы нигезендә иңдерделәр. Силки мәлик кушуы буенча җеназада дәүләт исеменнән Ярмәк углан катнашты.

Әүвәл бәкнең мәетен тирмәгә кертеп салдылар. Бераз вакыт үткәч, дәрәҗәле ир-ат төркеме тирмәнең ишек катына килеп, сүзсез генә үкси-үкси еларга тотынды. Авызларын былчайтып, тамак төпләре карлыкканчы үкерде даирә. Арып-талганнан соң гына аларны хуҗалык коллары алыштырды.

Һәрберсенең кулында камчы иде. Боларның вазифасы катгыйрак икән: тотындылар үзләрен-үзләре камчыларга, түз генә. Киемнәре ертылып бетте, тәннәре күм-күк булып, күгелҗем төскә керде. Җәрәхәтләреннән кан бәреп чыккач кына туктадылар.

Чират хөрмәткә җитте. Мәмләкәт хакын хаклап, кабилә-ыру хакын хаклап башкарган эшләренә дан күтәрү максатыннан, Ярмәк углан Дөрмән бәкнең шәхси байрагын тирмәнең ишек өстенә элеп куйды. Берничә сүз әйтмәкче иде дә, рөхсәт итмәделәр, йолабызга туры килми, диделәр. Мәетне кабергә иңдерер алдыннан аның җанын тынычлыкта калдырырга кирәк икән.

Җирләгәннән соң, кабер әйләнәсенә аның коралларын тезеп чыктылар да таралыштылар.

Нәкъ ике ел тулган көнне Ярмәк ишек өстендәге байракны урыныннан алып, аның кануни варисы – өлкән улы Исәнтәй угланга тапшырды.

Исәнтәй углан бәк хокукына керде, ә җәмәгате Сания бикә кияүгә чыгу хокукын алды. Һәм шул ук көнне ирле дә булды. Ике елга сузылган җеназа менә шулай тәмамланды.

*Тарихи белешмә:*

*Шушы хафалы көннәрнең берсендә Силки мәлик катына бер коткылы хәбәр җиткерделәр.*

*Византия император-кайсарының Идел елгасы төбәгенә караган Рус биләмәсендәге өлешендә, Каспий диңгезе тарафларында бик уңышлы яу чабып, күпсанлы әсирләр алып, бик мул мал туплап, ашыкмыйча, туктала-туктала гына, мәмләкәтләренә кайтып барышлары, имеш.*

*Әлеге хәбәр мәликнең зәһәрен кубарды, йокысын качырды.*

*Әзер ганимәт ләбаса!*

*Бу форсатны кулдан ычкындырсаң, җир йотар. Янә дә сәргаскәр вазифасына дәгъва итүчене сынау өчен дә менә дигән имтихан-сылтау.*

*Ул иртән иртүк Ярмәк угланны чакырып алды һәм аңа бурычларын тәфсилләп аңлатканнан соң әйтте:*

*– Җиңеп кайтсаң, сәргаскәр урыны синеке, – диде.*

*– Баш өсте, падишаһ.*

*Византиялеләрдә 250 меңлек гаскәр, болгарларда җәмгысы – 15 мең кылыч. Көч византиялеләр ягында. Кемнәрнеңдер аларга һөҗүм итүе ике ятып, бер төшләренә дә керми. Һәм җиңү китерә торган татлы әсәрләнү хозурында рәхәтләнеп ләззәт кичерүләре.*

*Ярмәк исә дала өермәседәй көтмәгәндә ташланып, пыран-заран китереп ташлады бу уяулыкларын югалткан мактанчык византиялеләрне.*

*Һөҗүм яу кору өчен түгел, мал өчен иде. Шуңа күрә кайсар аңына килеп, тышаулары чишелгән гаскәрен кузгаткалаганчы, Ярмәк кулына төшергән малларын, әсирләрен алып, аҗаган тизлеге белән күздән дә югалды.*

***

Туй мәҗлесләре тәмамланып, кунакларны озатып бетергәннән соң, кырыкмаса-кырык эшне кырык якка ташлап, хәтта сак та алмыйча, Ярмәк белән Бану Кыз күленә чыгып киттеләр. Аларның үзләренә насыйп ефәктәй затлы, мамыктай йомшак ак бәхетләрен, язгы ләйсән яңгырдай ашлы сәмави шатлыкларын икәүдән-икәү генә калып кичерәсе, хозурланасы килә иде.

Кояш, тау артыннан күз кырые белән генә карап, чыгып кына килә иде әле. Таң кызыллыгы салмак кына җәелә-җәелә, дөньяны үз кочагына ала бара.

Ярмәк кәләшен күтәреп алды да:

– Әй кояш, күр, минем былбылым бу, – дип кычкырды, – күрәсеңме, нурдан яратылгандай нинди матур ул!

Бану яшьләрен яшермәде дә, сөртмәде дә.

– Арысланым, син минем бәхетемә, мин синең бәхетеңә туганбыз, – дип, һич кыенсынмыйча иренең кайнар иреннәреннән үбеп алды.

Аннан соң алар көлешә-көлешә, шаярыша-шаярыша су коендылар.

Су өсте көмеш нурлар белән тулышкан иде. Битләрне таң вакытына гына хас үзгә бер йомшак дала исе иркәли. Ул шундый саф, шундый чиста вә пакь, сулап туеп булмый, сулаган саен сулыйсы килә.

Шулвакыт аларның шатлык-куаныч белән тулы ваемсыз чөкердәшүләре арасына күлнең вак таллык очыннан сагышлы аккош тавышы кереп кысылды.

– Айтулының изге кошына нидер булганга охшый, әйдә, барып күрик әле, – диде Бану, – бәлки, ярдәм кирәктер?

Чыннан да, бу сагышлы аваз ялвару авазы иде.

Бардылар, күрделәр. Сагышлы аваз иясе ата аккош иде. Пары яр читендәге куаклыкка ышыкланып, хәрәкәтсез калган. Баксаң, канаты каерылган икән.

– Ач козгын имгәткән бичараны, – диде Ярмәк, – пары шуңа өзгәләнә...

– Ярдәм кирәк ул, – диде Бану, – әйдә, тотып, үзебезгә алып кайтабыз, кош караучы бер-бер әмәлен тапмый калмас.

– Башта аккошны тотарга кирәк бит әле.

– Яралы бит ул, карап бак, хәзер мин аны куеныма алам, – дип, кулын сузды Бану.

Аккош исә бикәнең куенына керергә ашыкмады, эчкәрәк йөзеп китте.

– Әйдә, чишен, суга керәбез, – диде Бану, – аны бу хәлендә ташлап китеп булмый бит инде, аяз көнне яшен сугар.

Ярасы җитди иде булса кирәк, аккошның әллә ни тыпырчынырга куәте җитмәде. Муенына Бануның эчке күлмәген очырдылар да тотып та алдылар.

Кош карауч аккошны капшаштырып караганнан соң, озын муенын суза төшеп:

– Тырышып карармын, очу хәленә җитсә-җитмәсә дә, бәһасе бер алаша, – диде.

Ярмәк сатулашмак булып авызын ачкан иде дә, бикә алданрак җитеште.

– Үзебезгә килеп йөреп дәвалыйсың, – дип, ризалыгын белдерергә ашыкты.

Таң алдыннан аларны ачыргаланып сагышланучы аккош тавышы уятты. Торып чыктылар. Яктырып килгән аяз күктә яралы аккошның пары, сөйгәнен юксынып, өзгәләнә иде.

Тирән ярату хисе белән өрелгән бу назлы мәхәббәт авазын ишетмәү мөмкинме соң?

Озак та үтми, читлектәге аккош та җанашына сагынулы ашкын сәламен очырды.

Аккош ай буе һәр көнне иртә таңнан очып килеп, үз телләрендә мәгъшукасына сөю хисләрен ирештереп йөрде.

Ниһаять, кош караучы дәвалауның төгәлләнүе турында белдерде.

Пары килгән вакытка далага алып чыгып, мин аның тышауларын чишәм, – диде, – канатлары нычыганмы-юкмы, менә шунда күрербез инде.

– Ә оча алмаса? – дип, күзләрен чекерәйтте Бану.

– Мин, бикә, алдан килешкәнчә, булдыра алганның барысын да эшләдем, – диде кош караучы. – Калганы Тәңре кулында.

Чәкәләшү өзелде, чөнки күктәге ефәктәй өрфә каурый болытлар арасында Аккош пәйда булды.

– Әллү-лү, әллү-лү, кый-кый, мин килдем...

Ана аккошның гәүдәсе бәйге сызыгында түземсезлек белән тезген бушавын көтүче чабышкыныкы кебек бөтен көч-куәтенә тураеп, үзенә бер мәһабәт сурәткә керде. Аннан ак энҗе нәзберек муенын үзенә бер назлы кыланчыклык белән уйнаткалап торды да җилкәндәй киң канатларын җилпеп, аваз салды:

– Әллүлү-әллүлә, кый-кый... мин әзер, кый-кый...

Шуннан соң кызгылт томшыклы нәфис башын чайкый-чайкый, үзен күзәтеп торучы мәрхәмәт иясе кешеләрне рәхмәтле карашы белән сыйпап узды һәм йөгерә-атлый урыныннан кузгалды да очып та китте...

– Сөбханалла!

– Афәрин!

Бер-берсенә сыенышып баскан кешеләрнең күзләрендә яшь, күңелләрендә әйтеп бетергесез куанычлы шатлык иде.

Аккошлар күкне уратып, баш очларыннан ике-өч мәртәбә әйләнеп, аксыл-зәңгәрсу офык киңлекләре эченә кереп, күздән югалдылар, кайтаваз булып, тавышлары гына ишетелеп торды.

– Әллүлү-әллүлү, кый-кый, без сезне оныт-ма-быз...

Аккошларның бер-берсенә әһле тугрылыгы Бану бикәне бик дулкынландырды, күп уйларга этәрде. Ул моңарчы бәхет язмыштан, ул йә бар, йә юк, иңнәреңә кош кебек бер килеп кундымы – бу инде гомерлек,

дигән караштa тора иде. Баксаң, бәхет кешене тапмый, кеше аны үзе таба. Тик бәхет судагы шамбы балыгыдай шома икән, хәзер кулыңнан шуып төшәргә генә тора. Ычкындырдыңмы – бетте, аны кабат эләктереп булса да, йөзгә-меңгә бер генә була, ди.

Җыеп кына әйткәндә, язмыш язмыш белән, ә кеше үз бәхет бинасын үзе корырга тиеш. Шушы көннән башлап, ул Ярмәгенә энәгә сапланган җептәй тагылды, аннан бер дәкыйка да аерылып тормый: ул орыш күнегүләрендә – Бану да шунда кылыч уйната; хәрби җыен үткәрә – Бану янә иң алгы рәттә; мәлик белән очрашу – җефет шулай ук иренә тагылулы.

Тора-бара яшь бикәнең гайре мәгъкуль гамәлләре телгә керде. Силки мәлик тә угланны чакырып әйтте:

– Син рәсми вазифа иясе, бу вазифа эшләренә җәмәгатеңне катнаштыру дәүләти кагыйдәләргә сыймый, – диде.

– Падишаһ, ул да яугир, мин аның хәрби әзерлекләрдә катнашуында бер гаеп тә тапмыйм, – дип, хатынын якламак итте Ярмәк.

Мәлик угланның сүз көрәштерүен ошатмады, билгеле.

– Ир – аяк, хатын – олтырак, – диде ачу белән. – Ә син хатыныңны муеныңа атландыргансың, ир була бел!

Шушы ук көнне Бәхтияр бәк тә кызын чатырына чакыртып алды. Әүвәл кызларның балачактагы шуклыкларын исләренә төшереп, көлешә-көлешә чөкердәшеп, табын корып утырдылар.

– Син, суалчаннарны хәзер дә яратасыңмы? – дип, Бәхтияр бәк, шук кына күзләрен уйнаткалап, кызына текәлеп бакты.

– Минем аларны бервакытта да яратканым булмады, – диде бикә.

– Ай-һай-һай, хәтерең кыска икән, кызым-бикә, – дип, бармак янады бәк, – хәзер исеңә төшерәм. Сиңа дүрт яшь иде. Бервакыт кесәң тулы суалчанга тап булдым да:

– Бәләкәчем, нигә аларны кесәңә тутырдың? – дип сорадым. Ә син ике дә уйлап тормыйча:

– Атаем, яңгыг күлләвекләгендә алагга салкын, – дидең, – кесәмдә җылына алагг, кояш чыккач, игеккә җибәгәм мин алагны...

– Мәче баласы белән булган вакыйганы да исеңә төшерик әле, – дип, Хәдичә бикә дә сүзгә кергән иде дә, Бану кулларын чәбәкли-чәбәкли:

– Зинһар, анаем-бикә, суалчаны да бик җиткән, – дип, аны ярты юлда туктатты.

– Минем барасы җирем бар, бигайбә, – дип, урыныннан кузгалды Бәхтияр, – сез сөйләшә торыгыз, кайтып җитсәм, үзем дә кушылырмын.

Бу алдан килешенеп куелган уен иде.

Билгеле инде, ана белән кызны барыннан да элек гаилә хәлләре күбрәк кызыксындыра. Шул хакта гәпләшеп алдылар. Аннан Хәдичә бикә үзенә тынгы бирмәүче өлкәгә кармак салды.

– Шәһвәтегез тәңгәл киләме соң? – дип сорады.

– Бергә-бер, – дип елмайды Бану.

– Шөкер, атаең-бәк тә, чәчләренә бәс кунса да, ким-хур түгел, кәнизәкләрен дә онытмый, – диде Хәдичә. – Кыр кәҗәсе сөтенең, тау үләннәре төнәтмәләренең файдасы зур.

– Ә мин Ярмәгемне беркем белән дә бүлешергә теләмим, – дип,

иреннәрен бүлтәйтте Бану. – Хәер, аның үзенә дә миннән башка кыз-хатын кирәкми, дип беләм.

– Аксөякләргә кәнизәкләр тоту – ата-бабадан килгән дәрәҗәле йола, кызым-бикә, юкка гына әүвәле – Алла, икенчесе – патша, өченчесе – ир, димәгәннәр, – диде Хәдичә-бикә. – Аңа карап, гаилә дә, ыру кануннары да бозылмый.

– Гореф-гадәтме, дәрәҗәме, миңа барыбер, анаем-бикә, бел, ачуым чыкса, чабам да өзәм.

Хәдичә кызының бу ордым-бәрдеменә игътибар итмәде, борын астыннан елмаеп, яшь вакытта барыбыз да шулай һавалы идек, тора-бара дөнья барысын да үз урынына утырта ул, күнәрсең әле, дип кенә үткәреп җибәрде. Чөнки төп сүз әле алда иде.

– Кызым-бикә, кияүгә чыкканыңа дүрт-биш ай узып китте инде, ә син һаман кәҗә бәтие кебек сикергәләп йөрисең, үзең әйтмешли, бел, чәчәкле гөл генә кадерле була. Кысыр хатын – ярлыксез бия ул. Ир хатынының төп вазифасы – бала табу.

Бану әлеге сүзләрне авырга алмады, киресенчә, елмаеп-көлеп, теземен яңгыратты:

Алты бала тапкан хатынны
Ханым дисәң, урыны бар;
Җиде бала тапкан хатынны
Җаным дисәң, урыны бар;
Тугыз бала тапкан хатынны
Тугзак дисәң, урыны бар...

Теземне ана-бикә дәвам итте:

Өендә бала уйнаса,
Оҗмах дигән урыны бар...

Ишек уемында Бәхтияр бәк күренде. Тирләгән-пешкән. Иң элек табынчыдан салкын кымыз китертте, аны голт-голт эчеп, үзенә бер ләззәт белән кикереп куйганнан соң гына:

– Тел очы татлы, төбе кортлы, ди, сүзегез ятышлымы? – дип сорады.

– Түгел ятыш, – диде Бану, куе керфекле соргылт күзләрен челт-челт йомгалап. – Анаем-бикә мине бала капчыгына әверелдермәкче. Ә минем падишаһым, кавемем хакын хаклап яшисем килә...

– Кызым-бикә, безнең дә бит оныкларыбызны сөясебез килә, – дип, Бәхтияр бәк кызының чәчләреннән сыйпап алды.

***

Ярмәк углан мәлик катыннан язгы кояш кебек балкып чыкты, йөзе нур белән тулышкан иде.

– Бану бикә, былбылым, падишаһыбыз минем үтенечемне хуп күрде, Аллаһы рәхмәте белән иртә таңнан чыгып китәбез, җыен, – дип, шатлыгын бүлеште.

Бану иренең хәрби уеннар үткәрү хыялы белән янып йөргәнен белә иде, әлбәттә. Шөкер, менә мәлик хәер-фатихасын да биргән.

– Рәхмәт, бик сөендердең, арысланым, – диде, – мин сине сагынып көтәрмен.

Ярмәк көрәктәй киң учын куе кара чәчләренә батырып, хатынына текәлде.

– Арысланыңны алай куркытырга ярамый инде, былбылым, ничек инде көтәрмен, без бергә ләбаса!

– Углан, мин бу юлы яугир көбәсе кимәскә булдым бит әле, – диде Бану ниндидер үзенә бер мәгънәле елмаю белән. – Сәргаскәр гозеремне кабул итәр, дип ышанам.

– Сәргаскәр, әлбәттә, кабул итәр, – диде Ярмәк. – Ә ирең – юк, кабул итмәс.

Ярмәк барыбер хәрби уеннарга үзе генә чыгып китте.

Әле кайчан гына бернинди гайбәтләрне дә колагына элмичә анасына береккән ялгыз каз бәбкәседәй хәләленнән тотам да калмыйча ияреп йөргән бикәгә ни булды икән соң? Әлеге сорау күпләрне аптырашта калдырды.

Сәбәбе бар иде, билгеле, бик җитди сәбәп. Аны әлегә ул фәкать үзе генә белә, якыннарына да вакытыннан элек таратырга ашыкмый.

Хәл болай. Беркөнне, гомер булмаганны, атына сикереп атланыйм дигәндә генә, башы әйләнеп китмәсенме? Өзәңге бавына тотынып кына егылмыйча калды. Әмма мизгел эчендә генә булып алган бу халәт аны борчымады, шундук онытылды да. Ләкин озакка түгел, көтмәгәндә күңеле болгана башлады. Үзе монысына да гоман тапты, томауга сылтады.

Шулай атна-ун көн вакыт узып китте, тормышы да, үз-үзен тотышы да элекке эзенә төште. Ат менеп тә чаба, кылычын да уйната, сәрпи укларын да очырта. Ярсып-дулкынланып кайталар да, яратышып, татлы йокыга талалар. Әлеге төн бигрәк тә ләззәтле булды, мәрткә киткәндәй оедылар гына. Ә төн уртасында Бану гаҗәеп бер талпынышта уянып китте: эчендә кемдер тибенеп алгандай булды.

Башта аңышмыйчарак торды, и, туймас җан, дип, ирен битәрләргә чамалаган иде дә, аның аркага-арка мыш-мыш йоклавын күреп, уйга калды. Һәм шунда: «Әллә балага узганмын инде», – дип, гаҗәпкә калды.

Бану кулын иренең җилкәсенә салды... Шулай да уятырга ашыкмады.

Тукта-тукта, каударланма, дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә тукталып калды, бәлки шулай тоелгандыр гына, әнә бит хәзер, бернәрсә сизелми. Көмәнле хатыннарның корсагы тау чаклы була, аның исә эче кыз чактагы кебек, элекке күлмәкләреннән йөри...

Ул сузган кулын кире үз ягына шуыштырды.

Икенче көнне караңгы төшкәч, кача-поса гына кендек әбисе янына барды, хәлне сөйләп бирде. Тегесе капшаштырды-капшаштырды да әйтте:

– Бикә, балага узгансың син, – диде, – эчеңә карама, көмән төрле хатынның төрлечә була.

– Ялгышмыйсыңмы?

– Мин синең йөрешеңнән үк йөкле икәнеңне белдем, – диде кендек әбисе.

– Рәхмәт, тынычландырдың, – диде Бану, бүләкләрен тапшырып. – Тик колагыңа киртлә, кортка, бу хакта ләм-мим. Вакыты җиткәч, хәбәрен үзем таратырмын.

– Аңладым бикә, авызым йозакта.

Бануның бу шатлыкны үзе генә кичерәсе, хатын-кыз бәхете хозурында

үзе генә ләззәтләнәсе килә иде булса кирәк. Бала бит ул адәмнең җимеше, нәсел-ыруның, кавемнең киләчәге, яшәүнең мәгънәсе. Бу дөньяда варис калдырмый китәсең икән, ахирәттә сиңа сан булмаячак.

Бану ире өйдә юкта, көннәрен далада үткәрде. Чөнки бәхете дә дала киңлекләренә тиң очсыз-кырыйсыз бәхет иде.

Тезгенне ияр кашына бәйләп куя да толпарын иреккә җибәрә.

Сөлек үзеннән ни көткәнне бик яхшы аңлый. Хуҗабикәсенең кулында кылычы юк, димәк, бу яу түгел, ыжгырып чабасы юк. Җайдакны биләүдәге баладай ипләп кенә, җайлап кына, юргалап кына алып бару сорала. Сөлек исә – юргалауның остасы. Бервакыт шулай, кем беләндер бәхәсләшеп, аның янбашына су тулы касә утыртты хуҗабикәсе. Шактый араны юргалап үзарга кирәк иде. Һәм ул касәдәге суның тамчысын да чайпалдырмый үтте әлеге араны.

Далада ялгыз җайдакның юлдашы – җыру. Нәрсә күрә, күңеленә нинәрсә килә, шуны көйгә сала. Бану исә борынгыдан килгән җыруларны үз итә. Әле дә күңеленә баласын югалткан ана дөя турындагы җыру килде.

«Әй, кара күзле ак балакаем! Мин, яраткан анаең, менә ничә көннәр инде сиңа эндәшә-эндәшә ялан далада каңгырап йөрим. Ә син, кара күзле ак балакаем, җавап бирмисең. Кичләрен текә яр өстеннән узганда, иртәләрен үзәнлекләрдә буталганда, артымнан ияреп килмәс инде, бүтән икәү, яфрак ашый алмабыз инде, аңа ак сөтемне имезә алмам инде, дип кайгырып өзгәләнә күңелем.

Кайларда соң син, кара күзле ак балакаем? Эндәш, тавыш бир! Имиемнән, тулышып җиткән имиемнән, сөт тама, ботларыма ага. Кайда син? Тавышыңны ишетмим! Имиемнән, тулышып җиткән имиемнән сөт тама. Ак сөт тама...»

Җыруның азагын һәркем үзенчә гөманлап тәгаенли. Бану исә аларны кавыштырып төгәлләргә ярата. Үзе ана булырга җыенган әһле җефет башкача уйлый ала димени?!

Анаем – дөя, кайттым мин менә,
Күрсәтте юлны ак бүре миңа.
Сагындым бик тә үзең вә сөтең...

Бану бикә Ярмәген дә, баласын юксынган ана дөя кебек үк бик сагынып, түземсезлек белән көтте. Ярмәк үзе дә чарасыз иде. Күрешүгә:

– Былбылым, моннан ары мин сине үземнән калдырмыйм, – дип, сөеклесен кочагына кертте.

Бану иплэп кенә аның кулын корсагына яткырды. Анда нидер берничә тапкыр талпынып куйды.

– Былбылым, әллә...

– Әйе, арысланым, нарасыең сиңа сәлам бирә. Ходай инде аңа җан иңдергән, хәзер миңа син түгел, ул хуҗа!

***

Бану көмәнен җиңел кичерде, әмма тулгагы шактый дәвамлы һәм авыр булды. Кендек әбисе, аксөякләр даирәсендә генә аралашучы Җәмәйкә кортка иде. Кушаматы – Аздакы күвәндәсе, ягъни усал.

Тулгак бик тә хикмәтле халәт, табышмакның табышмагы, җавабы тирәндә. Кемдер, әйтик, очкылык токтандай, бер талпынуда котыла. Кемгәдер өч-дүрт омтылыш зарур. Болар янында Җәмәкәй корткага мәшәкать юк дәрәҗәсендә, кулларын уйнаткалап тору да җитә.

Бану исә башка. Аны күрүгә, бу бикә интегәчәк әле, бичара, дип уйлап куйган иде. Ник дисәң, янбашы кыз вакытындагыча нәфис, аны җәю, ай-һай, җиңелләрдән булмас.

Менә шундыйларга усал булырга кирәк тә инде: кычкыр-бакыр, әмер бир һәм аны үтәт. Айныгач, алар сине бүләккә күмә.

Бануның иртән иртүк башланган тулгагы әле һаман тарткалаша. Йөрәге тамагына килеп утыра, тыны җитми, тәне манма су була...

– Уф, үләм бит, ярдәм ит, – дип, Бану өстендәге япмасын чуаландырып, идәнгә эшереп төшерде. – Ярдәм ит...

Җәмәкәйнең сусыл иреннәре бәлештәй бөреште.

– Түз, сиңа гына килмәгән, барыбыз да баланы җитмеш тамырыбызны өзеп таптык, – диде коры гына.

Бануның иреннәре күм-күк булды.

– Аллаһым, мәрхәмәт кыл, Аллаһым...

Чатыр эчендә, ниһаять, яңа туган нарасый авазы яңгырады. Булышчы хатыннар бер-берсенә карашып елмаештылар да вазифаларына керештеләр. Берсе баланы ак биләүгә биләп корыта башлады, икенчесе кашык очына гына тамызып, бал белән май китерде, өченчесе җылы су әзерләде...

– Бал белән авызлаганның теле татлы булыр, май белән авызлаганның теле йомшак булыр, – дип, Җәмәкәй баланың мәмрәп пешкән чиядәй кызгылт иреннәренә бал вә май якты.

– Кем? – дип сорады Бану хәлсез тавышын күтәрә төшеп. – Кызмы, малаймы?

– Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер, диләр далада, – диде Җәмәкәй күгәрчендәй гөр килеп (ул инде Аздакы күвәндәсе түгел иде). – Ирең-угланны кыз бала табып сөендердең.

– Аллага шөкер, кыз булган икән, – диде Бану, – рәхмәт үзеңә, әҗерең мул булыр, инде кендеген кис тә, канын далага тамыз. Ил ашасын, йөз яшәсен. Ә исеме Хөснеруй булыр.

Хөснеруй йомгактай тыгыз тәнле, чәтрәннәп торган бик тә хәрәкәтчән тере кыз иде.

– Карале, былбылым, тибкәләнүен генә күр, кызыбыз менә дигән яугир булыр, – дип, атасы Ярмәк углан да сөенечен уртаклашты.

– Анаена охшаган, – диде Бану, борынын чөеп. – Киләсесендә чын яугир – малай алып кайтып куандырырмын үзеңне.

– Бирсен Ходай!

Бану кырык көнгә кадәр кигән эт күлмәген салдырганчы кызын берәүгә дә тоттырмады. Кырыклама йоласын да үзе башкарып чыкты. Хөснеруйны Кыз күленең кырык кашык чиста вә пакь суы белән коендыргач кына имидәшләренең ярдәмен кабул итте. Янә дә Идел буе кабиләләренең күпчелегендә баланы ата-анасы тудыра, әби-бабасы үстерә. Бану бикәнекеләр дә ошбу гореф-гадәткә тугрылыклы, кызчыкны үзләренә алып тәрбия итүне хуп күрәләр.

Ярмәк, ниһаять, җиңел сулап куйды. Чөнки хәзер инде алар хәрби осталыкларын элеккечә бергәләп чарлаячак.

Әйе, гореф-гадәт тә бар, әби-бабайлар да ике куллап риза, тик Бану бикә генә, һич көтмәгәндә, барысын да хәйранга калдырып:

– Мин үз баламны үзем карыйм, – дип кырт кисте.

Бер уйлаганда, бу һич тә гайре мәгъруф хәл түгел. Яшь хатын өчен бала табу Мәрьям радыяллаһу ганһәгә төшкән илаһи кичерешләргә тиң гамәл ул. Мәрьям-Ана адым саен сагалап торучы кыенлыклар алдында җебеп төшмичә, гомерен улы Гайсәгә багышлаган бит әнә.

Бикә элекке шикелле күңеленә ни килсә, ни теләсә, шуны эшләп күнеккән үзсүзле иркә вә нәзберек мөслимә түгел иде инде. Хәзер табынга утырганда да, иң әүвәл башыннан, кызчыгым-бәләкәчемә зыян китермимме, дигән борчулы уй йөгереп уза.

Ул хәзер фәкать Ана, Ана дәрьясының ярсу дулкыны.

Ярмәк барыбер хәләленең бала күләгәсендә калуын теләми иде. Әле бүген дә:

– Төштән соң мәргәннәр бәйгесе була, әйдә, син останың-остасы бит, катнаш, – дип, салпы ягына салам кыстырып караган иде дә, Бану аны җитәкләп, бишек янына алып килде. Ипләп кенә, нарасыйның биләвен чиште. Тегесе ирекккә куанып, очарга талпынган кош баласыдай аяк-кулларын селкеткәләргә тотынды.

– Гү-гү-гү-ү... гү-гү-гү-ү...

– Атае, күр, кызың сине ничек сәламли, – дип, үзе дә баласы булып гүелдәде.

– Гү-гү-гү-ү...

Ана баласы, бәгырь төене турында көннәр буе сөйләргә әзер. Янә:

– Карале, атае, аның аякларына, күгәрчен томшыгы кебек алсу табаны нинди нәфис, бармаклары каурый-каурый... Без инде үстек, атаем, имине үзебез суырып алабыз...

Ул җайлап кына баласы өстенә иелде. Кыз, чыннан да, анасының изүен эләктереп алды да, нәни кулын эчкә шудырды.

– Гү-гү-гү-ү... гү-гү-гү-ү...

– Атае, иснәп кара әле бәләкәчеңне, аннан оҗмах җимешләре исе килә, иснә-иснә...

Ярмәкнең борынына ниндидер яңа сауган сөт исенә тартым әчкелтемрәк татлы ис килеп бәрелде.

– Җә, ничек, оҗмах җимеше исе киләме? – дип, иренә текәлеп бакты Бану.

– Минем әле, былбылым, оҗмахта булганым юк, – диде Ярмәк көлемсерәп, – бала исе сугыш исе, кан исе түгел инде, күңелне тынычландыра...

– Рәхмәт инде җылы сүзеңә, – диде Бану, керфек очлары белән генә елмаеп, – балага мәхәббәт анада туксан тугыз өлеш, атада бер өлеш, ди. Бала моны үзе дә сизә. Менә шул нисбәттән бер хикәят.

Ике килен-килендәшнең берсе гел ир бала, икенчесе гел кыз бала таба икән. Янә көмәнле булганнар. Аңлашыла инде, ир бала тапканы кыз көтә, кыз бала тапканы ул көтә. Ләкин теләкләре акланмый. Үзара килешеп,

Күкләрнең хатасын төзәтмәк иткән болар: яшертен генә балаларын алыштырганнар.

Шулай берничә ел вакыт узган. Беркөнне каенана йортына кунакка килгәч, киленнәрнең берсе икенчесенең кулындагы баласын кочаклап алып, сөйгән-сөйгән дә кире биргән.

Шуннан бу бала үзен асрап үстергән киленнән:

– Анаем, нигә теге түтәйнең кулы бик йомшак икән? – дип сораган, имеш.

– Мине анаем үстермәде шул, күрәсең, шуңарга аңа карата ярату тойгыларым да юк дәрәҗәсендә, – дип көрсенеп куйды Ярмәк. – Ә син, былбылым, тулы ирек, үзең ничек кирәк табасың, шулай яшә, кызыбызны үстер, миннән барысына да салават.

– Рәхмәт, арысланым, Ата хакы – Тәңре хакы, икенчесендә сиңа ир бала алып кайтырга сүз бирәм, – диде Бану, иренә сыенып. – Мин бик бәхетле хатын, бик бәхетле ана.

Хөснеруйга иптәшкә Хөснеҗамал туды, Хөснеҗамал артыннан Хөсникамал аваз салды. Бануның бик вәгъдәле буласы килә-килүен, тик малай, варис юк та юк. Им-том итүчеләргә дә, өшкерүчеләргә дә, күрәзәчеләргә дә күп бүләкләр бирде, алар кушуы буенча әллә нинди тәмсез-тәмсез төнәтмәләр дә эчте. Хәтта хәтсез ара ире бүрек киеп тә йоклап карады. Ләкин – файдасыз. Аптырагач-йөдәгәч, бикә зарын Ибраһим дамелла белән дә уртаклашып карады.

– Ошбу нисбәттән кыз-хатынның бер гаебе дә юк, – диде дамелла, – бала үзе дә, аның җенесе дә ир затына Аллаһы Тәгалә насыйп иткән орлыкка бәйле, бу хакта Коръәни Кәримдә бик ачык әйтелә. Шуңа күрә им-томчылар, күрәзәчеләр юлын таптаудан бер фәтвә дә юк, шәригатьчә яшәргә, догада булырга, гыйбадәт кылырга, саф-пакь күңелдән теләкләр теләргә кирәк. Аллаһы Тәгаләнең бер исеме әгъзам Әл-Муҗиибдыр, ягъни изге теләкләрне ишетүче. Әлеге гүзәл исемне даими кабатлаганнарның догалары Аллаһы Тәгалә тарафыннан һәрвакыт кабул кылыныр, ди. Шәт, синең теләкләрең дә кабул булыр.

***

Силки мәлик Биләр авылы янындагы кальганы үзе төзетте, һәм ул аны һәрвакыт күз уңында тота. Чөнки дошман бу кальганы үтеп керә-нитә калса, казнага, тәхет иясенә, даирәгә турыдан-туры зур куркыныч яный.

Кальга Җаушир елгасының сул як ярында, Биләрдән көньяк-көнбатыш юнәлештә, аннан 22 чакрым ераклыкта урнашкан. Урыны бик кулай. Бер якта Бакай урманы эченнән агып чыккан инеш өстендә борынга охшаш калкулык, икенче якта текә ярлы елга.

Корылмалар шушы табигый рельефка җайлаштырылган. Янә дә Бакай ягыннан дошманны берничә рәт чокыр һәм ташлы балчык өемнәре. Җаушир ягыннан биек коймалар тоткарлый.

Чебен дә очып керә алмастай кальга. Тик соңгы вакытта шушы чебен дә очып керә алмастай кальгага да дошман качкы-шымчылар җибәреп, борын тыга башлады.

Бану бикә дә үсмер туташ вакытында шушы мәрәкәгә дучар булган иде.

Гадәттәгечә, ул көнне дә дус-ишләре белән далада ат уйнатып,

мәргәнлектә, төрледән-төрле уеннарда көч сынаша торгач, кирәгеннән артык мавыгып китеп, Бануның шома колаклы аткы угы мәрә-тәмекне урап узып, черек агач төбенә барып кадалгач кына исләренә килделәр.

– Кыйшык ук – аткан белән тураймас, – диде Байморат уенбаш, – әнә иң төз атучыбызның да кулы калтырый башлады.

Кояш инде бәү-бәү бишегенә кереп яткан, төн үзенең карасу пәрдәсе белән әкрен-әкрен генә офыкны томанлап, тавыш-тынсыз гына далага җәелеп килә иде.

– Каңтаруны бушатыгыз!

Йөгереп барып, һәрберсе атларының тирен катыру өчен ияргә тарттырып бәйләнгән тезгенен чиште, тик атланырга өлгермәделәр. Чөнки үзәнлектә эңгер-меңгер караңгылыгына сыенып, мыштым-мыштым гына кальгага якынлашучы җайдак төркемен күреп алдылар.

– Шымчылар, – диде Байморат.

Яшьлек – беренче чиратта, тәвәккәллек. Хис-тойгы, гаярьлек өстенлек иткән ашкынулы чор.

Әле дә Бану бикәч:

– Безнең турыга килеп җитүгә, өсләренә ыргылабыз, – диде.

– Тоткавылларга хәбәр итәргә кирәк, – диде арадан берсе.

Ләкин бу тәкъдимне ишетергә дә теләмәделәр.

– Һөҗүм! Һөҗүм! Һөҗүм!

Шымчылар бу көтелмәгән хәлдән башта югалыбрак калдылар. Әмма озакка түгел. Ат өстендә әлле-мәлле генә коралланган терсәк буе үсмерләрне абайлап алгач, үзләре һөҗүмгә күчте. Әүвәл Байморат җиргә тәгәрәде, аннан соңге Бануның бот итен ертып узды...

Җәрәхәтләр болай гына төгәлләнмәгән дә булыр иде, шөкер, тәкъдим иясе иптәшләреннән аерылып, сак-тоткавыллар тарафына элдерткән иде.

Ә алар эшне коры тотты, шымчыларның юлын бик тиз бүлделәр. Өлгергәне качып котылды, өлгермәгәне әсир төште.

Байморат кына, бичара, гомерлеккә гарип калды. Бануның ярасы тиз төзәлде, тик барыбер эзе югалмады. Һәм бу аның мактанычы иде.

Кальгага исә, соңгы вакытта дошманнарны да уздырып, кар-бураннар, яңгыр-гарасатлар, йөгәнсез ташулар, җир тетрәүләр күбрәк зыян сала башлады. Быелгы ел бигрәк тә хәвефле булды. Яз бик иртә һәм искәрмәстән килде. Төн эчендә елгалар котырынып, күперләрне агызды, ярларны җимерде, балчык өемнәрен пыран-заран таратты. Хәзер шуларны торгызу белән мәшгульләр.

Мәлик монда еш була, бүген дә иртән иртүк килеп җиткән.

– Көзгә кадәр корылмаларны рәткә китереп бетермәсәгез, башыгыз җиргә тәгәрәр, – дип, янавын да җиткерде.

Сөякчел йөзле, нәзек иренле төзүмәннең йөнтәс кашлары маңгаена җыерылып менде дә чыраена чарасызлык кыяфәте биреп тукталып калды.

– Эшче куллар җитешми, – дип акланды ул. – Бер ай эчендә иллеләп колны югалттык...

– Ничек югалттык?

– Эш четерекле бит, падишаһ, бик авыр, күбесе суга батты, агач астында калучылар да хәтсез, чирләп үләләр...

– Болар эленке-салынкы эшләргә сәбәп түгел, – диде мәлик. – Инде Бакай якларын күрсәт.

Төзүмәннең кашлары янә маңгаена җыерылып менде.

– Падишаһ, анда ни... баткак... пычранырсың...

– Кияүгә бирәсе кыз түгел, борчылма, – дип бүлде аны мәлик. – Киттек.

Ташу тузгыткан агач-таш, чүп-чар белән тулышкан мәйданда, чыннан да, вак-вак күлдәвекләр, чоңгыллы чокыр-чакырлар шактый иде. Шулай да, җирнең кипшенгән урыннары да байтак, барыр җиреңә бара аласың.

Төзүмәннең каушап калуы бөтенләй бүтән сәбәптән булган икән.

– Ни-нәрсә бу? – дип, мәлик атының тезгенен тартты. – Нинди тамаша бу?

Тамаша дигәне, тышаулы коллар иде. Түбән Идел, Кавказ төбәкләрендә качмасыннар өчен колларны арканга тагып эшләтү бар-барын. Ә монда – тышау. Гомумән, Болгарда колларны, әсирләрне ябып тоту, бәйгә кую кулланылмый.

– Болар төнлә бер игенченең икмәкләрен талаганнар, – диде башлык. – Сарыкларын суеп ашаганнар...

– Дәүләт эшендәге колларны без үзебез киендерәбез, үзебез ашатабыз-эчертәбез, – дип тузынды мәлик. – Бу нинди галәмәт?

Аннан күзләре белән генә Ярмәк сәргаскәрне абайлап алды да:

– Сизеп торам, углан, төзүмән безне казык башына утыртмакчы, бар, чын хәлне белешеп кил, – диде.

– Падишаһым, гафу ит, гаебемне таныйм, зинһар, кояш белән ант итәм, – дип, төзүмән мәликнең аяк астына ауды.

– Башына капчык кигезегез дә өзегез, – дип, әмер бирде Силки сакчыларына. – Гәүдәсен – козгыннарга!

Ул арада Ярмәк тә урап килде.

– Төзүмән колларны үлем җәзасы белән куркытып, Хәррас игенчене талаткан, ә талаган малны үз биләмәсенә озаткан, – дип, аңлатма бирде.

– Ә тышау?

– Җинаять беленә-нитә калса, гаепне коллар өстенә аудару өчен булса кирәк. Үзеннән белешергә дип торам менә.

– Дошман дустан ярала ул, углан, – диде мәлик уфтангандай. – Ә дошманны юк итәләр, ул инде шул тарафта.

Силки кебек мул гәүдәле, купшак тәнле, табак битле дәшмеш инсаннар, гадәттә, юаш, йомшак күңелле, юмарт вә ярдәмчел була.

Ул да ордым-бәрдем түгел анысы, һәр гамәлен төбенә төшенеп, кырык иләк аша уздырып кына башкарырга тырыша. Шуның белән бергә, аеруча мөһим саналган карарларын хаким мизгел эчендә кабул итәргә һәм алар шул ук мизгелдә үтәлергә дә тиеш.

Хаким каты куллы булганда гына хаким.

Тик төзүмән белән булган мәрәкә ни өчендер аны борчуга салды. Җәза – хак, монысы көн кебек ачык, әмма дөрес булдымы ул, ашыкмадымы?

Силки шул хакта баш ватты. Даирә аны читтән генә тавышсыз-тынсыз күзәтеп торды.

Менә ул атының тезгенен тарттырып куйды. Бу даирәгә ым кагу иде. Алар аны уратып алды.

– Углан, – диде мәлик, Ярмәккә мөрәҗәгать итеп. – Вакытлыча башлык вазифасын башкаруны сиңа йөклим. Гомумән, кальганы сәргаскәр карамагына бирү урынлы булыр сыман. Анысын якын көннәрдә хәл итәрмен. Хәзер эшеңдә бул. Ә мин Хәррас игенче биләмәсенә юл тотам. Ә колларны тышаудан ычкындыр.

– Баш өсте, падишаһ.

Силки мәлик әлеге биләмәгә барып җиткәндә, игенчене чатыры янына китереп бастырганнар иде инде.

– Эшем муеннан, кунак кабул итәргә вакытым да, теләгем дә юк, – дип, аяк терәп каршы килеп караган иде дә, яугирләр кылыч селтәгәч, авызы йомылды.

Моңарчы ул беркемгә дә зыян салмыйча, күршеләре белән тату мөнәсәбәттә үз шөгылен белеп кенә, уйнап-шаярып кына гомер кичерә иде. Шөкер, эше әйбәт бара, һәр елны мул уңыш җыеп ала, үзенә дә, алыш-бирешкә дә җитә. Икенче ел инде кәҗә көтүе булдырды, табышлы булырга охшап тора, әлегә үкенгәне юк. Хәлбуки, кәҗә мал түгел, дип мыскыл итүчеләр дә юк түгел. Андыйларга: кәҗә биргән ат алыр, дип, шук кына елмая.

– Сөйләмә юкны, бирделәр, ди, бетле кәҗәгә ат? – диләр.

Ә аның җавабы әзер. Һәм иреннәрен чапылдата-чапылдата тәмләп сөйләп китә.

– Үзегез дә беләсез инде, минем Хуҗахәсән исемле шалкан баш танышым бар. Көннәрдән бер көнне килде дә бу:

– Мин сиңа ат бирәм, син бер кәҗәңне бир, – диде.

– Ярар, мәйтәм, миннән күр игелек, теләгәнең сайлап ал.

Ике-өч көннән янә аяк басты бу шалкан баш.

– Кәҗә атка тормый икән, өстәп ашлык та бир, – диде.

– Мә ал, дип, биштән төреп, кәҗә тоягы күрсәттем бу хәерсезгә. Ә ул минем өстән казыйга барган. Чакырттылар. Казыйга әйттем:

– Ачу китереп йөрмәсен ул шалкан баш, кәҗәмнең сөте болак, эче ылак, тиресе кап, мөгезе сап, шуларның барысын бергә җыйсаң, менә сиңа чыгар ат.

Казый, Алланың рәхмәте төшсен, гадел хөкем чыгарды.

– Синең бу мәрхәмәт иясе кеше өстендә бер хакың да юк, эч пошырып йөрмә, – дип, тегенең авызын каплады.

Силки мәлик тә сүзен ерактанрак суктырып, игенченең үз кимәлендә башлап җибәрде.

– Игенчеләр арасында, алты уникегә җитсә дә, утыз ике тештән артмый, дигән кинаяле әйтем йөри, синең үлчәмең ничек? – дип сорады.

Хәррас җил-яңгыр хак төсен җуйган каз куыгыдай кабарынкы иреннәрен бүлтәйтеп торды да, бар кыюлыгын җыеп, хакимнең гөманына гөман белән җавап бирде.

– Җир эшләгәнгә – бәхет, патшаларга тәхет бирә, дигән әйтем дә бар, – диде.

– Ягъни мәсәлән?

Силки мәлик кара халык белән күзгә-күз очрашып, гәпләшүдән йөз чөерми иде. Бу бөтен кешегә мәгълүм. Шуңа аны үз итәләр. Әмма

дә ләкин падишаһ падишаһ инде ул. Хакимгә тел тигезмә, башсыз калырсың, диләр бит. Силки мәлик әмере белән дә күп башлар очты һәм һаман оча тора. Шуңа күрә Хәррас әңгәмәне икенчерәк юнәлешкә борып җибәрде.

– Иген төбе кинәнгеч бит ул, мөхтәрәм падишаһ, – диде, кулындагы бүреген йомарлап, – безнең ыру – башы-аягы белән игенче, исемем Хәррас та «игенче» дигән мәгънәне аңлата. Атаебыз безне кол кебек эшләгез, хан кебек ашарсыз дип, боргычлап үстерде, Алланың рәхмәте яусын.

– Димәк, эшләгәнең ике тештән арта?

– Без бит мөселман өммәтеннән, Ходай ярдәменнән калдырмый, – диде Хәррас башын иеп. – Аллага шөкер, итәгебез бөтен, җиңебез киң.

– Дәүләткә өлеш чыгамы соң?

– Дәүләт белән дә алыш-бирешебез, шөкер, елдан-ел арта, тамгачы риза-бәхил, әҗере дә әйбәт.

Мәлик кальга башлыгы язмышына бәйле сәяхәт мәсләгеннән читкә тайпылуын үзе дә сизми калды. Хәррас игенченең үз эшенә мөкиббәнлеге, оясыннан еланны да чыгарырдай тапкыр вә тәмле теле аны шулай әсир иткән иде.

– Мин бодай белән тары игәм, – диде Хәррас, – казнага күбрәк тары сатам, Ага Базарда да аны кулга да тигезми себереп алалар...

Силки аны тыңламый иде инде. Аның игътибарын күк тарафындагы нindидер чыр-чулы әвеш-тәвеш җәлеп иткән иде. Чекерәебрәк карап бакса, күкәй күмәчедәй кабарынкы болытлар арасында язгы җырларын түгәлләгәннән соң, токым мәшәкатьләре белән мәшгуль тургайлар өер-өер булып берләшкәннәр дә бер козгынны эзәрлеклиләр. Күрәсең, козгын әле канат чыгарырга өлгермәгән тургай балаларына нәфесен сузган.

Тургайлар челлә зилзиләседәй чәр-чәр ябырылалар да бер генә мизгелгә болытлар эченә кереп югалып торалар. Һәм яңа көч җыеп, янә атылып чыгалар.

Козгын башта, үз көченә ышанып булса кирәк, бу бер калҗа кадәрле генә кошчыкларның ду килүенә канатларын бик исе китмичә генә җәйгәләсә дә, һөҗүм аңа чын-чынлап куркыныч тудыра башлады. Чөнки һөҗүмчеләр чукышырга ук тотындылар.

Козгын шыпан-шыпан гына таю ягын карады.

Тургайлар куанышып таралыштылар. Мәликкә дә төп сүзен башларга җай чыкты.

– Синең дошманнарың бармы? – дип, игенчене күз иләгеннән үткәрде.

Хәррас берара чуер таштай карасу шома маңгаен сыйпаштыргалап торды. Аннан: «И-и, хөрмәтле мәлик, дошман вә сугыш-орыш ул падишаһларда, кара халыкның дошманлашырга вакыты юк, аңарда дөнья мәшәкате», – дип әйтәсе килгән иде дә, тиз генә үз кулын үзе чеметеп алды.

– Юк минем дошманым, – диде.

– Дошманың булмагач, өч-дүрт көн элек кемнәр синең мөлкәтеңә кул сузды соң алайса, сөйлә әле, ничек булды бу?

Хәррасның йөзе сыгылган чүпрәктәй бөрешеп катты, кыяфәте җитди рәвешкә керде. Башыннан, каян белә икән, дигән уй йөгереп узды. Ник дисәң, кыямәт куптарудан файда юк дип, бу хакта беркемгә дә сөйләгәне

юк иде. Җир кешесенә хас булганча, күкрәгендә ут кайнаса да, борыныңнан төтен чыгарма, дигән кыйбла нигезендә яши иде ул.

– Үзем җәйләүдә идем, падишаһ, җиде төн уртасында өерләре белән килгәннәр дә сакларга куелган бөтен ашлыкны алып киткәннәр, – диде Хәррас теләмичәрәк кенә. – Алар артыннан тикшеренеп йөрергә минем чамам да, вакытым да юк, тамакларына таш булып утырсын.

– Мин бүген синең мөлкәтеңә кул сузган адәм актыгының башын кистердем, – диде мәлик, – һәм бик дөрес эшләгәнмен. Синең яныңа шул гамәлемнең хаклыгын ачыкларга гына килгән идем. Күзләремне ачтың, рәхмәт.

– Мин сиңа һәрвакыт догада булырмын, падишаһ!

*Тарихи белешмә:*

*Игенчелек – Болгар икътисадының иң алга киткән тармакларыннан берсе.*

*X гасыр башында ук гарәп сәяхәтчесе Ибне Рус түбәндәгеләрне язып калдырган: «Болгарлар – игенчелек белән көн күрүче халык һәм һәртөрле иген ашлыгы үстерәләр, әйтик, бодай, арпа, тары вә башкасы».*

*Болгарларның игенчелек продуктлары һәм, гомумән, ничек туклanулары хакында шуңа охшаш сүзләрне аз гына соңрак Ибн Фадлан да әйткән: «Аларның ризыгы – тары белән ат ите, һәм аларда бодай белән арпа да бик күп, һәм ни чәчкән, аны үзе өчен җыеп ала».*

*Мәгълүм фарсы географы Әл-Гардизи бодай белән арпага ясмыкны һәм шулай ук кайбер бакча үсемлекләрен, мәсәлән, кабак һәм ногыт борчагын өстәгән.*

*Идел Болгары үз тамагын гына кайгыртмаган, күрше-тирә халыкларын да, бигрәк тә рус халыкларын ашлык белән бик теләп тәэмин иткән. Мәсәлән, Болгар әмире ачлык вакытында Төньяк-Көнчыгыш Рус кенәзлегенә Идел буйлап 30 зур көймәгә төялгән бодай бүләк итеп җибәргән.*

*Байтак елъязмаларда X гасыр азагында Суздаль җирләрендә зур ачлык булуы турында язалар. Бу очракта да руслар болгарларга баш ияләр, шул рәвешле ач үлемнән котылып калалар.*

*Болгарда ашлык җитәрлек булган.*

*(Ахыры киләсе санда.)*



Флёра Гыйззәтуллина

# КҮРШЕ ХАКЫ – ТӘҢРЕ ХАКЫ

ШИГЪРИ ДАСТАН

I

## Уфа юллары пыяла

*Уфа – Казан арасы,*
*Күзләремнең карасы!*
*Юлга чыксам, юл күрсәтеп*
*Сайрый былбыл баласы шул,*
*Сайрый былбыл баласы.*

Таркалмый дуслык-туганлык,
Иреге җырда туса.
Уртак җырыбыз исәнме?
Исәнме-саумы, Уфа!
Иман, җыр, шәфкать, нур өчен
Иркенме синдә колач?
Ирек тә, җыр да, Иман да –
Алладан иңгән мирас!
Туа-тумыштан без шушы
Мираска табынабыз.
Кан булып агылабыз да
Җыр булып кабынабыз,
Һәм чорның бөтен афәтен
Сөзәбез йөрәк аша.
Ә ирек һаман да бездән
Чигенә, ераклаша.
Юк.
Сыймый безнең җырыбыз
Ераклык кысасына...
Иманда, җырда яңарып
Киләбез сиңа, Уфа!
Назлап, кушучлап бирәбез
Йөрәкнең сөю утын.
Без сикереп суга төшкәндә,
Утларга пешкән токым!
Ник кирәк сөю? –
Янмасаң
Нур алып затлы дустан.
...Күкләрдә Алла – баш өсте!
Күршедә – Башкортстан!
Күршедә – Башкортстан!

* * *

Калдырсаң Алла хакларын
Гомернең азагына,
Әверелә бөтен ил-йортың
Хыянәт базарына.
Әмма мин ышанам –
безнең
Җырга хыянәт итмәс.

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (1931) – *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова, Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Айбикә, «Сөембикә» һәм
Тулган ай безгә сердәш.
...Тумышы
«Сөембикә»нең
Патшалар дәвереннән...
Ул,
    гасыр михнәтен кичеп,
Журналга әверелгән.
«Иңсен» дип бәхет яктысы
Уфаның дан юлына...
«Сөембикә»без
                ак сөлге
Салган юл сандыгына.
Милләтнең аен-кояшын
Чиккән ак калфагына,
Ышанып
            изге исемен
Иманда сакларына.
...Сөю-сәгадәт туена
Чакыра сезне дә ул...
Чорга эчкерсез сердәш тә,
Тапланмас көзге дә ул!

***

...Үкертеп татар-башкортны
Сагышлар кыйнаганда,
Хәтта ки гомерлек дуска
Эч серләр сыймаганда,
Үзенең милли ирегeн
Җуйганда Татарстан,
Бактык без шушы көзгегә
Юраулар атап юштан.

Инандык уртак сөюнең
Туйларын түргә алып...
Үз түре булмаган халык
Тилмерә гүрсез калып,
Әйталмый ана телендә
Сүзен ул вәкарь белән…
...Гүрсезне читләтеп,
                татар
Түрсезне мактар, димәм.
Ил-көнле, түрле халыкта
Иман өмете көйри.
Илеңнән иманың качса,
Илбашчың гүрдән йөри.
Бүгенге тормыш безне дә
Гүр хөкеменә сөрә:
Ал яктан өрәк үкерә,
Ян-яктан этләр өрә.
Өрәге өркер дә – кусаң...
Эткә син тибеп кара!
Эт тә бит тарих каршына:
– Мин сезнеке! – дип бара.
Тарихи этлектән килә
Безнең өзелгән үзәк!..
...Без сезгә язлар озатып
Калабыз куллар изәп.
Яшәсен шушы сөюдә
    Ихласлык – моңлы аһәң!
    И Уфа! Иркен түреңдә
    Югары торсын бәһаң!
    Дус-дошман газиз халкыңа
    Якмасын нахак яла...
    Ул яла адәм баласын
    Мәңгелек утка сала.

II

## Уралга тартыла күңел

*Чатыр тау – Кояш кыясы!*
*Уралда таңнар оясы! –*
*Безнең соң*
*            шушы түгелме*
*Милли татулык кыйбласы?*

...Урал ул – таулар алласы,
Тауларын тезә сафларга.
Иншалла, таулар каргышы
Ишелмәс безнең башларга.
Иншалла, юллар өзелмәс
Казанга Башкортстаннан...
Зур таулар гомер-гомергә
Бер-берсен яктыртышканнар.
Бөеклек, шоңкарлык хисен
Дус халык алган Уралдан.
Уй-гаме татар-башкортның
Бер йомгак булып уралган.
Татарның җанын шом басса,
Башкорт та керфек какмаган.
Батырша узган юлларны
Салават батыр саклаган.
Исбатлап ялган тарихка
Сөемнең төен икәнен
Бәетен көйләгән Урал
Ханбикә-Сөембикәнең.
Яудашлар, безнең таудашлар
Сөемгә урын тапканнар.

Тауларга вышка утыртып,
Җаннарын зырылдатканнар.
Җанны шик-шөһбә төртмәсә,
Арага кермәсә ялган,
Сөю һәм яшәү өмете
Саркылган кәрәзле балдан.

***

Каләмне кояшка манып,
Алсу таңнардан нур алып,
Дәртләнеп дәртле Казанда
Матур шигырьләр язганда,
Без дә бит чиксез гайрәтне
Татыдык башкорт балыннан...

Туган-тумача алдында
Кадерләп-зурлап әйтәсе
Рәхмәтләр телгә ягылган.
Һәм дә ки тешләнгән телләр
Какшавын тоеп девонның,
Чайпала эчәр суларда
Шомлы зәһәре фенолның!

***

...Әйе, агу да, бал да бар
Дәвернең кара моңында.
Кысрыклый безне күрәчәк
Үкенеч аралыгында.
Ә халык, бердәм кан елап,
Коча да куша моңнарны.
Алганда утлы упкыннан
Кайгылы эшелоннарны.
Тиеш без мондый кайгыны
Бары бергәләп татырга –
Таңнар атмаса Уралда
Кояш калыкмый Чатырга.

**III**

## Моң – безнең борынгы тамга!

*Аттай эшләп күпме гомер үткән,*
*Солы беткән язмыш улагында...*
*...Үзем йөрим Идел буйларында,*
*Ат яллары тузгый уйларымда.*

...Кояш та, таң да янәшә!
Үзгә соң безнең кай яклар?
Ник төшкә кереп җәфалый
Ялгыз һәм башсыз җайдаклар?
Дәвер ни җавап хәзерли
Аларның хатыннарына? –
Мин шушы хакта сорарга
Киләм Тау батырларына.
Тоям мин язмыш атының
Күкрәктә тояк какканын...
...Атларны җиктем, –
атландым,
Тик җирдә тынгы тапмадым.
Тоймадым ир-ат хакының
Зурлыгын тулаем көйгә...
Булса да ирем,
мин аны
Юксынып утырдым өйдә.
Шушы тарихи юксыну
Үрчеде менә ил тулып...
Бу тойгылардан, мөгаен,
Булмас та инде котылып.
Кабаттан атлы яу кубып
Кирәксә «Чатыр чабарга»
Җитмәс тә канатлы атлар
Бүгенге Батыршаларга.
Чөнки ир-атка каныгу –
Тәкъдирдә – борынгы ырым!..
Татар да, ат та кичерде
Суелу, кырылу чорын.
Даладан ирек откандa
Башкорт та коенды канда...
Ут – безнең бүгенге сулыш!
Моң – безнең борынгы тамга!

***

Йоланңнан, тамгаңнан танмау –
Халыкта уртак имандыр...
Шуңа да безнең күкрәккә
Җигүле атлар сыйгандыр.
Җаныбыз даулыйдыр ирек,
Ычкынып утлы кысадан...
Әнә ич ялкын яллары
Ат ялларына охшаган!
Башсыз җайдакка охшаган
Безнең бүгенге өметләр...
Бер ялгыз өйдә утырсаң,
Мондый өметне кем ипләр?
Кем ялгар
шәфәкътан иңгән
Үрелеп буй җитмәс араны?
Кая заманның чын ире?..
Кая ял тарар тарагы?..

***

...Гасырны корбан итсәк тә,
Ил белән зарыгып көтсәк тә,
Бәхетләр күктән төшмәде,
Муенга башлар үсмәде,
Юк. Табылмады тараклар...
Дөньяны отмакчы булып,
Тотмакчы булып пар атлар, –
Йөрәккә үрли караклар:
– Тәңредән илчеләр без! – дип
Алдыйлар алар халыкны.
Каравыл кычкыра алмый,
Халык таланып карлыкты.
Чарасыз калган халыкта
Ташыды ачу, үч, мәкер...
Ак аргамаклардай кешнәп
Йокыдан уята хәтер.
Агымы Урал-Чатырның
Араны якынлаштыра.
Салават торган ак ярга
Китереп безне бастыра.
Җай чыга шунда хыялга
Очарга канат очында.
Тезләнеп сәҗдәгә китә –
Ихласлык янә шушында.
Шушында сарыла кайтып
Аһ-зарлы богау чыңнары.
...Таш ватып, ломнар сынса да,
Рухы Уралның сынмады.
Батыры катор китсә дә,
Тынмады җырдан курайлар.
Тирәннән, язмыш төбеннән
Эндәшә безгә Юлайлар,
Һәм шулчак тере шаһиттай
Ай калка Казан күгенә...
Яклауга мохтаҗ күңелне,
Батырлык тарта үзенә.

IV

## Тауларга сәфәр

*...Уралга узар юл сорасаң,*
*Күршеләр безгә юл ачарлар...*
*Тик чорга нинди моң ташырлар*
*Шәфәкъка авышкан гасырлар!*

Азнакай тавы – Чатыр тау!
Уралдан соңгы дулкын.
Күкрәктә күтәреп йөрттем
Мин шул дулкыннар холкын.
Чатырда яздым җырымның
Уралга юралганын.
Чит-ятның аяк астына
Юк төшеп уралганым.
Тау рухы тотты гел мине
Биектә, югарыда...
Кайттым мин
туган ягымны
Җыр белән сугарырга.
Чакырып кайтарды мине
Балачак хатирәсе:
Чал гасыр ятимәсе мин,
Хатирә хакимәсе.
Мин сабыр
Әсәй халкының
Сагышы, йөз сарысы!
Сагыш – күл!
Ләкин бездәге
Күлләрнең юк камышы.
Сагыштан булса арынып,
Язмыштан булса узып,
Әверелер идем Ургылга,
Камышлар булып сызып.
Юнәлер идем максатка
Фәкать җыр кайтыр очтан.
Үзәктә – Әсәй!
Әсәйдән
Башлана Татарстан!
Әсәйдә, Азнакайларда
Туа төп Батыршалар...
Сула җыр, Илнең батырын
Чоңгылга батырсалар.
Сула җыр, шагыйрь өметен
Туган як какса кире...
Йога да, аяктан ега
Безне кирелек чире.
Тарихтан, киредән килеп
Яулар ябырыла тауга.
Һәр таңга яңый һәлакәт,
Һәр җанда тавыш-гауга!
Суыра җанын халыкның
Күрәчәк – күчмә базар...
Язмышка безнең ни язар
Бүгенге сатып азар?
Ни сайрар ятим күңелнең
Чатырга кунар кошы?

Төзи дә ата йөрәккә
Замана сунарчысы!
Халыкка хәрам фал сөйләп
Вәхшиләр бара алдан:
Йөз сукыр күзгә – бер күзлек,
Бер сүздә – йөзләп ялган!
Ялганын тоттырмаганга,
Базарын сүтмәгәнгә,
– Аздырма безне!
Пошёл! – дип,
Артына типмәгәнгә,
Килмешәк жирле халыкны:
– Сөрхәнтәй! – диеп сүгә.
Мәхәббәт, хәер сорашып,
Сәрхушнең учын үбә.
Шул учта калып йомыла
Хәнҗәрдәй үткер хәтер...
Хәтере йомшак дошманның
Күкрәге тулы мәкер!

* * *

Әнә шул мәкер йотты бит
Безнең дә балачакны...
Без шунда телсез-авызсыз
Күмелеп калачакмы?
Бу язмыш татар-башкортны
Алмасмы түргә дәшеп?
Илсезне, түрсезне, әнә,
Җил йөри читкә чәчеп.
Без көткән рәхәт вакытны
Кинәт җимереп-ватып,
Болганчык тарихы белән
Калган чор шунда катып.

* * *

Юктыр ул катканаклыкта
Бер юньле җан иясе.
Кая карама – сукырлар,
Чукраклар армиясе!
Шулар җитәкли
Рәсәйне
Утка йә канга манып...
...Чукракка тансык икән шул
Тавышсыз-тынсыз тәмуг!
Гамьсезлек, коллык, эшсезлек –
«Сукыр»га җиде җәннәт!
– Кит! – дип йөзеңә төкерер, –
Кара син аны җәлләп!
Көчләп тагылыр ул сиңа,
Иясез сунар сыман,
Әләкләп суйдырыр өчен
Пычаксыз сунарчыдан.
Данында дәрья гизәр дә
Чыланмый чыгар судан.
Эзендә кайнар кара кан,
Күзендә кара томан!

***

...Ләкин мин күрсәм дә илдә
Язмышым яшеннәрен,
Оялып күрәчәгемнән,
Күзләрем яшермәмен.
Күршедән узып
чит-ятка
Сөйләмәм йөрәк зарым...
Шигырьгә салам кайгымның
Йөрәккә төйнәп барын...
Булмагач чарам тарихның
Мәкерен ачыкларга,
Аккошлар булып очып мин
Әвереләм Сак-Сокларга.
Илдәге аккош чагымны,
Ярымны ятратканга,
Һәрвакыт канат очларым
Манчыла кара канга.
Язмышка якыннан карап
Ерактан күрәм үзем
Канатлы кошка каныгып
Шуышкан елан күзен.
Кояшым кереп баеса
Шул күзләр карасына,
Мин озак адашып йөрим
Ике тау арасында.
Юлыгам кара тауларга,
Кап-кара аккошларга...
Туган як моңы коткара
Әҗәлдә тартышканда.
Мең әҗәл кичкән дәверне
Назына төрсә Казан...
Иделгә Агыйделләрдән
Агыла Айлы Азан.
Уяна татар-башкортта
Тарихи тирән ваем...
– Әү! – дия башкорт әсәе,
Мин: «Әсәй!» – дигән саен.
Әсәйләр
изге ниятtә
Балага чишә телен...
...Анда соң...
читтәге кебек,
Кем теләр миңа үлем?!
Кем безнең башкорт шивәсен
Камчылап оныттырыр?
...Онытмас...
Минем якташлар
Тауларым кебек горур!

V

## Уралга йөз куям

*Күзләремдә чор сөрмәсе,*
*Бармагымда көмеш балдак.*
*Балдак моңы туганнарның*
*Иминлеген тора барлап.*

Күзем караларын,
Йөрәк яраларын
Гомер өлгем итеп
Чигәм шәлләремә.
Шәлем бөркәнәм дә
Күрәзәлек итәм
Дөнья хәлләренә.
Мөэмин-мөселманның
Аттырасы таңын
Сызылдырам якты
Аек уйларымда.
Илгә күзем төбәп
Мин яшисе төбәк –
Идел буйларында.
Идел буйларында!
Мин кичергән хисләр,
Мин күрәсе төшләр
Сибәр юлыгызга
Ләйсән тамчыларын...
Тамчыга күз уям!
Уралга йөз куям:
Тоям Салаватның
Йөрәк ярсуларын.
Адым саен ярсып,
Уфа урамының
Якты ак ташына
Басам мин үзем дә.
Гамен түкми-чәчми
Татар рухы яши
Ак ташлардан койган
Уфа нигезендә!

Күпме нужа сөргән
Парлы толым үргән
Татар, башкорт
бердәм
Нигез куша-куша!
Ямьле якты көнгә
Тарту көче синдә.
Шундый көчле Уфа!
Шундый көчле Уфа!
– Ирек!
– Азатлык! – дип,
Өзгәләнүләрең –
Мәхәббәткә чиккән
Гөл сабагы төсле!
Ялгыш утап атмыйк,
Кыраулардан саклыйк
Бердәй тойгы-хисне.
Безнең кыз-киленнәр
Әрнешмәсен берүк,
Кайнар күз яшьләрен
Ләйсәннәргә түгеп.
Хыянәткә кереп
Сызылмасын эреп
Парлы көмеш йөзек!
Кода-кодагыйның
Картаймасын җаны,
Яралмасын яңа
Йөрәк яралары!
Ай-кояшка хас бит,
Күз өстендә каш бит –
Бүген Уфа белән
Казан аралары.

VI

## Саҗидә Уралдан иде

*...Сагышы ярдан чайпалса*
*Ярлыкар тәкъдир үзе...*
*«Туган яр!» – ди дә мөлдери,*
*Шагыйрь ул – дәрья күзе!*

Саҗидә Уралдан иде,
Моңга уралган иде.
Берүзе ничә әҗәлгә
Каршы торалган иде.

Мин йөрәк сердәше идем
Саҗидә Сөләйманның.
Зиратлар гизеп узышлый
Күз-яшькә чыланганмын.

...Күрәсең, уртак кайгыда
Көйгәнгә, сусаганга
Урсалда яшьнәгән яшен
Күренә Уфаларда.
Чатныйдыр шушы яшеннәр
Тарихның ут-көлендә...
Истә бит тарих дәресе:
Сулкылдый чорлар әрнеше
Урал тау төпкелендә.
Уралга сәфәр сугарсаң:
«Уф!» – диеп авыр суласаң
Чайкалып куя Чатыр...
Шушы сулыштан ваз кичсәм,
Җырыммы Чатырга кайтыр?
Уралмы чәчәк атыр?..
Уралмы калкыр хәтердә,
Узар юлымны ямьләп?
…Шул Саҗидәле еллардан
Шигърият җәннәте булып
Әверелде, әйе, Әлмәт!
Әлмәткә Уфадан инде
Чакыру авазлары:
Моң бөдрәләре – болытта,
Гудокта – «КамАЗ»лары!
Уралны, Чатырны
бердәм
Төреп моң җылысында
Әлмәтле, җәннәтле булды
Гамиле, Нуры шунда...
Шул моңга килеп кушылды
Фәридә,
Фидан,
Айдар...
Чатырда сайраган былбыл
Уралда томшык кайрар.
Уралны җырлап акшарлар
Уфаның Диләрәсе...
Уртак талантлар күп безнең
Дан булып тибрәләсе.
Дуслар да, очар кошлар да
Уртак бит безнең, уртак!
Шигырьдә мондый язмышны
Язудан булмый туктап.
Тумыш һәм тормыш иреген
Юк, булмый сызып ташлап.
...Мин күргән иҗат көрәшен
Саҗидә йөрде башлап.
Бүген дә хисләремдә
ул
«Башлык»ка әйләнә дә...
Язмышым аккошы булып
Уралда гәүдәләнә.

***

...Мин шушы аккош сөюен
Әлмәттә татыганга,
Инанып мондый сөюгә
Һәркемнең хакы барга
Уфага килешли менә
Кагылдым тагын шунда...
Сак-Соклар үксүе чыңлый
Сагыну-сагышымда!
Үксетеп ычкына кулдан
Шигърият штурвалым,
Ишетәм колак төбемдә
Өрәкләр кычкырганын,
Һәм мине янәдән явыз
Ятимлек ялмап ала.
Эзлим бәхетне
далага
Калалар сала-сала.
Кая: «Мин – ана! Шагыйрь!» – дип
Яклану уе монда!
Калалар салган ир башы
Борыла муенымда.
Шомлана таулар-дулкыннар
Борынгы җәбер-үчтән...
Кайчандыр монда кош-кошка,
Тау-тауга бәрелешкән.
Тауга – тау, кылычка – кылыч
Күтәргән ата-баба
...Ил буйлап буын-буынга
Төзәлмәс хата бага.
Хатадан кисәтеп безне
Каф таулар сала сөрән:
Гөнаһсыз канда коена
Гәрчә гөл, гәрчә чирәм!!! –
– Үтер!.. Ат!.. Утка як!.. – дигән
...Аттылар татар егетен
Чеченга атмаганга.
Иваннар татар-башкортка
Яктылар яңа яла.
Ялага ялгана алмый
Тауларда үскән бала.
Сөюсез, назсыз эреми
Хәтернең ястык бозы! –
Шулай дип, әнә, татарча
Моңая башкорт кызы.
Яшьлекнең бөтен сафлыгы
Шул кыздан саркып тора.
Юл сорар булсаң аңардан,
Уралга калкып сора!
Сызлансаң, сора Ходайдан
Саҗидә түземлеген.

Юклыгы анын шундый нык
Сиздерә үзен бүген.

* * *

...Хисендә җәннәт тудырып
Әлмәттә яшәсә дә,
Йомарлап күкрәк катуын
Әҗәлдә яшнәсә дә,
Исбатлап һәрбер шигырьдә
Уралда туганлыгын...
Иҗатта төптән җигелеп
Тартты ул Урал моңын.
Юнәлде шигырь аша гел
Агыйдел ярларына
– Са-җи-дә-ә! – диеп эндәшәм
Таяныр талларыма.
Саҗидә күзләве белән
Күзлимен Уфа ярын.
Ышанам, шушы тугрылык
Гүрләрен кочар аның.
Һәм без дә балкып янарбыз
Жирнең күз карасында.
Булмабыз ямьсез халык без
Дус-дошман арасында.

**VII**

## Канатлар агартканда

*Булмасам да, Уфа, фаллар ачып,*
*Бәхет юрар «изгең»,*
*Канат яктысында төймә тездем –*
*Чәчелмәсен сиздем.*

...Мондый агарту чарасын
Агыйделдәнме аласың?
И Уфа, аклы кала син,
Канатлы, затлы кала син!
Карларың шулкадәр якты –
Яп-якты күрер күз алды...
Әйтерсең, ялап алган кыш
Юлга сарылган тузанны.
Ярдагы карлы кыяда
Пар кош утыра оядa
Юлларың, Уфа, пыяла,
Таң нурларына буяла..
Урамда йөргән халыкның
Юк сыман тамчы кайгысы
Чат саен балкып утыра
Манараларның айлысы.
Ак яулык чөйгән әбиләр
Намазда, хәер-догада.
Хәерсез, ямьсез көннәрнең
Барлыгы килми уйга да.
Ургый тик соклану хисе
Йөрәктә – шигъри учакта...
Ничәмә-ничә шагыйрьнең
Иманы синең кочакта?!
Мин синдә кунакта, Уфа! –
Иман шартлары тутырам.
Учаклар уйда йөзгәндә
Суларга сусап утырам.
Хәтерлим түреннән иңгән
Күпкырлы талантларыңны
Рухи очышка чакырып,
Канатлар таратканыңны.
Хәтерлим Казан ягына
Аккошлар очырганыңны,
Безнең яшь Сөембикәнең
Җырына кушылганыңны.
Ул көннәр мәңге-мәңге дә
Онытырлык түгелдер инде?!
Давылда сынмас, сыгылмас –
Канатлар безнең көр инде!
Канатлар җиледер инде
Иркәли яңакларымны.
Мин дә бит шигъри җирлектә
Агарттым канатларымны.
Алкышлап миңа да яуды
Халкыңның изге теләге.
И Уфа, аклыгың
җанны
Изгелек белән биләде.
Уелып безнең хәтердә,
Яшә гел шушы килеш син!
Татарстан сәламе сезгә
Матур җыр булып ирешсен!
Куәтләп ирек көрәшен,
Сөюдә дөрләсен күңел...
Агарып канатка иңү –
Халыкка зыянга түгел...
Тойгыдан тауларга күчү –
Туздыру түгел йортыңны...
Канатлар безнең
ничә ел
Талпынмый торып кыркылды.

Дуслыкта ихласлык юктан
Тайпылдык, сибелдек читкә...
...Бергәләп җыймасак көчне,
Кем куяр читләргә киртә?
Кот качты илдән,
                    ил гаме
Томанда томаланганга...
Кайтсыннар!!! –
Салыгыз хәбәр
Хәбәрсез югалганнарга.
Талантсыз, канатсызларга
Бирегез янә дә канат!
Олыгая, чыныга кеше,
Канатлар, каурыйлар санап.
Шул сан, сугылып маңгайга,
Хыялны безнең уята,
Таңны ал нурга буята,
Илгә ак бәхет юрата.

VIII

## Очабыз сиңа, Уфа!

*Яна ай туган көннәрдә*
*Шатлыгын котлап Уфаның,*
*Мин айлы азан моңнарын*
*Йөрәккә каплап очамын.*

Моң тулы шигъри күңелдә
Гөлләр чайкалып куйса,
Очабыз сиңа, Уфа, без,
Гасырлар коча-коча.
Очабыз тормышның шушы
Авыр минутларында.
Мәхәббәт утларында да,
Һава флотларында.
Очабыз көчле күкрәүләр,
Яшеннәр тарафыннан...
Сак-Сок сурәтенә кергән
Аккошлар арасыннан.
Очабыз...
          ишетеп сезнең
Чакыру авазларын.
Тик язмыш безне тоткарлый,
Дулатып кинәт ут камый
Уфасын... КамАЗларын...
Казанын, Мәскәү, Самарын
Ут сүндерергә әйдәп:
– Яна бит! Яна, Уфа! – дип,
Утларга ыргый Әлмәт.
Чыдамын сынап, сындырып
Тугандаш халыкларның,
Йөрәге шартлап ярыла
Илкүләм заводларның.
Убыла, ярыла таулар! –
Мең әрнеш аша күрәм.
...Тау халкы китә тауларга,
Җиңелми, төшеп түбән.
Төшмибез, очабыз без дә
Җиңүне алга сөреп.
Кайгыдан йөрәк сызганга,
Кыза җир дары кебек.
Юлбасар дошманда әнә,
Яманлык уты – убыр!
Шырпысы сызылган саен
Убасы кубып торыр.
Тырышыр безне «Убырлы»
Язмыштан уздырмаска,
Котып салкыны өрдереп
Җаннарны туңдыргач та...
Сугышыр өчен
                    кан дошман
Тудырыр яңа ваем...
Һич юкта яллар кәрләсен,
Маэмаен, алабаен.
Өстеңә гүрдән чыгарып,
өстерер өрәкләрен.
Ярылсын өчен куркудан
Кайгылы йөрәккәең.

* * *


Курыкмыйм бүген һичкемнән,
Ишетсен якын-тирәм!..
...Очабыз сиңа, Уфа, без,
Ярату, сөю хакында
Дөньяга салып сөрән,
Очабыз карап туп-туры
Гөлфия[1] үзәненә...
Ил кайгылары аның да
Үткәндер үзәгенә.
Сизгәндер йөрәге аша
Ул да моң өермәсен,

[1] Гөлфия Юнысова – 1978–1999 елларда «Башкортостан кызы» журналының баш мөхәррире булып эшләгән башкорт шагыйрәсе.

Каныгып аңа жиде ят
Күз генә тидермәсен.
Ят күздән сакласын илне
Илһамият киртәсе.
...Гөлфия – шигырь бикәсе –
Уфаның җан иркәсе.
Бүгенге тормыш сурәтен
Шигырьгә чигә-чигә,
Уфадан Казан юлына,
Әнә, ул гөлләр сибә.
Сөмбелләр, гөлләр телендә
Сәнгатен сүзнең коя.
Йорт-илле иркен күңелгә
Гөл тугайлары сыя.
Чишелә дуслык телебез,
Гөл белән араланып,
Без сузган эзләр Уфада,
Юк, калмас кара янып...
Чарланыр олы дуслыкта,
Белем дә, безнең көч тә.
Мәгърур Уралдан калкынып
Чыгарга язсын өскә.
Уртак моң, уртак кыйбладан
Ачылсын иркен дала.
Тау батыр дала батырын
Илгә күтәреп ала.
Гашыйклар белән тиңләшеп
Оча тау бөркетләре...
...Бу җирдә татар-башкортны
Кем генә өркетмәде?!

***

Мәхшәргә охшаш мохиттә
Кошның ни чарасы бар?
Аклыгын җуйган һәр илдә
Табыла «карачы»лар.
Үч итеп илне болгаткан
«Карачы» ялчысына
Эләм мәкерен тарихның
Салават камчысына.
Олылап иям башымны
Гөлләр ияләренә...
Тармасын кан-яшьле халык
Йөрәк өянәгенә!..
Йөз кат урасын ак өмет
Җир шарын Уфа аша.
...Яшәрбез, шушы йолабыз
Яшәүдән туктамаса!
Кочарбыз тигез ирекне,
Очарбыз таң атканда...
Як-яклап: «Уфа – Казан!» – дип
Язылган канатларда.



Хисаметдин
Исмәгыйлев

# ТАШ ТҮККӘН – СИХРИ БОҖРА*

РОМАН

*Авыр язмыш.*
*Уфада яшәүче Гафури егете В.Р. сөйләгәннәргә таянып язылды.*

Аның күз алдында томан куерганнан-куерды. Алга барыргамы? Әллә кире кайтыргамы? Нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап, кыя башында басып торганнан соң, ул кырдагы зур гына бер таш өстенә барып утырды. Таш салкын. Ул кешедән рәхимсез рәвештә аның тән җылысын, җан җылысын үзенә суыра. Ташның салкынлыгы да аны айнытып, уйлаган уеннан, башына килгән нияттән кире кайтара алмады. Кешенең әҗәл алды мизгелендә барча гомер юлын кино караган кебек күз алдыннан үткәрүе турында аның ишеткәне бар иде. Теге вакытта ничә тапкыр үлемне кичерде, ничә тапкыр рәхимсез әҗәлнең күзенә карап, шыксыз тешләрен шыкырдатканын ишетте. Тик ул чакта аның үткән тормышы күз алдына килмәде шикелле. Ә менә әлеге минутта аның алдында шундый ябышкак куе томан куерганнан-куера гына. Томан аны бөтенләй уратып алды. Аяк-кулларны да селкетерлек түгел. Хәтта томан куелыгыннан тын алулары кыенлашты. Артка борылып, хатыны янына кайтыргамы? Хатыны юк бит инде. Дус дип йөргән хезмәттәшләре дә артта калды. Дус түгел, ә хыянәтче булып чыктылар. Юк, кире кайтмас ул, чөнки аның тормышы ниндидер аңлашылмаган бер боҗрага эләкте. Әфгандагы хәл – Чечняда, Чечнядагы хәлләр монда тагы да аянычлырак булып кабатлана түгелме? Ә менә бүгенгесе? Бүгенгесе бигрәк тә коточкыч килеп чыкты. Элеккеге тормышына кире борылып кайтса, бүгенгедән дә гыйбрәтлерәк гомеренең яңа куласасы тагы кабатланачак. Ринат моның шулай булачагына бүген ныклап ышанды. Элек тә тормышындагы хәлләрнең бер-бер артлы шикле кабатлануына аптырый иде. Бүген барысына да нокта куярга кирәк! Һәм ул

* Журнал варианты.

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ (1953) – *язучы-прозаик; «Зимагур», «Никах» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанның Стәрлебаш районы Турмай авылында яши.*

бик авырлык белән таш өстеннән торды да үзен уратып алган куе томанны кулы белән ертып актарырга тотынды. Әйтерсең лә ниндидер гаҗәеп бер чаршау-чыбылдыкны актарып ачкан кебек алдындагы томанны өзгәләп аера башлады. Томан шулкадәр куе, ката башлаган кесәлне хәтерләтә. Аякларга кадәр авырайды, аларга икешәр потлы гер таккан кебек. Ул бар көчен җыеп, алга, томан эченә – үзенең мәңгелегенә таба җай гына атлап китте.

Сезнең чын тауларны күргәнегез бармы? Шул-шул. Күргәнегез юк. Ә бу, безнең яктагы таулар – ул безнең өчен генә тау. Ә чын таулар – бик биек һәм куркыныч. Хәер, башта гына куркыныч. Өйрәнеп китсәң, алай түгел. Әйе, куркыныч түгел. Аннан хәтта синең дустыңа әйләнеп, сине төрле бәла-казалардан саклап кала. Ә бездәге таулар чын таулар янында бер өем туфрак кына кебек. Шулай булуларына карамастан, бездәге таулар да үзенә күрә матур. Әнә тау башларында кылганнар нинди матур итеп җилфердәшеп утыралар.

Мин үзем чын зур тауларны армиягә баргач, Әфганда гына күрдем. Ерактан таулар ниндидер мамык өеменә, кабарып торган болытларга охшап тора. Әйтерсең лә ап-ак болытлар бергә җыелганнар да каядыр барып кар булып яварга әзерләнәләр. Тауларны яратсаң гына, алар сине үзләренә сыендыра. Яклыйлар, дошманнардан саклыйлар. Яратмасаң, бетте – сиңа үлем, йә булмаса зур бәла-каза буласын көт тә тор. Таулар үзләрен көчләп яраттыралар. Телисеңме, теләмисеңме, барыбер яратырга, ихтирам итәргә туры киләчәк. Бу закон! Беләсегез килсә, таулар да тере. Тик урыннарыннан гына кузгалып йөри алмыйлар. Мөгаен, йөриләрдер дә әле. Без генә күрә алмыйбыз. Алар бик әкрен, миллион елларга сузылган адымнар белән йөридер. Тау тау инде ул. Алар да кешеләр кебек.

Әйе, беренче тапкыр күрүгә таулар куркыныч, коточкыч. Тау кыялары аждаһа тешләре кебек ыржаеп өскә карап тора. Ә син шул тешләр арасында йөрисең. Кыя ташлар арасында йөргәндә, бигрәк тә куркыныч. Аннан инде өйрәнәсең. Өстән башыңа таш тәгәрәп төшү куркынычы турында уйламый башлыйсың. Ә Әфган – тау-ташлар иле. Үзенчә матур ил. Бик матур ил. Тик мин анда яшәмәс идем. Безнең Башкортстан мең тапкыр матуррак. Мөлаем һәм ягымлырак. Мин әйтер идем, йомшак күңелле безнең ил. Миһербанлы ил. Юкка гына Урал тавын дөньяның кендеге, димиләр. Һәм монда ниндидер без белмәгән сер ята.

Тере дошманны күргәнем юк. Сугыш булган алгы сызыкта үлеп яткан кешеләрне күргәч кенә, боларның мәетләр рухы икәнлеген әйттеләр. Шунда күрдем үлгән рухларны. Алар арасында төрлесе бар. Сакал-чәчләренә чал төшкән бабайлары да, сакалсыз яшьләре дә. Без икенче позициягә күченеп китеп бара идек. Бу урында каты сугышлар булды, диделәр. Икенче көнне безнең ротага тагы яңа солдатларны китерделәр. Болар икенче елын хезмәт иткән солдатлар. Аларның сөйләве буенча мәетләрне күрше кышлактан килеп җыеп алып киткәннәр икән. Үзләренең зиратларына җирләгәннәр, диделәр. Мин үзем үлгән кешедән элек-электән шикләнә идем. Ә монда унлаган рух тәгәрәшеп ята. Без, яңа килгән яшь салагаларга, бу шул кадәр нык тәэсир итте. Җитмәсә сержант:

– Сез аларны үтермәсәгез, алар сезне менә шулай үтерәчәк, – дип, тагын әллә нәрсәләр сөйләп, куркытып, күңелгә шом салды.

Рухларны[1] да үтерергә туры килдеме дип сорыйсызмы? Әлбәттә. Сугыш бит ул. Сугыш корбансыз булмый. Әфганлылар – бик астыртын һәм усал халык. Көндез дус булып, сине шурави да шурави дип кочаклашып йөриләр, ә төнлә шүрәле-шүрәле дигән кебек. Бармакларыңны таш ярыгына кыстыруын кыстырмаслар, әмма кабырга арасына пычак тыгып китәргә мөмкиннәр.

Яңа позициягә барып урнашкач, берәр атна үттеме, юкмы, рухлар безне бу урыннан бәреп чыгарырга уйладылар. Чөнки шушы елга буендагы юлдан аларга Пакистан ягыннан корал китерәләр икән. Юл дип әйтеп тә булмый инде, ишәк сукмагы. Бик каты сугыш булды. Тегеләр ягыннан да кырылдылар. Безнең яктан да күп кенә иптәшләр һәлак булды. Менә шунда беренче тапкыр рухларга аттым. Тере кешегә беренче булып атуы кыен. Ничектер кул бармый. Шуңа да зиһенгә иң башта шуны ныклап сеңдереп калырга кирәк, син үтермәсәң, ул сине үтерә. Шушы тәгълиматны миеңә сеңдереп, шушы ачы хакыйкатьне аңласаң, дошманга каршы ату әллә ни кыен булмый. Әмма тере кешене беренче тапкыр үтерү барыбер җиңел түгел. Җитмәсә, якыннан, зур ачылган күзләре белән карап, сиңа каршы килгәндә. Әллә ничек күңелгә авыр тәэсир итә. Әйтерсең лә алдыңда ниндидер күзгә күренмәгән бер киртә, стена тора. Шул киртәне атлап чыгып, шул стенаны җимерә алсаң – яшисең, ә шул каршылыкны җиңә алмасаң – беттең. Сиңа цинк калайдан ясалган табут әзер. Һәм әниеңә «кара тюльпан-лалә чәчәге» самолёты белән кайтарып җибәрәчәкләр. Бусы яхшы очракта. Ә иң аламасы – синең үле гәүдәң беркемгә дә кирәкми. Шунда ятып каласың. Йә берәр упкынга, йә чокырга очырачаклар. Козгыннарга азыкка. Аннан инде «хәбәрсез югалды» дигән кәгазь генә киләчәк. Шул күзгә күренмәс киртә-каршылыкны җимереп, рухны син беренче булып атып ексаң, яшисең. Менә шундый закон. Аннан инде өйрәнеп китәсең. Бигрәк тә бергә хезмәт иткән иптәшләреңне үтерсәләр, йә булмаса үзеңне яраласалар, үч алу хисе бар булмышыңны биләп ала. Анда инде карап та, уйлап та тормыйсың. Автомат магазинында патроннарың беткәнче, калашның көбәге ут булып кызганчы атасың. Тик бар патроныңны атып бетерсәң, үзеңә дә үлем яный. Таш артыннан калкып чыккан рухка атарга патроның һәрчак корылган булырга тиеш. Син аткан ядрә дошманга тиярлек булганда гына, атарга кирәк.

Армиягә барганчы, йодрык йомарлап, юньләп сугышканым да булмады. Үзегез беләсез инде, авылда кем белән генә сугышасың? Түбән очлар белән бер-ике рәт бәргәләшкән булды. Анда да әле теге Вахит сугыш чукмары аркасында. Мин үзем кешегә сугарга җәлли идем. Бигрәк тә авыз-борын тирәсенә, битенә. Үземне кыйнап кайтаргалыйлар, ә минем аларга сугарга кулым күтәрелми. Рәхмәт «кыек баш-придәтел» Заһит бабайга. Ул әзрәк өйрәтте кешенең кай җиренә сугып, һушын алырга.

Сөйләүче шулай авыл малайларына янап, куркытып алды да, сүз бетте дигәнне аңлатып, урыныннан ук торып китте.

Ринат кайчакта ачылып китеп, шулай үзенең Әфган сугышында күргәннәре турында үсмерләргә, бала-чагага сөйли. Таулардагы сугыш алымнарын үсмер егетләргә өйрәтә. Имеш, өйрәнегез, салагалар, алдагы

[1] Әфган сугышчысы.

тормышыгызда кирәк булуы бар. Сез бит егетләр, булачак сугышчылар, илне саклаучылар.

Аның авылга кайтып төшүе дә көтмәгәндә булды. 1991 ел иде, ахрысы. Сугышка китеп «хәбәрсез югалды» дигән кешенең ничәмә еллар үткәч, кинәт кенә пәйда булуы авылны тетрәндерде. Аны бит инде күптән Әфган җирендә үлде дип исәпләделәр. Хезмәткә китеп, бер ел да үтмәде, әтиләренә военкоматтан «улыгыз хәбәрсез югалды» дигән кәгазь тапшырдылар. Шушы кайгыны күтәрә алмый, әнисе дөнья куйды. Ел ярымнан улын һәм хатынын югалту хәсрәтеннән әтисе дә сызып мәрхүм булды. Бердәнбер уллары иде бит. Авылда, «минага эләгеп шартлаган икән, гәүдәсен дә җыеп ала алмаганнар, шуңа күрә хәбәрсез югалган дип кенә язганнар» дип сөйләделәр...

Яз көне иде, хезмәткә озатканда әтисе:

– Улым, берүк, яхшы хезмәт ит. Йөзгә кызыллык килерлек булмасын. Шунысын да онытма, син, улым, безнең бердәнберебез. Исән-имин йөреп кайтырга тырыш. Минем өчен, әниең өчен исән-сау кайт.

– Һич хафаланмагыз, моңа чаклы барысы да әйбәт булды бит. Армиядә да әйбәт булыр. Елама инде, әни. Синең күз яшьләреңне күрсәм, минем дә елыйсы килә. Иптәшләр алдында яшь күрсәтеп тору оят. Йә, йә, әни, тынычлан. Бер мине генә алмыйлар бит. Әнә теге очтан тагы өч егет, бергә китәбез. Күрше авылдан да егетләр бар, – дип, әнисен тынычландырырга тырышты.

Хезмәткә китүчеләр утырган җигүле ат өй кырына килеп туктагач, әти кешенең дә күз төпләре дымланып китте.

Әтисе дә әнисе кебек улының аркасыннан яратып алды. Ринат инде башкалар алдында әтисе кочаклап яратканнан кыенсынып та китте. Чөнки безнең халыкта, башка халыклардагы кебек озатышканда, чап-чоп үбеп елашу да, аһ-уһ килеп хисләрне тышка чыгарып түгү гадәте дә юк. Әниләр инде күңелләре белән йомшак булулары аркасында яшьләрен тыя алмыйча, күзләрен кулъяулык, алъяпкыч чите белән кипшендерәләр. Күрше-күләннәр дә хәтсез генә җыелган. Җитмәсә, теге оч Мәҗит гармунын сузып җибәрде. Ниндидер бер йөрәкләрне сыкрандыргыч моңлы көй иде. Үзе әзрәк салып та алган. Хатыны каршы килүгә карамастан, булачак әрмисләр утырган арбага менеп утырды. Алар белән район үзәгенә юл алды. Шулай итеп, хезмәткә китүче Таш Түккән авылы егетләре җырлаша-җырлаша, район үзәгенә бара торган юлдан урман эченә кереп киттеләр.

Таш Түккән урман-таулар арасыннан агып чыккан кечкенә елга буена урнашкан бер авыл иде. Егетләрне озата киткән Мәҗитнең гармун тавышы иртәнге һавада озак яңгырап ишетелде. Менә ул да тынып, авыл өстен ниндидер аңлатып бирә алмаслык моңсулык биләп алды. Ринатны озатып, өйгә кергәч, әнисе күз яшьләренә ирек биреп, бик озак елады. Ире дә тынычландырып карады, тик файдасы булмады. Хатынының:

– Улымның кайтканын күрәлмәм инде, күрәлмәм, – дип сулкылдавына ачуланып:

– Юньсез сүз сөйләп, аламага юрыйсың. Тукта шыңшуыңнан! Югыйсә үзем чәбәкләп ташлыйм, – дип караса да, әни кеше тыела алмады.

Ир инде хатынына ирек биреп, үзалдына мыгырданып, тышка ук чыгып

китте. Ул да җанын кая куярга белми, әле генә хезмәткә озаткан улы турында уйлады. Ринатның ничек үскәнен, нинди шуклыклар кылып уйнаган чакларын исенә төшереп, нигез буена барып утырды. Бераз уйланып утыргач, болай кул кушырып утырып булмый бит инде дип, бакчага чыгып яңа гына баш төртә башлаган бәрәңге үсентеләрен караштырып, чыккан чүпләрне уташтырган булды. Бу эшен ташлап, кичә төзәтә башлаган абзар бурасының баганасын юнырга тотынды. Йөрәге сулкылдавын баса алмый, балтасын бер читтә торган бүкәнгә чабып, бераз тирә-ягына карап торды. Бер эшкә дә кулы ятмый, күңеле тартмый. Шуннан, ниндидер бер карарга килеп, шап-шап атлап, өйгә керде. Хатыны иртәнге чәй әзерләгән, үзе тәрәзгә карап моңаеп утыра. Ир, керешли үк:

– Әйдә, әзерлән. Район үзәгенә барып, шуннан да озатып җибәрик, – дип чыгып китте.

Абзар эчендә торган колынлы биясен алып чыгып, юл йөри торган арбага җикте. Утырырга йомшак булыр һәм баргач атны ашатып алырга да кирәк дип, арбага хәтсез генә печән дә салды. Ат та, ерак юлга чыгасыларын сизеп, кешнәштереп, колынына ерак китмәскә кушты, ахры. Колын да әнисенең корсак астын ирене белән төрткәләп, имергә тотынды. Ир өйгә кергәндә, хатыны юлга әзерләнеп беткән иде. Шикәр капчыгыннан бәләкәйләтеп тегелгән капчыкка бер түгәрәк ипи, берничә баш корт һәм ике казылык салды. Казылыкны кичә үк әзерләп куйган иде. Ашыгып-кабаланып, улларына биреп җибәрергә онытканнар. Хатын шатлана-шатлана, шуларны капчыкка тутырды.

Ат та юл йөрүне сагынган, күңелле генә юртаклый. Хуҗасы берничә ай җикми торды шул. Колынлагач та әле, бер айдан артык җикмәде. Баласының аяклары ныгысын дип уйлады. Колынның да беренче тапкыр якты дөнья белән ныклап танышуы иде. Шуңа да әнисе тирәли чабулап бара. Койрыгын күтәреп, әле бер якка чыгып чабулый, әле икенче якка чыга. Ераккарак китсә, әнисе колынын кешнәп, үзе кырына чакыра. Һәр җан иясенә бала кадерле шул.

Май азагы гына булганга урман юлы кибеп бетмәгән. Тау башларыннан агып төшкән сулар кайбер урында юлны бөтенләй җебетеп, ашап-бозып бетергән. Ярый әле теге елны, юлларны төзәтеп, әзрәк вакташ-кырчын салдылар. Әти кеше егетләрне алып киткән атларның эзләрен карый-карый барды. Алар бик иртә юлга кузгалган булсалар да, җай барырга тиешләр, дип уйлады. Шулай булуына карамастан, атын җәһәтрәк куалады. Арба җиңел, ике генә кеше утырганга ат та алай куганны көтмәде. Үзе юыртты.

Район үзәгендәге военкомат урамына барып кергәндә, ерактан ук кара яу кебек халык төркеме күзләренә чалынды. Ир белән хатынның йөрәкләре җилкенеп, ир атын тагы да шәбрәк куалады. Военкоматка җитәрәк ат белән алга үтәрлек түгел, урам озатучылар белән шыгрым тулы. Әле тегендә, әле монда җигүле атлар тора. Шуңа да ир, якындагы бер капка ягына борылып, атын кырдагы ихатага бәйләп куйды. Ашый торсын дип, бия алдына печән салды, аркалыгын төшерде. Колын да ачыккан, шунда ук әнисенең корсак астына борынын төртте.

Военкомат алдында торган ике автобус тирәсендә халык кайнаша. Сыерчыклар да, бу җыелган халыктан шикләнеп, оялары тирәли куркышып

чыркылдашып очалар. Ә инде ару-талуны белмәс чыпчыкларга дөнья түгәрәк, өй кыекларына тезелешеп утырганнар да астагы халыкны күзәтәләр. Аннан тагы нәрсәдәндер шүрләп пырхылдашып, халык өстеннән очып үтәләр дә күрше йорт түбәсенә яңадан тезелешәләр.

Тизрәк-тизрәк, ир белән хатын арбадагы ризыклар салынган капчыкны икәүләп тотып, халык мәш килешеп кайнашкан капка алдына таба юл алды. Аһ малай, автобуслар кузгала түгелме соң? Шулай шул. Менә автобусларның алда торганы халык төркемен ерып бара. Шофёр, машина алдына каршы чыккан, бераз салып алган ир-егетләрнең тәгәрмәч астына килеп эләгүләреннән куркып, пипибен кычкырта-кычкырта, урамнан ары китте. Автобус кырында берничә милиция хезмәткәре кызмача булганнарны читкә этәрә. Шунда кайдандыр каршыларына гармунын култык астына кыстырган Мәҗит килеп чыкты. Ул инде авылдашларын күреп, ерактан ук:

– Безнекеләр алдагы автобуста, кузгалып киттеләр инде, – дип кычкырды.

Их! Өлгермәделәр! Тагы бер биш минутка иртәрәк килеп җитә алмадылар. Ничаклы ашыксалар да, булмады. Нинди үкенечле, нинди үкенечле. Хатынның аяк буыннары йомшарып китте. Ул чак атлап, халыкны ера-ера, урам читенә чыгып, ихатага сөялде. Ире, нәрсәгәдер өметләнеп икенче автобуска таба ашкынып бара башлады.

Кырда торган ике милиция хезмәткәре, халыкны куып, бу икенче автобуска да юл әрчи. Әти кеше шулай да икенче автобус тәрәзәсе янына якыная алды. Һәм кулындагы күчтәнәчләрне автобус тәрәзәсеннән ниндидер бер такыр башлы әрмис егеткә сузып:

– Вәлитов Ринатка тапшыр, улым. Вәлитов Ринатка. Ул алдагы машинада, – дип кычкырды.

Күрәсең, аның этисе булды, янында гына торган ир:

– Ал, улым, ал! Баргач тапшырырсың. Безнең районнан барганнар бер тирәдәрәк буласыз бит. Фамилиясен онытма! – диде.

– Әйе, әйе, Вәлитов Ринат дигән егет. Таш Түккәннән без, Таш Түккән авылыннан.

Автобус бер-ике пошкырып алды да, авырсынып, чак урыныннан кузгалды. Халык аның саен «гү» килеп кычкырышты. Кычкырып елашкан марҗалар да, лышык-лышык килеп, яшьләрен сөртүче апа-җиңгиләр дә бергә кайнашты. Халык шулай улларын, якын туганнарын армиягә озатырга килгән. Мәҗит үзенең мәңге аерылмас гармунын тартып җибәрде. Теге баштарак тагы бер гармун аңа кушылды. Кемдер, йөрәкләрне әрнетеп, Герман көен суза башлаган иде, тегене тиз тыйдылар. Берәү аңа:

– Алйот, туктат бу җырыңны! Югыйсә башыңны ярам! Безнең егетләр сугышка китмиләр. Армиягә генә баралар. Ике ел нәрсә инде, баралар да хезмәт итеп кайталар.

– Син үзең ахмак, абзый кеше! Әфган сугышын онытма! – дип, бераз кызмача булган ир, бу абзый белән сүз көрәштереп тормыйча, үз юлы белән китеп барды.

Әхмәт үрелеп-үрелеп, халык төркеме аша хатынын эзләде. Ихатага сөялгән хатынын күреп, җиңел сулап куйды. Инде тарала башлаган халык арасыннан һаман гармун уйнаган авылдашы янына китте.

Мәҗит инде ныклап исерергә дә өлгергән. Ул авылдашын күреп, гармуннан көйләр суза-суза, алар янына килеп басты. Уйнавыннан туктап:

– Егетләрне бик яхшы итеп озаттым. Берсе дә, менә бу җебегәннәр кебек яшь түгеп, җиңнәрен суламадылар, – дип сөйләнде.

Автобуслар китте. Күктәге кояш та күңелсезләнеп калган кебек булды. Ничектер барча дөньяны моңсулык биләп алды. Җыелган халык кайсыкая таралып бетте. Ат җигеп килгәннәр дә атларына утырып, кайтыр якларына кузгалды. Мәҗит тә авылдашларына иярмәкче иде, булмады. Аны, ниндидер танышы очрап, үзләренә алып китте.

Ир атын атлатып кына, район үзәгеннән кайтыр якка кузгалды. Авыл читендәге бер кибеткә туктап, бер ярты алып чыкты. Хатынының ничектер гаепле кеше сыманрак итеп:

– Эчәргә уйладың мәллә? – диюенә:

– Юк. Аллаһы бирсә улым кайткач бәйрәм итәрбез. Шуңа дип алдым, – диде.

Шуның белән бетте. Хатын да ләм-мим сүз дәшмәде. Ир дә башкача сүз кузгатмады. Ат та ял итеп ашап алырга өлгергән. Кайтыр якка елдам гына юырта. Яз – яз инде, тирә-як кояш нурына коенып шатлана. Кошлар бер-берсен уздырырга тырышып сайраша. Әхмәт белән хатыны гына үзләренең авыр уйларына уралып, ат йөгерткән уңайга арбада тирбәләләр. Икесе дә аңлыйлар иде: бүгеннән башлап, ниндидер билгесез тормышка аяк бастылар. Бердәнбер уллары хезмәткә китте. Ичмаса күңелләрен юатырлык башка балалары да юк бит. Тагы берәр балалары калса, йөрәккә җиңелрәк булыр иде. Юк шул, Ходай насыйп итмәде.

***

Автобустан төшүгә егетләргә «Тезелергә» дигән команда булды. Шунда кемдер:

– Валитов Ринат. Вали..то..в! – дип кычкырды.

Ринат «мин» дип дәшәргә дә өлгермәде, соңыннан килгән автобустагы бер егет аның кулына әниләре җибәргән күчтәнәчләрне китереп тоттырды. Менә шулай башланды инде Ринатның туган илгә булган бурычын үти башлавы.

Җыелу пунктында эшне тиз тоттылар. Элекке вакытлардагы кебек «кая озатачакларын көтеп» атна буе яткырмадылар. Шул ук кичне аэропорттан самолётларда Ташкент каласына озаттылар. Үзбәкстандагы ниндидер бер хәрби частьта булачак сугышчыларны айга якын өйрәтеп «Хәрби ант» та кабул иттерделәр. Бусы «карантин» дигән нәрсә икән. Аннан соң Термиз шәһәрендә ике айга якын тау шартларында ничек дошман белән алышу серләрен төшендерделәр.

Анда инде уйларга да вакыт калдырмыйча, төрле сугыш алымнарына өйрәттеләр. Таң белән «подъём» командасын ишетүгә, яткан урыныңнан корт чаккандай торып йөгерәсең дә кич «отбой» командасына һушың алынып, урыныңа килеп авасың. Барысын да тиз, бик тиз башкарырга кирәк. Әллә йоклап ял итәргә өлгердең, әллә юк. Анда һичкемнең эше юк. Икенче, өченче һәм башка көннәрне дә шул ук хәл. Тәмам чын солдат рәвешен алып, эт каешына әйләнгәч, сугышның эчендә кайнап чыныккан частьларга тараттылар. Анда инде бөтенләй икенче тәртип, башкача законнар.

Беренче көннән үк Ринатның взвод командиры белән ничектер эшләре пешмәде. Взвод командиры «старик» иде, ягъни тагы ярты елдан өенә кайтып китәсе солдат. Командир үзен әллә кемгә санап, яңа килгән яшь солдатларны кол урынына күрә башлады. Кирәксә-кирәкмәсә дә әле теге эшне куша, әле монысын. Һичьюгында үзләренең позицияләрен ныгыттыра. Суга мохтаҗлык булмаса да, якындагы тау елгасыннан салкын су китерергә куша. Күрәсең, командирның яшь солдатларны юкка интектерүен күреп, икенче бер карт солдат аның белән әйткәләшеп тә алды. Юк, аның үз туксаны туксан. Имеш, яшьләрне чыныктыра. Тормышка өйрәтә. Аптырагач, теге карт солдат яшьләр янына килеп:

– Ярар, бик бирешеп бармагыз. Тагы ике ай түзсәгез, ул кайтып китә. Аның урынына әнә теге «черпак» Ваня сержант калырга мөмкин. Ул болай ару гына егет. Аннан инде сезнең урынга икенче молодойларны китерәчәкләр. Тәк што, юкка башыгызны иеп, кайгырып йөрмәгез. Сезнең урамда да бәйрәм булыр көннәр алда әле. Менә шуңа күрә үзегез исән-имин калып старик булгач, яшь салагаларны кыерсытмассыз.

Яшь солдатлар бу карт солдатны дәшми генә тыңладылар. Ничектер күңелләре күтәрелеп китте. Аларны аңлаучылар һәм җәлләүчеләр дә бар икән. Тик бу солдат әйткән бәйрәм көннәр урынына кара кайгылы көннәр килде.

Үзәктән кышлакка рухларның зур гына төркеме килеп урнашачагын хәбәр иттеләр. Кышлакка БТР һәм танклар белән бару турында уйларга да түгел, юл юк. Тик җигүле ишәк чак-чак үтәрлек тар гына сукмак инде. Сукмак дисәң киңрәк, юл дисәң хәтере калыр шундый бер нәрсә инде. Ике ягы да биек таулар белән уратып алынган тарлавыкта урнашкан шушы кышлакны рухлардан тазартырга дигән приказ булды. Күз бәйләнгәч, юлга кузгалдылар. Юлга кузгалыр алдыннан командир тешләрен кысып, һәрберсенә:

– Карагыз аны, тәмәке тартканыгызны күрсәм, үзара сөйләшкәнегезне һәм итекләрегез белән шап-шоп атлаганыгызны ишетсәм, үзем муеныгызны борып очырам. Аңлашыламы?

Солдатлар сүзсез генә баш кагалар. Бу тагы:

– Ишетмим! Әллә мин әйткәннәр аңлашылмыймы? – дип ысылдады.

Солдатлар да аның уңаена:

– Аңлашыла, – дип пышылдауга күчте.

Ике взвод белән шушы хәрби операциягә җитәкчелек итүче яшь кенә лейтенант дәшми. Аны бу частька яңа гына җибәргәннәр. Картлар әйтүенчә, әле дары исен иснәргә өлгермәгән яшь офицер. Шуңа да лейтенант сугышчан рейд-операцияләрдә чыныгу алып, эт каешына әйләнеп шомарган сержантларга һәм карт сугышчыларга таяна. Барча эшне аларга ышанып тапшырды.

Шурави дип, безнекеләрне урындагы халык – әфганлылар атый. Төне буе атладылар, инде яктыра да башлады. Ул Әфган илендә таң бездәге кебек озаклап тормый. Әз генә офык алсуландымы, көн туа да куя. Кичләрен дә шулай ук, ә дигәнче караңгы төшеп, төн була. Тау арасында төн бигрәк тә тыгыз. Караңгылык шул кадәр куе, кем әйтмешли, күзгә сылана. Ярый әле күктә, яраланудан яртыга гына калгандай, ай, күз яше аралаш сулкылдап, саран гына җирне яктырта.

Кышлакка иртәгәсе көнгә генә килергә тиешле рухлар тау битендәге ташлар арасыннан көтмәгәндә ут ачты. Шуравилар юньләп аңларга да өлгерә алмый калды. Мәхшәр купты. Кайда кем кычкырганын да, кайдан рухлар атканын да белерлек түгел. Ике яклап, аларны утка тоталар. Ниһаять, безнең миномётчылар да коралларын көйләп, тау битендәге ташлар артында яткан дошманга каршы ут ачты. Ул да булмый авыл ягыннан да солдатлар өстенә миналар ява башлады. Күрәсең миномётларын алдан ук көйләп куйганнар. Миналар нәкъ алар яткан урынны актарып, җир сөрә башлады. Хәл нык кискенләште. Сержант рация аша үзәккә хәлне аңлатып, ярдәм сорап кычкыра. Аннан юньле җавап бирмәделәр. Рация лейтенантны бәйләнешкә чакырырга кушты шикелле. Сержант офицерның яралануын хәбәр итте һәм аты-юлы белән сүгенергә тотынды. Менә шушындый кискен вакытта урыс сүгенүенең нинди олы әһәмияткә һәм сихри көчкә ия икәнен аңлый башлыйсың.

Шуравиларның хәле бик тә мөшкел иде. Тагы бер-ике сәгать шушылай ташлар арасында ятсалар, рухлар аларны берәмләп чүпләп бетерәчәк. Егетләр тирә-якка сибелеп, кайсы кая яшеренде. Солдатлар үзләре яшеренгән урынны, ничек итсә итте, кулларыннан килгәнчә ныгытырга тотынды. Өстеңә ут яуганда, әллә нәрсә эшли алмыйсың. Тирә-якта аунап яткан ташларны үзеңнең кырыңа өя алсаң, бик хуп. Окоп казу турында уйларга да түгел. Өлгерә дә алмыйсың. Җире дә таш та мәте. Берничә солдат, яраларына түзә алмыйча, авыртудан кычкырып еларга ук тотынды. Берәү бөтенләй үлеп ята.

Дошман ничек көтмәгәндә ут ачкан булса, шулай кинәт кенә тынып калды. Сержантның гына рация аша ярдәм сорап кычкырганы ишетелә. Ул да мина шартлавы һәм ату тавышлары тынганын чамалап, тавышын әкренәйтә төште. Вакыт агышы үзенең элеккеге хәленә кайтты. Кинәт кенә барлыкка килгән тынлыкны бозып, тау итәгендәге ташлар артыннан рус сүзләрен вата-җимерә, коралларны ташлап бирелергә тәкъдим итәләр. Имеш, тормышыгызны саклап калабыз, сез бит әле яшь. Үзегезне, әниләрегезне уйлагыз, диләр. Бирелмәсәләр, бөтенләй кырып бетерергә вәгъдә итәләр. Шунда сержант янында яткан лейтенант:

– Син кем? Курыкмасаң, күрен. Кем икәнеңне карап карыйк, – дип кычкырды.

Тау битендә кыядан тәгәрәп төшкән галәмәт олы таш артыннан бер сакалтай чыгып басты да үзенең бирелергә кушкан тәкъдимен кабатларга өлгермәде, солдатлар ягыннан берничә ату тавышы яңгырады. Сакаллы рухка әллә тиде, әллә тимәде, ул таш артына яңадан посты. Шуны гына көткән кебек, тегеләр ягыннан шуравилар яткан позицияне яңадан утка тота башладылар. Солдатлар аларга җавап уты ачмады. Ут ачып та ни эшли аласың? Рухлар бик уңайлы урынны сайлаган. Шуннан инде патроннарны да саграк тотарга кирәк. Монда күпме ятасын белеп булмый. Әллә берничә сәгать, әллә тәүлек. Тегеләр ягында снайперлары да бар шикелле. Ялгыш таш артыннан күренгән совет солдатларын берәмләп чүпләргә тотынды. Кай төштә урнашканын да белерлек түгел. Тауларда барча тавыш мең кабат яңгырап ишетелә. Шуңа карамастан, солдатлар яткан урыннарын бәләкәй сапёр көрәге белән әзрәк яшеренерлек итеп тирәнәйтә алды. Кемнәрдер

тирә-яктагы ташларны алдына өйде. Кемнәрдер, яшеренеп яткан таш артларындагы җирне казып, шунда яшеренде. Җир дисәң, бу сүзеңнән шайтан көләр. Җир юк. Мәтесе кырчын ташлы. Юньләп казырлык та түгел. Теш арасына эләккән ком кебек шыгырдап тора.

***

Рухлар кинәт ут ачудан Ринат каушап калмады. Ул айның зәгыйфь яктылыгында һәм караңгылык сыегая башлау белән тирә-юньне карап өйрәнә-өйрәнә, стройда атлавын белде. Алдан атлаган солдат зәгыйфь утлы фонарь белән сукмакны гына яктыртып алгалый. Анда да учы белән каплап кына. Шулай итмичә дә булмый. Ут яктысы төнлә әллә кайлардан күренә. Фонарь тик аяк астына таба гына төбәлгән. Аны да гел яктыртып бармыйлар. Бик кирәк чакта сукмакны чамалар өчен генә. Мондый хәвефле мәлдә кешенең күзе бүре күзе кебек төнлә дә күрергә сәләтле. Әйе, ерактагы тау башлары күзгә шәйләнә башлау белән Ринатның башында шундый фикер чагылып үтте. Әгәр дә рухлар көтмәгәндә һөҗүм итсәләр, ул кайсы таш артына качар иде икән? Шушы уй белән ул янында яткан зур-зур ташларны барлый-барлый атлады. Ата башласалар шушы таш артына сикерсәм булыр микән? Ә тегесе ничек булыр иде? Алдан засададан ата башласалар яшеренергә бу таш кулайрак булмасмы? Ә монда үсеп утырган әрем, йә бу дөя чәнечкесе, ә бу чокыр ничегрәк булыр иде икән? Рухлар кайсы кыя, кайсы таш артында яшеренеп торып, ут ачарга мөмкин дип уйлап, тирә-якны җентекләп күзәтергә дә онытмады. Ә безне алгарак җибәреп, арттан һөҗүм итүләре дә бар бит дип, артына да әйләнеп карады. Менә тәмам яктырды. Шул вакыт әле генә үзләре үтеп киткән борылыштан өстә, битләүдәге таш артында ул нәрсәнеңдер селкенеп куюын шәйләде. Әллә инде күзенә күрендеме? Юк шикелле? Ринат үзенең шиген яныннан атлаган солдатка әйтергә дип, авызын да ачарга өлгермәде, тирә-якны автомат тырылдавы, миналар сызгырып шартлавы чолгап алды. Ринат алдан ук күзәтеп, чамалап куйган чокырга сикерде. Чокыр ару гына тирән булып, җитмәсә, чокыр яны биек кенә үскән әрем белән капланган иде. Тәүдә үзенең бу чокырга килеп эләгә алуына шатланудан бигрәк янында атлаган солдатның да үз янында ятуына аптырады. Солдат:

– Селкенмә! – дип ысылдады.

Командир һәм сержантларның:

– Ут позициясен биләп урнашырга!

– Ятыгыз!

– Дошман атакасын кире кайтарырга әзерләнергә!

– Тирә-якка таралып яшеренергә! – дигән сүгенү һәм төрле күрсәтмә-боерыклары яңгырады. Күрәсең, яраланучылар да бар иде.

– Ярдәм итегез! Ярдәм!

– Вася, Вася! – дип кычкырулар ишетелде.

Вася ротада санитар булып исәпләнә. Ул – ниндидер медицина училищесын тәмамлап, армиягә үз теләге белән килгән Саратов егете.

Безнекеләр ягыннан атулар сирәк ишетелә. Күрәсең, һәркем үзенә яшеренергә урын әзерләү белән мәшгуль. Кайда, кайсы якка атасың? Тәүдә

рухларның кайда яшеренүен ачыкларга кирәк. Берничә минуттан солдатлар да үзләренең утларын көчәйтә төште.

Ринат янында яткан солдат:

– Җайлап кына кара әле, рухлар кайсы тирәдәрәк икән? – дип дәште. Үзе аркасында күтәреп килгән йөктән араланып, чокырны бәләкәй сапёр көрәге белән тирәнәйтеп җайлаштыра башлады.

Ринат мүкәләп, чокыр кырыена менә башлаган иде, теге:

– Кая мүкәлисең? – дип җикерде.

Ринат чокыр янына шуышып кына күтәрелеп, башын сак кына чыгарып, тирә-якка карап алды. Тау битләвеннән безнекеләр ягына таба берничә урыннан трассирлы пуля белән аталар. Күрәсең, рухлар шулай итеп үзләренең миномётчыларына шуравиларның кайда ятканлыкларын төгәлрәк күрсәтәләр иде.

Солдат һәм Ринат әзрәк тын алгач чамаладылар: рухлар тау итәгендәге ташлар артыннан аталар. Каршы яктагы рухларны күрерлек түгел. Кырдагы зур таш комачаулый. Аның шулай ятуы чокырдагылар өчен кулай гына. Дошман да аларны күрә алмый. Карт солдат бераз тирә-юньне өйрәнгәч:

– Әнә теге таш артындагы пулемётны күрәсеңме?

– Әйе.

– Мин ботына чамалыйм. Миңа аягы гына күренә. Ядрә тигән көе ул йә әйләнеп ята, йә булмаса артка каерылачак. Шул вакытта син гәүдәсенә атарга тырыш. Минем автомат төз җибәрә. Һәм калашкаңның прицелын өч йөзгә куй. Болай төз атасыңмы? Прицелың көйләнгәнме?

– Әйе.

– Алдыңда яткан таш өстенә автоматыңны куй. Селкенерлек булмасын. Дошманның кырында яткан ташка тияр-тимәслек итеп төзә! Рух шул якка авачак. Шуны чамалап атарсың. Төзәдеңме?

– Әйе.

Бу Пенза ягыннан булган Руслан исемле карт солдат, ничектер авыз эченнән, «бисмиллах иррахман» дип мыгырданып алды да атып җибәрде. Шул секундта таш артында яткан рухның аягына эләкте, ахры. Теге кинәт боргаланып алды да мүкәләп, читкәрәк китә башлады. Солдат тагы сүгенеп, нәрсәдер кычкырырга өлгермәде, Ринат шул мизгелдә тәтегә басты. Һәм рух кинәт кенә бөтенләй тураеп утырды. Ринат тагы тәтегә басты. Икенче мизгелдә инде теге пулемёты янына авып төште. Руслан шаркылдап көлеп җибәрде һәм яман сүгенеп:

– Шул кирәк сиңа. Анаңны сатыйм! Без дә ата беләбез! – дип куйды. Усал көлүеннән туктамыйча: – Хәзер башкаларын да чүпли башлыйбыз. Исемең кем әле? Онытып торам.

– Ринат булам.

Карт солдат шулай сөйләнә-сөйләнә, тау битендәге ташлар арасыннан үзенә яңа корбан эзли башлады.

– Тәк, әнә тегендә яткан таш артын күрәсеңме? Әнә анда әле тегеләй, әле болай чабышалар. Мөгаен, миномётлары шундадыр. Югыйсә бик кызып киттеләр. Иң тәүдә син атасың. Рух таш артына кереп югалгач, өчкә чаклы сана да ат. Һәм тагы атарга автоматыңны ныклап төзәп куй. Мин атканнан соң «егерме бер» дип әйт тә шул ук урынга тагы ат. Башкача тидереп

булмый. Берәмләп атарга кирәк. Һәм коралыңны яңадан шул урынга ныклап төзәп өлгер. Мин генә атсам, икенче атуга төзәп өлгерә алмыйм. Тидерүе кыен булачак. Икәүләп, алмаш-тилмәш атабыз. Ферштейн?! Башладык!

Карт солдат өйрәткәнчә, рух күзгә күренеп калган җиргә Ринат атып җибәрде. Аннан карт, аннан ул атты. Шулай алмашлап ата торгач, ниһаять, таш артыннан чыккан рух авып төште. Аңа ярдәмгә сузылган иптәше дә тәгәрәде.

– Менә шулай!

Руслан тагы шаркылдап көлеп җибәрде. Ә тирә-якта мәхшәр дәвам итә иде. Тик хәзер рухларның бу як тау буендагы пулемётлары белән миномётлары дәшмәде. Әмма кышлак ягындагы һәм арттагы пулемёт белән миномётлары котырынып, солдатлар позициясен үтүкли.

Күктә безнекеләргә ярдәмгә җибәрелгән ике вертушка күренде. Алар инде хәлне чамалап алганнар. Килә-килешли үк рухларның тетмәсен тетәргә тотындылар. Шуравилар дәртләнеп китеп, атакага күтәрелде. Һавадан ярдәм булгач, бәрелеш озакка сузылмады. Рухлар мәетләрен дә алмыйча, тараканнар кебек кайсысы-кая качып бетте. Берсе генә кулларын күтәрергә мәҗбүр булды. Ул да аягы яраланган әфганлы иде. Шуравилар бик кызган һәм күп уйлап тормыйча аны «расходка» җибәрделәр. Безнекеләр ягыннан да унга якын югалту бар иде. Яралылар да хәтсез генә. Ринатлар взводы командиры да яраланган булып чыкты.

Тәүге дары исен менә шулай иснәде Ринат. Ә аның белән бер чокырда яткан карт солдат лейтенант янына килеп, пулемётчы һәм ике миномётчыны Ринат юк итүе турында доклад ясады. Теге ышанмаска чамалаган иде дә, Руслан аны үзләре яткан чокыр төбенә алып төшеп, рухларны ничек атып юк иткәннәрен аңлатты. Аннан тагы теге дошман яткан таш артын барып карадылар. Рухларның яралары старик әйткәнчә булып чыкты. Ышандылар. Ринатка рота командиры строй алдында аерым рәхмәт белдереп, медальгә тәкъдим итәчәген әйтте.

Ринатка бу карт солдат ничектер бөтенләй якын булып китте. Әйтерсең лә, алар гомер буе бергә яшәп, бер авылда үскәннәр. Һәм ул туры китереп:

– Теге рухларны юк итүдә синең өлеш күбрәк булды. Мин тик синең әйткәннәрне генә үтәдем. Медаль сиңа тиеш. Миңа, үзең әйтмешли, бакыр котелок кебек хезмәт итәргә дә хезмәт итәргә. Медальгә өлгерер идем. Ә сиңа, бүген-иртәгә дигәндәй, дембельгә. Өеңә медаль тагып кайтсаң ярар иде.

Карт аны ишетмәгәндәй, күзләрен кысып, һавада кызып-кызып сайраган тургайны күрергә тырышып, өскә каравын дәвам итте. Аннан карашын тирә-яктагы тау башларына күчереп, аларны барларга тотынды. Шуннан сәгатен яңа гына күргән кебек аны өйрәнеп, боргалый-боргалый:

– Вот парадокс, бу вакытны һич аңламассың. Йә ыштан резинкасы кебек сузыла да сузыла. Һич үткәреп булмый. Йә кырыңнан очып үткән пуля кебек үткәнен дә сизми каласың. Иртән генә нинди озак сузыла иде, ә инде кич тә җитеп бара, – дип куйды.

Чынлап та яралылар белән һәлак булганнарны вертушкага төяп, тылга озатканчы һәм коралларны тәртипкә китереп, яңа уңайлы позициягә урнашканчы, вакыт кичке якка да авышкан иде. Менә ашап алырга дигән

команда булды. Солдатлар үзләре белән алып килгән коры паёкларындагы консерваларын җылытып, төшке һәм кичке ашны бергә ашый башладылар. Ринат белән карт та ашарга икесе бергә утырды. Карт алдындагы тушёнкадан каерып-каерып, ит кисәкләрен авызына озата-озата:

– Гражданкага медаль тагып кайтсаң, шәп булыр иде, дисең инде, ә? – дип, инде Ринат күптән онытып бетергән темага кире кайтты. Егет тәүдә бу нәрсә сөйли инде дип аңламыйчарак торды. Карт сүзен дәвам итеп: – Яшьсең шул әле. Аңлап бетермисең. Беренчедән, минем орден белән медалем бар инде. Икенчедән, вакыты җиткәч, үзең дә шулай яшь солдатларга ярдәм итәрсең. Монда, брат, бер-береңә шулай ярдәмләшмәсәң – хана! Исән калуың икеле. Сугыш бит, сугыш. Ә теге сержант командирыңа үпкәләп йөрмә. Хәзер ул синең өчен юк. Ярасы ул кадәр авыр булмаса да, аның өчен сугыш тәмам. Бүген үк тылга госпитальгә озатачаклар. Ә медальгә килгәндә, күкрәгеңә тагылгач кына медаль алганыңа ышанырга мөмкин. Вәгъдә иткәнне бездә өч ел көтәләр. Ә без бит ике генә ел хезмәт итәбез. Менә шулай, брат, вәгъдә ул – һавадагы торна, ә торнага ышанма. Әле синең кулыңда чыпчык түгел, ә сынган канатлы чебен дә юк.

Шулай бик мәслихәт кенә якыннан таныша-таныша сөйләшеп ашап алдылар. Ринат үзен иртән үк аптыраткан сорауга җавап табар өчен бик игътибар бирмәгән кебек:

– Бер сорау бирсәм буламы? – дип куйды.

Карт солдат та юморга әвәс кеше икән. Көлемсерәп алды да:

– Тамак туйды. Хет ун сорау бир. Җавабы әлегә бушка була. Тик әллә нинди катмарлы сорау булмасын. Катмарлы һәм этажлы сорауларны яратмыйм. Йә, нинди сорау?

– Иртән теге рухка атар алдыннан әллә безнеңчә бисмилла иттең инде?

Карт башын селкеп көлеп җибәрде. Ринатка мут елмаеп карап алды да:

– Ну син хәйләкәр булырга охшагансың. Барысын да күрәсең, барысын да ишетәсең һәм барысын да чамалыйсың. Әйе, мин сезнең кебек бисмилла иттем. Минем әни яклап – картәниләр татарлар. Алар өйрәтте. Монда сугышта, сынок, бисмилла да әйтерсең, сүгенә-сүгенә чукынырсың да. Яшисе килә бит. Ну син молодец! Тик шуны әйт әле, минем кырга теге чокырга ничек килеп төштең?

Бу сораудан Ринат кычытмаса да, такыр башын кашып алды. Дөресен әйтергәме, әллә белмим дигән җавап кына бирергәме дип уйлап алды да дөресен сөйләп бирде.

– Мин – әти белән әнинең бердәнбер уллары. Башка балалары юк. Икесенең дә сәламәтлекләре чамалы. Алар укытучы булып эшлиләр. Әгәр дә минем белән бер-бер хәл булса, алар да кайгыларына түзә алмыйча икесе дә вафат булачак. Шуңа күрә миңа икеләтә сак булырга һәм бу мәхшәрдән исән-имин йөреп кайту кирәк. Дошман һөҗүм иткәндә дә, атакага күтәрелгәндә дә, гел уйлыйм. Ничегрәк итсәм, миңа рухлар атып тидерә алмас. Иртән синең арттан атлаганда да карап бардым. Һөҗүм итә калсалар, кайсы таш артына яшеренеп, аларның үзләрен ничек юк итү турында уйладым. Кайсы очракта дошман пулясы куып тота алмас? Теге чокырны алдан ук чамалап куйган идем. Шунда сикердем. Тәк што, миндә өч кешенең гомере. Әти белән әнинең гомере минем өстә.

– Да, брат. Бу яклап син дөрес чамалыйсың. Безгә исән калырга кирәк. Минем дә синең чамадарак. Минем өч апам бар. Но, син исән калачаксың. Менә әйтте диярсең. Афәрин! Парень, монда һәр адымыңны үлчәп, кырык кат уйлап атларга кирәк. Алдан уйлап йөрүең – дөрес һәм яхшы сыйфат. Исән-имин өеңә кайтып, ишек тотканда тотынуга мине исеңә төшерәчәксең әле. Мин әйтте, диярсең менә. Минем исемемне беләсең инде, нейтральный исем. Руслан булам мин. Әни шулай теләгән.

– Ә мин Ринат булам. Икебез дә Р хәрефендә.

Көлешеп алдылар. Һәм шулай танышып киттеләр. Бу солдат хезмәтенең нәкъ йөз егерменче көнендә булды. Төгәл әйтүе шуңардан, һәр солдатның түш кесәсендә бәләкәй генә календаре бар. Менә шунда һәр хезмәт итүче үзенең хезмәттә үткән көнен билгеләп бара. Кемдер календарена энә белән тишек тишә, йә түгәрәккә ала. Кайберләре Ринат кебек, үткән көнне аркылы-торкылы сызып куя. Ринат бу көнне кемнәндер кызыл төсле ручка табып, түгәрәк эченә алды. Кызыл түгәрәк дошман белән бәрелешкән көнне күрсәтергә тиеш иде. Яшь салагалар бүгенге көнне кабат-кабат күз алларыннан үткәреп, яраланган һәм һәлак булучыларны уйлап, аннан да бигрәк бик тә киеренке психик кичерешләрдән, йокыга китә алмый озак боргаланып яттылар. Тик нык талчыгу һәм эт кебек ару үзенекен итте. Алар саташу-бастырылулы йокыга чумдылар.

Кышлак зур гына булып, бүген үк тикшереп чыгу мөмкин түгел иде. Шуңа да авыл кырындагы бер калкулыкка урнашып, шунда төнне үткәрергә булдылар. Лейтенант, картлар белән киңәшләшеп алгач, шул калкулыкны ныгытырга боерык бирде. Дошман көтмәгәндә килеп чыгып һөҗүм итәрдәй якка дозорлар һәм каравыл куелды. Рация аша иртәнгә тагы өстәмә көчләр җибәрербез дип, мондагыларның кәефен күтәрделәр. Югыйсә яңа килгән яшь солдатларның беренче мәетләрне күрүдән шөлдерләре бөтенләй коелып, үзләрен кая куярга белми, әниләреннән аерылган бәрән хәлендә иделәр. Әле дә карт солдатлар бар. (Карт солдат дип, кайтырга алты ай калган солдатларны атыйлар.) Аларга мондый гына бәрелешләр һәм корбаннар гадәти күренеш. Шуңа да алар бүгенге бәрелешне бар дип тә белмәделәр. Үзара шау-гөр килеп, чәй кайнатырга тотындылар.

Лейтенантның кулбашын пуля сыдырып үткән. Ярасы куркыныч түгел. Вертушка белән килгән врач аны тылга алып китмәде. Шуңа да аның кәефе юк иде. Күренеп тора: бу бәрелеш аның беренче алышы булып, бик нык курыккан иде. Ярый картлар тәҗрибәле, аның хәлен аңлап, тынычландырган булдылар.

Позицияне ничек булдыра алалар, шулай ныгыттылар. Тирә-яктан ташлар җыеп, бруствер сыман нәрсә дә әмәлләп алдылар. Дүрт якны да утка тотарлык итеп, өч пулемётны урнаштырдылар. Берсен, алай-болай килеп чыга калсалар дип, кышлак ягына каратып куйдылар. Бүгенге мәхшәрдән халык нык арып талчыккан иде. Шуңа да төнге сакка барасы солдатларга ял итәргә кушылды. Кая инде ял итү дигән нәрсә?! Ятасың шулай оеп, ни уяу, ни йокылы дигәндәй. Әйтерсең лә, исерек кеше. Башыңда әллә нинди саташулы куркыныч уйлар бөтерелеп йокларга ирек бирми. Ә старикларга кушмасаң да, башларын ташка терәп булса да, йокларга әзерләр. Алар, эт каешына әйләнеп, мондый гына хәлләргә өйрәнеп беткән.

Төн болай тыныч үтте. Совет солдатларын бимазалаучы булмады. Күрәсең, кичәге алышта рухларның да тетмәсе тетелгән. Һавадан вертушкалар белән ярдәм булмаса, бу алыш безнекеләр өчен бик фаҗигале тәмамланачак иде. Ходай саклады.

Кышлакны тикшереп чыгарга дигән боерык булды. Тик аның нәрсәсен тикшерәсең инде? Картлар фаразлавы буенча рухлар тау-таш арасына кереп поскан. Алар берничә көн үзләренең өннәрендә утырачак. Ә авылдагы рухларның чынлап та рух икәнен ничек исбат итә аласың? Бу мөмкин түгел. Шуңа да коралларын шалтыратып, кышлак урамыннан әле тегеләй, әле болай үткән булдылар. Урамда очраган һәр кеше тизрәк капка артына, йә булмаса берәр тыкрыкка борылып, каядыр кереп качарга тырыша. Шуравилар күзеннән югалырга өлгерә алмыйча, каршы очраган бала-чага һәм ирләрнең күзендә йә курку, йә нәфрәт чаткылары гына ялтырый. Башын-күзен каплап, күбәләк курчагына охшап, карага төренгән хатын-кызны бөтенләй күрермен димә. Командир, бу эшнең файдасыз икәнен төшенеп булса кирәк, тиздән моны туктатты. Кышлак тирәсен җентекләбрәк тикшереп чыгарга боерды. Позициядә калганнарга урнашкан урынны ныгытып, окопларны тирәнәйтергә кушылды. Тирә-якны тикшергән булдылар. Тик ерактагы сөзәк тау буенда көтү көтеп йөргән ике үсмерне генә күрделәр. Алар янына бара башлагач, үсмерләрнең зуррагы елгага таба торып йөгерде. Солдатларның берсе, командир тарафыннан боерык булмаса да, малайны атып екты. Якынрак килеп карасалар, бу бөтенләй 12-13 яшьләрдәге генә малай иде. Солдатлар килә башлагач, башын куллары белән каплап, куркуыннан кычкырып еларга ук тотынды. Пуля малайның ботын үтәли тишеп чыккан, һәм ярадан кан ага иде. Картларның берсе, яралы килеш этләшеп ятмасын бу дип, калашкасын малайның маңгаена китереп терәде. Малай Ринатлар авылындагы теге оч Хәйбулла абзасы улына бик тә охшаган иде. Шуңа да Ринат малайны кызганып:

– Син нәрсә, «дед» башың белән шушы баланы атып үтерер идең мәллә? – дип, картны этеп җибәрде.

Яшь солдаттан моны көтмәгән карт, малайны онытып, аның изүенә ябышты. Тарткалашып алдылар. Карт усал иде һәм Ринатның битенә башы белән китереп бирде. Ул бераз артка янтаерга өлгерде. Һәм тегенең башы алай нык ук тимәде. Шулай да борыны канады. Тавышка лейтенант килеп җитте.

– Нәрсә булды?

– Менә малайны бастырганда абынып егылдым. Борын бәрелде.

Лейтенант солдатларның барысын да үзенең сынаулы карашы белән бораулап чыкты. Беркем дә ләм-мим дәшмәде. Чөнки әләкләшү дигән нәрсә монда юк. Командирның кушуы буенча малайның җәрәхәтен бәйләп, күтәреп алып кайтып, кышлак урамында очраган берәүгә тапшырдылар.

Малай юкка гына елгага таба йөгермәгәндер, рухларны искәртергә уйлагандыр дип, елга буен да тикшереп чыктылар. Тик анда шикле берни дә таба алмадылар.

Кичкә таба кышлактан солдатлар урнашкан калкулыкка таба ишәк җигелгән ике генә тәгәрмәчле арба килгәне күренде. Солдатлар ул-бу була калса дип, арбага таба бер пулемётны төзәп, бер миномётны әзерләп

куйдылар. Тик ишәкне бер карт кына бабай җитәкләгән, ул позициягә килеп җитәр-җитмәс туктап калды да кычкырырга тотынды. Карт солдатларны чакыра иде. Ике солдат аның янына барды. Командирның кушуы буенча картны әйдәкләп, җигүле ишәге белән позициягә ук алып килделәр. Карт ямаулы буй-буй сырган чапаннан иде. Башында бу якларда киеп йөри торган, түбәтәй дисәң хәтере калыр, шундый бер нәрсә элгән. Әфганча хали дигән нәрсәме инде. Ул, арбасына төртеп күрсәтә-күрсәтә, нәрсәдер сөйләргә тотынды. Арбада яралы көтүче малай ята иде. Ринат бу картны аңлады да, аңламады да, күп кенә сүзләре безнеңчә. Бабай үзбәк милләтеннән булып чыкты. Солдатлар арасында тылмач булмаганга, бабай сөйләгәнне аңламадылар. Ә Ринат бабайның бар сүзен дә аңлап бетермәгәнгә дәшмәде. Аннан да бигрәк таякның авыр башы алдан йөргән күп белүченең башына төшкәнен дә чамалый. Шуны уйлап дәшми калуны кулайрак күрде. Чөнки ул әле салага гына. Ә салагаларга юк-бар шикле һәм авыр-хәвефле эшләрне тагарга гына торалар. Шуңа да дәшми калуың хәерле генә түгел, ә алтынның алтыны. Бабай кырына җыелган солдатларның кемедер, ашаганнан соң ялгыш амин тоткан өчен «Мулла» кушаматы алган бер татар егетен чакырып карарга кирәк, диде. Мөгаен, ул аңлар диделәр. «Мулла» позициянең аргы ягындагы ташлар арасында сакта тора булып чыкты. Аны алып килделәр. «Мулла» бабайның арбада яткан яралы малайга карап сөйләвен тыңлап торды-торды да командирга карап:

– Картның сөйләвеннән шуны аңларга була. Малай ятим икән. Әти-әнисе үлгән. Башка кышлактан килеп, монда көтү көтә, ди. Үзебезгә дәваларга куша, – диде.

Санитар Васяны чакырып китерделәр. Ул яңадан яралы малайны карап тикшерде. Ике укол ясады. Әле командирга, әле «Муллага» карап:

– Мин нәрсә эшли алам инде? Кулдан килгәнен эшләдем. Ярасы бик алай куркыныч түгел. Сөяккә тимәгән. Пуля, үтәли тишеп, чыккан ягында бераз итен умырып алган. Тегәргә кирәк иде дә, миндә андый әйберләр юк. Шуннан инде мин хирург та түгелмен. Ике сәгать саен антибиотик укол кадап торырга кирәк. Югыйсә гангрена башланырга мөмкин, – диде.

Лейтенант уйга калды. Карт солдатларның әле берсенә, әле икенчеләренә карап, аларның сүзен көтә башлады. Картлар дәшмәде. Шуннан ул палаткага кереп китте. Аның рация аша база белән сөйләшкәне ишетелде. Күрәсең, анда урындагы халык белән низагка кермәскә, килеп чыккан четерекле хәлне ничек булса да тыныч юл белән көйләргә куштылар. Палаткадан ул үзалдына сүгенә-сүгенә килеп чыкты. Кичә һәлак булган мәрхүмнәрдән калган коры паекның икесен малайны алып килгән картка бирергә кушты һәм «Муллага» карап:

– Монда алып кала алмыйбыз. Иртәгә иртән яралыны тагы алып килсен. Шулай дип аңлат.

Федя, ә чынлыкта исә Фәрит исемле булган, тик күп вакыт «Мулла» кушаматы белән генә йөргән тылмачыгызның моңа бер дә исе китми иде. «Мулла» тек мулла. Федясына да, Фәрит, йә булмаса «Мулла» дип дәшүләренә дә һич кыенсынмады. Ул үзбәк картына татарчалап, иртәгә иртәнгә тагы уколлар кадап, җәрәхәтне дарулап, яңадан бәйләргә кирәклеген аңлата башлады. Федя, ягъни Фәрит шәһәрдә үскәнгә күрә, татарчасы такы-

токы гына булып, бабайга бик аңлатып бетерә алмады шикелле. Бу хәлне читтән генә күзәтеп торган Ринат аңа:

– Иртәгә җомга көн бит. Җомга көнне иртән килергә куш. Мөгаен, аңлар. Җомга көн диген, – дип, үзе дә сизмәстән әйтеп салды.

Башка эшләре булмыйча, бу хәлне күзәтеп торган унлап солдат, җәһәт кенә борылып, Ринат ягына карадылар. Картлардан кемдер:

– Вот ещё один басурман, – дип мыгырданып алды.

Аның ягына карачы да булмады. Карт та җомга сүзен ишетеп, Ринат ягына карап елмаеп җибәрде. Аннан әллә канәгатьсезлек билгесе күрсәтеп, әллә бүтән нәрсә әйтергә теләп, үзалдына мыгырдана-мыгырдана, кулларын бутап алды да, ишәген авыл ягына борып кайтырга кузгалды. Лейтенант җыелган солдатларга ризасызлык белдереп:

– Нәрсә авызыгызны ачтыгыз? Эшегез беткәнмени? Марш позицияне ныгытырга! Коралларыгызны чистартыгыз! Сержант Фёдоров, кайда, нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәт! Әнә теге яктагы окопларны тирәнәйтергә кирәк. Көньяк белән көнчыгыш яктагы окопларны бергә тоташтырыгыз. Менә бу якка ташларны җыеп өегез! – дип, күрсәтмәләр бирде. Һәм үзенең палаткасына китеп барышлый, сержантның Ринатка теге окопны тирәнәйтергә кирәклеге турында сөйләгәнен күреп:

– Ә аны минем янга чакыр! – дип, әмер бирде.

– Әнә, командир сине чакыра. Марш шунда!

Ринат кителенең өске төймәсен каптырганлыгын барлап, каешын әйбәтләп алды да командир палаткасына килеп керде һәм үрә катып, честь биреп:

– Иптәш лейтенант, рядовой Валитов сезнең боерык буенча... – дип әйтеп бетерә алмады, командир:

– Вольно!

– Откуда призывался?

– Башкортстан.

– Үзбәк телен кайдан беләсең?

– Мин үзбәкчә белмим. Тик безнең телләр охшаш икән. Шуңардан чамаладым.

– Яхшы. Тегеләй-болай кирәк була калса, тәрҗемәче Исламов Фәриткә ярдәмләшерсең. Аңлашылдымы?

– Яхшы, иптәш лейтенант! Аңлашылды!

Командир палаткасыннан чykканда, Ринатның башына шундый уй килеп китте: кара син аны, мәктәптә укыганда укытучылар рус телен камил өйрәнегез, тормышта гел кирәк булачак, башка милләтләр белән аралашу теле ул, рус теле – иң мөһим тел, диләр иде. Ә менә үз телен белүе дә бик ярап куйды. Аның теле дә – башка милләтләр белән аралашу өчен иң мөһим тел икән. Чынлап та үз ана телен камил белүе аңа алдагы тормышында нык ярдәм итте. Ярдәм итте генә түгел, күп бәла-казалардан саклап, ничәмә үлемнәрдән алып калды. Ә әлегә Ринат бу турыда белми һәм күз алдына да китерми иде. Әлеге минутта үзенең үзбәк телен дә яхшы аңлавын белде.

Төнлә шау-шу булып алды. Сакта торган каравылчы олы яшьтәге сәләмә генә киенгән әфганлыны атып үтергән булып чыкты. Ул:

– Тукта! Кем килә? – дип тә, атам дип тә кычкырган. Һавага да атып

караган. Әфганлы туктамаган. Җитмәсә позиция кырыннан гына үтә торган юлдан кышлакка таба торып йөгергән. – Бик тә шикле шәүлә күренде. Шуңа да атып ектым. Мин аны куркытырга теләп кенә аткан идем, – дип сөйләде.

Әмма әфганлының ярасы тирән иде. Ядрә күкрәгенә тигән булып чыкты. Мәетне тентеп тикшергәннән соң шул ачыкланды: билендәге матурлап сырлап эшләнгән кыныга салынган гади генә әфган пычагы һәм аркасындагы биштәрендә учакта пешергән көлчә-икмәктән башка нәрсәсе юк иде. Икенче ел хезмәт иткәннәрдән Ринат һәм аның кебек яшь солдатлар шуны белделәр. Монда яшәгән һәр адәм ун-уникe яшеннән үк билендә пычак йөртә икән.

Иртәнчәк яралы малайны уколга алып килгән карттан сорашып, шул билгеле булды: бу үлгән бәндә алар кышлагыннан булмыйча, ниндидер ерактагы кышлактан икәнен чак аңлата алды. Мәетне үзе белән алып китәргә тәкъдим ясалгач, бу тәкъдимнән кискен баш тартты. Көн кызу булганлыктан, аны юлдан читтәге бер калкулык битенә әштер-өштер күмеп, баш очына таш та бастырып куйдылар. Икенче көнне иртән үк ниндидер өч карт килеп, кабер кырында бик озак кына утырып, кире кайтып киттеләр. Күрәсең, кабер иясенә догалар укып, мөселманча соңгы йола үтәп, кадер-хөрмәт күрсәттеләр.

Командир әфганлыны аткан солдатка сакта уяу торганы өчен командование исеменнән рәхмәтен белдерде. Һәм тагы да тырышыбрак хезмәт итсә, мөгаен, ун көнлек ялга да кайтарырбыз әле дип вәгъдә итте. Кайбер солдатларның бу сүзләрдән күзләрендә көнләшү чаткылары ялтырады. Ринат та үзалдына:

– Бәхетле, – дип сөйләнеп куйды.

Кай арада кырына килеп баскандыр, үзе белән теге көнне чокырда яткан карт солдат:

– Кеше үтерү – бәхет түгел, – дип төрттереп алды.

– Нинди кеше булсын, рух бит ул. Син аны үтермәсәң, ул сине үтерәчәк. Дошман ул.

– Юк, син яшь әле, дөрес уйламыйсың. Ничек кенә булмасын, кеше ул. Ә менә без аларга дошман. Аның иленә басып кергән дошманбыз.

– Әфган хөкүмәте үзе безне чакырып китерде. Без интернациональ бурычны үтибез. Әфган халкына ярдәмгә килдек, – дип, Ринат карантин үткәндә, командирлар сөйләгән нотыкларны кабатларга тотынды.

Ә Руслан аңа астан гына көлемсерәп карап алды да:

– Ярар, бу турыда туктатып торыйк. Әлегә барыбер аңламыйсың. Вакыты җиткәч аңларсың әле. Монда хөкүмәт башында феодаллар утыра. Һәм алар халык түгел. Әйдә киттек. Политинформация дәресен әлегә ябык дип игълан итәм. Әнә безне көрәк-ломнар көтә, – дип, Ринатны үзләренә тәгаенләнгән сектордан окопны тирәнәйтергә алып китте.

Хәрбиләр әфган халкы – гади декханнар алдында ышаныч һәм ихтирам яулар өчен аларга төрле вак-төяк эшләрдә ярдәмләшергә тиеш иде. Шуңа да тәүге елны солдатларга ничек кенә булмасын, корал кулланырга катгый тыелды. Әмма халык тарафыннан шуравиларга карата каршылык көчәеп, корбаннар күбәя башлагач, корал кулланып җавап бирергә рөхсәт ителде. Шулай булуына карамастан, гади халыкка ярдәмләшергә дигән күрсәтмә үз көчендә калды.

Яралы малайны көн дә уколга алып килә торган карт үзбәк кичә дә, бүген дә килмәде. Шуңа да командир өч солдатны ияртеп, санитар Васяны кышлакка җибәрде. Яралы малайны карап-дәвалаган булып, кышлакны җентекләп тикшереп, разведка үткәреп чыгарга иде исәбе.

– Ул-бу шикле кешеләр, кораллы сакалтайлар күренмиме? Урамнан, йортлар арасыннан игътибар белән тыңлап үтегез, ирләр шаулашмыймы, корал-мазар шалтырамыймы? Кыскасы, күргән-ишеткәннәрегезне хәтерегезгә сеңдерегез. Кайткач, барысы турында да миңа җиткерергә! – дип, катгый күрсәтмә бирде.

Бу кышлак күпчелеге үзбәкләр яшәгән кышлак булганлыктан, тылмач урынына Ринатка барырга боерылды. Карт солдатлардан, мондагы халыкның астыртынлыгы һәм явызлыгы турында күп ишетергә туры килгәнлектән, анда барырга ашкынып торучылар юк иде. Шуңа да алар кышлакка кәефсез генә кузгалдылар.

Төш вакытына әле иртә иде. Басуда эшләп йөргән әфганлылар кышлакка таба китеп баручы шуравиларны күргәч, тизрәк берәр калкулык артына ышыкланырга, һич булмаса басуда үскән арпа-бодай арасына чүгәләргә ашыкты. Берничәсе күрмәмешкә салышты. Әмма барысы да шикле кызыксыну белән астан гына аларны күзәтте. Юл кырындагы басуда эшләп йөргән ике әфганлы, кулларын күкрәгенә куеп, мондагы гадәт буенча бераз гына иелеп исәнләшеп алдылар. Солдатларга командир итеп билгеләнгән сержант та аларга охшатып исәнләште. Һәм үзенең кул астындагыларга да шулай итәргә кушкач, барчасы да ул кушканча эшләделәр. Бу хәлдән тузанлы юлдан кышлакка баручы солдатларның кәефләре бераз күтәрелә төште.

Кышлак урамында чыр-чу килеп уйнаган бала-чага тилгән күргән тавык чебешләре шикелле кайсысы кая качып, юк булды. Арык янында үскән тут агачы күләгәсендә эссе кояштан качып, бер карт кына үз уйларына бирелеп утыра иде. Әйтерсең лә аңа бу хәлләр күптән таныш. Һәм ул бернигә дә гаҗәпләнми иде. Егетләр сержант өйрәткәнчә, үзбәкчәләп, кулларын күкрәккә куеп, бил бөгә биреп, баш иеп исәнләштеләр. Шунда гына әфган карты аларга игътибар итеп, нәрсәдер укынып, әппәр әйтеп куйды. Ринат та бабай кебек битен сыпырып алды. Аңа башкаларның гаҗәпләнеп карауларына ул авылдагы бабайларның бер-берсе белән исәнләшкәч, әппәр әйтүләрен исенә төшереп:

– Шулай кирәк. Бу картларны хөрмәтләүгә керә, – диде.

Төркем командиры вазифасына билгеләнгән сержант та, теләр теләмәс битен сыпырып куйгач, аңа башкалар да иярде. Аларның язмышы бу кышлакта кыл өстендә торганлыгын һәм шушы кешеләргә бәйле икәнен сержант аңлый иде. Тик ул шуны белмәде. Әфганлылар үзләре яшәгән кышлакта һәм өйләренә кергән чит кешегә һич тимәсләр. Чөнки ул, кем булуына карамастан, кышлакның кунагы. Ә кунак – ул изге, хәтта коралллы булса да. Тик коралын гына эшкә җикмәсен. Корал кулланган булса инде, ул чакта башка мәсьәлә.

Бабайдан теге җәрәхәт алган малай кайда торганлыгын сорашырга тотындылар. Бабай әллә үзе шуравиларны аңламады, әллә башка сәбәп белән «белмим» дигән кебек башын гына селкеде. Ринат ничек кенә аңлатып

караса да, бабай бернәрсә дә белми иде шикелле. Якындагы капкадан 10-12 яшьләр тирәсендәге бер малайның башы күренде. Карт аңа дәшкәч, малай курка-курка гына, карт янына килде. Бабай аңа нәрсәдер әйтте. Малай үзе артыннан барырга кушып, шуравиларга кулы белән ишарәләде дә, аларга шикләнебрәк карый-карый, алдан атлады. Малай бер тыкрыктан кереп китте. Шуннан зур гына капкалы бер йорт алдына туктап, башы белән ымлап, йортка күрсәтте дә, эшем бетте дигән кебегрәк ашыга-ашыга, кире китте. Бераз баргач туктап, ерактан гына шуравиларны кызыксынып күзәтә башлады. Бу йорт бүтәннәргә караганда, үзенең түбәсе белән аерылып тора. Түбәсе кыеклап калай белән ябылган. Һәм йортка керә торган бизәкле капкасы да ачык булып чыкты. Солдатлар йортка үтмәделәр. Командир капканың келәсен шакылдатып алды. Озак та үтми, ризасызлыгы йөзенә чыгып, «тагы монда кемнәр йөри инде» дигән кыяфәттә бер хатын күренде. Чит кешеләрне күрү белән, куркуыннан нindидер бер аваз чыгарды да тизрәк битен каплап, йорт эченә кереп югалды. Шул ук минутта дияргә була йорттан бер матур гына сакаллы ир капка алдына чыкты. Ринат ничек кенә теге яралы малай турында сорашса да, ир аларны аңламады. Шуннан Ринат теге ишәк белән килгән бабайның исемен исенә төшереп, Ширали, Ширали, диде дә чатанлап, теге малайның аягы яралы икәнен аңлатырга тырышты. Васяның санитар сумкасыннан бинт һәм дарулар алып күрсәткәч кенә, теге адәм төшенде, ахры. Солдатларны өйгә чакырды. Тик курку дигән нәрсә егетләрдә көчле иде. Алар йортка үтмәделәр. Теге бәндә йортка кереп китте. Ачык капкадан аның йорттагыларга нindидер күрсәтмәләр бирүе, йортта тагы кемнәрнеңдер шәп-шәп атлап, әрле-бирле үтеп китүләре күренде. Шуннан чутыр кара 6-7 яшьләрдәге ике әфган малае килеп чыктылар да кызыксынып, солдатларны күзәтә башлады. Эчтән аларга нindидер хатын кычкырды. Малайларның елмаеп торган йөзенә шундук курку йөгерде. Һәм алар ничек пәйда булсалар, шулай ук бик тиз капка артына кереп качтылар. Озак та тормый теге ир нindидер төенчек тотып, яңадан солдатлар янына килеп чыкты һәм үзе артыннан әйдәде.

Яралы малайны караучы карт кышлакның теге башындарак тора икән. Бераздан аның өе янына да килеп җиттеләр. Капка монда да бикле түгел иде. Капка дисәң хәтере калыр, ни ишек, ни капка дигәндәй, чак эленеп торган бер нәрсә инде. Ул авыр ыңгырашып шыгырдый-шыгырдый, эчкә ачылды. Егетләр тагы урамда көтәргә чамалаганнар иде дә, ир, санитар Васяны җитәкләп дигәндәй, эчкә үтәргә өндәде. Санитарның үзен генә йорт эченә кертеп җибәрергә шикләнделәр. Барысы бергә сак кына йорт алдына үттеләр. Йорт бик ярлы иде. Йортта ишексез бәләкәй генә ике каралты, алар алдында читтәрәк тандыр дигән мичләре күренә. Өй почмагына терәлеп дигәндәй, озын гына чинар агачы үсеп утыра. Каралты алдында унлап тавык белән ике әтәч һәм инде чебешләре күгәрчен зурлык булып үсеп килгән бер чебешле тавык, «корт-корт» килеп, тибенеп йөри.

Өйдән карт кына бер кортка килеп чыкты. Солдатларны күреп, бөтенләй курка калды. Ишек төбендәге урындыкка утырып, нindидер дога укып, битен сыпыра башлады. Шуравиларны озата килгән ир карчыкка нәрсәдер сөйләргә тотынды. Алар шәп-шәп сөйләшкәнгә, төркемгә тылмач итеп җибәрелгән һәм әфганлыларның һәр сүзен тәрҗемә итәргә тиешле Ринат

аларның шыр-быр килеп сөйләшүеннән берни дә аңламады. Озатучы ир карчыкка кулындагы төенчекне тоттырды да Васяны җиңеннән тотып, үзе артыннан өй эченә әйдәде. Башкалар да аның артыннан ияргергә чамалаганнар иде дә, сержант туктатты. Ринатның аркасыннан этә биреп, санитар артыннан керергә кушты. Эчкә үттеләр. Йорт эче дә бик ярлы иде. Тыштагы эссе тынчу һавадан өй эченә үтү базга төшкән кебегрәк булды. Балчыктан өеп салынган яссы түбәле өйдә салкынча һәм җиләс икән.

Малай идәндә иске палас-юрганнар өстендә утырып тора. Яктыдан ярым караңгы өй эчендә авыруның җәрәхәтен карарлык түгел иде. Шуңа да Вася:

– Басурманнарыңа әйт, авыруны тышка, яктыга алып чыксыннар, – диде.

– Алар минеке түгел, – дип, Ринат та үз чиратында төртелеп куйды.

– Син, салага, әйткәнне үтә! Тәрҗемә ит!

Вася бер ел хезмәт иткән «черпак». Шуңа да яшь солдатлар алдында үзен картлар кебек һавалы тота. Ринат сүз көрәштереп тормады, чөнки вакыты ул түгел дә, бу «черпак» азактан барыбер үч алып, берәр аламалык эшләячәк. Ринат бар сәләтен җыеп, белгән үзбәк сүзләрен кушып, яралыны тышка, яктыга алып чыгарга кирәклеген аңлата башлады. Аңладылар. Санитар, яралыны карап, җәрәхәтенә дарулар сөртеп, арт ягына ике укол кадады. Малай бик түземле иде. Вася үз эшен башкарганда, тик иренен тешләп, йөзен генә сытып күзеннән бер-ике бөртек яшь кенә күрсәтте.

Өй эченнән кортка чыгып, солдатлар белән килгән әфганлыга нәрсәдер аңлатырга тотынды. Әле Васяга карап, әле алачыкның берсенә күрсәтеп-күрсәтеп сөйләде. Әфганлы санитарны алачык эченә чакырды. Монысын инде Ринат тәрҗемә итмәсә дә, аңларга була иде. Алачыкка үттеләр. Сәке сыман нәрсә өстендә әбинең карты, малайны уколга йөрткән бабай ята иде. Аягы шешкән икән. Хәтта чәлтере эренләп чыккан. Санитар шеш урынын йода белән эшкәртеп, шешне ярды. Бабай кеше ул кадәр үк түземле булмыйча, шешне ярганда кычкырып ук җибәрде. Вася җәрәхәтне дарулар белән эшкәртеп, шеш тирәли аягына берничә урынга уколын да кадады. Җәрәхәтне бинт белән бәйләп куйды.

Эшне бетереп, бабай яныннан чыгуга, карчык аларны чәй табынына чакыра башлады. Ринат моны тиз аңлады һәм командирга үзе аңлаганча тәрҗемә дә итте. Аларны бу йортка алып килгән әфганлы да чәй эчеп китәргә тәкъдим ясады. Тик сержант катгый рәвештә баш тартты. Егетләрнең чәйләп алырга бик теләкләре булса да командир ризалашмады.

Теге бай йорттан килгән озатучы әфганлыга рәхмәтләр әйтә-әйтә кайтырга урамга чыктылар. Ә урамның ике башында да ыбыр-чыбыр бала-чага җыелган. Барысы да солдатларны күзәтә. Солдатлар килеп чыгуга, кайсысы кая качып та беттеләр. Егетләр килгән урам-тыкрыклар аша, командир кушканча тирә-якны җентекләп күзәтә-күзәтә, кайтыр юлга чыктылар. Кышлакта ул-бу шикле кешеләр, кораллы сакалтайлар күренмәде. Гомумән, кышлакта тыныч иде.

Төш вакыты җитте. Кояш рәхимсез кыздыра. Һавада һичбер болыт әсәре күренми. Үлән арасында туктаусыз чикерткәләр чыркылдавыннан башка бер җан иясен күрмәссең. Тик биектә-биектә берничә тилгән баласы гына үзләренең әниләрен чакырып чикылдашып очалар. Басуда эшләп йөргән кешеләр дә күренми. Алар да эсседән качып, өйләренә таралышкан.

– Эх, су коенып алырга иде, – дип куйды Вася.

– Туйганчы чишмә суы эчсәң дә шәп булыр иде, – диде сержант.

– Һе, үзең теге карчык чәй эчәргә чакыргач рөхсәт итмәдең. Хәзер чишмә суы эчәсең килгән, – дип куйды Вася.

Сержант атлаган җиреннән туктап, бөтен төркемгә карап алды да битеннән аккан тирен баш киеме белән сөртә-сөртә:

– Син, санитар кисәге, белергә тиешсең. Монда сиңа тәмле чәй, мул ризык тәкъдим итеп агулап куюлары да бар. Әфганлылар кулыннан бернинди ризык та, эчемлек тә алырга ярамый. Агулану очраклары җитәрлек.

– Үзләренә ярдәм иткән кешене агулыйлар димени. Малаен дәвалыйбыз, бабасын даруладык. Берәр чынаяк чәй эчкәннән әллә нәрсә булмас иде, – дип, санитар һаман үзенекен сөйләде.

Сержант сүзгә әвәс булмыйча, юкка тел чарлаганны бик өнәп бетерми иде. Шуңа да катгый гына:

– Сафта быкылдап бармаска! – дип куйды. Шуннан бераз дәшми генә баргач, күрәсең, сүзсез бару аны да ялыктырды, ул:

– Иң яхшысы, син Валяң белән ничек төн кунганыңны сөйлә. Хет атлавы күңеллерәк булыр, – дип, ефрейторга дәште.

Ә инде тегесенә шул гына кирәк, ничәнче тапкыр яңадан сөйләргә тотынды. Ул сөйләгән саен ниндидер яңартулар кушарга ярата. Әле дә шулай булды. Ә Ринат хикәятне яттан белә. Шуңа күрә аның сөйләвенә игътибар итмичә, авылда калган Галимәсен уйлады. Галимә аның кызы түгел,  аның белән Вәсил йөри. Тик кыз гына гел Ринатка тартыла. Ул Ринатка да бик ошый. Тик Ринат Галимә белән дусларча мөнәсәбәттә калырга тырыша, чөнки алар Вәсил белән дус. Шуңа да дусты күз атып йөргән кызны тартып алырга күңеле тартмый.

Ринатның тәмле уйларын сержантның:

– Уң яктагы тау битенә игътибар итегез! – дигән боерыгы бүлдерде.

Барсы да шул якка күз ташлады. Тик тау битендә шикле нәрсәләр күренмәде. Ниндидер бер җайдак кына атын җай гына атлатып,ерактагы тау битеннән каядыр китеп бара иде. Менә ул да каршыдагы биек булмаган тау артына кереп югалды. Башкача шикле нәрсәләр күренмәде. Шулай эсседән әлсерәп, лагерьга кайтып җиттеләр. Барча күргән-белгәннәрен лейтенантка җиткерделәр. Тирә-як тыныч иде. Беренче көндәге рухлар һөҗүмен искә алмаганда, әйтерсең лә сугыш бөтенләй юк. Шул ук чикерткәләр тавышы, шул ук югарыда-югарыда тилгән балаларының пипелдәп кычкыруы да, тау буенда йөргән сарык-кәҗә көтүе. Иртә-кичләрен теге кышлак өстеннән күтәрелгән сыек кына төтен баганалары да шул ук. Кайчакны җил авыл ягыннан искәндә, намаз вакыты җиткәнне искәртеп, тонык кына азан тавышы ишетелеп куя. Һичнәрсә сугыш барганын хәтерләтми. Тик хәрбиләр урнашкан лагерьда гына ниндидер киеренкелек. Теге көндәге бәрелешне көн саен диярлек искә төшереп гәпләшеп-бәхәсләшүләр бераз тына төште. Лагерьдагы хәрби тормыш көн саен бер җай белән үтә торды. Ринат кына тылмач роленә башы-аягы белән чумды. Лейтенант биргән «Рус-пуштун һәм пуштун-рус» сүзлеген кызыксынып өйрәнә башлады. Дөресрәге, әфганлылар пуштун телендә һәм үзбәкләр күпләп яшәгән җирдә үзбәк телендә сөйләшәләр. Үзбәк теле безнең телгә якын. Шуңа да

аңлавы җиңелрәк. Ә менә пуштун теле башкача – авыр. Шулай булуына карамастан, күп сүзләр безнең сүзләргә охшаш.

Ринатлар көн дә дүртәүләшеп кышлакка теге малай белән картка уколлар кадап, җәрәхәтләрен бәйләргә йөрделәр.

Санитарның:

– Малай белән картның хәле көннән-көн яхшыра бара. Шуңа да алар янына көн саен бармасак та була, – диюенә, командир:

– Малай белән бабай безгә шайтаныма да кирәкми. Сугыш корбансыз булмый. Ә менә разведка – кирәк нәрсә. Ул сугышта иң мөһиме. Сез кышлакка аларның яраларын бәйләргә генә йөрмисез. Сез разведкага йөрисез. Моны барыгыз да колагыгызга киртләп куегыз! – дип кисәтте.

Сүз шуның белән бетте. Ринатлар төркеме инде ничәнче көн тагы разведкага, ягъни малай белән картның яраларын эшкәртергә кышлакка киттеләр.

Ә бу вакытта төп базага штабтан яңа күрсәтмә килде. «Кандагар шәһәре тирәсендә рухларның бик зур көчләре туплана башлаган. Шуңа әзер торырга кирәк. Мөгаен, алар безнең көчләргә каршы ниндидер операция әзерлиләр. Безнең позицияне ныгыту өчен һәм шул юнәлештәге көчләрне Кабул шәһәренә бара торган юл янына шул тарлавыкка күчерергә» дигән яшерен боерык килеп төште. Боерыкта: «Кичектергесез эшләргә!» – дигән катгый күрсәтмә дә бар.

Боерык үтәлергә тиеш. Радист яшерен шифрограмманы командирның кулына тоттыру белән боерык кичектергесез үтәлә башлады. Лагерь, әйтерсең лә, кырмыска оясына таяк тыккан шикелле мәш килеп, юлга җыена башлады. Ул арада һавада вертушка һәм ерактагы юлдан ике БТР килгәне күренде. БТРлар лагерьга якын ук килә алмадылар. Юл юк иде. Ә вертушка лагерь янына ук килеп кунаклады. Аннан бер капитан төште. Ул лейтенантка пакет тоттырып:

– Кичектергесез, боерык белән таныш! – диде.

Лейтенантның пакетны ачып укыганын көтеп торды да аңа дәшәргә дә ирек бирмичә:

– Рация һәм радистны, барча кәгазь документлар белән, вертолётка утыртырга! Үзең солдатлар белән БТРга, марш! БТРлар кая барырга кирәклеген беләләр. Маршрут карталары аларда бар. Барыгыз, үтәгез!

Радистны җиһазлары белән тиз-тиләмән алып, вертолёт һавага күтәрелде. Лейтенантның фаразлавы буенча, очкыч башка позицияләргә юл алды.

Ярты сәгатьләп вакыт та үтмәгәндер, бөтен лагерьны тартмага тутырылган шырпы бөртекләре шикелле шыплап, БТРларга төяделәр. Урын бик кысан иде. Шуңа да чак сыеп кузгалып киттеләр. Шунда рухлар белән беренче көнне үк бәрелешкәндә, Ринат белән бер чокырда яткан карт солдат кышлакка ярдәм күрсәтергә китүчеләрне исенә төшерде. Лейтенант БТР командирына кичекмәстән туктап, кышлакта калган солдатларны барып алырга кирәклеген әйтте. Тик БТР командиры сәгатенә карап:

– Без болай да графиктан соңга калдык. Ниндидер ике-өч солдат өчен бик мөһим булган хәрби операцияне туктатып булмый. Нәрсә генә булуына карамастан, безгә билгеләнгән квадратка шул-шул сәгатькә барып җитәргә кушылды. Бу приказ! Һәм бу кичектергесез үтәлергә тиеш!

– Егетләр кызганыч. Юкка гына харап булулары бар. Ярый да бит башлары эшләп, безнең эздән килсәләр.

– Кайтырлар, юк өчен хафаланма. Төп базага моннан бер утыз чакрымлап булыр. Йөгерә-атлый кайтканда, биш-алты сәгатьлек юл. Кулларында шул автоматлары гынадыр бит?

– Шулаен шулай да ул. Тик без позициядән киткәнне белсәләр, кышлактагы дошман яклылар аларны тотып алырга мөмкин.

– Аламалыкны алдан ук уйлап, карга кебек каркылдап чакырырга ярамый. Тегеләй-болай була калса, солдатларыңа әйтеп куй. Хәрби задание-разведкадан вакытында кайтмадылар дияргә онытмасыннар. Кышлак артындагы тауда атыш тавышлары ишетелде. Мөгаен, рухларга тап булганнардыр, дисеннәр. Исән булсалар кайтырлар. Син миңа бу турыда сөйләмәдең. Мин ишетмәдем. Яшьсең шул әле. Аңлап бетермисең. Боерык ничек кенә булмасын, боерык инде ул. Нинди булуына карамастан үтәлергә тиеш!..

Ә бу вакытта өч шурави бабай өендә әзерләнгән гади генә чәй табынында тәмләп-тәмләп, тирләп-пешеп, әфган чәе эчеп утыралар иде. Башта чәйдән баш тартырга уйлаганнар иде дә «черпак» Вася:

– Юк өчен куркып торыр чак түгел әле. Лагерьга кайтып җиткәнче байтак вакыт үтәчәк. Тамак кипте. Пулядан үләргә насыйп булса, чәй эчкәннән генә харап булмабыз әле, – дигәч, сержант та ризалашты.

Табын артында Вася тагы телен чарлап:

– Күпме ярдәм иттек. Үзебез ашамыйча күпме коры паекны аларга китердек. Безгә каршы аламалык эшләсәләр, басурманнарның Алласы аларның башларыннан сыйпамас. Шулаймы, басурман калдыгы?

Бу «черпак» урысның Ринатка чираттагы төртелүе, аны кимсетергә тырышуы иде. Ринат дәшмәде. Әфган чәе бик тәмле иде. Ә сержант «черпак»ка ачуланып:

– Син нәрсә? Телең белән чүп бутыйсың. Аппетитны бозма. Югыйсә мин маңгаеңа биреп, мөгезеңне кәкрәйтергә дә булдыра алам.

Сүз шуның белән тукталды. Әфган чәе генә түгел, ә әби пешергән көлчә дә бик тәмле иде. Бүген алар монда өчәү генә килделәр. Менә туйганчы чәйләр дә эчелде. Һәм шуравилар кайтырга кузгалды. Һәрвакыттагыча, урамда аларны еракта гына кызыксынып, бала-чага күзәтте. Егетләр сиземли иде: һәр йорттан аларны капка ярыкларыннан булса да карап озаталар. Шулай кышлак та артта калды. Егетләр чәй табынын исләренә төшерә-төшерә, лагерь ягына сузылган тузанлы юлдан иренеп кенә атлауларын белделәр. Кая ашыгырга? Һәркем үз уйларына чумды. Барысы да көндәгечә, кышлакта һәм басуда тыныч кына эшләп йөргән берничә үзбәктән башка алай-болай шикле адәмнәр күренмәде. Тирә-як тып-тыныч. Шул ук бытбылдыклар үлән арасыннан бер-берсенә сайрашып хәбәр бирешәләр. Шул ук йомраннар, бу өч солдатны күреп, сызгырышып куялар. Ринат кына, гадәтенчә, һәр чокыр, һәр таш артын, тау битләрен күзәтеп атлавын белде. Көтмәгәндә, күзе үзләре урнашкан биеклек түбәсенә төште. Позициядә палаткалар да, радиостанциянең антенна мачтасы да күренми иде. Дертләп китте. Хәтта йөрәге кысылып куйды. Һәм ул шып туктап калды. Үзеннән артта атлаган сержант аңа килеп бәрелде. Командир

авызын ачып, нидер әйтергә әзерләнгән иде дә Ринатның лагерь ягына ымлап күрсәткәнен чамалап, карашын шунда текәде. Лагерь урыны буш. Чөнки лагерь, моннан ярты сәгатьләп булыр, боерык буенча башка урынга күчеп китеп бара иде. Сержантның хәтта йөзе агарып китте. Ул бик яман итеп, бер сүгенеп алды да лагерь булырга тиешле калкулыкка таба торып йөгерде. Ринат та, билгеле, артык сораулар бирмичә аңа иярде. Алардан алда авыз эченнән нидер көйләп барган «черпакны» да узып киттеләр. Ул инде:

– Сез нәрсә? Ни булды? – дип кенә дәште дә алар артыннан йөгерергә тотынды.

Эшнең нидә икәнен чамалап алды, ахры, ул инде кычкырып ук сүгенә-сүгенә, лейтенантны, лагерь белән бергә үзен ташлап киткән иптәшләрен сүгәргә тотынды.

Тыннары бетеп егылыр чиккә җитеп, лагерь урынына килеп җиткәндә, анда буп-буш иде. Тик кухня дип атап йөргән палатка булган урында бер өем буш консерва банкасы һәм пакет өеме, катыргы кисәкләре генә аунап ята. Бергәләшеп, буш лагерь биләмәсен җентекләп карап чыктылар. Сержант тешләрен кысып:

– Вәт кабахәтләр! Ичмаса бер-ике коры паек калдырсалар, ни булыр иде. Тагы бер атналык запас бар иде бит, – дип куйды.

«Черпак» бөтенләй елап җибәрде. Ул инде бертуктаусыз:

– Иптәш сержант, командир! Хәзер нәрсә эшлибез инде? Безгә нәрсә була? Бер сүз белән әйткәндә, капут. Аңлыйсыңмы? Капут.

Фельдшер шәһәр егете иде. Ул шушы яшь кенә гомерен гел күмәк кешеләр арасында үткәргәнгә, шулай читтә, бигрәк тә таныш булмаган таулар арасында өчәү генә калуны дөнья җимерелүгә, катастрофага тиңләде. Аңа ияреп, Ринат та үзен ничектер борчулы сизә башлады. Аның авылда печән әзерләгәндә, үз биләмәләрендә өчәр-дүртәр көн ялгызы гына урманда үткәргән чаклары күп булды. Әтисе ашарга алырга авылга кайтып киткәндә, андый ялгыз калулар еш була иде. Җитмәсә, якында гына аю биләмәсе. Аю туры килгәндә, үзенең монда хуҗа икәнен кешеләргә искәртеп, өеп куелган чүмәләләрен, йә булмаса чабылган печән пакусларын туздырып китәргә дә күп сорамый. Кайбер төннәрне ачуланып, ухылдап, пошкырып, яшь агач-куакларны сындырып йөри. Ул чакта учактагы утны төне буе туктаусыз ягып, утка чи үләннәр салып, төтен җибәрергә кирәк. Аю төтен исен яратмый, тизрәк читкә китәргә тырыша. Шуңа да Ринат бу хәлләргә әллә ни борчылмады. Тик «черпак»ның лышкылдавы гына күңеленә тия башлады. Ирексездән, теге көндәге рухлар белән бәрелешкән чакны исенә төшерде. Әйе, бүген дә шундый засадага юлыксалар, эшләре бик шәптән булмас. Һәм ул бу куркыныч уйларны башыннан тизрәк куып чыгарырга чамалады. Печән чапкандагы чакларны, аюның кешеләрне куркытырга теләп кылган усаллыклары турында уйларга тырышса да, барып чыкмады. Алдагы билгесезлек һәм үзләренең әлеге хәлләре күңелен борчып, йөрәген кимерде.

Санитарның паникага бирелеп:

– Нишләргә, хәзер нишләргә кирәк? – дип еламсыравына Ринат тамагын кыргалап:

– Уйларга кирәк, – дип куйды.

Сержант аның бу сүзен эләктереп һәм «черпакка» усал җикереп:

– Шыңшыма! – дип куйды. Һәм дәвам итеп: – Минә хәзер башыгызны эшләтегез! Уйларга кирәк! Молодой дөрес әйтә. Уйларга кирәк!

Һәм ул яндагы казылып бетмәгән пулемёт позициясе төбенә төшеп чүгәләде дә:

– Паникасыз гына! Кемдә нинди фикер бар? Чокырга төшеп утырыгыз! Флаг кебек җилфердәп тормагыз! Бер-ике сәгатьтән монда рухлар киләчәк. Ярый әле ул кадәр вакыт үтсә, рәхмәт әйтерсең. Ярты сәгать тә үтмәскә мөмкин. Алар безнең бу позициянең ничек корылганын һәм безнең нәрсә ашап, нәрсә эчкәнне энәсеннән җебенә чаклы тикшереп чыгачаклар. Алар булмаса, кышлак халкы киләчәк. Чөнки без тирә-якка миналар урнаштырып өлгермәдек. Дөресрәге миналарны китереп җиткермәделәр. Кемдә нинди уй-план туды? Чыгарып салыгыз! Йә, салабон, син нәрсә уйлыйсың? – дип, ул иң элек Ринатка мөрәҗәгать итте.

– Мин нәрсә әйтә алам инде? Җәһәтрәк төп базага китәргә кирәк. Моннан тизрәк табан ялтырату ягын карыйк.

– «Черпак», синдә нинди өмет-ышаныч пыскый?

– Миндә бернинди дә фикер-өмет юк. Хәзер син – командир. Син уйла!

Сержант теш арасыннан читкә төкереп куйды да:

– Кайчакта бигрәк миңгерәү инде син. Ничек фельдшерга укыгансыңдыр? Анысы миңа билгесез. Ә син, молодой, дөрес фикерлисең. Сыпыртырга кирәк. Һәм никадәр моннан тизрәк табан ялтыратабыз, үзебезгә шулкадәр яхшырак булыр. Бер ун минут хәл алыйк та юлга кузгалабыз, – диде һәм чокыр төбендә һаман лышык-лышык килеп утырган «черпакка» карап: – Лышкылдавыңнан туктамасаң, шушында бәйләп калдырабыз. Бигрәк куркак, паникёр булып чыктың. Җитәр! – дип җикерде.

Теге тынып калды. Күрәсең, кайчак куркакны тагы да ныграк куркыту таман гына була. Һәм сержант үзалдына сөйләнә-сөйләнә фикер йөртә башлады. «Бергәләп атларгамы, әллә бер-беребезне күрә-күрә интервал белән барыргамы? Алай итсәң дә, берәм-берәм чүпләп бетерергә мөмкиннәр. Төнлә атласак, адашачакбыз, карта юк. Иң яхшысы көндез һәм бергә бару. Ни булса да, бергә күңеллерәк. Ярар, әзрәк хуш алдык. Кузгалырга вакыт. Ягез, Аллага тапшырдык. Син, молодой, үзеңнең мөселманча догаларыңны укы. Без үзебезнең догаларны укыйбыз. Ярар, Аллаһ безнең белән! Язмышыбызны Аның кулына тапшырабыз. Мәңге Алланы исенә дә төшермәгән сержантның бертуктаусыз Алланы исенә төшерүе Ринатны бераз аптыратты аптыратуын. Күмәк булганда гына бик куркытмый икән. Ә шушылай өчәү генә калгач, әллә нәрсәләр уйландыра. Бигрәк тә үзеңнекеләр сатлыкҗаннарча ташлап киткәч. Хет авыл ягына карап, бер-ике тапкыр миномёттан атарга кирәк булган. Шартлау тавышын алар һичшиксез ишетерләр иде дә тизрәк кайтыр якка сыпыртырлар иде. Җитмәсә, чәйләп утырган булдылар. Тамак тәмугка кертә менә шул була инде.

Сержант, егетләрне аптыратып, һич тартынмыйча өч тапкыр чукынып алды. Юлга кузгалдылар. Ашарга юк, хәтта эчәргә су да бик аз. Фляжкалардагы берәр литр су күпмегә җитә инде? Кояш ныклап кыздыра башласа, ике сәгатькә дә җитми. Һәркайсысында дүртәр магазин патрон

Барлыгы унике магазин. Бик нык саклап атканда да ун-унбиш минутлык нәрсә. Икешәр лимонкалары бар инде. Сержант егетләргә катгый гына:

– Син уң якны һәм арт якны күзәтеп бар. Ә син сул яктан күзеңне алма һәм арт якка да күз салгалап алырга онытма. Ал як һәм тау башлары минеке.

Шулай килештеләр. Йөгерә-атлый калкулыктан аска, юлга таба төшеп киттеләр. Юлга җиткәч тә, сержант йөгерүеннән туктамады. Әмма йөгерүен әкренәйтте. Хәзер салмак кына йөгерә башладылар. Берәр сәгать шулай лырт-лырт йөгерүдән тәмам һушлары алынды. Командир ролен үтәгән сержант аңлый иде, болай йөгереп, әллә ни эшли алмыйлар. Бу эсседә тагы берәр сәгать йөгерсәләр, соңыннан атлап барырлык та хәлләре калмаячак. Шуңа да бер уйсурак урында шып туктады да:

– Унбиш минутлап ял итеп алабыз, – диде дә, ухылдап, җиргә үк сузылып ятты. Башкалар да бер сүз әйтми-нитми, аның янына сузылдылар. Ул тау башларын күзеннән кичерә-кичерә: – Чынлап та безгә моннан тизрәк шылырга кирәк. Шуңа йөгердек. Качып китүчеләр җәяү атласалар, куып җитәргә ышаныч булыр иде. Күрәсез бит, ике БТРга төялеп киткәннәр. Ну инәләрен саткыры!

Сержант ямьсез итеп сүгенеп алды.

Йөгергәндә генә сизелмәгән икән, талгын гына җил искәләп ала. Нәкъ менә шул җил аларның колагына еракта күк күкрәгән сыман тавышлар алып килде. Командир, корт чаккандай, капыл торып утырды да ярым пышылдауга күчеп:

– Тавыш! Тыныгыз! Тыныгызны да арт ягыгыздан алып утырыгыз!

Тавышны егетләр дә ишетеп, алар да торып утырдылар. Тыннарын да чыгармый тыңларга тотындылар. Тик уң яктагы таулар ягыннан ниндидер кошның гына сайравы ишетелеп, якында гына үлән арасында чикерткәләр безелдәште. Бераздан тагын тонык кына шартлау тавышы ишетелгән кебек булды.

– Ишеттегезме?

Командир шат ялтыраган күзләрен егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күчерде. Егетләр колакларын торгызып, тыңлауларын дәвам итә-итә, сүзсез генә башларын кактылар. Ерактагы күкрәү тавышы тагы кабатланды. Монысы инде ачыграк ишетелде. Сержантның күзгә күренеп, кәефе күтәрелеп китте. Ул тантаналы тавыш белән:

– Безнекеләр рухларны миномёт белән үтүклиләр. Мөгаен, вертушкалар да килгәндер әле. Әйдәгез, егетләр, үзебезнекеләргә таба җил булып очыйк. Тавыштан чамаларга була, моннан унбиш-егерме чакрымнарда булырга тиешләр. Безнең бәхеттән ун-унбиш чакрымда да булырга мөмкиннәр. Тау арасында тавышны үзегез беләсез, ничек таралганын һич аңларлык түгел.

Алар тагын торып йөгерделәр. Йөгерү башта җитез булса да, берәр сәгатьтән тәмам салмакланды. Аннан бөтенләй атлауга күчтеләр. Бу кадәр йөгерүдән тыннары капты. Өсләрендәге китель манма су булды. Ә күктә кояш рәхимсез кыздыра.

Бу кадәр ялсыз йөгерүдән Вася бөтенләй мәлҗерәп, җебеп төште. Ул инде беркемгә дә карамый:

– Бетте. Мин бүтән бара алмыйм. Хет атып егыгыз, – дип, җиргә ауды

һәм еш-еш тын ала-ала: – Сезгә рәхәт, ә бит минем аркада – автоматтан башка, дарулар тулы санитар сумкасы.

Сержант барган уңайга артына да борылып карамыйча туктап калды. Ул да автоматын җиргә ташлап, басып торган урынында җиргә чүгәләде һәм тау башларына күзен йөгертеп, Ринатка:

– Нәрсә, салабон, син дә җебеп төштеңме? – диде.

Ринат та җиргә сузылып ята-ята:

– Әлегә түзәрлек, – дип куйды.

Аның да һушы алынган иде. Тик шәһәрдә үскән Вася кебек бөтенләй бетеренмәде. Ни дисәң дә, авыл малае. Мондый гына хәлләргә тарыганы бар.

Ун-унбиш минутлап ятып алгач, командир тагы:

– Әйдә, торыгыз! Кузгалырга кирәк. Болай ятып, Алладан мәрхәмәт көтеп булмый. Алга атлыйк.

Санитар бөтенләй еламсырап:

– Нигә тудым мин? Нигә шушы каһәр суккан армияга килдем? Хезмәткә бармый калырга да мөмкинлегем бар иде бит, – дип, инде хәзер елый ук башлап: – Хет шушында атып китегез, мин башкача бара алмыйм. Аякны көзән җыера башлады, – дип, сул аягындагы итеген салып, балтырын уарга тотынды. – Бу аяк минем тугызынчы сыйныфта укыганда сынган иде. Шуның зарары инде, – диде.

Сержант тәмам ачуы кабарып:

– Синең медицинаң нәрсә ди соң бу вакытта? Китапларыңда нәрсәләр язалар? Шул гына җитмәгән иде. Сумкаңда юкмыни шунда бирәр уколың? Кадап җибәр!

– Бар да ул, тик мин куркам. Үземә-үзем укол кадаганым юк.

– Кайда, нинди укол? Күрсәт әле!

Вася сумкасын актарып, уколлар арасыннан берсен чыгарып, командирга күрсәтте. Командир:

– Кайсы урында көзән җыера? – дип сорады.

– Менә бит. Үтерә инде.

Сержант аптырап карап торган Ринатка эндәшеп, күз кысып алды да:

– Тот! – диде. Үзе кырагай җәнлек җитезлеге белән аягын уып утырган санитарның өстенә менеп тә атланды. Һәм Ринатка: – Ныграк тот! – дип кабатлады. Анысы да эшнең кая таба борылганын чамалап, санитарның аягына ябышты. Вася аны-моны аңлап алганчы, сержант тегенең көзән җыерган балтырына уколын китереп тә батырды. Бу хәрби-кыр шартларында авыртудан була торган шокны баса торган әзер укол иде. Санитар тыпырчынырга да өлгермәде. Тик җир ертып:

–А...а..аа! – дип акырып алды да сүгенергә тотынды. Һәм лышкылдый-лышкылдый еламсырап: – Укол кадыйсы урынга башта йод сөртәләр. Югыйсә ярасы бозылырга мөмкин, – диде.

– Соң, сөрт! Нәрсә утырасың. Барысы да үзеңнең кулыңда бит, – диде командир, тегенең өстеннән төшә-төшә.

Бераздан Васяның бер якка кәкрәеп каткан аягы турайды. Күрәсең, көзән җыеруы басылды. Командир моны чамалап, Ринатка ымлап:

– Күтәр слабакның сумкасын. Мин автоматын алам.

Шулай иттеләр дә тагы юлга кузгалдылар. Әллә бераз ял итеп алу, әллә укол тәэсир итте, санитар да алар артыннан җәһәтрәк атлый башлады. Аның билендәге каешында эленеп торган өч магазин патрон гына калган иде. Флягасындагы суны ул күптән эчеп бетергән иде инде.

Бераз баргач, барысын да сискәндереп, каршыдагы тау артыннан ап-ачык итеп, бер-бер артлы ике ату тавышы яңгырады. Бу шомлы ату тавышы иде. Чөнки безнең «калашкаларның» тавышы болай яңгырамый. Ниндидер ят тавыш. Алда барган сержант уң кулын өскә күтәреп туктап калды. Бу аның туктагыз дигән ишарәсе иде. Тынып калдылар. Командир усал ысылдап:

– Яшеренегез! – диде дә, үзе юлдан читтә яткан олы гына бер таш артына посты. Аңа буйсынып, Ринатлар да артыннан иярделәр. Алар икесе дә ничек булса да, командирга якынрак елышырга тырышты. Шулай озак кына таш артында ятып, тирә-якны күзәттеләр. Андый-мондый шикле нәрсәләр дә күренмәде һәм башкача шик тудырырлык тавышлар да колакларына чалынмады. Табигать кенә барысына да битараф иде. Чикерткәләр үзләренең эчпошыргыч көйләрен сызгырды. Һавада сирәк-саяк тилгән тавышы һәм дә егетләргә таныш булмаган кошлар сайрашты.

Сержант тамагын кыргалап алды да:

– Беребезгә разведкага барып килергә кирәк булачак, – дип, санитар Васяга карады. Ул инде баягы хәлдән айнып бетмичә:

– Минем аяк бит, аяк. Аннан мине үтерсәләр, сезнең яраларны кем бәйли?

Командир, ачы лимон капкан шикелле йөзен чытып, бер Василийга, бер Ринатка карады:

– Рәхим итеп шыңшымый гына тор әле. Синнән башка да чиркангыч. Укшыта башладың, Васькин кот. Санитар хреновый!..

Бераз дәшми торгач, каршыдагы зур булмаган сөзәк тауга карап:

– Ярар, яшь шурави. Ни булса, шул була. Кемгәдер барырга кирәк. Бәхетеңне сынап карыйк. Кул артың ничек икән? Иптәш рядовой, бу ефрейтордан он да юк, йон да юк, – дип, башы белән ефрейтор чинлы санитарга ымлады. Һәм Ринатка кыскача гына күрсәтмәләр бирә башлады.

– Таштан-ташка кача-поса гына бар. Шул ук вакытта тирә-ягыңны һәм тау башларын да карарга онытма. Менеп җитәр алдыннан бөтенләй шуышып кына бар. Тау башында басып торган кеше әллә каян күренә. Кара, калкулык артында нәрсәләр бар. Нәрсәләр ишетелә, тыңла. Бу юл шул якка борыла. Аннан без теге вакытны засадага эләккән урын да күренеп торырга тиеш. Засада корырга бик уңайлы урын ул. Әйдә, братан, кузгал. Алай-болай шикле нәрсәләр күзеңә чалынмаса, баш киемеңне болгарсың. Санитар сумкасын калдыр. Җитте, үзе күтәрсен. Саклыкка ефрейторның ике лимонкасын да ал. Дөнья хәлен белеп булмый. Патроннарыңны саклап ат. Без ярдәмгә килеп җитәргә тырышырбыз. Әлбәттә, киләчәкбез. Айболит, лимонкаларыңны бир әле салабонга.

Санитар, зур канәгатьсезлек күрсәтеп, каешындагы лимонкаларны ычкындырып, Ринатка суза-суза:

– Нигә разведкага үзең генә бармыйсың? – диде.

– Цыц, черпак-чүмеч! Югыйсә тотканыңны сындырырмын. Унлап чакрым үтмәдек, җебеп төштең. Озакламый бөтенләй таралып китмәсәң ярый әле.

Миңа үземне дә, сезне дә исән-имин базага алып кайтып җиткерергә кирәк. Әйдә, туган, кузгал.

Ринат артык сүз катып тормыйча, йөгерә-атлый, ташлар артына кача-поса, кузгалып китте. Ярый әле тау битендә анда-санда төрле зурлыктагы ташлар тәгәрәшеп ята. Тау башына исән-сау менеп җитте. Командир өйрәткәнчә, азаккы дистә метрларны шуышып кына менде. Тик тау өстеннән алдарак тагы бер тау сырты барлыгы ачыкланды. Ул тау башыннан ачылган панорама-күренешне җентекләп өйрәнде. Шикле нәрсә күренмәгәч, алдагы тауга таба торып йөгерде. Ярый әле, ара әллә ни ерак түгел – дүрт йөзләп метр гына.

Кинәт борынына резина янган ис килеп бәрелде. Әллә ни уйлап тормыйча, кырдагы зур гына таш артына барып ятты. Җилнең кайсы яктан искәнен чамаларга тырышты. Юк, чамаларлык түгел. Карт солдатлардан күргәненчә, имән бармагын төкереклэп, өскә күтәрде. Җил алгы яктан аңа таба исә икәнен чамалады. Аңа да бик ышанмыйча, кырдагы тузганакның башын өзеп алып туздырып өскә атты. Тузганакның мамыгы җай гына артка таба очып китте. Талгын гына һава агымының аңа таба искәнен ачыклады. Шуыша-шуыша алга китте. Резина янган ис хәзер бигрәк тә нык сизелә башлады. Тау түбәсеннән алга карады. Каравы булды, барча тәненнән ток булып, курку хисе йөгереп үтте. Чынлап та еракта астан юл үтә, һәм иң куркынычы – юлда ике БТР янып бетеп бара. Ара ерак кына булса да, ул БТР тирәсендә үлеп яткан солдатларны ап-ачык шәйләде. Болар безнекеләр иде.

Озак күзәтте ул юлны, тик шикле берни дә күрмәде. Һавада гына үләксә козгыннарының тавыш биреп, бер-берсен чакырганнары ишетелде. Аһ, нәләт төшкере нәрсәләр. Кайдан сизеп алалар диген, дип уйлап куйды. Кабат, беренче тау түбәсенә, артка торып йөгерде. Үзен иптәшләре күреп калачагына ышангач кына, бер таш артына ышыкланып, афганка-эшләпәсен салып, аларга шартлы ишарә бирде. Алай гына да түгел, гимнастёркасын салып болгады. Күрделәр. Командир белән санитар шулай ук кача-поса, йөгерә-атлый дигәндәй, тауга күтәрелә башлады.

Алар килеп җитмәстән, Ринат тагы теге түбәгә торып йөгерде. Сержант та нәрсәдер чамалап, аның артыннан иярде. Түбәгә җитмәстән, Ринат бер зур гына таш артына посты. Кулын болгап, үзе кырына чакырды. Тыннары бетеп килеп җиткән иптәшләренә хәлне аңлатып бирде. Яшеренеп кенә, тау түбәсеннән асны күзәтә башладылар. Юлдагы ике БТРның тәгәрмәчләре янып бетеп бара. Тик бер БТР гына болай янганга охшамаган. Тирә-якны һәм юлны озак күзәттеләр. Һичбер шикле нәрсә сизелми. Мәет исен сизгән козгыннар гына бөтенләй әрсезләнеп, юл өстенә үк төшеп утырганнар.

– Тере кеше булса, козгыннар болай оятсызланмаслар иде. Шулай булгач, дошман юк дияргә була. Безнекеләрнең дә исән калулары шикле. Кузгалдык! Әмма барыбер сак булырга кирәк, – диде сержант.

Шуравиларның таудан кача-кача төшеп килүләрен күргән козгыннар читкәрәк очып киттеләр. Егетләр янган БТРлар янына килеп җиткәндә, алар һаман да һавага сасы ис таратып төтиләр иде. Тирә-якта безнең солдатлар ята. Бигрәк тә БТР тирәсендә күпләр. Күрәсең, түгәрәк оборона оештырырга чамалаганнар. Лейтенантның гәүдәсе дә шунда гына ята. Кырында тагы ике яшь солдат мәете. Бу солдатлар Ринатлар белән хезмәткә килгән Самара

егетләре. Ринат елап җибәрмәс өчен тешләрен кысты. Ә инде ефрейтор Вася бөтенләй җиргә капланып, истерикага бирелеп еларга кереште.

Сержант бөтен мәетләрне дә карап йөргән арада Ринат теге баштагы янмаган БТР янына барды. Тирә-ягын бик җентекләп карап чыкты. Астын да иелеп карады. Юк, шикле нәрсә күренми. Ирексездән кулы белән тимергә тукылдатып алды. БТР эченнән тонык кына:

– Кем анда? Үзебезнекеләр булсагыз, коткарыгыз мине. Ишектә растяжка. Чамалап, шартлый күрмәгез, – дигән тавыш ишетелде.

Нәрсә булса да, Ринат аптырамас иде, эчтән шундый тавыш килгәнгә, бөтенләй шыр җибәрде. Бер мизгел аптырап торды да, җай гына командирга сызгырды. Тегесе борылып карауга, бармагын иреннә тидерде дә, кулын болгап, аны үз янына чакырды. Сызгыру тавышын ишетеп эчтән тагы дәштеләр.

– Кем бар анда? Мине минага утыртып куйдылар. Сак булыгыз шартларга мөмкин.

Шунда Ринат түзмәде:

– Үзебезнекеләр. Без хәзер сине коткарырга чамалап карыйбыз. Урыныңда тик кенә утыр.

Сержант та килеп житте. Бераз гына киңәшләшеп алдылар. Һәм кабаттан җентекләп, БТРның ишекләрен карап чыктылар. Чынлап та арттагы ишектән нечкә генә тимерчыбык БТР астына таба сузылган иде. Күрәсең, мина куйган рух бик тәҗрибәле булмаган. Егетләр бу минаны тиз зарарсызландырды. Алар БТР эчендә кемне күрсәләр дә аптырамаслар иде, анда карт солдат Руслан утырганын күрделәр.

Ул ишек ачылган көе:

– Егетләр, мин лимонка өстендә утырам. Күрәсез бит, куллар өскә күтәреп бәйләп куелган. Селкенеп тә булмый. Менә утырам инде.

Ринат Русланга мөрәҗәгать итеп:

– Селкенмә! Үлсәк икәү үләбез. Хәзер чамалап карыйм.

Ринат сак кына кулы белән Русланның бот арасыннан аска кереп китте. Әһә, чамалап алды: лимонка нәкъ уртада урнашкан. Бармаклары белән сак кына капшап, аның ничек ятканын белде. Чека тоткасы аскы якта икән. Лимонканы селкетмәскә тырышып, ничек итсә итте, учына ала алды. Тотканы кысып, җай гына дустының астыннан шудырып чыгарды. Ярый әле, рухлар тагы берәр этлек-табышмак уйлап куймаганнар иде. Шулай да бәйләнгән кулларын ычкындырганчы, тагы бер карап, тикшереп чыктылар. Алай-болай шикле нәрсә тапмагач кына, Русланның кулын бәйләгән бауны кисеп алдылар. Аның инде шатлыгыннан күз яшьләре бәреп чыкты.

– Менә бит әй, егетләр, гомер бетмәгәч, сез дә исән, мине дә коткардыгыз. Рәхмәт инде, рәхмәт сезгә. Ә бит сезнең кышлакта калганыгызны лейтенантка әйттек. Ул БТРда приказ алып килгән капитан белән дә сөйләшеп карады. Анысы сезне көтеп торырга кискен каршы төште. Кышлакка барып килик дип тә сорадык. Юк, имеш, яшерен приказ. Кичекмәстән юлга кузгалырга. И баста! Менә нәтиҗәсе. Ярар, болай булуы сезнең исән калуга, минем исән калуыма бер сәбәп. Мөгаен, күктәге канцеляриядән шундый күрсәтмә булгандыр инде...

Коткарылган карт шулай бертуктаусыз сөйләнде дә сөйләнде. Гадәттә,

Руслан алай күп сөйләшә торганнардан булмаса да, котылу шатлыгы аның күңел читеннән таша иде. Ринат үзенең кулындагы лимонкага күрсәтеп:

– Нишләтәбез?

Сержант:

– Очыр ераккарак.

Моны ишетеп алган Руслан сөйләнүеннән туктап:

– Тукта, очырмый тор. Бу бит мине үтерергә әзерләнгән нәрсә. Шулай булгач, ул минеке.

Һәм ул бер очы ишеккә, икенче очы минага эләктереп куелган нәзек тимерчыбыкны сындырып алды да лимонканың саклык келәсе итеп тыгып та куйды. Һәм Ринатның кулыннан лимонканы алды.

– Бу талисман кебек була инде. Минем бердәнбер коралым. Рухлар бит барча коралны җыеп алып китте. Ә минем бернәрсә дә юк. Ичмасам миндә лимонка булыр.

Чынлап та тирә-якта чыра яндырып эзләсәң дә, корал табарлык түгел иде. Хәтта коры паекларга чаклы алып киткәннәр.

Сержант һаман сөйләнүеннән туктамаган Русланга карап:

– Йә, әйт, син ничек уйлыйсың, бу мәетләрне нишләтәбез? Болай калдырырга ярамый бит. Әзрәк җыештырмасак килешеп бетмәс. Базага кайтып хәбәр бирер идек тә. Безнең позиция кебек алар да күчеп киткән булса, нишлибез?

Руслан, сержантны яңа гына күргәндәй, сөйләнүеннән туктап, аңа карап, бер мизгел тын калды да:

– Нәрсә дисең?

– Мәетләрне нишләтәбез дим?

– Бер урынга җыярга кирәк. Аннан күз күрер.

Шулай иттеләр дә. Үлгәннәрне теге янмаган БТР кырына китереп тезеп салдылар. Ай, ул мәет җыюны... Ринат гомерендә беренче тапкыр мәетләр күтәреп йөрде. Мәеттән бала чактан ук шикләнеп курка иде. Ярый әле, Руслан:

– Йөзләренә карама. Әллә нәрсәләр дә уйларга тырышма. Үлгән – үлгән инде, ни эшлисең. Әмма без исән. Без исән бит, браток. Син коткардың мине. Югыйсә нәселсез дә кала идем, үлгән дә булыр идем. Ә теге дөньяда андый кеше кемгә кирәк? Тәмугка да кертмәсләр, оҗмахка да алмаслар. Ике арада адашып йөрерсең шунда. Хур кызлары да якын китермәс.

Руслан шулай юк-бар, оятлы-оятсыз, тозлы-тозсыз сүзләр сөйләп, үзен коткарган бу яшь солдатны күңелсез уйларыннан арындырып, кәефен күтәрергә тырышты. Егетләрнең һушлары алынып, әфган кояшының рәхимсез кыздыруыннан качып, төзек БТР күләгәсенә тезелешеп утырдылар. Сержант тамак кыргалап алды да мәетләр ягына башы белән ымлап, Русланга мөрәҗәгать итеп:

– Монда нинди мәхшәр купты? Нәрсә булды?

– Нәрсә булсын инде. Без килгәндә, шушы БТР юл уртасында утыра. Ни тегеләй, ни болай урап үтәрлек түгел. Туктадык. Мин ишек кырында утыра идем. Шуңа да безнең янда утырган капитан нәрсә булганын миңа барып белеп килергә кушты. Үзе дә минем арттан килеп төште. Ул тәмәкесен кабызды, икәүләп БТР кырына килеп җитмәдек, безнең янда гына мина

шартлады. Шуннан бернәрсә дә хәтерләмим. Һушыма килгәндә, барысы да беткән иде. Тере икәнемне белгәч, теге җаһилләр мине өстерәп, шушы БТР эченә кертеп кулларны күтәртеп бәйләделәр дә чекасы алынган лимонка өстенә утыртып куйдылар. Шушы вакыт эчендә әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Әллә, мин әйтәм, кинәт кенә торып шартларгамы? Рухлар яңадан килсә, шулай итә идем дә. Шулай да, егетләр, үләсе килми. Әле дә сез килдегез. Сусап үлә идем.

Сержант берни дә дәшмәде. Бераз таулар ягына карап торды да:

– Эх, бик шәпләп мунча керәсе иде. Эссе мунча күрмәгәнгә дә ике атнадан артып китте.

– Әйе, бик тә таман булыр иде ул. Җитмәсә арка ышкырга берәр яшь тана да булса, бөтенләй оҗмах булыр иде. Лазареттагы юмарт Вера да ярап куяр иде.

Шулай ике карт бернәрсә дә булмаган кебек, мунча, хатын-кызлар турында тыныч кына сөйләшә алуларына Ринат гаҗәпләнеп карап торды. Янда гына кырыкка якын мәет ятканда, шулай сөйләшеп була микәнни? Ичмаса әзрәк оялырлар иде дә, һәлак булган хезмәттәшләргә хөрмәт йөзеннән дәшми утырырлар иде дип, эчтән генә аларны тиргәде. Ну, бу кяферләрне, һичнәрсәдән чирканмыйлар. Ә тегеләр, сүзләрен икенче якка борып, битараф кына яңадан алга таба нәрсә эшләргә икәнлеге турында киңәшләшә башладылар. Берсе, мәетләрне исән БТРга төяп, базага кайтырга дисә, икенчесе, мәетләрне калдырып, үзебез генә кайтыйк, диде. Ринат аларны тыңлап торды да үзе дә сизмәстән:

– БТР миналанган. Алдагы юлга да миналар куелган, – дип куйды. Барысы да аңа борылып карадылар. Сержант:

– Мина куелган булса, Русланны коткарганда ук, күптән күккә очкан булыр идегез, – дип, Руслан ягына башы белән ишарәләп куйды. Һәм: – Тик кем БТР йөртә белә?

Фельдшер Вася урыныннан ук сикереп торды да:

– Мин бераз чамалыйм, – дип, БТРның ачык ишегеннән эчкә кереп тә китте.

Менә БТР бер-ике төчкереп пошкырып алды да тигез генә эшли башлады. Егетләр БТР тәгәрмәченнән читкәрәк китеп торып бастылар. Һәркемнең йөзендә шатлык нурлары балкый. Ә нәрсә, бронетранспортёрга утырып, базага кайтып керсәләр, нинди шәп булыр иде. БТР башта бераз чыгымчы ат кебек алга-артка тартылып торды. Аннан кара төтенен чыгарып, кинәт кенә артка чигенде. Тагы шып туктап үкереп алды да, алга ыргылды. Бер биш метр да алга китә алмады, ул ничектер очып китәргә җыенып, гаҗәеп бер көч белән астыннан чыккан ут өстендә берничә метр өскә күтәрелде. Башкасын Ринат абайламый да калды һәм шартлау дулкыны аны читкә атып бәрде. Ул һушын югалтты.

Яңадан һушына килгәндә, дыңгыр-дыңгыр килгән арбада бәйләүле килеш ята. Арба әле ташларга бәрелеп сикерә-дыңгырдый, җай гына тау юлы белән өскә үрмәли, йә булмаса бөтенләй даңгырдап, түбән таба тәгәри. Башы бертуктаусыз арба төбенә бәрелгәнлектән, Ринат тагы караңгылыкка чумды.

Күрәсең, өстенә су сиптеләр. Күзен ачканда, ул ниндидер йорт уртасында

сулы туфракта аунап ята. Ә каршыда гына кулына чиләк күтәргән бик тә ямьсез, зур авызын ерып, бер сакалтай басып тора. Хәтта көрәктәй олы сакалы да аның авызының зурлыгын яшерә алмый иде. Ринат тирә-ягына каранып алды. Зур гына әфган йорты. Йорт тирәли кулдан сугылган яндырылмаган кирпечтән өеп эшләнгән каралты-кура. Гомумән, монда барча каралты-кура һәм өйләр шундый кирпечтән төзелгән. Читтәге алачык алдында шул ук җиргә казып эшләнгән тандыр миче. Аның кырында такталардан ничек җитте шулай әмәлләп куелган өстәл сымак нәрсә. Арырак бер япма астында тавык абзары иде бугай. Аның алдында дистәләгән тавык җим чүпли. Әтәч кенә читән өстенә басып, үзенең тавыкларын барлый да әледән-әле муенын кыйшайтып, тилгән тавышы килгән якны караштырып, һаваны күзәтә. Һәм мин монда хуҗа дигән кебек канатларын кагып, сирәк-сояк кычкырып куя да тагы сыңар күзе белән генә һаваны сөзә. Өй нигезе буенда әсирләргә карап, ике карт сөйләшеп утыралар. Картларның берсе сакалтайга нәрсәдер әйтте. Тегесе Ринатның күзен ачып селкенгәнен чамалап алды да аны якасыннан тартып утыртты. Егетнең кулы янында яткан икенче солдатның кулына кушып бәйләнгән. Теге Ринатка карап, урысчаны вата-җимерә исемен сорады. Ринат ваемсыз гына үзенең исемен атады. Картлар аны ишетмәделәр. Шуңа да сакалтай аларга әсирнең җавабын кычкырып әйтте. Аннан алар җирдә ятучыларның диннәрен сораша башладылар. Ринат үзенең мөселман икәнен әйтте. Нигез буенда утыручылар тел шартлата-шартлата, менә сиңа мә дигән кебек, башларын кагып, үзара тагы да җанланып гәпләшергә тотындылар. Ринат аларның һичбер сүзен аңлый алмады. Картлар пуштун телендә бәхәсләшәләр иде. Аның башы авыртырга тотынды. Җитмәсә, башы әйләнеп, күңеле уйнап укшыта башлады. Әйтерсең лә, аны җир дигән зур коштабакка утыртып, әле тегеләй, әле болай тирбәтеп, әйләндерергә тотындылар. Җир-коштабак кайчакны бөтенләй авып капланыр чиккә җитеп кыйшая. Ринат шушы коштабактан егылып төшмәс өчен нәрсәгә булса да тотынырга чамалый. Янында яткан иптәшеннән башка һичнәрсәгә тотынырлык түгел. Тик теге солдат та аның белән бергә әйләнә. Ринат тагы һушын җуеп, җиргә ауды. Ринат өчен әсирлек менә шулай башланды.

Ул дөбер-шатыр килеп, ишек ачылган тавышка уянып китте. Үзенең кайда һәм ни эшләп ятканын аңлый алмый торды. Селкенергә тырышып карады. Юк, булмый икән, тәне таш булып каткан. Борылып ятарга чамалады. Борылырлык та түгел. Ике кул ике якка каерып, чылбыр белән стенага тарттырып куелган. Җитмәсә, яткан урыны караңгы иде. Аякларын боргаларга тырышты. Чылбыр зыңлавыннан аяклары да бәйле икәнен аңлады. Күп тә үтми, бүлмә ишеге ачылып китте. Бүлмә яктырып, саф һава кергәне сизелде. Ишектән чапан кигән озын гына кеше килеп керде. Ул бер сүз дә дәшмичә бераз карап торды да иелеп, стенадагы кулчага йозакланган чылбырны ычкындырды. Һәм карлыккан тавыш белән:

– Фставай, кяфер! Приехал, килеп җиттек, – диде.

Ринат үзенең нинди хәлдә икәнен, монда ничек килеп эләккәнен исенә төшерергә теләде. Башын көчкә эшләтеп, уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Тик бернәрсә дә хәтерли алмады. Уйлары бер урында гына чуаланып буталды. БТРның ут өстендә һавага сикергәнен генә хәтерли.

Аннан нәрсәгәдер салып дыңгырдатканнарын гына бераз уйлый алды. Тәне кыйнап ташлаганнан да болайрак авырта. Әлеге вакытта ул тик шуны гына сизде дә үтереп су эчәсе килгәнен белде. Йөрәге, әйтерсең лә, баш эченә күчкән һәм ул «су, су...су» дип кенә тибә иде.

Керүче аның аягындагы чылбырын ычкындырды. Аягына басарга булышты. Кулын богаулаган чылбырның озын башын тотып, аны чыгарга өндәде. Әйтерсең лә, абзардан бозау алып чыга. Йортка чыккач, Ринат якты кояш нурыннан чагылган күзләрен йомды. Шул килеш тегенең артыннан иярде. Күзләрен ачканда, ул инде урындыкта утырган ике бәндә каршында иде. Берсе бик чиста итеп кырынган. Куллары да ап-ак. Күрәсең, тупас авыл кешесе түгел иде. Ә икенчесе калын кашлары астыннан карчыга күзләре белән аны бораулаган бер сакалтай. Нәфис куллысы кесәсеннән ниндидер затлы сигара чыгарып, чакмасы белән аңа ут элде дә, тәмләп-тәмләп суырырга керește. Авызыннан төтен бөрки-бөрки, каршындагы тоткынны баштан-аяк өйрәнергә тотынды. Аннан Ринатны алдына китереп бастырган сакалтайга кулы белән аны борып күрсәтергә кушты. Тегесе солдатны тупас кына итеп, артына борды. Һәм яңадан йөзе белән тегеләргә каратты. Урындыкта утыручылар үзара нәрсәдер гәпләшеп алдылар. Шәһәрчә киенгәне, әзрәк русча акцент белән елмаеп, аңа сигарасын сузып:

– Мә, тартып җибәр. Тартасың киләдер бит?

Ринат тәмәке тартмавын белдереп, башын гына чайкады.

Тегенең аптыравы йөзенә чыгып, ниндидер «хе» дигән аваз чыгарып, ияген селкетеп алды да тагы да ныграк игътибар белән Ринатны энә күзеннән үткәреп:

– Кайсы частьтан? – дип сорады.

Ринат әйтергәме, әйтмәскәме дип икеләнеп торганда, артындагы сакалтай кулындагы очлы хәнҗәре белән авырттырып калак сөягенә китереп төртте дә русчалап:

– Яшисең килсә, сөйләшергә туры киләчәк. Яшисең киләдер бит? Югыйсә без кяферләргә бик ялынырга яратмыйбыз.

Ринат эшнең болай ук ышанычсыз булуын көтмәгән иде. Ишетеп белә, рухлар әсирләр белән бик назланып тормыйлар. Бигрәк тә яралылар белән. Аларны бәрелеш булган урында ук атып китәләр. Шулай да мөселманнарга кайчакта миһербанлы булуларын да белә. Ул кинәт кенә миен ярып үткән уйдан айнып киткәндәй булды. Һәм «әсир төшү шушылай була микәнни», дип уйлап алды. Үзе дә сизмәстән үз телендә:

– Мин кайда? – дип сорап куйды.

Каршыда утырганнар тагы бер-берсенә карашып, нәрсәдер сөйләштеләр. Русча ару гына сөйләшкән шома битле бәндә:

– Сарт мәллә? Кайсы өлкәдә тудың? – диде.

– Мин сарт түгел. Мин Башкортстаннан, – дип җавап бирде.

– Русча белмисеңмени? Русча сөйлә, – дигәч кенә, Ринат җавабын русча кабатларга мәҗбүр булды.

– Русча чамалы беләм. Авыл малае мин. Башкортстаннан.

– Башкортстан дигәнне белмибез, ул кайсы тирәдә? Нинди шәһәрләрегез бар?

– Уралдан мин. Уфа шәһәреннән.

Бу икәү тагы үзара сөйләшергә тотындылар. Яңадан аның кайсы частьтан икәнен, ничәнче ел хезмәт иткәнен сораштылар. Командирларын, тагы әллә кемнәрне сорап, барчасының төбенә тоз койдылар. Нәфис куллысы портфеленнән әллә нинди билгеләр куелган һәм төрле сызыклар белән бизәлгән СССР картасын чыгарып Уралның кайсы тирәдә икәнен күрсәтергә кушты. Картадагы язулар латин хәрефләре белән язылган булса да, Ринат чамалады. Бу картада Башкирия чикләре күрсәтелмәсә дә, Уфа шәһәре бик ачык күренеп тора. Ул калтырануын басарга тырышып, дерелдәп торган бармагы белән Уфага төртеп күрсәтте. Бераздан сорау алуны тәмамладылар. Карлыккан тавышлы рух аны кире абзарга кертеп, богавыннан стенага беркетеп куйды. Аякларыннан эләктерергә дә онытмады.

Ринатның зиһенен бетмәс-төкәнмәс сораулар бораулый иде. Шушы буладыр инде әсирлеккә эләгү дигән нәрсә. Барысы да көтмәгәндә булды бит. Теге янган БТРларны һәм тирә-якта аунап яткан иптәшләренең мәетләрен күреп, бер тетрәнгән иде. Аннан шушы мәетләр арасында үзенең дә булуы мөмкин иде бит. Менә шуны уйлап шатланды. Тик исән калу шатлыгыннан исереп, озак йөрергә туры килмәде. Әсирлеккә эләктеләр. Башкалар кайда? Алар исәнме икән? Әллә ул берүзе генә рухлар кулына эләктеме?

***

Икенче көнне иртән Ринатны, сорау алырга диптер инде, тагы йортка алып чыктылар. Борынына бик тәмле пылау исе килеп керде. Ул шунда гына үтереп ашыйсы килгәнен чамалады. Бакчадагы алма һәм йөзем куагы астында бик шәплләп табын әзерләнгән. Шул табын күренеп торган урынга утырттылар. Кичәге шома йөзле ир бүген икенче, кыска җиңле күлмәктән иде. Ул Ринатны күрү белән үк:

– О...о, шурави, хәерле көн! – дигән булды.

Ринат аңа карап, баш кына кагып куйды һәм астан гына тирә-якны ялт-йолт карап алырга да өлгерде. Монда шулай инде, һәр йорт үзе бер бәләкәй крепость-ныгытма. Ихаталары балчыкка таш катырып өелгән һәм биек. Тиз генә сикереп чыгып качармын, димә. Ул ирексездән авылларындагы киртә һәм тактадан гына корып эшләгән коймаларны хәтерләп алды. Кайбер кешеләрнең андый коймалары да юк.

Егетнең астан гына тирә-якны караштырганын теге адәм дә сизеп алды. Ул инде үз чиратында:

– Файдасыз. Моннан качып китә алмыйсың. Качкан очракта да тарлавыктан чыкканда, әфганлылар постына, йә булмаса засадага барып төртеләчәксең. Ә анда минем кебек кешечә сөйләшеп тормыйлар. Үзегездә җитештерелгән, сезнеңчә әйтсәк «калашка»дан бер генә очередь җибәрәчәкләр. Шулай булгач, якынрак килеп утыр, – дип, егетне үзе янына чакырды. Ринатның кулындагы чылбыр-богавын алмаганнар иде. Ул чылбырларны чылтыратып, аның яныннан бер-ике метр читтә торган ташка барып утырды. Таш әле кояш нурыннан җылынып кына килә, салкынча иде.

Ул башының бертуктаусыз гүләвен басарга тырышып, ирексездән бакча эчендәге сый-нигъмәтләр тулы өстәлгә күз төшереп алды. Күрәсең, аның бу хәрәкәте дә ирнең игътибарыннан читтә калмады. Ул мыек астыннан елмайгандай итеп, дусларча сүзен башлады.

– Кичә ныклап танышырга форсат булмады. Минем исемем Джон Смит. Һәм мин Халыкара Кызыл хач оешмасының Әфганстандагы күзәтчесе булам. Безнең оешма турында ишеткәнең бардыр. Без Халыкара Кызыл хач оешмасы, илләр арасындагы конфликт һәм сугышлар аркасында бәла-казага юлыкканнарга, шулай ук әсирләрнең тормышын җиңеләйтергә күп көч салабыз. Әсирлектән котылырга ярдәм итәбез. Шулай булгач, син минем белән очрашып танышуга шатланырга гына тиешсең. Без бар җирдә дә була алмыйбыз. Сине очратуыбыз да очраклы гына булды. Сине бу әсирлектән коткарырга тырышачакбыз.

Ринат һаман бакчадагы мул сыйлы өстәлне уйлап, тегенең сөйләп бетергәнен дә көтмичә:

– Кайчан ашаганны да онытттым. Ашыйсы килә, – дип куйды.

Болай әйтә алганына үзе дә аптырап китте. Һәм ашау турында сүз кузгаткач, аның чынлап та бик ашыйсы килә башлады.

Шома бит үзе дә өстәл ягына карап алды да:

– Әле безнең сүзләр бетмәде. Берәр гомуми фикергә килгәч, иркенләп ашап, чәйләп алырбыз. Сезнең халык чәй ярата бит. Баллап һәм каймаклап, шулаймы? – дип тә өстәп куйды.

Ринат эчтән генә: «Тик ятмаган, безнең Уралда яшәгән башкорт һәм татар турысында сорашкан, ахры», дип уйлап алды.

Егет тагы взводтагы сержантны исенә төшерде. Төшке аш вакыты җитә башласа, «Ач корсакка эшлисе дә, уйлыйсы да килми. Ә сугыш турында сүз дә юк. Сугыш, сугыш инде ул, ә төшке аш вакытында булырга тиеш», – ди торган иде. Шуңа да ул тагы да үҗәтләнеп:

– Ач корсакка башка юньле фикер килми. Ашарга иде, – дип куйды да янә бакчага күз төшерде.

Кызыл хач әгъзасы:

– Ашау качмас. Тәүдә сөйләшеп килешик. Аннан иркенләп, мәҗлес оештырырбыз.

– Юк, тәүдә ашау, аннан сөйләшү. Табын артында да сөйләшеп була бит.

Кызыл хач әгъзасының бу тискәре шуравидан беренче җиңелүе иде. Ә әсирлеккә эләккән үҗәт егетнең бәләкәй генә булса да җиңүе булды. Бу совет солдатын эт итеп кыйнап ташлап, йә булмаса берәр атна суда гына тотып та сындырып булыр иде. Юк, ул үзенчә – яхшылык белән егетне үз ягына аударырга уйлады. Шулай да, җиңелүен яшерергә тырышып, солдатны табынга чакырды. Кырдагы алмагачка эленгән юынгычта, чиста бит кулларын чайкап алды. Ә шурави җае чыкканда түзмәде, битләрен дә юып алды. Алар табынга килеп утыруга, лампа эченнән чыккан дию малае шикелле кыланып, алар янына чиста гына киенгән яшь кенә әфган егете килеп басты. Һәм табындагыларга хезмәт күрсәтергә тотынды. Шуравинең табын читендә зур гына самавыр өстендә парларын чыгарып утырган чәйнеккә карап алганын күреп, тиз арада аның алдына яшел чәй ясап куйды. Чәйдән хуш исләр таралуына карамастан, совет солдаты касәдән бер-ике генә йотым ясады. Аның яшел чәйне тәүге тапкыр тәмләп каравы иде. Бик ошатып бетермәде. Табын бик мулдан иде. Ринат җайлап, иркенләп ашарга уйлаган иде дә, хатын-кыз куллы адәм тагы сүзен дәвам итеп:

– Йә, нәрсә уйлыйсың, яшь кеше? Әле сиңа, мөгаен, унтугыз яшьләр

чамасы. Барча гомереӊ шушында пленда үтүен теләмисеӊдер бит? Аннан да бигрәк, бу кыргый халыкны беләсеӊ, күп сорап тормыйлар. Патроннары җитәрлек, аларга кешене аттылар ни, мал суйдылар ни – аерма юк. Фанатик, кара халык. Хәтта күмеп тә җәфаланмыйлар. Әнә тау өстендә очып йөргән тилгән һәм үләксә козгыннарына азык буласыӊ да куясыӊ. Менә шулай, кабереӊ дә булмый.

Ринат авызын тутырып чәйни-чәйни:

– Мине коткарырга исәбеӊ булгач, коткар! Мин риза.

– Сез, урыслар, бик кызык халык. Һәм олы кеше белән бик дорфа сөйләшәсез.

– Мин рус түгел.

– Менә тагы үзеӊнеӊ тупаслыгыӊны күрсәтәсеӊ. Тыӊлап бетер. Рус булмавыӊ бигрәк тә әйбәт. Сәяси хәлләрне аӊлап бетермисез. Имеш интернациональ ярдәм күрсәтәсез. Ә бит сез – агрессорлар. Чит мәмләкәткә басып кердегез. Менә шуӊа да син әле минем алда әсир хәлендә утырасыӊ. Әйе, бу коллыктан сине азат итәргә, сине коткарырга, әйе-әйе, азат итәргә мин генә булдыра алам. Синеӊ кебек пленга төшкәннәр СССР дигән дәүләткә кирәк түгел. Котылып кайтсагыз да, барыбер сезне Себер көтә. Салкын себер, хурлык һәм кимсетелүләр көтә. Менә шулай, туганым, уйла. Барысын да уйла! Миӊа иртәгәдән дә калмый Исламабадта булырга кирәк. Кичектергесез эшләрем бар. Иртәгәгә чаклы уйла, – диде.

Гафу үтенә-үтенә, инде сый-нигъмәтләрдән канәгать булып туя башлаган Ринатны әле бер яктан, әле икенче яклап та, чарт-чорт иттереп, фотога төшереп алды:

– Сине коткара торган документларны тутырганда кирәк булачак, – дип куйды һәм хушлашып: – Аӊла, туганым, иртәгәгә чаклы вакытыӊ бар. Хуш, – диде дә, бер кабым ризык та капмыйча, өстәл артыннан торып, өйгә кереп китте.

Шуны гына көткән диярсеӊ, теге сакалтай аныӊ кулын богаулаган чылбырдан килеп тотты, һәм башы белән ымлап, үзе артыннан иярергә кушты. Нишләсен, әсир әсир инде. Язмышы да колларныкы кебек. Аны тагы теге ярым караӊгы сарайга кертеп, чылбырыннан стенадагы боҗраларга беркетеп куйдылар. Тик бу юлы астына бераз салам җәйгәннәр иде.

Ринат ярым караӊгы келәттә үз уйлары белән ялгыз калды. Ярый әле туйганчы ашаттылар. Теге Кызыл хач хезмәткәре сөйләгән сүзләрне тагы бер тапкыр исенә төшереп, кабатлап уйлады. Болар нинди ният белән аны коткарырга уйлыйлар?

***

Ринат шуларны уйлап, яӊадан оеп киткәнен сизми дә калды. Икенче көнне тагы ишекне ачтылар. Гел караӊгыда ятканга, битенә көлтәдәй яктылык бәрелүдән күзләре чагылып китте. Уянган иде инде. Тик тыштагы тавышларны тыӊлап, ярым йокымсырап ятты. Тышка алып чыктылар. Бүген башыныӊ гүләве һәм авыртуы бераз басыла төшкән иде. Тагы теге кичәге бәндә янына алып килделәр. Кичәге өстәл артына утырттылар, тик бүген сый-мазар юк. Кызыл хач кешесе исәнләшкән булды. Тегесен, монысын сораштырып алды. Кейсыннан бер төргәк кәгазь чыгарып,

Ринатка шушыларны укып чыгарга һәм имза куярга кушты. Һәм: «Без кыскача гына синнән интервью алырга тиешбез. Ни өчен частеңне ташлап киттең? Һәм ни өчен Әфганстанда сугышырга теләмисең? Барысы-барысы турында да сөйлә», – диде.

Ринат бу бәндәнең сүзне кайсы якка борганын чамаламыйрак торды, аннары шуны аңлады: аңардан чынлап торып сатлыкҗан ясарга уйлыйлар бит! Имеш, ул үз теләге белән дошман ягына чыккан да, ә хәзер бөтенләй Америкага качарга җыена имеш. Бу шома бит, хәтта шул Америка президентыннан сәяси яклау сораган үтенечкә имза куйдырырга чамалый түгелме соң?! Менә сиңа мә!

Нык уйлаудан аның баш гүләве һәм авыртуы көчәя башлады. Шул вакыт әти-әнисен исенә төшерде. Алар бу турыда ишетсәләр, нәрсә диярләр дә, авылдашлар ни уйлар. Туганнарына, барча нәсел ыруларына нинди кара тап ятачак. Юк! Тагы бер тапкыр юк!

Ул бит үз теләге белән әсирлеккә төшмәде. Көчле шартлаудан контузия алу сәбәпле һушын югалтты. Һушын югалтмаган булса, болай гына бирелмәс иде.

Аның дәшми генә башын иеп, үз уйларына бирелеп утыруын күреп, американ (Ринатның моның шулай икәненә шиге калмады) егеткә текәлеп карап:

– Йә егет, нәрсә уйга калдың?

– Уйлыйм.

– Күп уйлаган – сазга баткан. Уйланган күркә – ашка эләккән, диләрме әле руслар?

– Мин рус түгел!

– Беләм. Бик яхшы беләм. Әйдә алайса бер кино күрсәтәм. Минем арттан ияр.

Американ урыныннан торып, капкага таба юнәлде. Читтә генә торган автоматлы сакалтайга башы белән генә ымлады. Коралын әзер тотып, сакалтай да алар артыннан иярде. Урамга чыктылар. Урамда чыр-чу килеп уйнаган бала-чага аларны күрү белән шым булды. Барчасы бу сәер киемле кешеләрне күзәтте. Арыкның теге ягында безнең «ашыгыч ярдәм» машинасына охшаган бер машина тора, шуның янына килделәр. Алар килеп җитүгә машина шофёры, урыныннан төшеп, арткы ишекне ачты. Кереп утыргач, американ:

– Менә күр, бездә җитештергән һәм соңгы электрон казанышлар белән җиһазландырылган машинаны. Без хәзер синең белән Әфган әсирлегеннән котылып, элекке совет солдатының Америкада ничек яшәп ятканын карарбыз.

Һәм ул өстәл өстендә торган бер зур гына тартманы, аннан стенага беркетелгән бер шкаф ишеген ачты. Өстәге шкафта телевизор урнаштырылган булып чыкты. Аны аскы тартмадагы зур гына магнитофонга тоташтырды да кабызып җибәрде. Ринат белми иде әле бу нәрсәнең видеомагнитофон икәнен. Ул инде гаҗәпләнеп, мондагы таулар арасындагы шайтан куенына урнашкан кышлакта да телевизор күрсәтә микәнни, дип уйлады. Менә экраннан нindider музыкага кушылып, бик тә матур һәм моңлы тавыш белән хатын-кыз җырлаганы ишетелде

дә шушы ук бәндәнең йөзе күренеп китте. Американы үзенең элеккеге совет солдатыннан интервью алачагын тәүдә инглизчә, аннан русчага күчеп әйтте. Менә Ринатлар яшендәге егетне күрсәтә башладылар. Ул ниндидер бер цехта машиналар юа икән, русча сөйләп алып китте. Озак кына сөйләде. Үзенең ничек качып китүен, аннан Америка хөкүмәтеннән сәяси сыену сораганын һәм менә хәзер Америкада ирекле гражданин булып яшәве турында тел чарлады. Шушында эшли икән. Ярты елдан менә дигән машина алып җибәргән. Ул шулай итеп, Америкада яшәүнең нинди рәхәт икәнен үтереп мактады. Һәм азактан элеккеге ватандашларына, бергә хезмәт иткән иптәшләренә мөрәҗәгать итеп: «Нигә сезгә кан коеп, коммунистларның әллә нинди тормышка ашмастай, утопик идеяләре өчен сугышып йөрергә? Коралларыгызны ташлап качыгыз! Исән калырсыз! Мәскәүдә утырган бер генә түрәнең, бер генә коммунистның баласы да мылтык күтәреп, Әфганда сугышып йөрми. Әти-әниләрегезне, ага-туганнарыгызны уйлагыз. Сугышта хәтта райкомда, райсоветта эшләгән түрәләрнең балаларын да күрмәссең. Без бит Әфганстан иленә басып кергән агрессорлар...»

Шундыйрак интервью белән тагы дүрт-биш егет чыгыш ясады. Барысы да Американы мактады. Барысы да корал ташлап, капиталистлар ягына чыгарга өндәде. Ринат аларны караса да карады, карамаса да карады, дигәндәй. Бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Һәм ул көтмәгәндә, Кызыл хач уполномоченныен гаҗәпләндереп:

– Бүген ашамыйбызмыни? – диде.

Теге бераз аптыраган төссез күзләрен аңа төбәп, бер мизгел карап торды да Ринат алдына баягы кәгазьләрне этәреп:

– Күрдеңме элеккеге әсирләрнең ничек иркен яшәгәннәрен? Менә, мин күрсәткән урынга имзаңны куй. Һәм сине видеофильмга төшереп, интервью алачакмын. Мин бирәсе сорауларга җаваплар менә монда язылган, – дип, артына әйләнеп, тагы язулар белән тулы биш-алты бит кәгазьне егет алдына куйды. – Ә аннан инде син ирекле һәм без синең белән туйганчы сыйланачакбыз. Ашарга да, эчәргә дә булыр. Теләсәң, иң матур Азия кызларын да алдыңа тезеп куярбыз. Теләгәнен сайлап алырсың.

Ринат үрелеп, кулына ручка алды. Мондый ручканы беренче кат күрә иде, шуңа да әйләндереп-тулгандырып, бераз аны өйрәнеп утырды.

Американ, егетне дәртләндереп:

– Әйдә, кыюрак бул! Монда һич куркасы юк. Син үзеңнең гомереңне коткарасың. Моннан әллә исән котылырмын дип уйлыйсыңмы? Болар – кыргый халык. Боларга кеше гомере ни дә чебен гомере ни – аерма юк. Бер сәгатьтән ни буласын белә алмыйсың. Һәм безгә моннан тизрәк таю ягын чамаларга кирәк. Әйдә, әйдә, туганым. Әти-әниеңнәргә дә яшерен каналлар аша исән икәнлегеңне хәбәр итәрбез. Югыйсә синең исем-фамилияң белән берәр детдомда үскән солдатның йөз-битләрен танымаслык хәлгә китереп «кара лалә» белән авылыгызга кайтарырга мөмкиннәр. Монысы яхшы чакта. Әниеңнәргә азмы-күпме пенсиясе булыр. Ә бит, ул дошман ягында безгә каршы сугышып һәлак булды диюләре дә бар бит. Ә кем ачыклый? Кем сине эзли? Сезне күптән оныттылар инде. Сезнең позициядәгеләр хәзер беркемгә дә кирәкми. Сез – һәлак булганнар, хәбәрсез югалган-мәетләр. Иң

аламасы: рухларга сатылганнар исемлегендә булу. Без барысын да күреп торабыз. Ышанмасаң, менә кара!

Теге тагы ниндидер төймәләренә басты. Шунда Ринатка космостан төшерелгән видео күрсәтергә тотынды. Анда хәтта аларның БТРлары ничек шартлаганына чаклы күренә иде. Иптәшләренең ничек һәлак булганын күрү Ринатның бу иргә тора-бара ачуын кабарта башлады, һәм ул, үзе дә сизмәстән, кулындагы матур ручканы урталай сындырып ташлады. Ручка сынды һәм ул ничектер җиңел сулап куйды да:

– Юк инде! Коткарасыгыз килсә, болай коткарыгыз. Юк икән, юк! Мин бернинди дә кәгазь-документка имза куймыйм!

Америкалы авыр сулап алды һәм бу тискәре совет солдатын сындырып булмаслыгын аңлап:

– Юк тек, юк. Мин сине чынлап торып коткарырга теләдем. Һәркем үз язмышына үзе хуҗа. Ярар, Аллаһ сиңа түземлек бирсен. Мине исеңә төшерәсе көннәрең алда әле, туганым. Сезнең кебекләрне монда сукага җигеп, миналар куелган җирне сөрәләр. Шулай да мә, менә минем адрес, түзәр әмәлең калмаса, шушы адрес белән хат җибәр. Булдыра алсаң инде. Шәһәрләрдә почталары эшли. Тик мондагы шайтан да керергә курыккан тау арасында почта йөрми.

Менә шулай тәмамланды аларның сөйләшүләре. Машина китте. Сакалтай аның аркасына «калашка» көбәге белән ару гына китереп төртте дә нәрсәдер әйтте. Шурави аңламады, шулай да алга атлап китте. Аны тагын теге караңгы сарайга кертеп яптылар. Ашау һәм су дигән нәрсә бүген булмас, ахры.

Озак ятарга ирек бирмәделәр, бераздан икенче бер рух кереп, тышка алып чыкты. Йортта аның кебек тагы бер әсир басып тора иде. Әсирләрнең богауларын бергә эләктереп, җитмәсә, күзләрен дә кысып бәйләп куйдылар. Яннарына арбага җигелгән ат килеп туктады. Күзе бәйләүле булса да, Ринат моның шулай икәнен сизде. Өтеп-төртеп дигәндәй, арбага утырттылар. Арба кузгалып китте. Сакалтай әллә нинди карлыккан тавыш белән нәрсәдер әйтте. Тик әсирләр аңламады. Ринат үз янында утырганның колагына туры китерергә тырышып:

– Син кем? – дип пышылдады.

Теге дәшмәде. Ринат тагы соравын кабатлаган иде, тик аларны алып барган сакалтай икесенең дә башларына йодрыгы белән ару гына китереп сукты да үзенең килбәтсез тавышы белән баягы сүзен кабатлады. Ринатка ару гына эләкте. Башы тагы үтереп шауларга кереште. Хәтта укшытырга итә башлады. Озак бардылар. Бер уңайга гына һәм җайсыз утырып барганлыктан, аяклары оеп, сизмәс хәлгә килде. Баш түбәсендә Әфган кояшы рәхимсез кыздыра, эссе. Шабыр тиргә баттылар. Тау арасыннан баралар, ахры, шарлап аккан су тавышы да ишетелеп китә. Су янында җиләс һава. Үтереп эчәсе килә. Шулай озак, бик озак бардылар. Менә алда эт өргән, тавыклар кыткылдаган тавышлар ишетелеп китте. Колакка бала-чага тавышы килеп эленде. Күрәсең, ниндидер авылга килеп җиттеләр. Арбаны чыр-чу килгән балалар тавышы уратып алды. Арба артыннан иярделәр. Бераздан ниндидер агач күләгәсенә килеп туктадылар. Аларны, арба үрәчәсенә ныклап бәйләп куелган аяк-кулларын чишеп, өтеп-төртеп,

утырган урыннарыннан тартып төшерделәр. Ринат, аягы сизмәс хәлгә җитеп оеганлыктан, басып тора алмыйча, гөрселдәп җиргә ауды.

Бала-чага булды шикелле, бер-икесе:

– Кяфер, кяфер, – дип, аның аркасына тибеп китте. Кайсыдыр, балаларга елан кебек ысылдап алды. Тегеләре шым булды. Кемдер егетне җилкәсеннән тартып торгызды һәм тагы төрткәләп, ары алып китте. Ниндидер йортка алып керделәр кебек. Ул шулай сиземләде. Менә күзләренә бәйләнгән чүпрәкне чиштеләр. Тик ул бернәрсә дә күрмәде. Кысып бәйләүдән ул ниндидер вакытка күрү сәләтен югалткан иде. Күзне уарлык та түгел. Кулы кыска итеп икенче тоткынның кулына бәйләнгән. Ринат ничек итсә итте, иелеп, күзләрен угалап алды. Шуннан соң гына әзрәк яктылыкны шәйләп, күзен каплаган караңгылык ачыла төште.

Алар ниндидер балчык белән таштан өелгән биек ихаталы йорт эчендә басып торалар булып чыкты. Йорт бусагасында ару гына киемле, озын гына буйлы берәү күренде. Күрәсең, йорт хуҗасы иде. Аның кырына тагы берәү килеп басты. Алар, бу икәүгә карап, нидер сөйләшеп алдылар. Һәм йорт хуҗасы, ниндидер Әхмәтне чакырып, әсирләрне йортның аргы башында урнашкан сарайга ябарга кушты.

Сарай эчендә аларга охшаган тагы да дүрт шурави утыра икән. Аларның да куллары бәйле булып чыкты. Керүчеләр сарай эчендәгеләр белән исәнләштеләр. Шунда берсе яңа керүчеләрне искәртеп:

– Әкрен! Пышылдашып кына сөйләшегез. Ишетеп калсалар, кереп кыйнарга тотыналар. Сез кайдан, кемнәр? – диде.

Шулай әкренләп танышып алдылар. Төрле өлкәләрдән икән. Башкортстаннан Ринат берүзе булып чыкты. Әсирләрнең күбесе бер ай элек әсирлеккә эләгүчеләр. Араларында яралылар да бар.

Бераздан тоткыннарга берәр түгәрәк үзбәк әпәе – нан таратып чыктылар. Су почмактагы зур гына калай савытта иде. Мондагы беренче көннәре шулай үтте.

Икенче көнне аларны караңгылы-яктылы чакта ук ныклы сак астында кышлак кырындагы басуга алып килделәр. Авыл текә тауларга сыенып утырган иде. Кышлакның каршы ягында сөзәк кенә таулар тезмәсе күренә. Һәм шушы сөзәк тау битендә күптән чәчелмичә ташландык хәлгә килгән басу җәелеп ята. Шунда сакчыларның берсе русчаны вата-җимерә басуга күрсәтте:

– Менә алдыгызда сезнекеләр миналаган басу. Үзегез миналадыгыз, үзегез тазартыгыз! Әйдәгез алга!

Шуравилар, аптырашып, тынып калды. Шунда берсе:

– Кулларны бәйләгән килеш ничек миналарны зарарсызландырасың? Ичмаса кулларны чишегез, – диде.

Боларны алып килгән сакчыларның өлкәне идеме, әллә командирлары булдымы:

– Кача башласагыз? – диде.

– Соң, сез бит безне саклыйсыз. Шулай булгач, без качмасын өчен ныграк саклагыз! Нык сакласагыз – без дә качмабыз.

Бу җавап рухка ошады, ул шаркылдап көлеп җибәрде. Һәм нигә көлгәнен кырында торган иптәшләренә дә тәрҗемә итте. Барысы да көлешеп алдылар.

Ниндидер чит ил машинасына төялеп, баштан-аяк кораллы тагы биш-алты рух килде. Командирлары аларга күрсәтмәләр биреп, төрлесенә төрле якка басарга боерды. Берничәсе, машинага утырып, басуның аргы башына китте. Шаркылдап көлгән сакалтай берәм-берәм шуравиларны чылбырларыннан ычкындырды. Бер рәткә тезеп куйды да башы белән ымлап:

– Алга, бөркетләр! – диде.

Шуравилар барысы да диярлек христиан динендәгеләр иде. Берничәсе чукынып алды. Моны күреп калган сакчы төкеренеп куйды. Ринат аларның чукынганына карап, үзенчә бисмилласын әйтеп, картинәсе өйрәткән доганы укып, битен сыпырып куйды. Һәм күңеленнән генә Ходай язмаган эш булмас, бүтән төрле үләргә язган икән, шартлап үлмәбез әле, и Аллам, үз ярдәмеңнән ташлама, миңа эти-әни янына да кайтасы бар бит әле, дип пышылдады да, беренче булып басуга кереп китте. Әмма кайдандыр, Кавказдан иде шикелле, озак кырынмаудан шул ук рухларга охшап калган шурави:

– Мин христиан! Сезнең шакшы җирегезне безнең миналардан чистартмыйм. Тиздән сез, басурманнар, үзегезнең Аллагыз белән бергә тончыгачаксыз! Качыгыз, егетләр! – дип кычкырды да елгага таба торып йөгерде. Ничек кенә боргаланып, «зигзак» ясап йөгермәсен, кырдагы сакчы ашыкмый гына шул якка борылды да «калашка»дан бер генә сиптерде. Теге бахыр, йөгергән уңайга гөрселдәп барып төште.

Бу хәл калганнарга бик тә авыр тәэсир итте. Качу турында уйлап та булмый. Һәр солдатка – ике-өч сакчы. Алар инде үз коралларының затворын күптән тартып, саклык келәсен ычкындырып куйган. Чак кына шикле хәрәкәт ясасаң да, атып үтерәчәкләр.

Ринат бөтен игътибар-дикъкатен үзе аяк басасы җиргә күчерде. Полкның уку мәктәбендә һәм карантинда ятканда алган бөтен белгәнен исенә төшерергә тырышты. Нинди миналар кулланылганын һәм аларны ничек зарарсызландырырга кирәклеге турындагы белгәнен барларга тотынды. Тик бар белгәне башыннан чыгып очкан булып чыкты. Гадәттә, миналарны шахмат тәртибендә урнаштыралар икәне исенә төште. Игътибар белән һәр үлән төбен, һәр очраган таш-балчык кисәген өйрәнә-өйрәнә аягын алга шудырды. Иң курыкканы – зарарсызландырып булмый торган миналар. Шулар гына булмаса ярар иде дип уйлады. Чөнки аларны ала башласаң – шартлыйлар. Тагы кеше адымына шартлый торганнары да бар. Андыйларны урынында гына шартлатып юкка чыгарып була. Әле генә күз алларында булган шундый коточкыч вәхшилек аның барча уй-зиһенен биләп алды. Теге егетнең гөрселдәп егылуы башын томалады. Аңа да шушындый, бернинди дә калыпка сыймаган юньсез үлем белән үләргә туры килер микәнни? Картинәсе әйтә торган иде: «Ахырзаман алдыннан нәрсә уйлыйсың, шул алга килә», – дип. Шуны исенә төшереп, үлем турында уйламаска тырышты. Ничек кенә әлеге фаҗигане исеннән чыгарып очырырга теләсә дә теге егет белән булган хәл күз алдыннан китмәде.

Ринат шуларны уйлап, чираттагы адымын ясарга гына уйлаган иде, нәкъ ул аягы белән басасы урында үлән әзрәк саргаебрак тора. Тирә-яктагылары ямь-яшел. Башын яшен уты кебек ярып, «монда мина булырга тиеш» дигән уй үтте. Ул ирексездән туктап калды. Ятып ук бу урынны өйрәнде. Һәм

читләтеп кенә, теге урынның кырын кулы белән чокый башлады. Җир каты иде. Шулай да тырнакларын авырттырып булса да, чирәмне актарып ташлады. Бармаклары белән сиземләп алды, бу мина иде. Чынлап та пехотага каршы кулланыла торган совет минасы. Бик тә явыз һәм каһәрле, астыртын мина. Моны берничек тә зарарсызландырып булмый. Җитмәсә, шартлаганда, тәүдә метр-метр ярым җир өстенә сикерә, аннан соң гына шартлый. Җиргә ятып та качып котылырмын, димә.

Ринат тирә-ягына каранып алды. Аңа беркетелгән сакчы – теге русча сукалаган рух. Ул иптәше белән аның ягына караштырып, нидер сөйли-сөйли, тәмләп, тәмәке көйрәтә. Менә Ринат торып басты. Рухлар, автоматларын аңа төзәп, игътибар белән күзәтә башладылар. Ул, кулларын күтәреп, рухларга якынрак килде дә үзе тапкан минага күрсәтеп, шуңа атарга кушты. Тик сакалтай тешләрен ыржайтып, усал гына көлеп алды да:

– Иди, идии, кяфер! Иди делай свое дело! Кяфер, үз эшеңне эшлә! – дип, автомат көбәге белән аңа янап, минага таба күрсәтте.

Егетнең бер дә юкка гына үләсе килми иде. Шуңа да халыкның, «чукын улым, чукын, кяфернең күңеле булсын!» дигән әйтемен исенә төшерде. Шуларны уйлап алды да кояшка карап, кыйбланы чамалады. Кыйбла Әфган җирендә көньяк-көнбатышка таба иде. Тагы да мондагы картларның намазны шул якка карап укыганнарын күргәне бар. Шуңа күрә кыйбла якка карап басты да кышлакта көненә әллә ничә яңгыраган азанны ярты тавыш белән генә кабатларга тотынды. Ул инде аны ятлап ук алды. Бәләкәй чагында ук мулла бабайдан азанны ишеткәне бар иде. Шуңа да азан тавышын ишетсә, гел балачагы исенә төшеп, туган авылын, туган-тумачаларын һәм әти-әнисен хәтерләүдән күзеннән яшьләр чыгар дәрәҗәдә хисләргә бирелеп китә иде. Әле дә шул азанны кабатлап, берничә тапкыр «Әгузе бисмиллаһи рахман ир-рахим»ны кабатлады. Башканы белми иде.

Шуравиның болай азан әйткәнен аптырап карап торган рухлар бер-бер артлы минага төзәп атып җибәрделәр. Бу атуны ишетеп Ринат: «Беттем, миңа аттылар! Хәзер авыртуны сизеп, җиргә авам инде», – дип уйлап та өлгермәде, пуля тиюдән детонация булып, мина шартлап ярылды. Ара ерак кына булуга карамастан, хәлсезләнгән ярчыклар шыбырдап, алдына коелды. Бераздан җил кебек шартлау дулкыны шуравины иркәләп үтте. Әйе, ул шулай уйлады. Шартлау дулкыны да гел генә җан иясе кешене үтермичә, кайчакны җылы таң җиле кебек иркәләп тә китә икән. Егет шулай уйлап та бетмәде, рухлар аның янына килеп басты. Русча сукалаган рух тамакларын кыргалап алды да:

– Син кем?

– Ринат. Вәлитов Ринат, – дип тә өстәде.

Бу тагы кабатлап:

– Син кем? Мөслимме?

Ринат аны аңлап бетермәде. Чөнки «мөслим» сүзен беренче ишетүе иде: Юк, дип башын селкеде.

Тегенең ачуы кабара биреп:

– Христианин-кяфермени?

Ринат чамалап алды, болар милләтен, динен сорыйлар, ахры. Тагы юк дип башын чайкап алды да:

– Юк, мин мөселман, – дип, азактан өстәп куйды.

Тегеләр үзара гәпләшергә тотындылар. Учка-уч сугышып, кызу-кызу гына бәхәсләшеп тә алдылар. Шуннан теге, шуравига:

– Төшер чалбарыңны!

Егет бу ике рухның нәрсә әйтергә, нәрсә эшләргә чамалаганнарын аңламады. Чалбар каешын тоткан килеш тора бирде. Рух ярым ачуланып:

– Сал ыштаныңны! Сөннәтлеме?

Ниһаять, шурави аңлап алды. Болар аның сөннәтле булу-булмавын тикшерәләр. Читләр алдында болай кыланганы булмаса да, нишләсен инде. Чалбар-трусигын төшереп, бу икәү каршында басты. Ринат сөннәтле иде. Әйе, бәләкәй чагында, әле дә хәтерли, ниндидер бер карт аңа матур чалбар тегәбез дип, сәкегә яткырып сөннәтләп киткән иде. Менә хәзер шуның нәтиҗәсен тегеләргә күрсәтеп тора.

Рухлар, күрәсең, аның сөннәтле-сөннәтсезме икәне турында бәхәсләштеләр. Отылганы, йөзләрен бозып, откан иптәшенә кабы белән тәмәке һәм чакма-зажигалкасын сузды. Отканы, русча сукалаган рух булып, шурави кырына якын ук килеп, канәгатьлек белән аның кулбашыннан какты да, башы белән ымлап, эшен дәвам итәргә кушты. Тик Ринат ике адым да атларга өлгермәде алга киткән иптәшләренең икесе, аяк асларында мина шартлап, авып төштеләр. Күрәсең, берсе яраланган гына иде, авыртудан кычкырып, әнисен исенә төшереп, ярдәмгә чакыра башлады. Озак акыра алмады, аңа автоматтан ут сиптерделәр. Бахырың тагы бер-ике кычкырырга теләгән кебек гырылдады да, бөтен гәүдәсе белән тартышып, тынып калды. Бу икәү кемнәрнең генә баласы булды икән дә, кемнәрнең генә газизләрдән-газизе икән? Төннәр йокламый карап үстереп, зур өметләр баглаган кемнәрнең генә җан кисәккәе икән?

Ринат бүген сигез мина тапты. Аның бәхете бар иде. Ул исән калды. Басуны минадан тазартканда, шулай итеп, өч иптәше үлде. Алдарак бер сыермы, ишәк үләксәсеме күренде. Аны яртылаш козгыннар ашап бетереп бара. Аларга да шушындый үлем яный микән? Аларны да шулай козгыннар чокырмы? Мәетләрне күмәргә рөхсәт итмәделәр. Һәлак булганнарны басу читенә чыгарырга куштылар. Аларны күтәреп җәфаланмадылар. Күтәрерлек тә түгел, үлгән кеше ике тапкыр авырая диләр, дөрес икән. Аякларыннан тотып, өстерәргә туры килде. Шулай иптәшләренең берсен чыгарганда, аның астында тагы мина шартлады. Бахыр үлгәч тә, иптәшләренең гомерен саклап кала алды. Минаның зарары егетләргә тимәде. Тик тегенең гәүдәсе генә теткәләнде. Ахры, сакчылар да бу ялыктыргыч эштән арганнар иде. Тизрәк кайтырга ашыктылар. Басуда беренче көннәре шулай үтте.

Кайткач, аларга тагы берәр түгәрәк үзбәк икмәге бирделәр дә теге сарайга кертеп яптылар. Яптылар гына түгел, кулларын баш очындагы шүрлеккә ныгытылып куелган лимонка чекасына бәйләделәр. Аякларыннан да шулай ук тарттырып, аяк очларындагы мина чекасына эләктерделәр. Качу түгел, саксызрак селкенсәң дә, шартлап, күлең күккә очачак. Лимонкалар янында танкка каршы куела торган зур миналар да ята. Алар да детонация белән шартлаячак. Монда кешеләр генә түгел, бөтен абзарың юкка чыгачак. Әйтәм аларны бөтенләй читтә ялгыз гына торган абзарга кертеп яткырдылар. Ярый, хет аста әзрәк салам. Элек монда йә сарык, йә кәҗә абзары булган.

Әйе, бу әфган җирендә көндез түзеп торгысыз эссе. Ә төннәрендә суык. Таулардан суыкның рәхимсез тәгәрмәч кебек тәгәрәп төшкәне сизелеп тора. Җылы киемең булмаса, кәкрәясең, рус әйтмешли – калатун.

Ринат бүген күргәннәреннән шулкадәр тетрәнгән иде. Бер көн эчендә үзен ун елга, юк, егерме елга картайган кебек хис итте. Кичергән психик киеренкелектән арыды. Контузия алганнан соң тынгылык бирмәгән башы, салам өстенә тынычлап яткач, тагы гүләп авыртырга тотынды. Әйтерсең лә, башы вагон тәгәрмәчләре астында калып, йөрәге типкән саен чатнап ярыла башлый. Хәтта юньләп уйлый алмас дәрәҗәгә җитә. Бөтен уйлаганы: качарга, качарга һәм качарга! Йөрәк, бер erткыч карчыга булып, баш эченә кереп утырган да, авырттырып, үз ритмына миен чукый да чукый.

Тоткыннарның барысы да бер кагыйдәне аңнарына сеңдереп куйды: нәрсә генә булуга карамастан, селкенергә ярамый! Иртәнгә чаклы яшисең килсә – селкенмә! Ә инде иртәгәсе Аллаһ кулында. Ялгыш селкенүдән баулар тартылып, мина чекасы ычкынса, бетте. Әппәр итеп, амин тотарга гына кала. Өлгерсәң инде. Монда алар өчен әппәр итүче дә, амин тотучы да булмас. Менә шулай маңгаеңа нәрсә язылган. Йа Ходай, әгәр дә бу Галәмдә барсың икән, коллыкта җәфаланган колларыңа ярдәм ит. Язмышларын әзрәк кенә булса да җиңеләйт!

Иртәгәсен аларны теге басуга алып бармадылар. Үзләре кунган сарай алдына чыгарып утырттылар. Ринатның чамалавы буенча рухлар кемнедер көтә. Тегеләй-болай кереп-чыгып йөргән тылмач рух күренеп калды. Ринат аңа кул болгап үз янына чакырды да, басуны миналардан тизрәк тазарту өчен ыргак-тырма ясарга кирәклеген аңлата алды. Һәм туфракка ниндирәк ыргак булырга тиешлеген сызып та күрсәтте. Сакалтай әллә аңлады, әллә юк. Бер сүз дә әйтми китеп барды. Төшкә таба капкадан бармак юанлык троска чылбырлар белән кулларыннан бәйләнгән җиде әсирне алып керделәр. Ринат ниндидер бер иске китапта Америкадагы негр колларны тезеп, базарга сатарга алып килү турындагы рәсемне күргән иде. Монда да тегеләрне нәкъ шулай тезеп куйдылар. Беренче көнне бу өй бусагасына чыгып карап торган ир бүген дә шулай ук яңа килгәннәрне барлап чыкты. Үзенең ярдәмчеләренә ниндидер күрсәтмәләр бирде дә тагы кереп югалды. Яңа килгәннәрне Ринатлар алдына утыртып, алар бәйләнгән чылбырга эләктереп куйдылар.

Ринат алдына туры килгән солдат бик таза һәм башкалардан бер башка биегрәк иде. Ул каш астыннан күзләрен уйнатып алды да үзенең алдында утырганнарга карап:

– Кайсыгыз монда бугор, ягъни старший?

Егетләрнең берсе дә дәшмәде. Бу өчәү кичәге хәлләрдән күбесе шок хәлендә, үзләренең авыр уйларына бирелеп утыралар. Дәшүдән дә ни фәтва. Алар монда барысы да бертигез хәлдә – барысы да әсирләр. Теге кырыс кына:

– Нәрсә, телегезне йоттыгыз мәллә?

Ринат яңа килгәнгә күтәрелеп карады да янындагылар дәшмәгәч:

– Ну, мин старший, – дигән булды.

– Не нукай! Салабоннар, мине тыңлагыз! Мин дед! Шулай булганга күрә бүгеннән башлап, монда мин старший. Дөресрәге, шушы минуттан мин

монда бугор. Ишеттегезме? Ә син, нукающий, минем ярдәмчем булачаксың! Шылдымы?

Әсирләрнең берсе дә әйе, дип тә, юк, дип тә дәшмәде. Ринат та җавапсыз калды. Бу үзен дед дигән әсир яңарак кына рухлар кулына эләккән шурави иде. Анда да әле үз гаебе белән: әфьюн эзләп, казармадан качып, базарга чыкканда эләктереп алдылар. Шуңа да монда булган хәлләрне һәм булачак вакыйгаларны күз алдына да китермәде. Һаман этәчләнеп һәм үзен күрсәтергә теләп, Ринатка күзен алартты:

– Нигә дәшмисең? Әллә мине аңламыйсыңмы? Дәшмисең, значит, мине аңламыйсың. Карага буялган – черномазый, син дә шул рухлар нәселеннәнме әллә? Шуларга охшап торасың!

Ул Ринатның башкаларга караганда карарак булуына һәм йөзе белән руска охшамавына басым ясап, аны кимсетергә чамалады. Бу әзмәвернең тавыш күтәреп, башкаларга кычкыра-кычкыра, нәрсәдер сөйләгәнен сакта торган рух ишетеп алды. Күп уйлап тормый, килеп торып, тегенең сыртына приклад белән ару гына тондырды да, үзенчә нәрсәдер искәртеп, тагы берике нык кына тибеп, кире урынына барып басты. Әзмәвер авыртудан йөзен чытып һәм тешен кысып:

– Синең аркада эләкте. Мин моны исеңә төшерермен әле. Инәңне һәм авызыңны шулай итәрмен... – дип кабахәт сүгенеп ысылдады.

Ринат дәшмәде. Нигә дип талашып, каршы әйткәләшеп торырга? Монда барысы да дошман кулында. Барысы да алар ихтыярында. Телиләр икән, яши бирәсең, теләмәсәләр, шушы минутта ук атып үтерергә мөмкиннәр. Ә бу, яңа килгән юньсез аңлап бетерми иде әле мондагы тәртип һәм тормышны. Тормыш дип әйтеп булса. Тормыш түгел – ормыш, ә дөресрәге, әҗәл белән качышлы уйнау. Кем кемнән хәйләкәррәк тә, кем кемне тизрәк алдый.

Бераздан тоткыннарны тезеп, арык тазартырга алып киттеләр. Ринат рухларның үзара сөйләшкәннәренә игътибар белән колак салып барды. Күп сүзләр безнекенә охшашлыкка охшаш та, тик сүзнең нәрсә турында барганын гына аңларлык түгел. Болар үзбәкләр түгел шул. Аларны аңлавы җиңел иде.

Ринат юл уңаена тирә-якны карап-өйрәнеп барды. Әйе, таулар биек һәм текә. Башларында ялтырап, кар ята. Ә бу яктагы таулар ул кадәр текә булмыйча, сөзәгрәк. Кояш белән чамаласаң, көньяк шул якта булырга тиеш. Ә безнең СССР иле Әфганстанның төньягында, бу биек кыя таулар артында. Ул шулай география фәненнән алган белемен исенә төшереп барды.

Көннең калган өлешендә авылга агып килә торган арыкны тирәнәйтеп тазарттылар. Эш беткәч, кайтыр алдыннан Ринат теге сакалтай сакчыдан кулы белән ишарәләп һәм русчалап юынып алырга рөхсәт сорады. Рөхсәт иттеләр итүен. Тик рус милләтеннән булганнарны арыктан ераккарак кудылар. Егетләрнең аңлавы буенча кяфер юынган су кышлакка барырга тиеш түгел. Нишләсеннәр, арыктан читкә канау ерып, шунда чайкандылар. Су, таулардан килгәнгә, бик салкын иде. Шулай булуына карамастан, су – су инде, билгә чаклы чишенеп, рәхәтләнеп юынып алдылар.

Кайткач, тагы теге сарай алдына тезеп утырттылар да көндәгечә берәр түгәрәк нан таратып чыктылар. Бүген аларга кружкаларга тутырып, кайнар

яшел чәй дә бирделәр. Теге әзмәвер ничек итсә итте, Ринат янына утыра алды. Ашарга гына тотынганнар иде, җаһил Ринат кулыннан икмәген тартып алды да:

– Бүгенге көннән кич бирелгән ашың минеке булачак. Югыйсә төнлә буып үтерәм, – дип ысылдады.

Белми иде әле ул сарай эчендә ничек кунасыларын. Хәтта кече хаҗәтеңне дә чалбарыңа бушатасыңны. Олысы булса да шулай. Хет үлеп кит, синең янга беркем дә кермәс һәм беркемне чыгармаслар. Чөнки урыныңда боргаланып яту түгел, ә селкенә дә алмыйсың. Ринат та төшеп калганнардан түгел, тегенең олы гәүдәсеннән куркып тормады – үз өлешен кире тартып алды. Моны көтмәгән әзмәвер егетне бугазыннан эләктереп буарга чамалады. Ринат бу юньсезне көч белән алып булмасын аңлап, бармагын тегенең күзенә батырды. Бу ыгы-зыгы, тарткалашуны күреп калган сакчы, кычкыра-кычкыра килеп, икесенең дә сыртына приклад белән тондырды. Кычкыруга аргы алачыктан тылмач килеп чыкты. Сакчы кулларын бутый-бутый, аңа нәрсәдер аңлатырга тотынды. Тылмач тарткалашучылар янына килде. Әзмәвер, авырткан күзен угалап, яшенә манчылып утыра иде. Ул әзмәвердән:

– Нәрсә булды? – дип сорады.

– Юктан гына күзгә китереп төртте, – дип, әзмәвер алдашырга тотынды.

Шуннан ул Ринатка карап, башын гына кагып, сораулы карашын төбәде. Ринат дөресен сөйләп бирде. Ничек мыскыллавын һәм тагы әллә нәрсәләр дигәнен дә, әпәен тартып алганын да әйтте.

Тылмач Мәскәүдә укыган чагында бер профессор малаеның аңардан шулай черножоп-чабан дип көлгәне өчен биргәләп ташлаган иде. Һәм шуның аркасында ничек итсә итте, теге профессор кисәге аны ел ярым дигәндә укуыннан кудыртты. Тылмач шуларны исенә төшереп алды. Аңардан да кяферләр шулайрак көлгән иде бит. Тавышка башка рухлар да җыелды. Тылмач сугышучыларның икесен дә торгызып, кара-каршы бастырды да Ринатка төртеп күрсәтеп, әзмәвердән:

– Бу басурман буламы? – дип сорады.

Теге күзен дә йоммый:

– Әйе, ул кара чутыр. Әйе, ул басурман. Юкка гына күзгә китереп төртте. Мин аны барыбер инәсен тегеләй-болай итеп, акылга утыртам, салаганың, – дип, күзен һаман угалап янарга ук тотынды.

Тылмач үзенең күкрәгенә төртеп:

– Миңа кара әле, мин дә бит сезнеңчә – кяферчә, кара чутыр. Һәм, әлбәттә, кырагай басурман. Шулай булгач, син миннән дә көләсең булып чыга. Ә без үзебездән көлгәнне бик яратып бетермибез. Бигрәк тә кяферләрнең көлгәнен. Шуңа күрә сиңа сайларга туры киләчәк. Йә үзең теләп, басурман-мөселман буласың, ягъни үз-үзеңне сөннәтлисең. Йә басурман булырга теләмичә, кяфер калып стенага басасың һәм без сине атабыз. Сайла! Йә басурман булып яшисең, йә кяфер булып үләсең.

Рух кулындагы сәгатенә карап алды да дәвам итеп:

– Менә шулай, сиңа иртәнгә кадәр уйларга вакыт бирәбез. Иртә – кичтән яхшырак, диләрме сездә? Ә хәзер марш ял итәргә!

Барча әсирләрне теге абзарга кертеп, көндәгечә кул-аякларын мина

чекасына бәйләп йокларга салдылар. Кеше йоклаганда, кырык тапкыр урынында әйләнеп, боргалана, диләр. Мөгаен, шулайдыр, санаган юк. Ә менә монда бер тапкыр да борылып ята алмыйсың. Арка-артларың бер уңайга гына чалкан ятудан, такта кебек катып китсә дә боргалана алмыйсың.

Яңа килгәннәр минага бәйләнеп ятуның нәрсә икәнен белмиләр иде, шуңа да бөтенләй телсез калдылар. Тик теге башта яткан әзмәвер генә үз алдына сүгенеп, барчасын каһәрләп ятты. Бераздан юньле-рәтле уйлый алырлык хәлгә килеп тынычлангач:

– Кара әле, теге ни... чукча. Откуда ты?

Ринат үзенең авыр уйлары белән уяулы-йокылы ята иде. Ни дисәң дә, йоклаган килеш ялгыш селкенеп китүдән, йә булмаса үзен белештерми борылып ятудан курка. Шулай да тәннең һәм аңның кешенең үзенә дә билгеле булмаган, яшәргә кирәклеген искәртеп тора торган һәрчак уяу булган үз сакчы-каравылчысы бар икән. Менә шул эчке сакчы функция үз эшенә ныклап тотынган иде. Шуңа да эчке сак функция селкенүдән саклап, егетне уяткалап торды. Ул уяулы-йокылы ята иде, тик Ринат үзенә дәшүчегә җавап бирмәде. Теге бераз уфтанып ятты да:

– Татармы әллә? Сездә ничек эшлиләр аны? Күпме кисеп ташлыйлар? Сөйлә әле.

Ринатның нык арыганлыктан, бу юньсез белән әңгәмә корасы да, аның сорауларына җавап бирәсе дә килмәде. Шуңа да дәшмәде. Авылда калган туган-тумачаларын, әти-әнисен уйлап ятты. Өйне, авылдашларны уйлау ничектер күңелгә җиңеллек, җанга рәхәт тынычлык бирә иде. Ә почмактан бертуктаусыз төрлечә уфтанып мыгырдау, хәтта лышык-лышык елау да ишетелеп торды. Шунда кемдер түзмәде:

– Туктыйсыңмы син, юкмы? Үзең гаепле бит. Монда сиңа казарма түгел. Монда старик-дедлар да, салабон-черпаклар да юк. Барыбыз да монда тип-тигез. Барыбыз да кол-әсирләр. Яп авызыңны, ипи шүрлегеңә менеп төшкәнче! Аллаңа һәм өеңдәге почмакта эленеп калган изгеләреңә табын! Мөгаен, ярдәм итми калмаслар, – дип ысылдады.

Тегенең лышык-лышык елавы ишетелсә дә, лыбырдап ялваруы тукталды.

Иртән барысын да көндәгечә абзар нигезе буена тезеп утырттылар. Күренеп тора: яңа килгәннәр бөтенләй йокламаганнар. Беркемнең дә тиккә генә үләсе килми. Күзләре кызарып, үзләре әңге-миңге килеп утыралар. Көндәгечә берәр үзбәк икмәге көтсәләр дә, бүген шул әпәй зурлыктагы юка кабартма-көлчә генә бирделәр. Менә сакчы кырына тылмач килеп басты. Шуны әйтергә кирәк: тылмач – бу сакчыларның түрәсе шикелле. Үзен гел шулай калганнардан өстен тота. Бүген нәрсә булырын башка рухлар да беләләр шикелле. Барысы да, тамаша карарга җыенган кебек йорт алдына җыелдылар. Күрше йорттагылар да керде. Тылмач әзмәверне, башкалар бәйләнгән тростан ычкындырып, аерып алып, читкә бастырды. Һәм тегенең аякларын аерым богаулап куйды. Билендә асылынып торган зиннәтле пычагын әзмәвергә сузган иде дә, кире уйлады. Нәрсәдер җыелган халыкка әйтте. Шундагы халык шау-гөр килеп көлешеп алдылар. Тел шартлатып, тегенең дөрес эшләвен хупладылар. Тылмач: «Үземнең зиннәтле пычагымны шакшы кяферне сөннәтләп пычратмыйм», – диде. Һәрхәлдә, Ринат шулай аңлады. Тылмач артына борылып, сакчыны чакырып

алды да аның «калашка»сына эләктерелгән штык-пычакны алып, бөтенләй кеше төсе калмаган әзмәвергә сузып:

– Йә, карап карыйк әле, ничек итеп син үз теләгең белән басурман-мөселманга әйләнерсең икән? Сөннәтлә үзеңне! Сезнеңчә әйтсәк, – дип, рус телендә булган бөтен әшәке сүзләрне әйтеп бетерде, бик каты итеп катлы-катлы сүгенеп, әсирләр алдында үзенең русча яхшы сүгенгәнен күрсәтеп мактанып алды.

Шулай шул, СССРда чит илдән килүчеләр, гомумән, чит ил кешеләре, студентлар иң тәүдә сүгенергә өйрәнергә тиеш. Чөнки бу илдә яшәүче төп халык, иң тәүдә яхшы сүгенсәң генә, сине аңлап, хөрмәт итә башлый. Сине үз итә.

Әзмәвер бөтенләй бөгелеп төште. Кичәге зәһәрлегенең тамчысы да калмаган иде. Кулындагы штык-пычак җилдә җилфердәгән яфрак шикелле калтырый башлады. Чалбарын салдырдылар. Тик теге нәрсә эшләргә дә белми елап җибәрде. Яшь аралаш:

– Булмый! Егетләр, булдыра алмыйм! – дип, акырып ук еларга тотынды. Һәм Ринатка яшьле күзләре белән карап:

– Ярдәм ит, татар, син... син бит беләсең. Үзем булдыра алмыйм. Кайсыгыз белә? Берәрегез ярдәм итегез, рәхим итеп! Ну, пожалуйста, егетләр, – дип, башкаларга карап ялынса да, аңа ярдәм итәргә теләүче табылмады. Чөнки бу рухларның уенда нәрсә икәнен белеп булмый. Үзеңне дә әзмәвер кырына бастырып куярга мөмкиннәр.

Бахырның кулыннан штык-пычак төшеп китте. Тылмач күрсәтмәсе буенча ике рух аны өстерәп дигәндәй, абзар стенасына илтеп сөяделәр. Чөнки әзмәвернең атларга аяклары карышты. Рәте бөтенләй калмаган иде. Сакчы коралын аңа төзи башлады. Шул чакта Ринатка бу мескен шулкадәр кызганыч булып китте. Үзенең әти-әнисен уйлап алды. Бу мәлгуньнең дә әти-әнисе бардыр инде. Үзен «дед» диде бит. Мөгаен, бер айдан өенә кайтырга тиеш булгандыр инде бу. Ә әниләре белми дә улларының кая эләккәнен. Һәм, үзе дә сизмәстән, капыл:

– Туктагыз! Мин үзем аны сөннәтләп, үчне алам, – дигәнен сизми дә калды. Рухлар арасында үзбәкләр дә бар иде шикелле. Алар, шаулашып, атарга әзерләнгән сакчыга туктап торырга куштылар. Шунда бер рух Ринат янына килеп, аны богавыннан ычкындыра башлады. Һәм үзбәкчә:

– Ну егет, булдыра алсаң, коткар кяферне, – диде дә, җирдә яткан штык-пычакны кулына алып, үткерлеген бармагы белән сыпырып карап, Ринатка тоттырды.

Йорттагы барча халык алда ни булырын кызыксынып көтә башлады. Ә инде абзар стенасына сөялгән теге бахыр бөтенләй бетеренде. Ул бу басурман миннән хәзер барча үчен ала инде дип куырылып төште. Аңардагы кичәге мин-минлегенең, үзен һавалы тотуының эзе дә калмаган иде. Хәтта әзмәвернең буй-сынына чаклы кечерәеп, бөрешеп калды. Ринат сакалтайдан йод белән бинт сорады. Бүтән чак булса сораган әйберләрен бирмәсләр дә иде. Алда нindидер кызык буласын көткән рухлар анысын да тиз табып китереп тоттырдылар. Ринат үзенең бу өлкәдә белгәннәрен исенә төшерсә дә, дулкынланудан аның да куллары калтыранды. Унынчы сыйныфны бетергәч булды шикелле. Бер җае чыкканда, авыл мулласыннан:

«Сөннәтләү нигә кирәк?» дип сораган иде. Мулла абзый әллә ни төпкә төшми генә:

– Беренчедән, чисталык, һәм ирлек көчләре ныклы булсын өчен, – диде. – Яһүдләр – акыллы халык. Алар барысы да безнең кебек сөннәтле. Һәм бу юкка гына түгел, улым. Сөннәтләү нәрсә инде, гаурәтнең башын каплап торган яры-тирене генә кисеп ташлыйлар. Һәм шуңа да ислам динендәге халыкларда ул әгъза шешеп һәм башкача авырулар белән җәфалану юк дәрәҗәсендә. Бу турыда медицина китапларыннан укып белергә мөмкинсең. Сөннәтләнмәгәннәр юк-бар чир белән һәм ир көчсезлегеннән җәфаланалар. Ә без – мөселман һәм яһүдиләрдә ул юк. Шуңа да мөселман булган ирләргә хатыннар ябышып ята, ничек булса да кияүгә чыгарга тырыша. Ә син, улым, берүк алар халкына якын барма!

Бабай шулай дип аңлаткан иде. Менә хәзер шул барлы-юклы белемен һәм тәҗрибәсен барлап, теге мәхлукның гомерен саклау өчен кулланырга чамалый. Ә әзмәвер куркып, аның күзләренә карап тора. Әйтерсең лә, буар елан күзеннән карашын ала алмаган куян баласы. Ринат тегенең куркынган күзләренә карап, янына килеп басты да:

– Монда куркырга кирәкми. Һәм бу куркыныч нәрсә түгел. Күреп тор, азактан рәхмәт кенә әйтәчәксең. Мин сиңа начарлык эшләргә теләмим. Бу каһәр суккан Әфган илендә бер-беребезгә ярдәм итмәсәк, безне берәм-берәм кырып бетерәчәкләр. Мин дә сөннәтле, үлмәдем бит менә. Әзрәк авыртыр инде. Укол кадаганнан да нык булмас. Курыкма, мин дә кеше бит. Син ахмакны коткарырга телим. Югыйсә аталар бит үзеңне. Әти-әниең синсез нәрсә эшләр?

Ринатның шулай тыныч, бик тә басынкы сихри тавышына теге дә бераз тынычланды. Аның әйткәннәрен тыңлап һәм ниндидер өмет белән аның карашыннан күзен алмыйча, егеткә текәлде. Ринат, тәҗрибәле психолог кебек карашын аңа төбәгән килеш, әкрен генә эшкә кереште. Әзмәвер бераз дертләп куйса да, карышмады. Ринат тагын да басынкырак һәм әкрен генә:

– Тынычлан һәм курыкма. Безне әле малай чакта ук сөннәтләделәр. Бер дә үлеп китмәдек һәм исән-имин шушы тоткынлыктан котылсак, балаларыбыз да булыр әле, Аллаһы боерса!

Әзмәвер, Ринатның тыныч кына сөйләвеннән һәм миенә үтеп керердәй карашыннан, чынлап та гипнозланган кебек күзен аңардан ала алмады. Менә шулай итеп, Ринат бу әзмәверне сөннәтләде.

– Менә күрдеңме, барысы да гап-гади. Үтте дә китте. Исемең ничек?

– Ваня Соколов.

– Ярар, Иван, ачуланма. Мин сиңа ачу тотмыйм. Менә хәзер киселгән урынны йода белән эшкәртербез. Әзрәк әрнер һәм канар. Алай гына була инде. Туйга чаклы төзәлер!

– Бетте дәмени?

– Әйе, ә син куркып торасың.

Ваня үзенең бот арасына карарга курыкса да, елмаеп җибәрде. Бу тамашаны тын да алмый карап торган рухлар да Иванның елмаюын күреп һәм аның җәрәхәтен сөрткәләвеннән, бу эшнең уңышлы тәмамлануына сокылануларын яшермичә, тел шартлатып, ах-вах килеп, бабачы ролен уйнаган Ринатны мактадылар.

Менә шундый хәлләр белән Ринат рухлар арасында бераз ихтирам яулауга иреште. Аларны яңадан теге троска чылбырларын бикләп, бүген дә басуны минадан тазартырга алып китәргә әзерләнделәр. Ул, тылмач белән сөйләшеп, яңа гына сөннәтләнгән солдатны бүгенгә эштән азат итүләрен үтенде. Теге аптырап:

– Кяфернеме? Юк! – диде.

Ринат үҗәтләнеп:

– Ул хәзер кяфер түгел. Ә сөннәтле кеше. Мөселман булырга әзерләнә. Тимик аңа бүген. Әнә нинди таза кыяфәтле шурави. Ул әле, әллә нинди эшләр башкарачак. Юкка имгәтмик. Көче җитәрлек, ат кебек эшләячәк ул, – дигәч, кул гына селтәде.

Иванны сарай алдына богаулап калдырдылар. Басуга килеп җиттеләр. Өченче көн үлгән мәетләр өстендә козгыннар өере утыра. Иң элек, олы гына кабер казып, мәетләрне шунда күмделәр. Әле эш башланмаган, ә барча тоткынның кәефе иң түбән ноктасында. Мәетләрне козгыннар эштән чыгарып бозган иде. Әсирләрнең күбесе бу хәлгә түзә алмый укшып, барлыюклы ашаганнарын да косарга тотынды.

Рухлар тоткыннарны, ничек кирәк шулай кимсетеп, түбәнсетү һәм аларның рухын сындыру өчен шулай эшлиләр иде. Чөнки рухы сынып, түбән тәгәрәгән әсирдән теләсә нинди әшәкелек эшләтергә була. Теләсә нинди мәлгуньне әвәләп була.

Менә япон машинасында теге көнне Ринат сөйләгән тимер тырнаклар, озын безләр белән арканнар китереп киттеләр. Егетләр эшнең рәтенә тиз төшенде. Иң мөһиме минаны табарга гына кирәк. Ә инде аны зарарсызландыру хәзер уен эш кебек кенә иде. Эшләр худка китте. Һәм егетләр үзләренең белгәннәре һәм тәҗрибәләре белән үзара бүлешеп, киңәшләшеп алды. Кем дә кем мина таба, шунда ук мина артына бер ярты метр чамасы ераклыкта теге ыргакны җиргә батыралар да җай гына арканнан тарта башлыйлар. Тырнакка эләккән мина еракта шартлый. Шуңа да зарары егетләргә тими. Тик ашыкмаска гына кирәк. Ринат безнең солдатлар урнаштырган миналарны ничек табарга кирәклеген тапкырлау таблицасы кебек күңеленә сеңдереп куйды. Яшергән әйберне табар өчен яшерүче роленә керергә кирәк. Мин сапёр булсам, минаны кайда урнаштырыр идем дип уйлый белергә кирәк.

Бу басуга соңгы баруларында барысын да гаҗәпләндергән тагы бер хәл булып алды. Басуны миналардан арындырып бетердек дигән көнне Ринатның башына ниндидер бер шик килеп, ул басу межасы янына килеп басты. Күңеле белән сизде: шушы тирәдә мина булырга тиеш. Уйлап та бетермәде, аның янына Чиләбе якларыннан булган чуваш егете йөгереп килде дә:

– Сине көтәбез. Кайтырга команда булды, – дип борылып китеп тә барды. Ринат аны искәртеп өлгерә алмады, егет минага басты. Көчле шартлау яңгырады. Чиләбе егете нәрсә булганын да сизмәде, теткәләнеп җиргә ауды. Ринатны да шартлау дулкыны җиргә күтәреп бәрде. Ул аңын югалтты. Мәрхүмне басу читенә җирләделәр. Сакалтайлар рөхсәт итте. Ринат яраланмаган булып чыкты. Тик кырындагы минаның көчле шартлау тәэсиреннән тагы бер каты контузия алды. Әзмәвер аны берүзе күтәреп,

кышлакка чаклы алып кайтты. Контузиясе бик каты булды шикелле, икенче көнне иртән генә аңына килде. Башта аңгы-миңге килеп йөрде. Җайлап, зиһене ачылды. Һәм шушы көннән башлап, ул чын сапёрга әверелде дисәң дә була. Аллаһ аны бу юлы да үз рәхмәтеннән ташламады, саклады. Бу кышлактагы басуларны миналардан тазартып бетергәч, аларны икенче кышлакка озаттылар.

Бу соңгы контузиясеннән Ринат әйтерсең лә яңадан туды. Һәм аның бик тә гаҗәеп сәләте ачылды. Ул инде миналарның кайда урнаштырылганын һич ялгышсыз әйтеп бирә башлады. Әйтерсең лә ул аларны телевизордан күрә иде. Шушы сәләте белән тиз кызып китүчәнлек тә барлыкка килде. Кызып китсә, нәрсә эшләгәнен аңламас хәлгә җитеп үзгәрә дә куя. Күзләре ларып, күзенә ак-кара күренми башлый. Ул чакта янында тормавың хәерлерәк. Үлемнән бөтенләй курыкмас дәрәҗәгә җитеп, Ринатның холык-фигыле үзгәрде. Шулай да була икән.

Тауларда кыш җитте. Беренче кар озак яумый торды да бер көнне иртән дөнья ап-ак иде. Бу яңа кышлакта аларны төрле-төрле төркемнәргә бүлеп, башка кышлакларга озаттылар. Бай һәм хәллерәк халык аларны үзара бүлешеп алды. Эшче-хезмәтчеләр барысына да кирәк булып чыкты. Качу турында уйларлык та түгел. Бу кышлак бер зур гына тарлавыкта урнашкан. Әйтерсең лә, бер зур капчык. Якты дөньяга чыгар өчен капчык авызыннан үтәргә кирәк. Ә анда сакчылар тора. Бу Әфганстанны аңламассың. Һәр авыл үзенә бер аерым дәүләт кебек. Һәр авылның үз биләмәсе, үз сакчы-сугышчылары бар. Кайчакны бер авыл белән күрше авыл сугышып та алырга мөмкин. Йә булмаса, әле генә үзара сугышкан ике авыл берләшеп, икенче күршеләренә сугыш белән барырга да булдыралар. Ә инде барча ил өстенә берәр бәла-каза, йә булмаса, дошман яу белән килсә, бөтен ачу-үпкәләрен онытып, тиз арада берләшеп, дошманга каршы күтәреләләр. Ирләр бала чактан ук корал белән эш итәргә өйрәнгән. Ә коралның нинди генә юк. Хан заманыннан калган, көбәгеннән кора торган филтәле мылтыклардан башлап, лазер төбәгечле пистолетларга чаклы табарга мөмкин.

Ринатны бер бик олы яшьтәге Лотфулла исемле бабайга бирделәр. Бабайның өч малае булган. Әмма алар шушы сугышта һәлак булганнар икән. Бабайның ике хатыны бар. Ә иң гаҗәбе: яшь хатын бабайдан бик яшь булып, яшь аралары илледән дә артык шикелле. Ринат бу яшь хатынны тәүдә бабайның кызы дип уйлаган иде. Алай түгел икән. Һәм бабайның барча йорт-җире шушы яшь кенә хатын кулында. Дөньяны ул көтә. Бабайның дөньясы ныклы. Менә шушы бабайга Ринатны хезмәтче итеп билгеләделәр. Бабай барысын да сорашып, кем-кайдан икәнен белгәч кенә, үзе ун әсир арасыннан Ринатны сайлап алды. Кул-аяктагы богауларны күптән алдылар. Ул хәзер ирекле йөри. Кышлак урамыннан да иркенләп үтә ала. Беркем бер сүз әйтми. Башта аны кызыксынып күзәтсәләр дә, хәзер алай караучы да юк шикелле. Һәрхәлдә ул андый карашларны сизмәде. Кышлак зур гына булып, бер лавкалары да бар. Ул лавкада җаның ни тели, шуны табарга була. Кәкре, тутыгып беткән шөреп-кадактан башлап, видеомагнитофонга чаклы бар. Безнең СССР нинди алга киткән космик держава булса да, Ринат беренче тапкыр сатуда видеомагнитофонны шул кибеттә күрде. Чынлап та халык урта гасырлардан калган гореф-гадәтләр белән яшәсәләр дә, «Мантана»

джинсы белән аякларына соңгы модалы «Адидас» кроссовкилары кигән кыз-егетләрне һәр адым саен очратырга була. Советларның төшенә дә кермәгән хуш исле сагыз чәйнәп йөрүче, япон сәгате таккан балалар да җитәрлек монда.

Тырышлыгы бушка китмәде. Ул инде пуштун телендә дә, үзбәк телендә дә матур гына аңлашып сөйләшергә дә өйрәнде. Ни дисәң дә, ике ел шушы халык арасында тоткынлыкта үтте бит. Хәзер менә дари телен үзләштерә башлады. Бабайның өендә батарейка белән эшли торган транзисторлы радиоалгыч та бар. Шуның аша әле сугышның һаман дәвам иткәнен ишеткәләп ала. Мөгаен, әтиләренә улыгыз үлде дип, йә булмаса хәбәрсез югалды дигән кәгазь дә килгәндер. Әнисенә авырдыр инде. Ул бит гаиләдә бер генә малай иде.

Ринатны таң калдырганы Лотфулла бабайның яшь хатыны булды. Башта шурави аны үзеннән олырак яшьтәге хатын дип уйлаган иде. Пәрәнҗәсез күргәч, исе-акылы китте, булгач та була икән охшашлык кешеләрдә. Бу яшь кенә хатын авылдагы күрше Тимербикә әбиләргә Уфадан кунакка кайтып йөргән кызга охшаган. Әйтерсең лә, аның игезәге иде.

Менә шушы хатын Тимербикә әбинең оныгы Айсылуны исенә төшерде дә инде. Ә Айсылу шәһәр кызы булса да, кыргый. Үз янына авыл егетләрен якын китермәде. Аны озатырга һәм әзгә генә булса да, кулыннан тотарга күпме егет хыялланды. Юк, Айсылу авыл егетләре өчен күктәге ай сыман буй җитмәс бер сылу булып калды. Ринат та аны күпме озатырга хыялланып, байтак йокысыз төннәр үткәрде. Аптырагач, егетләр бу буй җитмәс кызга якын килми башладылар. Ә аңа авыл егетләре бар ни дә, юк ни. Менә хәзер шул буй җитмәс Айсылуга ике тамчы су кебек охшаган хатын шушы картның йортында дөнья көтә.

Егетнең үз киемнәре күптән тузганга, ул инде баштарак ни бирсәләр, шуны киде. Шуңа да ниндидер бер йолкышка охшап тора иде. Бабайда эшли башлагач, аңа бабайның үлгән улларының киемнәрен бирделәр. Картлар күңелләре белән бик кешелекле һәм ачык кешеләр булып чыкты. Әлеге шул уллары советларга каршы сугышта һәлак булулары аркасында башта шуравига ничектер шикләнеброк карадылар. Аның һәр эшен, һәр адымын күзәтеп тордылар. Ә шурави авыл егете бит, йортта булган бөтен эшне белеп һәм җиренә җиткереп башкарды. Һәм ул көч ягыннан да нык егет иде. Картлар аның эшеннән канәгать булып, ашау ягын да кысмадылар. Шуңа да шурави бераздан тәненә ит кунып, матурланып китте. Югыйсә бу йортка килгәндә, тире дә сөяк кенә иде.

Тәрәздән әсирнең йортта эшләп йөргәнен карап торырга яраткан әби бу әсир солдатны үзенең кайсыдыр улына охшата да башлады шикелле. Кайчакны Ринатны күзәтеп, еш кына күзеннән яшьләрен дә сөрткәли иде. Ә бабай яшь чагында мөгаллим-хәлфә булып, балалар да укыткан. Ринатны, көчләп дигәндәй, гарәп әлифбасыннан хәреф танырга да өйрәтте. Шулай итеп, буш вакытында шурави гарәпчә укырга, язарга өйрәнде. Аннан инде үзе үк кызыксынып, Коръән китабын һәм кайбер догалыклар да укып карады. Тик гарәпчә аңламагач, кызыгын тапмады.

Кышның кыска бер көнендә бабай белән әбине башка бер кышлакка кунакка алып киттеләр. Бер-ике көннән кайтырга тиешләр иде дә, бик каты

буранлап кар яуды. Буран дип әйтеп тә булмый, монда тау арасында әллә ни бураны да юк. Ә менә карны иште генә. Бабайның яшь кәләше өйдә бу шуравига күз-колак булып, эшләр кушып, шуларны тикшереп торырга тиеш иде. Ринат ул көнне көне-төне яуган карны көрәде. Чишмәгә суга бара торган юлны кардан чистартып, бик нык сусаган иде. Шул чишмәдән тирләгән килеш учлап су эчте. Менә шунда тамагына бәрде, күрәсең. Иртәнгә тамагы шешеп, тавышына чаклы югалды. Урынга ятты. Барча эш яшь хатын җилкәсенә калды. Шурави хәтта керткән ризыкны да йотарлык хәлдә түгел иде. Авыруның бик җитди төс алганын чамалап, яшь хатын әсир егетне үзенчә дәваларга тотынды. Шул вакытны битен ярым каплаган пәрәнҗәсен салырга туры килде. Башта Ринат бу хатынны танымады. Өйгә чакырылган берәр табиб кыздыр, дип уйлады. Тик киемнәренә игътибар иткәч һәм тавышыннан гына бу кызның бабайның яшь хатыны икәнен чамаламады. Ул үзен Зөһрә дип таныштырды.

Яшь хатын да бабайларның өйдә булмауларыннан файдаланып, үзен иркенрәк тотты. Ринатның аңа аптыраулы гаҗәеп матур күзләре белән йотардай булып каравыннан бераз кызарынса да, битен капламады. Тамагына ниндидер әчкелтем нәрсәләр каптырып, төрле төнәтмәләр эчерде. Яшь хатын рәхәтләнеп, бу яшь егетнең тәннәрен капшап, майлар сөртте. Зөһрә ир назына сусаган иде. Чөнки бабай бик карт һәм авыру сәбәпле, яшь кәләше белән бер төн кундымы, юкмы? Нишлисең, бабай бабай инде. Икенче көнне әзрәк арулангач, ни булса шул була дип, азагын уйлап та тормыйча, егет хатынның беленнән алып үз өстенә яткырды. Тәүдә курыккан иде, каршы килеп кычкыра башлар дип. Ә инде «миңа кул сузды, йә булмаса пәрәнҗәмне күтәреп карады» дисә, шуравины һичшиксез атачаклар иде. Хатын бик карышмады. Өстәлдә торган шәмне генә сүндерде. Бергә кундылар. Озак сөйләшеп яттылар. Хатын үзенең тарихын сөйләп бирде...

– Безнең кышлак таулар арасында иде. Һәм сезнең гаскәрләргә каршы бик нык каршылык күрсәтте. Бер очкычыгызны да бәреп төшерделәр. Шуңа үч итеп, авылны һавадан килеп, утка тоттылар. Авыл бетте. Мин дә һәлак була идем, авылдан ерак кына урында кышкылыкка утын әзерләргә энем белән елга буена төшкән идек. Шул сәбәпле, бер без генә исән калдык. Барчасы һәлак булды. Энем белән икәүләп кулдан килгәнчә кабер казып, мәетләрне җирләргә тотындык. Тик ике кеше нәрсә генә эшли ала? Күпләрен шул бомбадан калган чокырларга тутырып җирләдек. Үзебез бер зур гына баз табып, шунда яши башладык. Чөнки кышлакта бер исән йорт та калмаган иде. Энем, үч алырга теләп, авыл хәрабәләре арасыннан берәр корал табып булмасмы дип йөри торгач, ике автомат табып кайтты. Барча туганнарның үчен алырга дип, үзе теләп, сугышка китте. Өч ел элек булды бу хәл. Бабайның әбисе чыгышы белән шул безнең авылдан. Уллары сугышның беренче елында ук өчесе дә шәһит булган. Энем сугышка киткән ел иде. Лотфулла бабай шул елның кышында, әзрәк эшләре беткәч, кайнешенең хәлен белергә дип, авылга килгән. Ә авыл да, туганнары да юк. Тик мин яшәгән баздан гына бераз төтен чыкканын шәйләп алган. Кышкылыкка юньле рәтле ризык та әзерли алмадым. Менә шунда бабай мине килеп тапты. Кыш, үзең беләсең, караңгы тиз төшә һәм тауларда

бик суык. Бабай куна калды. Ә иртәгәсен бөтен дөнья котырып, асты-өскә килде. Буранлап, айдан артык кар яуды. Ә без бабай белән ачлы-туклы шул базда яшәдек. Җитмәсә, базның өстенә дә күпләп кар өйгән. Баз капкачын күтәреп кенә чыгарлык та түгел. Ярый әле, морҗа булып хезмәт иткән калай торба буйлап тамчы тама. Менә шул суны эчеп айдан артык икәү генә яшәдек. Шул чакта оялып тору дигән нәрсә калмады. Һәм бабай үзенең кайгысын сөйләде.

– Улларым һәлак булды. Әбием картайды, яңадан бала китерерлек хәлдә түгел. Миңа икенче хатынлыкка риза булып кил. Барча мөлкәтемне калдырырга кешем калмады. Авылыгыздагы Абдулла – кайнешем иде. Аның малаена васыятьнамә китергән идем. Күреп торасың, барысы да һәлак булганнар. Риза булып килсәң, балабыз булса да, булмаса да – барча мөлкәтемне сиңа калдырам. Башка кешем калмады. Без карт инде, безне карарсың. Каһәрле сугыш аркасында илдә ир-атлар әз калды. Ичмаса үзең мал-мөлкәтле бай хатын булырсың. Риза бул, кызым, – дигәч, ризалаштым инде. Нишлисең, безнең әфган хатыннары бик оялчан. Ә монда бер баз эчендә яшәп ятабыз. Баз почмагына чокып, шунда бәдрәф ясадык. Бик оят булмасын өчен бер чыбылдык сыман нәрсә элдем. Менә шулай булды. Февраль башында гына, яз кояшы ныклап карый башлагач, баз өстендәге кар эреде. Һәм бер төнне тышка күтәрелдек. Көндез үк күтәрелә идек, бабай-ирем ризалашмады. Сукыраюыбыз мөмкин диде. Хәзер менә шушы өйдә асрау кыз вазифасында хуҗабикә булып, өченче ел инде дөнья көтәм, – дип, яшь хатын уфтанып алды. Базда чагыбызда никахны үзе укыган булды. Һәм дәвам итеп: – Ирем белән бала турында күп сөйләштек. Бабайның ирлек хәле дә шул үзе кадәр генә. Шуңа да болай диде: «Әгәр дә балага узсаң, барча күршеләр, халык алдында минем яшь хатыным, диярмен. Ә инде бала булмаса, асрау кыз булып яшәрсең. Асрау кыз булып калсаң, икенче кияүгә чыгарга да җиңелрәк булыр. Без карт бит инде, тагы күпме калган яшәргә, бер Аллаһ үзе генә белә». Ул үзе миңа синең белән йокларга тәкъдим итте. Балага узсам, бабай миңа өйләнгәнен халыкка белдерәчәк. Шулай булгач, бик оялып торма. Күреп торам, әле син өйләнмәгәнсең һәм хатыннар белән ничек йокларга кирәген дә чамаламыйсың.

Һәм менә совет солдаты-шурави, ә чынлыкта Әфганстан әсире – Ринат беренче тапкыр хатын-кыз белән кунды.

Бабай әбисе белән кунакта ун көнгә якын торып кайтты. Һәм бабай бик хәйләкәр карт иде. Үзенең яшь хатыны авырга калганын белгәч кенә, теге оч мулласын чакырып, үзе белән яшь бичәсенә никах укыткан булды. Янәсе, белсеннәр: бабай үзе асрау кызым дип йөрткән хезмәтче кызга өйләнде. Әгәр бабайның асравы рус әсиреннән авырга калган дип, гайбәт таралса, Зөһрәне кыйнап, авылдан куачакларын көт тә тор. Дошман солдаты белән төн кунганын белсәләр, хатынны үтерергә дә мөмкиннәр. Ә хәзергә барысы да бабайны гаепләп: «Картаеп беткән бит инде, бер аягы, гүрдә, үзе һаман яшь кызга өйләнде», – дип, аны чәйнәделәр.

Монда өйләр өянкеләрне сырып алган карга оясы кебек. Кышлакта буш һәм өй төзергә яраклы җирләр әз булу аркасында, өйләрне тау битендә әзрәк тигезрәк урын булса, шунда менгереп салалар. Читтән карасаң, тау битен,

кыя асларын төрле-төрле зурлыктагы өйләр ябышып сырып алган. Шуңа да тау-кыяга ябыштырып салынган өйгә җәяүләп керерлек кенә сукмактан йөриләр. Шул сукмактан суын да, ягарга утынын да үз җилкәләренә күтәреп ташыйлар. Абзарлары булып, сарык-кәҗә тотканнары да малга азыкны шул тар сукмактан бауга бәйләп, үз җилкәләрендә күтәрәләр. Бу бабайлар кышлагында шулай. Ә бабайның өе аста, тигездә һәм су кырында булганга, су һәм мал азыгы ташу алай ук кыен түгел. Юл-урам да якыннан үтә. Шушы тарлавыкта урнашкан башка кышлакларда да шулай. Ни-нәрсәсенә кызыгып, шушындый тар урынга тыкшынып утырганнардыр? Аңламассың. Бер туры килгәндә, бабайдан сораган иде, ул:

– Улым, безнең кышлакка беркайчан да дошман аягы басмаган. Һәм басмас та. Үзең күреп торасың: тирә-якта нинди биек кыя-ташлар. Безгә тик бер юл белән генә керергә була. Ә ул юлны безнең кешеләр саклый.

Бабай шулай аңлатты.

Март башларында кояш ныклап кыздырып, кар күпләп эри башлады. Рухлар Ринатның бабайда яшәгәнен онытмаганнар икән. Бер көнне кинәт кенә бу таулар куенына ышыкланып утырган кышлакка килеп менделәр дә монда булган тагы өч әсир белән бергә Ринатны да алып төшеп киттеләр. Бабай рухларга үзендәге шуравины алып калыр өчен акча да тәкъдим итеп карады. Тик тегеләр ризалашмады. Әсир белән, нечкә күңелле бабай күз яшьләрен сөртә-сөртә хушлашты. Зөһрә аны тәрәзәдән генә карап озатты. Ул да елый иде. Бабай әсирне алып китүчеләргә бу әсирнең әйбәт, яхшы һәм йомшак күңелле кеше икәнен әйтеп, бик кыерсытып җәфаламауларын үтенде. Ринат һәм тагы өч әсирне арбага утыртып, аска, тигезлеккә алып төштеләр. Тигезлеккә якынлашкан саен яшеллек тә мулрак күренә башлады. Менә тарлавыктагы сак постын да үттеләр. Алда – билгесезлек. Чөнки тарлавык авызына җитәрәк аларны алырга килгән адәмнәр исләренә төшеп, егетләрнең күзләрен бәйләп куйды. Постны үтүләрен шундагы сакта торган рухларның тавышыннан чамаладылар. Арба тәгәрмәченең үзенә май сорап, сызланып, сыкранып шыгырдавы гына йөрәкне әрнетә. Тәгәрмәчнең елавын бер Ринат кына аңлый иде. Ул инде шушы тәгәрмәчнең сызлануына кушылып үз уйларына батты. Әйе, Зөһрә тау арасындагы кышлакта калды. Өч көн элек кенә Лотфулла бабай, әсир яшәгән җылы алачык эченә кереп, аны үзләрендә калырга бик нык итеп үгетләде.

– Улым (әйе, хәзер ул аңа бөтенләй якын итеп, улым дип дәшә башлаган иде), намаз укый беләсең. Хәзер син – чын мөселмансың. Безнеңчәне дә, үзбәкчәне дә яхшы аңлап, матур сөйләшәсең. Бездә генә кал. Син – бик эшчән һәм уңган кешесең. Тормыш көтү сиңа монда авыр булмас. Укый-яза белгән кеше кышлакта икәү-өчәү генә. Санасаң, бер кул бармагы да җитә. Кышлакта яшәүчеләрнең балаларын укытырсың. Теләсәң, Зөһрәгә өйләнерсең, теләсәң башка кызны алып бирербез. Калымны үзем түләрмен. Аның өчен һич кайгырма. Балаларың булыр. Кал, улым, бездә генә. Күреп торасың, минем улларым сугыш башланган елны ук һәлак булдылар. Карт көнемдә беркемем дә калмады. Безне карарсың. Теләсәң, аерым өй салып, башка чыгарсың.

Бабай шулай озак үгетләде егетне. Ә шурави сүзсез генә үз уйларына

бирелеп, туган илен – Башкортстанын, әти-әнисен уйлап дәшми генә утырды. Һәм бабайның күзләренә карап:

– Рәхмәт, бабай, рәхмәт! Тик минем үз илемдә әти-әнием ялгыз калды. Алар минем исәнме-юкмы икәнемне дә белмиләр. Менә ничә ел миннән хәбәр юк. Аларны шулкадәр сагындым. Сөйләп аңлатырлык та түгел. Авылыма кайтып, аларны күрмәсәм, үзем дә сагыштан үләрмен кебек. Юк, бабай, монда кала алмыйм. Тагы бер тапкыр рәхмәт сезгә! Мине үз улларыгыз кебек карадыгыз. Ашаттыгыз, киендердегез. Сездә үз өемдә яшәгән кебек яшәдем.

– Ярар, улым, алай үз әти-әниеңнәрне кайгырту – яхшы сыйфат. Уйла, улым, әле вакыт бар. Барысын да уйла. Үз илеңә кайткач, Себер җибәрмәсләрме? Шунысын да уйла, – дип, урыныннан торды. Уфтанып һәм егетнең аркасыннан бер яратып алды да чыгып китте.

Әйе, Лотфулла карт бик укымышлы иде. Шушы әллә нинди җәһәннәм авызындагы кышлакта яшәп, Себернең нинди урын икәнен белер булгач, күпне күргән булып чыга. Себер начар ягы белән бик данлыклы урын, әллә бабай үзе дә шул якларда булып кайткан кешеме?..

Арба һаман шул бер көйгә елап, үз моң-зарын арбадагыларга сөйли төсле иде. Тау арасыннан шул арбаның елавын тыңлап, ике көн төштеләр. Төн кунарга туктаган бер постта гына ары-бире капкалап алдылар. Бүтәнчә ашату булмады. Тагы шул богау, тагы шул качмасыннар өчен бәйләп яткырулар. Янә шул эт тормышы башланды.

Хәзер юл кырындагы миналарны тазартырга куштылар. Тагы бик куркыныч, һәлакәтле көннәр башланды. Бу төрле техникага каршы куелган зур миналарны да Ринат оста тапты. Аны мондагы тигезлеккә шулай теләсә нинди минаны тиз таба алу сәләте булганга күрә алып төштеләр дә инде. Тик әсирләр һаман туган ил чигеннән ераклаша барды. Шуңа эче пошты. Сөйләшүләрен тыңласаң, Пакистан чигенә дә ерак түгел. Ринат үзенең пуштун телен аңлавын яшерергә тырышты. Чөнки рухлар аның үз телләрен аңлаганын белсәләр, тоткыннар арасында бик сөйләшеп бармаслар. Уйниятләрен алар алдында бөтенләй ачып салмаслар. Ә болай, әсир барыбер аңламый дип, бер-берсе белән ачыктан-ачык сөйләшәләр.

Тирә-якта яз. Миналардан арчылган басуларда эш кайный. Бу дүрт әсирне шунда эшләргә йөртәләр. Кичә Ринат өчен бик тә куркыныч хәл булып алды. Бу кышлак гүелдәп аккан тау елгасының ике ягына урнашкан. Ике якны тростан эшләнгән асылмалы күпер генә тоташтыра. Эштән кайтканда, ерактан ук күрде: халык өелешкән һәм кычкырышалар. Якынрак килгәннәр иде, шул асылмалы күпернең нәкъ уртасында субай-баганага тотынып, бер бала акырып елый. Ә күпернең өстеннән ике яклап та бик куркыныч итеп кайнап, тау елгасы ага. Бала бу күпер уртасына ничек барып эләккән? Кем белсен. Күпернең ике як кырын су каплаган, җитмәсә, су агымына ул бик яман итеп чайкалып тирбәлә. Бахыр балага арканнар да ыргытып карыйлар. Тик бала бик курыккан, үзенең нәзек кенә беләкләре белән субайны кочаклаган да кычкырып, әнисен чакыра. Әнисен бала кырына җибәрмичә ике ир тоткан. Җибәрсәләр, ул да суга батып һәлак булырга мөмкин. Чөнки менә-менә таудан тагы да көчлерәк су ташкыны төшәргә тиеш, ди. Барысы да кычкырыша, барча хатын-кыз елаша. Ирләр,

тешләрен кысып, нәрсә булырын көтәләр. Чөнки бала, баганадан кулын ычкындырып, бауга тотынырга курка. Су тавышы белән бала ярдагы олыларны ишетми дә.

Шурави шунда үзенең яз көнендә ничек суга акканын һәм Заһит бабасы аны судан алып чыкканын хәтерләп, калтыранып куйды. Бу баланы коткармасалар, бала һәлак булачак бит. Ул бер балага карап алды, бер, баламны коткарыгыз, дип елаган хатын ягына күз салды. Сакчының аны туктатырга тырышып җикеренүенә дә карамый, ярдан аркан ыргытучы сакалтай янына килеп басты. Тегенең очырырга әзерләнгән бауның очын тотып, үзенең биленә нык лы гына бәйләп, суга да кереп китте. Ярдагы кычкырышулар тынды. Барысы да ни буласын көтә башлады. Берничә хатын аны дәртләндереп кычкырышып алды. Ринат, аягы белән капшап, такталарны барлап һәм троска ике куллапябышып җайлап алга атлады. Су бик тә салкын, бозлы-карлы. Менә ул бала ябышкан уртадагы субайга барып тотынды. Су монда әле баланың аягына килеп җитмәгән. Шуңа да бала бик өшемәгән. Әмма теше-тешкә тими калтырый иде. Ринат аның кулыннан тотып, баганадан ычкындырырга тырышты. Тик бала шул кадәр куркып баганага чытырдап ябышкан ки, һич кенә дә ычкындырырлык түгел. Бер кулын ычкындырса, икенче кулы белән ябыша. Чөнки асылмалы күпер су агышына бик нык итеп чайкала. Шуның аркасында әсир дә кулыннан тросны ычкындыра алмый. Ычкындырса, чайкалып суга егылырга мөмкин. Аннан икесе дә һәлак булачак. Ничек итсә итте, Ринат баланы кочагына ала алды. Бала хәзер чытырдап, Ринатның муенына тотынды. Баланың кысып тотуыннан тын алулары кыенлашты. Егет ышанычлы булсын өчен баланың киеменнән дә тешләп алды. Чөнки суыктан балага шок булып һушын югалтса, егылырга мөмкин. Тау елгасының агымына карарга куркыныч. Алдан-арттан котырып аккан елгага караган көе бер мизгелгә аның башы әйләнеп, зиһене чуалып китте. Шуңа да ул чытырдатып, күзләрен йомып кирегә борылды. Шунда ул: «Бауның очын озынрак калдырырга кирәк булган. Алай иткәндә бауның буш очы белән баланы үз гәүдәмә бәйләгән булыр идем» дип уйлап куйды. Менә халыкны куркыткан икенче яктан килеп кушыласы ташкынның да гүләгәне ишетелде шикелле. Ярда халык тагын ныклап кычкыра башлады да кинәт кенә тынып калды. Ринат артына борылып карый алмады. Зур йөк машинасы биеклегендә ажгырып килгән икенче ташкын аны бәреп екты. Әсирнең башыннан: «Их тагы өч метр араны чыгып өлгерә алмадым. Бала әрәм була инде», дигән уй яшендәй сызылды. Аннары: «Баулары гына түзсә ярар иде» дип куйды.

Алар бәхетеннән, бау түзде. Чөнки аркан капроннан эшләнгән альпинистлар арканы иде. Һушларын югалтыр дәрәҗәгә җитеп, суга егылган Ринат белән баланы ирләр күмәкләшеп тартып, ярга чак чыгарып өлгерде. Яр башында тәгәрәтә, селкетә торгач, бала һушына килеп, әүвәл косып, аннан елап җибәрде. Әсир дә үпкәсенә эләккән карлы-бозлы сулардан йөткереп, чак тын ала башлагач, күзләрен ачты. Җыелган халык әсирнең бу батырлыгыннан таң калып, башларын чайкап, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, аны мактады. Кемнәр булгандыр, кулларын кысып, рәхмәтләр әйттеләр. Коткаручы белән баланы якындагы бер йортка алып,

кереп, сәкегә салдылар. Ике сакчыны халык нәрсәгәдер әрләп ташлады. Шурави азактан гына белде. Каравылчылар бу әсирне алып кайтып зинданга ябарга теләгән икән.

Шуравинең хәле бик шәптән түгел иде. Карлы-бозлы су астында калудан, әлеге шул, тамагы шешеп чыкты. Икенче көнне аны зинданга алып кайтып яптылар. Ярый әле, юеш киемнәре иртәнгә чаклы кибеп өлгерде. Югыйсә бу салкын зинданда бөтенләй бетә иде. Шушы вакыйгадан соң әсирнең сәламәтлеге бермә-бер начарланды. Тын алулары авыраеп, тамагы нык шешүдән, ашый алмас булды. Ике көннән соң коткарылган малайның туганнары аның хәлен белергә килделәр. Әсирнең хәл эчендә базда ятканын күреп, аны бик нык кызгандылар. Малайның әтисе авылны үз кулында тоткан байга барып сөйләшеп, әсир солдатны үз өйләренә алып кайтырга рөхсәт алды. Рухлар арасында да, гади халык арасында да шуравиның абруе бермә-бер артса да, аның хәлләре бик алама иде. Суык нык тигән. Им-том белән шөгыльләнүче карчыкны чакырганнар. Ул да булдыра алмагач, ниндидер бер ирне күрше шәһәрдән алып килделәр. Менә шул ир шуравигә әллә ничә уколны берьюлы кадап, иртәгә дә кадарга дип, тагы дарулар калдырып китте. Шуннан соң гына бераз хәле җиңеләеп, терелү ягына бара башлады. Ул атна-ун көн урында ятты. Терелеп, урамга чыгып йөри башлагач, аны тагы басуларны минадан тазартырга алып киттеләр. Һәм халык бу шуравине курку белмәс, «тере мина эзләгеч» дип йөртә башлады. Хәтта бу гаҗәеп әсирне күрергә, башыннан аягына чаклы коралланган ике тән сакчысы белән шушы кышлак егетләренең командиры булган рух килеп китте. Шуравигә эчәргә дип тагы ниндидер дарулар да калдырдылар. Имеш, тизрәк ныклап савыксын. Аны икенче, мөһимрәк урынга күчерәчәкләр, дип тә өстәде. Авырып ятканда, аның әфган-пуштун һәм үзбәк телен яхшы аңлап, сөйләшә белгәне ачыкланды. Шуңа да хәзер рухлар аның белән тылмачсыз аралаша.

Чынлап та аларны тау елгасы буенда урнашкан олы юл үтә торган бер зур кышлакка китереп урнаштырдылар. Бу елгага эреле-ваклы инеш-чишмәләр килеп кушыла. Аларны һаман элекке кебек, тик авыр эшләргә генә йөртәләр.

Басуда эшләп йөргән чагында ул гүләү тавышын ишетте. Бу безнең БТР һәм КАМАЗлар тавышы иде. Аны каравыллап йөртүче сакчы әллә берәр якка киткән, әллә тагы әфьюн тартып миңгерәүләнеп ята, үзенең куышы янында күренмәде. Ринат, барча көчен җыеп, кышлакка таба торып йөгерде. Олы юл кышлак уртасыннан үтә иде. Шуңа да тизрәк кышлакка кайтып җитәргә кирәк дип ашыкты. Барча нияте безнең үтеп баручы гаскәрләр колоннасы каршына чыгып, берәр БТРны, йә булмаса берәр машинаны туктату иде. Колонна каршысына чыгып өлгерә алса, күптән хыялланып көткән азатлык киләчәк бит. Ниһаять, азатлык, азатлык!

Менә инешнең текә ярыннан йөгереп төшкән уңайга суга барып капланды. Тагы торып йөгерде. Каршыда текә генә инештән су ташый торган бормалы сукмак. Сукмакны да тиз менеп җитә алды. Колоннаның бу башы кышлакка кергән, ә теге очы күренми. Өлгерәм дип уйлап алды. Өлгерәм, өлгерәм. Менә бу тар урынны үтсә, иркенгә чыга. Нәкъ шушы тар урында бер әфганлы чиләкләрен күтәреп, судан кайтып бара. Ул юл биреп, бу тар урыннан үткәреп җибәрсә, котылачак. Югыйсә тар урынны урый-

урый, ташлар артыннан хәтсез ара йөгерергә туры киләчәк. Өлгермәскә мөмкин. Ринат ерактан ук пуштунча:

– Юл бир! Үткәреп җибәр! – дип кычкырды.

Мондагы йола буенча тау сукмагы, тау юлында очрашкан чакта ашыгучыга һәрчак юл бирелергә тиеш. Бу язылмаган, әмма катгый үтәлергә тиешле канун. Теге бәндә чынлап та юл бирде. Сукмакка куйган чиләкләренә чаклы үзенәрәк тартты. Кырыннан туктамый йөгер дә үт. Ләкин, әлеге шул язмыш дигән нәрсәнең «ләкине» бар икән шул. Ләкин бу рух үзенең бик нык булмаган сәламәтлеге белән гел шул каравылда, сакта торып булашкан әфганлы булып чыкты. Башкалар кебек дошманга корал күтәреп йөри алырлык түгел һәм бик астыртын, ялкау бер бәндә иде. Кыскасы, рух аны таныды. Чөнки әсирләрне күп тапкыр саклап йөртте. Теге вакытта язгы ташкында, халык әрләп ташлаган сакчы иде бу бәндә. Әйе, ул таныды һәм, шурави аның кырыннан йөгереп узганда, кулындагы көянтәсе белән әсирнең тез астына бар көченә китереп сукты.

Мондый хәлне көтмәгән Ринат, авыртудан һәм көянтәгә абынудан җиргә егылды. Ярый әле, яңадан ташлары тырпаеп торган текә яр астына тәгәрәмәде дә, аяк сөяге сынмады. Барча өмет-хыяллар пыяладай ватылып, челпәрәмә киләме? Шурави үзен-үзе белештерми сикереп торды, аңа мыскыллы елмаеп, черек тешләрен ыржайтып карап торган рухның бугазына ябышты. Җиргә бөгеп салды. Әсирдән бу кадәр җитезлек һәм көч булырын күңеленә дә китермәгән әфганлы каршылык та күрсәтә алмады. Шуравинең күзенә черек тешнең башына тондырырга хет берәр яраклы зурлыктагы таш та күренми ичмаса. Шул мизгелдә сулы чиләк торганын чамалап алды һәм үзен-үзе белештермичә, тегене башы белән суы тулы чиләккә тыкты. Өч минут үтмәгәндер, черек теш инде, суга тончыгып, бөтенләй тынып калды. Әсирнең колагына тагы БТР һәм машиналар тавышы чалынды. Ул аяк сөякләре авыртуын да белештермичә, юл кырына килеп чыкты. Әһә, колонна үтеп бетмәгән икән әле. Тагы бер-ике «Урал» машинасы күренде. Шурави юлга ук чыгып басты да бар көчен җыеп кычкыра-кычкыра, кулларын бутап, машинаны туктатырга чамалады. Кабинадагылар ике әфганлының яр читендә сугышып ятканын бая ук күреп, тамаша кылып киләләр иде. «Бу нинди тиле әфганлы, сугышуыннан туктап, безгә каршы чыкты? Җитмәсә, туктарга куша. Бетмәс монда җыен кырагай дип, кырыннан чажлап үтеп киттеләр. Менә азаккы машина әкренәюен әкренәйде, бу сәер рухны таптап китүдән курыкты, ахры. Ул да үтеп китте. Машина әрҗәсендә безнең солдатлар утыра иде. Әсир, машинаны куып җитәргә теләп, артыннан кычкырып йөгерә башлады. Тик машинада утырып барганнар исерек идеме, әллә әфьюн чәе эчүдән миңгерәүләнгән иделәрме, берсе кулына автоматын алып, Ринатның баш очыннан пулялар сиптереп, очередь бирде. Ул колак кырыннан гына пулялар сызгырып үтүенә игътибар да итмичә, тагы да кызурак йөгереп, тамагын яра-яра, мин шурави, мин совет солдаты дип кычкыра башлады. Машинадагылар аны ишетмәде. Теге солдат яңадан аның аяк астына тагы ут сиптерде. Пуляларның юл тузанына кадалуларын күргән әсир, барча тырышлыгы бушка киткәнен аңлап, тешләрен кысты. Тамагына сулышын каплап төен тыгылды. Һәм ул хәлсезләнеп, юл читенә барып утырды да машиналар

тавышы белән азатлыкның үзеннән ерагая барганын тоеп елап җибәрде. Нинди уңышсызлык, нинди үкенечле хәл. Менә-менә котылам дигәндә, бар ниятләр җимерелде.

Ике көннән шәригать суды була, диделәр. «Черек тешнең» кайдандыр абыйсымы, энесеме кайтып житәргә тиеш, ди. Шуны көтәләр. Ринатны басуга миналардан тазартырга да алып чыкмадылар. Зинданда бер почмакта богаулы килеш утырып калды. Бетеренде егет. Бөтенләй өметсезлеккә бирелде. Ул хәзер инде, атсалар тизрәк атсыннар, этләп җәфаламасалар ярар иде, дигән уйларга бирелеп утырды. Теге «черек тешне» тончыктырып үтергән өчен, әлбәттә, атачаклар. Аны тончыктырганга һич үкенмәде. Бер җаһил үлде. Ичмаса башка тоткыннарга әзме-күпме җиңеллек булыр.

Суд һаман булмый торды. Көтмәгәндә аны таулардан төшкән Лотфулла бабай эзләп тапты. Ринатны баздан чыгардылар. Бабай аны кочаклап алды дигәндәй, бик җылы итеп, куш куллап исәнләште. Ул күчтәнәчләр дә төяп килгән икән. Әсиргә генә түгел, шундагы сакчыларга һәм башка рухларга да өлеш чыкты. Ни гаҗәп, шул ук көнне теге кышлактан суга бата язган баланың да этиләре килде. Күрәсең, алар бу әсир-шуравине нәрсә көтәчәген беләләр иде. Әсир кыскача гына нәрсә булганын сөйләп бирде. Теге тешсезне ничек тончыктырганын гына ипләп сөйли алмады. Бары тик: «Юньләп хәтерләмим дә инде. Барысы да кызулык белән эшләнде», – диде.

Икенче көнне суд булды. Судлары да бик кызык икән. «Черек тешле»нең теге кайткан энесе казыйдан үлем җәзасы таләп итте. Ташуда коткарылган баланың этисе һәм әнисе бу шуравигә мәрхәмәтле булуларын үтенде. Ә инде Лотфулла бабай бөтенләй икенче яклап сүз башлады. Мөселман мөселманга гына түгел, барча тоткын-колларга мәрхәмәтле булырга тиешле икәнен Коръәннең нindидер сүрәсен укып ишеттерде. Аңа каршы казый шул ук Коръән китабының икенче урынын ачып «күзгә – күз, тешкә – теш, үтергәнгә – үлем», дигәнен укыды. Тагы да мәрхүмнең туганнары нәрсә әйтер, җәза шуңарга да бәйле дип өстәде. Шунда аның яклылар егетнең менә ничә ел инде басу-юлларны минадан тазартканын да әйтеп үттеләр. Шулай озак кына бәхәсләшеп, барысы турында да сөйләшенгәч, казый шуравины «черек тешнең» гаиләсенә мәңгелек коллыкка бирергә дигән карар чыгарды. Ярар, монысы өчен дә рәхмәт. Коллык кабергә кереп яту түгел. Ринатны бу авылдан ерак та булмаган бәләкәй генә күрше кышлакка алып киттеләр.

Аллаһы Тәгалә анда да үз мәрхәмәтеннән ташламас әле. Лотфулла бабай шулай дип тынычландырган булды. Теге «черек теш»нең гаиләсе яшәгән күрше кышлакка чаклы озата барды. Һәм Ринатның колагына:

– Зөһрә малай алып кайтты. Безнең улыбыз бар, – дип куйды да, егетнең күзләренә карап, серле генә елмаеп алды.

Ринат бу хәбәргә шатланырга да, кайгырырга да белмәде. Тик Лотфулла бабайга:

– Әбиләргә миннән сәлам әйтерсез. – Ә улыгызга кем дип исем куштыгыз диюенә, картлач яз кояшыдай җәелеп:

– Синең исемне куштык, улым, синең исемне, – диде. Шурави бу хәбәргә елмаеп: «Әфганда мондый исем бармыни?» – диюенә: – Хәзер булыр. Без аңа Ринатулла дип куштык. Зинатуллага якын исем. Бәләкәй улымның

исеме Зинатулла иде. Аерма бер хәрефтә генә. Син кайгырма, улым. Әзрәк акча әтмәлләгәч, мин сине килеп сатып алам. Барыбер боларда калдырмам. Бик төшенкелеккә бирешмә, улым. Аллаһы Тәгалә сине юкка гына әллә ничә үлемнән алып калмады. Тәкъдирең әле укылып бетмәгән. Тәкъдир агачындагы яфрагың урынында нык эленеп тора. Төш күрдем, балам, өеңә кайтып җитәсең әле син. Шунда безне исеңә төшереп, безнең хөрмәткә берәр дога да укып куярсың.

Лотфулла бабайның тагы нәрсәләрдер сөйләргә исәбе бар иде дә, Ринат кол булып хезмәт итәсе өйгә килеп җиттеләр. Бабай белән капка төбендә бик җылы гына саубуллашып аерылыштылар. Аерылышыр алдыннан бабай, Ринатны бөтенләй аптыратып, колагына чеп-чи татарча:

– Мин үзем дә шул Урал ягында балалар укыттым бит. Утызынчы елларда качып китәргә туры килде. Йөри торгач, менә кая килеп эләктем. Мин бит – Уфа татары, – дия алды.

«Менә сиңа мә!» дигәндәй, шаккаткыч хәбәрне салды бабай. Тик капка ачылып, хуҗалар егетне эчкә төртеп керттеләр. Аларның бу шуравигә карата ачулары көчле иде. Озаклап Лотфулла бабай белән хушлашырга да ирек бирмәделәр. Капка ябылды. Бабай капка артында калды.

Шулай итеп, Ринат «черек теш» йортында хезмәтче-кол булып яши башлады. Кол – кол инде. Йорттагы бар эшне аңа өйделәр. Таң атар-атмастан эшне өйгә су ташудан башлый. Ринат яшәгән йортта карт белән карчык олы улының хатыны белән тора. Ә «черек тешнең» өй-йорты күршедә. Әсир шул йорттагы алачыкта көн күрергә тиеш булса да, киленнәре кискен каршы төшеп:

– Йортымда чит ирнең яшәвен теләмим. Ул минем иремне һәлак итте. Сездә генә яшәсен, – дип, каенатасына белдерде.

Йортта вак-төяк һәм ялыктыргыч эшләрне аның җилкәсенә өйделәр. Эш-эш инде. Басуны минадан тазарту түгел. Анда минут саен, секунд саен синең гомерең кыл өстендә генә асылынып тора. Үзең ялгышсаң да, иптәшең ялгышса да бетте, үлдең дигән сүз. Басу, сукмак-юлларны минадан арчыганда, күпме дус-танышлары һәлак булды. Юньләп танышырга да өлгерә алмый калган солдатлар әллә нихәтле иде.

*(Ахыры киләсе санда)*



Рәфкать
Шаһиев

# ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕМНЕ ТИКШЕРӘМЕН...

## Асрамага туган телем бирәм

Асрамага туган телем бирәм!
Алсагызчы – саклар өчен генә.
Ят кулларга бер дә бирмәс идем,
Җитеп бетми минем көчем генә.

Асрамага туган телем бирәм!
Арагызда юкмы татар бае?
Аллаһ сезгә әҗерләрен бирер,
Әманәтен үтәсәгез бары!

Асрамага туган телем бирәм!
Алыр бәлки берәр милли түрә?!
Сездә закон, кулыгызда – мөһер,
Әйтүем дә бары шуңа күрә.

Асрамага туган телем бирәм!
Бер депутат юкмы арагызда?
Балаң сөйләшмидер, тик шулай да
Ул тел булгандыр бит, бабагызда?!

– Үзем алам, абый, саклар өчен,
Тукайлардан калган изге гөлне!
Халкым арасыннан яңа Апуш
Күкрәгенә кысып иркәләде
Ана сөте сеңгән туган телне.

***

Таңнар нурлы, төннәр якты безнең якта,
Син дә аны күңелеңдә шулай сакла.
Ихлас сүзләр сөйләсеннәр безнең хакта,
Өстебезгә бер уч туфрак салган чакта.

---

Рәфкать ШАҺИЕВ (1968) – *шагыйрь,прозаик, филология фәннәре кандидаты. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Атамалар – тарих ачкычы» (2004), «Сагыну исе» (2017), «Элеккечә түгел без генә» (2022) һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

## Ерагаймас ара

Мин авылга кайттым әле үзем генә,
Кояш баеп бара иде үз көенә.
Туган йортны күреп, җаным мең сөенә,
Кайту рәхәт эти салган үз өеңә.

Тәрәзәгә төшкән шәфәкъ кызыллыгы,
Һәм сүрелгән җәйге көннең кызулыгы.
Сокландыра авылымның хозурлыгы,
Тауларының биеклеге һәм зурлыгы.

Тәрәзләрдән миңа яран гөлләр карый,
Карт алмагач салмак кына чәчен тарый.
Ишегалды яшел келәм – ул да ярый,
Каршы алыр кешем генә каршыламый...

Мин авылдан бер ялгызым китеп барам.
Күптән инде җөйләнде күк йөрәк ярам.
Тик шулай да, ерагаймый һаман арам,
Хыялымда әнкәй дәшә:
«Кайт син, балам!»

***

Ике кулын канат итеп җәеп,
Каршы йөгерә ана баласына.
Егыла, тора, тез башлары каный,
Көчкә түзә йөрәк ярасына...

…Хәзер булса, алай итмәс идем,
Гел янында торыр идем, сакта.
Егыла-тора үзем чабар идем,
Кырык эшем ташлап кырык якка.

Утырасың... Бар, чап!.. Ник чапмыйсың?
Йөгер, көтәр кешең исән чакта!

***

Гамәл дәфтәремне тикшерәмен,
Кызыл кара белән.
Балачакның мизгелләре калган,
Озын ара белән.

Бер хата юк, бар да чиста, төгәл –
Әби дәресләре.
Кызыл кара тидерерлек түгел –
Иман, фәрештәле.

Әти белән әни биргән сабак,
Игътибарсыз хата –
Гамәл дәфтәремнең кай битенә
Кызыл кара ята?

Эчкә узган саен «дәфтәр бите»
Чуарлана бара.
Йә җиренә җитеп бетми калган,
Йә артык буш ара.

Әти-әни, укытучы әйткән
Сүзләр читләп узган.
Менә тагын кызыл кара белән
Калын сызык сызган.

Ә шулай да, тикшерелгән чаклы –
Бик аз анда шакшы.
Төзәтүләр күренсә дә шактый,
Эчтәлеге яхшы.

Сызган, бозган гамәл дәфтәремне
Син дә ачып кара.
Кызыл кара белән язып куйган:
– Туры юлдан бара.

## Сорау-җавап

***1.Сорау***
Кирәк тапса, берәү, үзен аклап,
Синең өскә пычрак өя икән.
Шакшы киемнәрен тизрәк салып,
Өсләренә акны кия икән.

Кирәк тапса, берәү, үзен мактап,
Синең өскә яла яга икән.
Шакшы җанын бик тә оста яшереп,
Үзе һаман тапсыз кала икән.

Кирәк тапса, берәү, сине күрми,
Таплап, таптап, атлап уза икән.
Һәм ул кеше үзенең гомер җебен
Өзеп, ялгап, алдап суза икән.

Кирәк тапса, шул ук берәү, сине
Мактап туймый, күңеле «кече» икән…
Кайда мактап, кайда яман сөйләү,
Аның иң җаваплы эше икән.

Ә ул берәү...
Чынында соң Кеше микән?!

***2. Җавап***
Кеше генә, бары адәм заты
Этлек кыла, кызармый да йөзе.
Имансызлык җанын керләндереп,
Сукырайса әгәр күңел күзе.

Кеше генә, бары адәм заты
Бер-берләрен аулар тозак ясый.
Мут елмаеп, тәмле теле белән
Башта ашың, аннан башың ашый.

Кеше генә, бары адәм заты
Кешелектән чыгып, ерткычлана.
Үз иманын сатып эчүчеләр
Үзендә юк иманыңны ала.

Кеше генә, бары адәм заты
Хайваннан да узып, була хайван.
Нәҗес тулган җанга сыялмагач
Намус белән оят чыгып тайган.

Иманнарын җуйган бәндәләрнең
Җан түренә шайтан оялаган.

## Җеназада

Фәлән кеше вафат.
– Йа Ходаем,
Бигрәк яхшы иде инде мәрхүм.
– Үзе тырыш, табигый бер талант,
Аның кебек булса иде һәркем.

– Кешелекле иде, берәүгә дә
Күтәрелеп, каршы дәшмәс иде.
– Белгәнгә дә, белмәгәннәргә дә
Никадәрле яхшылыгы тиде.

– Туры сүзле иде, курыкмады,
Дан-дәрәҗә даулап йөрмәде...
Үзе исән чакта бу сүзләрнең
Хәрефен дә ләкин белмәде?

Бакыйлыкка күчкәч никадәрле
Ишетелми калган купшы сүзләр...
Бисмиллалы япма аша узып,
Буш ноктада катып калган күзләр.

Әрнү катыш ялтыравык сүзләр
Кайсы җанга, кайсы канга тиде.
Әйткәннәрен ишетеп ятса ләкин,
Үлгәчтен дә сөйләмәсләр иде.

Баш иелгән, күзләр читкә карый,
Намус та юк әллә? Җанда бушлык?
Буталды бу дөнья. Яхшысын да,
Яманын да – барын бергә куштык.

## Мин хатынны мактыйм

Урап-урап, тышта карлар ява,
Шундый матур иртә.
Пар канатлы булып яшәүләргә
Җирдә соң ни җитә.

Янәшәңдә гомер иткән ярың
Җанга җылы бирә.
Өйләр якты, ашлар тәмле һәрчак –
Ул барына күрә.

Дөнья булгач, төрле чагы була –
Җилләп ала көннәр.
Тик, яңадан балкып кояш чыга,
Чәчәк ата гөлләр.

Урап-урап, тышта карлар ява,
– Дөнья актан-ак, – дим.
Акыллылар атын мактасыннар,
Мин – хатынны мактыйм.

## Элеккечә түгел бу дөнья

– Дөнья инде элеккечә булмый...
Хәзер һәркем шуны кабатлый.
Бу сүзләрдә һичбер яңалык юк,
Тормыш гел дә алга тик атлый.

Кырга чыгып, көлтә бәйләмиләр,
Бөк(е)рәеп урак урмыйлар.
Хәзер инде бодай түгел, учлап
Миллионлаган алтын урлыйлар.

Чишмә суларын да, ләззәтләнеп,
Бушка эчү бетте күптәннән.
Өч тиенгә газлы сулар алу
Сәлам булып калды үткәннән.

Күптән үзгә инде безнең дөнья,
Бәдрәфкә дә түләп керәбез.
Йомышыңны үтәп чыкканчы ук
Тимер тәңкәләрне бүләбез.

Фабрикада хәзер робот эшли,
Компьютерлар эшли заводта.
Комбайнчы түгел, йон йолкучы,
Тырнак ясаучылар почётта.

Дөнья элеккечә, үзгәрмәде,
Кояшы да чыга шул яктан.
Синең белән мин ул, без – кешеләр,
Бу дөньяны шулай болгаткан.

***

Сакла, диләр туган телне,
Сакла, алып китмәсеннәр.
Алып китеп берәр җирдә
Башын харап итмәсеннәр.

Саклап кына торып булмас,
Эш йөртергә кирәк гел дә.
Кулланмасаң коралны да
Тутык каплый якын көндә.

Белемне бит алган саен
Артып кына бара, диләр.
Киң таралсын туган телем –
Өйрәнсеннәр башка илләр!

Шул чагында сакланыр ул –
Дәүләт теле итеп йөртик.
Өйдә генә авыз чайкап,
Почмак якка куып кертмик!

Башкалар да сокланырлык
Йөзек кашы итеп йөртик!

***

Озын өстәл яннарында,
Утыралар түрдә тулып.
Телләренә җен төкергән,
Сайрашалар карга булып.
Берсен берсе уздырышып,
Төкерек чәчте, акыл сипте.
Иман белән намус бергә
Оялышып чыгып китте.

***

Эт – баш булып куйган, сыер – аяк...
Атасы, анасы кая соң?
Кем хуҗа, кем ялчы – баш җитмәс,
Бу дөнья кай якка бара соң?

***

Алда – чәчәк, артта – себерке лә...
Без ниндиләр?! Безгә карагыз!
Төпсез чуманнарга төялешеп,
Агым белән йөзеп барабыз.



Халисә Мөдәррисова

# КАЛХУЗ ХИКӘЯТЛӘРЕ

## Бер башы бит, бер башы!

Карада гынай урман,
Караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк
Үтәргә...[1]

Әйе, яшәр өчен ат кирәк. Кем белми аны? Яхшы ат булса, тагын да шәбрәк. Җигеп йөрергә атың булса, дәрәҗә инде! Моны Әхмәтгали бик яхшы аңлый. Шуңа да тормышыннан канәгать ул. Канәгать булмыйча, өйдә Сәлимәсе көтә, балалар канатланып, ояларыннан очып чыгып беттеләр, һәркайсының үз дөньясы, өй җылы, абзарда буаз сыер, кышлау күши, келәттә поши кадәр кышкылыкка суеп эленгән ике сарык түшкәсе өстенә дистәгә якын каз-үрдәк, бер читтәрәк җәйгә дип тозлап, өч литрлы ике банкага дыңгычлап тутырылган каз ите ымсындырып тора. Җәйге кичтә шул банкадагы бер-ике кисәк иттән пешкән, Сәлимә кискән токмачлы ашка әче катык катып, ике тәлинкә ашны «бөкләп» куйсаң, арулар бетеп китә. Шәп яши алар Сәлимәсе белән, мулдан. Эш кенә булсын! Атлы эш булсын. Ат – дөньяның тоткасы. Ат ашата. Арба төбендә көн дә булмаса да, тегесе-монысы кайта. Печәне, силосы, вакыт-вакыт капчыклап фуражы-ашлыгы да эләгә. Тик соңгы вакытта силсәвит Фаек белән завферма Әсхәт бик җаһилләштеләр. Бигрәк тә малчы Хәсән фураж урлап эләккәч. Фермага «Кызыл почмак»ка җыеп, җыелыш үткәрделәр. Силсәвит Фаек: «Ызначит, җитте, агай-эне, фураж белән шаярырга, әйе-ыһы, закун каты хәзер, алай-болай шик керсә, юлда туктатып, чаналарыгызга тентү үткәрәчәкбез, аннан үзегез беләсез, атны алу гына түгел, милиция юлыннан башыгыз чыкмас, ызначит, әйе-ыһы», – дип куркытты. Завферма Әсхәт: «Аңлашылдымы,

[1] Халык җырыннан.

Халисә МӨДӘРРИСОВА (1953) – *шагыйрә, прозаик, драматург; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. 8 китап авторы. Башкортстанның Нуриман районында яши.*

Әхмәтгали абзый? – дип, тәгаен аңа карап өстәде. – Кемнең кем икәнен карап тормабыз». Бу инде турыдан-туры янау иде. Димәк, ул шик астында, аңа каныгалар. «Дояркалар, сезгә дә кагыла, бераз чама белегез, шешә-шешә сөт ташыйсыз, мине белми, дисезме әллә?» Дояркалар ачулы карашларын Миңсылу ягына төбәделәр...

Шуннан бирле шүрләтә, тик келәт тулы нигъмәт булсын өчен абзардагы малларны да аз булса да, ялмандырырга кирәк. Печән-салам белән генә мал симертеп булмый, каз-үрдәкләргә дә язгылыкта йомырка салдырыр өчен түл җыйдырырга кирәк.

Шундый уйларга батып, Әхмәтгали иртән иртүк дубрга юнәлде. Каравылчы йортының туң тәрәзәсеннән саран яктылык төшә, димәк, шурник Галиәхмәт килгән дигән сүз, эш шәбрәк барачак, конюхларны көтеп, вакыт үткәрәсе түгел. Һәм ул сбруй, камыт, ыңгырчак, дилбегә, бер сүз белән әйткәндә, дирбияне мал өенең каен бүрәнә диварына кагылган озын агач чөйдән салдырып алып, урамга чыкты да малкайны җигеп, ферма ягына кузгалды.

Их, ул күфәйке өстеннән киеп куйган плащының мул капишунын маңгайга күтәрә биреп, кәлүш кидерелгән чүчинкә пималы аякларын чанага сузып, печән кабартылган чана ләшәнкәсенә терәлебрәк «җәһәтрәк, малкай», – дип, дилбегәне бер кагып алып җилдерүләр!

Еракта күңелгә җылы биреп, кәрәздә ялтыраган бал кебек ферма утлары җемелди, сыер савучылар килгәннәрдер инде. Тизрәк маллар алдына курым салып чыгарга, силосын ташырга, бозауларга печән китерергә, шул арада чиләк, сөт флягаларын юучы савымчыларның авыл хәбәрләрен, гайбәтләчтитләрен дә тыңлап өлгерергә кирәк. Чөнки өйгә кайткач, хатыны Сәлимә сорау алачак: «Нинди яңалыклар, ни сөйлиләр, кемне яманлыйлар, кемне мактыйлар, кем кемгә нәрсә әйткән, кем кавышкан, кем аерылышкан? Чөнки ферма – авыл штабы, бөтен яңалыклар иң беренче монда туплана, иң кызыклы эш-мөнәсәбәтләр дә монда кылына. Аннан соң инде бөтен авыл хөкеменә тапшырыла. Шуңа да эш җиңелдән булмаса да, яшәү күңелле.

Әнә, бозау эчергән арада Миңсылу Нуриягә бәйләнеп тә өлгерде. Күптән инде араларыннан «кара мәче» үтте аларның. Сәбәбен барысы да белә, белмәмешкә генә салышалар. Инде кырыгын күптән тутырган Миңсылу белән завферма Әсхәт арасындагы озакка сузылган гыйшык-мыйшык турында белмәгән кеше юктыр. Берничә ел аяк-кул сызлавыннан интегеп, урын-җирдә авырып яткан хатыны Фәимәне Әсхәт карамый түгел, карый. Тик Әсхәт тә кеше ласа! Миңсылу да тол хатын, җитмәсә утар биясе кебек дастуен, уйнаклап тора, үзе уңган: дөньясын да көтә, сыер да асрый. Килмәгән җире юк. Кызу барды аларның мәхәббәте, тик соңгы вакытта Нурия эшли башлаганнан бирле күңелен көнчелек корты кимерә, чөнки Нурия яшьрәк тә, матуррак та иде. Миңсылу кемгә бәйләнергә дә, кемнән үч алырга да белми. Бер көнне доярка Дамирага, икенче көнне пенсиягә чыгарга әзерләнгән Галиягә, өченче көнне чатан Раузага бәйләнә.

Тулы флягаларны сөт ташучы машина килгәнче ферма авызына илтергә кирәк. «Күтәр бер ягыннан, – дип җикерде ул Нуриягә, – нигә асылынып барасың аның колагына, җыбыткы, җыен эшкә ашмаган кешеләрне җыялар да, бөтен авырлык безгә төшә». Фляга шап итеп күтәрмәгә кунгач: «Юньле

булса, ире куып чыгармас иде», – дип мыгырданды. Миңсылуга беркем дә каршы киләлми иде, чөнки фермада аның урыны үзгә – ул завферманың «күзе-колагы», ышанычлы кешесе!

Ул арада сыкы сарган агач ферма ишеге ачылып китте. Тыштан кергән салкын һава белән йөзләгән сыер җылысы кушылып, ап-ак пар болыты хасил итте дә, ул гыйфрит кебек өскә таба ургылды. Пар таралып бетмичә, кем кергәнне чамалап булмый иде әле. Монда да Миңсылуның хуҗабикә тавышы ишетелде: «Кем анда, арт ягыңа кулың җитмимени, ишегеңне яп!» – дип җикерде керүчегә. Җикерде дә телен тешләде, пар таралуга ишек катында силсәвит Фаек белән завферма Әсхәт шәйләнде.

– Ызначит, исәнлектәме, агай-эне, эш барамы, әйе, ыһы?

– Ару әле, бара, уртасында бул, Фаек абзый!

– Какрас, сыерлар астын алабыз.

– Тот көрәк сабын, Фаягөлгә файдаң тияр!

– Ул көрәк сабы тотып өйрәнмәгән...

Китте көлешү, китте төртмә телләшү.

Инде күп еллар авыл советы рәисе булып эшләсә дә, Фаек ферма кызларының телләреннән бераз шүрли иде, бигрәк тә савым вакытында эш хәтәр. Ул гына түгел, терлекчеләр, тизәк түгүчеләр, фуражирлар да бу вакытта дояркалардан ераграк йөрергә, күз уңыннан читтәрәк булырга тырышалар иде. Бер савымчы башына егерме бишләп, аңа «кара» сыерларны да өстәсәң (район алдында «кара» сыерлар белән савым планын үтәү – персидәтелнең йөз аклыгы) утызлап сыер төшә. Һәрберсен аранга кертергә, мөгезләрен эләктереп бәйләргә, тышауларга, таңга кадәр ятып пычранып беткән имчәкләрен юарга, кул белән саварга кирәк. Һәр сыерның үз холкы: берсе мөгезен бирми, берсе аягын бәйләтми, бәйләмәсәң, ботын күтәреп, савып бетердем дигәндә генә чиләккә кереп баса, берсе сөтен төшерми. Тавыш-гауга, сүгенү, кычкырыш, тартыш – болар барысы да ферма тормышы. Ачуны китереп, завфермадан алып, бригадиры, парткомы, персидәтеле, силсәвите, профкомына хәтле: «Удой төшә, эшегез бармый, эш хакыгызны кисәбез», – дип, җанга тияләр. Бозау үлсә, анысы үзе бер фаҗига, өскә чыгарырга да күп сорамыйлар.

– Ызначит, агай-эне, эшегез беткәч, «Кызыл почмак»ка җыелышып алыйк әле, бер кәлимә сүз бар иде, әйе-ыһы, – диде дә силсәвит Фаек завферма Әсхәтне ияртеп чыгып китте.

– Тагын нәрсә булган?

– Премия бүләләр...

– Тот капчыгыңны!

Эш беткәч, халык «Кызыл бүлмә»гә тартылды. Дояркалар өйгә алып кайтырга дип тутырып, куенга тыгылган берәр шешә сөтләрен, Миңсылуга күрсәтмәскә тырышып, кем кая кар эченә батырдылар, грелкага тутырылып, билгә бәйләнгән сөтләр күфәйке астында авырлы хатын корсагы кебек төртеп торса да, моңа әһәмият бирүче юк иде.

Ферма тормышының үз кагыйдәләре, үз гадәтләре бар. Вакыт-вакыт авыр эштән соң, калай мичнең җылысында, такта эскәмиягә тезелешеп утырып, чәй эчеп алу күңелле бер гадәт иде. Гәҗит ябылган озын имән өстәлгә өйдән алып килгән (бүген кемдә нинди байлык) «мендәр»

кәнфит, шикәр, чәй, кыстыбый-пәрәмәч, коймак, бавырсак ише камыр ашы куела. Кырлы стаканга коелган куян каны шикелле куе чәйгә мул итеп сөт салып, акбур белән агартылган стенага эленгән партиянең Үзәк Комитеты әгъзалары рәсемнәренең уяу, үткер карашлары астында чәйләп алу, шул арада авыл яңалыкларын барлап, «чәйнәшеп» алу күңелгә җылылык, ләззәт, рәхәт йомшару бирә. Түрдә – кызыл постау белән ябылган президиум өстәлендә, калын пыяла астында илнең төп законы, сайлаулар турында нигезләмә, иптәшләр судының составы, социалистик ярышның шартнамәсе, савым-үрчем күрсәткечләре һәм башка кәгазьләр урын алган. Иң түрдә бригадалар арасындагы социалистик ярышта җиңгән өчен бирелеп эленергә тиеш вымпелның буш кадагы ыржаеп тора.

Әсхәт сүзне уратып-нитеп тормады:

– Иптәшләр, эш болай тора. Сез беләсез, мин завферма булып, күп еллар эшләдем. Гомер буе дигәндәй. Әйтергә кирәк, тырышып эшләдем.

Ул тамак кырып, фикер җыеп, бераз туктап торган арада Фаек телгә килде. Йомры эче бүртеп, артка, җилкәгә таба тарткан, каешланып каткан кәчтүм якасын ике кулы белән түшенә табарак тартып алды да:

– Әйе, ызначит, дөрес сөйли иптәш Әсхәт, тырышты, чыдады, гаилә хәленә карамыйча тир түкте.

Сүзнең кая таба барганын аңламыйча аптырап калган халык гөрләшә башлады:

– Сузма инде, турысын әйт, Фаек абзый!

– Эш нидә?

– Җәмәгать, эш менә нидә, – дип, сүзне дәвам итте завферма Әсхәт, – җомга көнне калхузның еллык отчёт-сайлау җыелышы алдыннан безнең бригаданың да җыелышы тәгаенләнгән. Җыелышта персидәтел үзе катнашачак, районнан да түрәләр көтелә.

– Эштән китәргә җыенмый микән бу дип уйлаган идем мин сине, Әсхәт туган, хак икән, – дип, сүзгә кушылды терлекче Нәгыйм, вымпелның буш кадагына ымлап.

– Китсә дә, жәл түгел, тырышмады түгел, тырышты, – дип өстәде, фураж урлап тотылганнан соң иптәшләр судында җәза алып, аттан колак каккан һәм су куарга тәгаенләнгән Хәсән.

– Авыр инде, авыр, өйдә чирле хатын, үзе көне-төне фермада, – дип өстәде Миңсылуны җаны-тәне белән күралмаган Галия.

– Дисциплина какшый, – дип ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш бирде яңа эшли башлаган савымчы Нурия, Миңсылу ягына карабрак.

Көтелмәгән хәбәрдән чак ушына килгән Миңсылу сикереп торды да: «Әсхәт абзый кебек белдекле завферманы каян табасыз бүтән, җибәрмибез, җибәрмибез!» – дип кычкырып җибәрде.

Силсәвит Фаекның: «Ызначит, туктагыз әле, агай-эне, туктап торыгыз», – дигән сүзе тоташ гөрләү арасында югалып калды.

– Китсен, китсен, җитте аңа, яшьрәк кешене куярга кирәк, – дип чәрелдәде былтыр акчасын тотып калган бозау караучы Әлфия.

– Калсын, өйрәнгән яу сугышырга яхшы, – дип яклашты Миңсылуның ахирәте Гөлсем.

Фаек белән Әсхәт нидер әйтергә теләсәләр дә, беркем дә аларны тыңламый иде инде.

– Ояты бетте Әсхәтнең, тере хатыны өстеннән уйнаш итә, китсен, – дип кычкырды арттан кемдер.

– Җибәрмибез, эшләсен, әллә кемне тәгаенләгәнче, белгән кеше яхшырак!

Ә Әсхәтнең үз хәле хәл иде. Кичә төн уртасына чаклы Миңсылуның кышкылыкка тәгаенләп туңдырып эретелгән каен суыннан коелган әче балын чамадан тыш чөмерү аркасында бәвел куыгы шартлардай булып тулышкан, кече йомышын үтәү теләге миен бораулый иде.

Түзәр әмәл калмаган иде, Әсхәт Фаекның колагына иелеп, нидер пышылдады да урамга чыгып китте. Бер минутка тынлык урнашты.

Хәлиткеч вазгыять менә хәзер җиткәнен җаны-тәне белән тойды Әхмәтгали: «или-или!» Теге кисәтүне онытмаган иде ул. Әсхәт завферма чакта куркыныч гел янап торачак. Бүген йә Әсхәтне «түңкәрәләр» һәм аты-канаты үзендә кала яки Әсхәт囲 эштә кала да Әхмәтгалинең аты – «тү-тү!» – киләчәктә атын алырга мөмкиннәр, үзен тизәк тазартуга чаклы түбәнәйтү куркынычы яный. Аның күз алдына сарайда фураж сорап мөгрәп торган ябык сыеры, май кунмаган зәңгәр тиреле казлары, булдыксыз дип битәрләгән кыяфәттә сытык чырайлы Сәлимәсе килеп басты. Тәвәккәлләде Әхмәтгали. Тамак кырып алды да торып басты. Халык тынып калды.

«Җәмәгать, – диде ул, тавышына кискенлек өстәп, – җитәр Әсхәткә халыктан көләргә, безнең фермада хәлнең хөрт икәнен барыбыз да белә. Сыерлар күтәрәмгә калып бара, сөт аз, су кушмасаң, бөтенләй юк чутында, нәсел үгезе ябык, хәлсез, сыерларны каплый алмый, үлгән бозауларны тирес астына күмү мисаллары да бар, тизәк сөйри торган транспортёрлар ватык, поилкалар эшләми. Нурия сеңел әйтмешли, фермада әхлак түбән, бетерде ферманы Әсхәт, бетерде. Соң булганчы котылыйк бу кешедән!»

Авыр тынлык урынлашты. Ниһаять, Фаек сүз алды:

– Ызначит, агай-эне, эшнең төбенә төшмәдегез бит әле сез, әйе-ыһы. Эш шунда ки: безнең персидәтелне районга алалар, аның урынына калхуз персидәтеле итеп, райкомнан иптәш Әсхәтнең кандидатурасын тәкъдим итәләр. Шуны сезгә җиткерергә, фикерегезне белергә теләгән идек.

...Тирән тынлыкны ярып, шыгырдап, ишек ачылды, аннан бик тәкәббер кыяфәттә Әсхәт кереп, президиум артына утырды. Әхмәтгалине яшен суккан кебек булды, күз аллары караңгыланып китте, тамагына төер тыгылды. Ул күзләрен йомды, бер секундка муенында аты-канатының кайнар тынын, үпкәле карашын тойган кебек булды. Ул тагын тамагын кырып алды, кичекмәстән ситуацияне төзәтергә кирәк иде:

– Авырлыклар күп булса да, бик күп көч түгә безнең Әсхәт туган ферма өчен. Ә безгә күрсәткән ярдәмен сөйләп-аңлатып булмый. Азмы-күпме кимчелекләр бар икән, бетәр алар, бетәр, нишләсен, бер башы бит, бер башы! Ә болай, зур эшкә лаек, бик лаек Әсхәт туган, райком дөрес уйлаган, аның кандидатурасын ике куллап яклыйм!

Кемнәрдер колактан-колакка сөйләшеп, кемнәрдер көлешә-көлешә таралыша башладылар. Түрәләрнең кошёвкага утырып кузгалып китүләрен көтебрәк торган савымчылар Миңсылуга күрсәтмәскә тырышыбрак, кар

астыннан шешәләрен суырып алып, куеннарына тыктылар. Әхмәтгали генә утар артына карга күмелгән бер капчык фуражны бүгенгә чана төбенә печән астына алмаска булды.

Дөнья хәлен белеп булмый: дус бар, дошман бар!

## «Уау-уау» Шакир

Ир күрмәгән хатын түгел Мәдинә, күргән, бик күргән, дияргә була. Тик шул затлар аркасында нужасын да шактый татырга туры килде аңа. Җитмәсә менә бу звеновод Шакир итәккә эләккән тигәнәк кебек теңкәгә тиеп бетте. Уңаймы, уңай түгелме, төрле сәбәпләр белән очрашып, сүз катарга форсат эзли. «Сихерләдең син мине, йокыдан яздым, ач ишегеңне, беркем дә белмәс», – дип, аулак урында сүз кушып та, ишеген шакып та карады. Мәдинә: «Бәйләнмә, Шакир абый, күңелемдә дә, уемда да юксың, кеше сизәр, галәмгә сүз чыгар, хатыныңа әйтәм», – дип яхшы итеп тә, куркытып та әйтеп карады, тик аңламады ир.

Үскәндә, яшь кызларның һәркайсы кебек хыялларга төренеп үсте ул. Укып чыгып, кеше булырга, табиб яки укытучы хезмәтен сайларга ниятләде, акыллы, тәртипле, уңган егет белән тормыш кору турында хыялланды. Аның тормышы башкаларныкы кебек булмаячак! Ул бәхетле булачак!

Мәңге исерек атасының әнкәсен кыерсытканын күреп үсте Мәдинә. Эчмәгәндә, аз сүзле, хәтта бераз тартынучан, күзгә кереп бармаучан, хатынына да, кызына да яхшы мөнәсәбәттә булган Хатмулла авызына шайтан суы керүгә алмаштыргандай үзгәрә дә куя. Еш кына бер төркем механизатор дуслары белән эштән кайтышлый тракторларын МТМда калдыралар да тыкрыктан гына үтеп, Хатмуллалар өенә җыелышалар. Дүрт-биш ирнең өс киемен салганнан соң аңкыган тир исенә өйрәнелгән мазут исе белән бергә аракы сасысы да килеп кушыла.

«Әнкәсе, бер-бер кабымлык куй, ачыктырды, – дип, әткәсе иптәшләрен өстәл артына чакыра: – Узыгыз, узыгыз, түгәрәк өйнең түре юк!»

«Аштан олы булып булмас», – дип, кыенсынып кына, иптәшләре өстәл тирәли утырыша.

Бүген тышта яңгыр пыскаклый, чәчү тукталган иде.

Читтәге сәкене каплап торган чыбылдык ярыгыннан Мәдинә аларны күзәтә. Әнкәсе өстәлгә олы табак белән ярып пешерелгән, булары күтәрелеп торган бәрәңге, тирән тустак белән кызыл катык, дистәләгән пешкән йомырка куя.

– Ипи кис, әнкәсе!

– Алдыңда, үзең киссәң дә була, – ди кергәннәренә хуҗабикәдән гафу үтенгән кебегрәк итеп, «Беларусь»та симәнә ташучы Мәдияр.

– Ипи кискәндә чыккан көч кире керми, – ди әткәсе аңа. – Икмәк игү – ирләр эше, ипи кисү хатыннарныкы, – дип өсти ул, үзенең хуҗа икәнлегенә басым ясап.

Акча салышып алынган аракының беренче ярты стаканы голт-голт итеп йотылып тамак буйлап төшеп китә. Итагать белән генә агач кашыклар катыкка тыгыла.

– Заманасына күрә – өе, өенә күрә – көе, җитешегез, – ди әнкәсе.

– Тәнзилә түтинең кызыл катыгына җиткән катык юк, – дип, сүзгә кушыла «ДТ-54»тә йөргән Нәҗип. – Минем хатынга да өйрәт әле, җиңги, шуның серен, – дип өсти ул, бәрәңгегә үрелеп.

– И, сере бармыни инде аның, кызыл чөгендер кушып, озак итеп кайнатасың, – ди Тәнзилә.

– Кулдан ул, кулдан, – дип мактап җибәрә әнкәсен әткәсе.

– Җитешегез, җитеш, – ди, мактау кармагына эләккән әнкәсе, – капкалап утырыгыз!

Мәдинә өчен бу минутлар иң татуы, иң матуры, иң тынычы. Тик тиздән хәлнең кискенләшәсен белә инде ул, эчү озынга китсә, әткәсенең холкы кыскара бара.

Икенче ярты стакан телләрне бөтенләй ачып җибәрә.

– Чәчү башланганчы кайтаралмады яңа запчастьләрне помпотех, – дип башлады сүзне Хатмулланың тракторына тагылган чәчкечтә йөргән кулдашы Рәшит.

– Әйтмә дә, шлангы өзелеп чыкты минем «ДТ»ның, ярый әле үземнең запас бар иде, утырыр идең эшсез, – диде йомырканы самавыр утырган поднос кырыена бәреп ватып Хөснулла. – Өченче бригада Зиннурның самосвалының радиаторы аккан, – дип өстәде ул.

– Радиаторга чүбек тыгып йөреп булмый, – дип, сүзне дәвам итте Мәдияр, – тәртип юк калхузда.

– Симәнә агулаган хатыннарның респираторлары брак булып чыккан, йөткерәләр, төчкерәләр, Самат хатынының авыры төшкән шул агудан.

– Тәртип юк, хуҗа йомшак!

– Әмрикәне әйтәм, үз башына котыра, чистый аздылар бит, әй!

– Теге вакытта юкка Кубага куймадылар ракеталарны.

– Әле дә соң түгел, безнекеләр йоклап ятмас!

Эш Америкага ук барып җиткәч, шешәнең төбе ялтыраган дигән сүз, эш җитди төс ала иде.

– Чыгар, Тәнзилә, теге тыгып куйганыңны, – дип, каты гына дәште Хатмулла хатынына.

– Каян алыйм, теге көнне төпләп куйдың бит үзең.

– Чыгар, димен!

– Кызма-кызма, Хатмулла абзый, бүгенгә җитәр, иртәгә ял түгел, яңгыр туктый, диделәр, – дип тынычландырырга тырышты Рәшит, урыныннан кузгалып.

– Рәшит, кузгалма, «утыр урыннан – сәке түреннән!» Ишеттеңме, Тәнзилә, чыгар!

Чара юк иде, әнкәсе мич артына яшерелгән яртыга калган шешәне алып, өстәлгә куйды да шәлен алып, мыштым гына ишек ягына юнәлде, аңа Мәдинә иярде.

Гадәттәгечә, алар күрше Галимә түтиләргә керделәр. Ихата уртасында күлмәгенең бер як читен үзе теккән буйлы-буйлы ыштанының бөрмәсенә кыстыра биребрәк, җимерек киртә-читәннәренә, кыйшайган иске алачык ишегенә, җиргә сеңгән күтәрмә идәненә карап зарланып каршы алды Галимә: «Бөтен җиркәйләрем дә ир сорый шул, ир сорый, чукынчык, теге

карт иртәрәк тайды «ялга», бөтен дөнья мәшәкатен миңа салды, җаны җәннәттә булгыры! Биш ел була яренгә, ялгыз картаям менә. Узыгыз. Тагын котырамы? Кит аннан, нигә түзеп яшисең шуның белән, мин алъяпкычымны сузып, өйдән-өйгә хәер сорашып йөрсәм дә, яшәмәс идем мондый ир белән», – дип такмаклады Хатмулланы җаны-тәне белән яратмаган күрше карчык. Чөнки Хатмулла кызып алган чагында читән аша тозлы-борычлы сүзләр аңа да эләккәли иде.

– И Галимә түти, кая барыйм, кемгә сыйыйм, мине кем көтеп тора? Мәдинәмне үстерәсем, кеше итәсем бар. Хатмулла да гел эчми, айный да, кызыма әткәй, миңа ир була.

– Әнкәңә охшап, мәмәй булма, кызым, – дип дәвам итә күрше әби, Мәдинәгә карап. – Унга бар, уңганчы бар, дип, дөрес әйткәннәр. Гомер бер генә!

– Алай димә, күрше! Беренче төшкән җирендә таш булсын, ирдән-иргә йөрү бәхет түгел.

Бәхетле булырга тырышып карады Мәдинә. Мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә барып, педагогия институтына яхшы гына билгеләргә имтихан тапшырды, канатланып йөрде, үтәргә тиеш иде, тик соңгы көндә укырга керүчеләр исемлегендә ни өчендер ул юк иде. Авылына, тагын шул ук шартларга кире кайтып төште. Озакламый Мәдинә күрше авыл егете, клуб мөдире Рифкә гашыйк булды. Армиядән яңа гына кайткан, ыспай егет иде ул, җитмәсә, шәп гармунчы да үзе. Өйдәге мәхшәрдән котылу да кирәк иде аңа. Тиздән яңа гаилә туды. Рифнең бер өздереп уйнап җибәрүе була, җан күкләргә чаклы җилкенә, йөрәк ярсый, яшь күңелләрдә моңарчы очкын булып көйрәп яткан, хәзергәчә аңлаешсыз хис-теләкләр давылы кузгала, әллә нинди яңа дөньяга тарта башлый. Риф тә үлеп яратты аны. Озын кара бөдрә чәчләренә күмелеп, дөньясын онытып иркәләде ул аны. Чибәр иде Мәдинә, бик чибәр иде. Өзелеп торган нечкә билле, зифа буйлы, зур кара күзле, шома яңаклы, энҗе тешле, бер сүз белән әйткәндә, коеп куйган әртис инде. Ел ярым яңа гаилә көймәсе бәхет дәрьясында йөзде. Мәдинәнең чут эшенә башы эшли, алгебрадан гел бишлегә укыды, кибеттә декретка киткән хатын урынына эш тәкъдим иткәч, райпога барып, бераз өйрәнчеклектә йөреп алды да эшли башлады. Тик көзгә мәктәпкә яңа укытучы кыз Зиләрә килгәч, гаилә кояшын болыт каплады. Матур җырлый иде Зиләрә, ул җырлый, Риф уйный. Риф эшеннән соңга калып, кайсы вакыт таң алдыннан гына кайта башлады, сәбәбен районда үтәчәк үзешчән коллективларның конкурсына әзерләнү, репетицияләр белән аңлатып маташты. Алты айлык авырлы хатын үзен моңа ышандырырга тырышса да, гайбәт авыл өстендә йөри иде инде.

Озак көтте ул төнне Мәдинә ирен. Төнге өчтә иңенә шәлен салып, аска тартып авырткан эчен ике кулы белән күтәрә биребрәк, клуб ягына юнәлде. Таңнан кояш батканчыга чаклы авыр эштән тәмам эт булып арыган авыл тирән йокыга талган. Тагын бер-ике сәгатьтән таң сызыла башлаячак, тагын, нигездә, кул эшенә корылган авыл тормышы үзенең гадәти мәшәкатьләренә уралачак. Авылда һәр өйдә дип әйтерлек бер үк яшәү рәвеше. Хуҗабикәгә йокыдан уяну белән алдан баш ясап, кичтән

тугылап куйган күәс чиләгендәге камырны ишләп, ипи басып куярга, мичкә ут төртергә кирәк. Аннары сыер саварга, кош-кортка җим бирергә, көтү килгәнче озын саплы зелпе себерке белән ихата, өйалдын себереп алырга, шул арада күршеләр белән авыл гайбәтләрен чәйнәшеп алырга, бозауны муенчаклап, бәрәңге бакчасы артындагы үләнлеккә илтеп, җиргә кагылган агач чөйгә бәйләргә кирәк. Чиратта ипине мичкә тыккач, сөт аертырга, аннары инде табада пешереп алынган көлчә, самавыр эченә тезеп пешергән күкәй белән каймаклап, рәхәтләнеп чәй эчәргә дә була. Өйгә мичтән яңа чыккан тәмле ипи исе тарала. Эшкә китәр алдыннан балаларны уятып, һәрберсенә бүген эшләнергә тиеш эшләрне бүлеп бирергә: бәрәңге бакчасын утарга, агач идәнне кәсир пычак белән кырып юарга, кош-кортка, җимгә кушар өчен кырдан ат кузгалагы сыдырып алып кайтырга, мунчага су ташып куярга һәм башкалар, һәм башкалар… Менә ул авыл тормышы!

Ә хәзергә авыл рәхәт йокыда, хәтта этләр дә бу ләззәтле, кадерле йокыдан хуҗаларын җәлләп, уятмаска тырышкан шикелле сирәк-мирәк акрын тавыш белән генә аралашып алалар иде.

Мәдинәнең генә күңелендә давыл: кайда ул, нигә аның янында түгел, нәрсә булды аларның мәхәббәтенә? Авыл өстендә йөргән чыш-пыш сүзләр дөрес булса? Юк, бу мөмкин түгел! Ул клубка якынлашты. Ут юк иде, бернинди тавыш та, музыка да ишетелми. Ишеккә якын килде, тыштан бикле иде, бинаны урап, арткы ишеккә китте, эчтә тыелып кына көлгән тавыш ишетелде.

– Ялкытты үзенең көнләшүе белән, туйдым, – диде Риф тавышы.

– Ялыккач, нигә аның белән яшисең? – диде хатын-кыз тавышы. Бу Зиләрә иде.

– Аерыр идем, бала булачак.

– Булса соң, яратмагач…

– Әйтүе җиңел, кешеләр ни дияр, парткомга барып җитәчәк, эштән куарлар.

– Чыгып китик бу авылдан, миңа да ошамый монда, мәктәп директорының хатыны кырын карый, иреннән көнләшә. Күрше районда минем абый райкомда инструктор булып эшли, икебезгә дә эш табылыр.

Мәдинә тавыш-тынсыз гына өй ягына юнәлде. Ир бирмәк – җан бирмәк, диләр. Ә таңга таба ашыгыч ярдәм машинасы аны дәваханәгә алып китте. Шул көнне Мәдинә баласын югалтты һәм шуннан Риф йортына кайтмады.

Ата-ана йортында да рәт булмады аңа. Әнкәсе тиздән йөрәк авыруыннан дөнья куйды, эчкән эткәсе белән бер йортта яшәү мөмкин түгел иде. Хатыны үлеп, тол калган Әмир сораткач, риза булды, тик тагын уңмады. Сугышты Әмир, каты бәрелде, эчеп кайтып, пычрак сүзләр белән рәнҗетте. Мәдинә тагын аерылып кайтты.

Ә яшьлегендә хыялланган экият егете күренмәде, юк иде ул.

Бер көнне күрше Галимә әбигә авыр заманнарда Урта Азия якларына бәхет эзләп чыгып киткән Наһар карчык кайтты. Карчык дип, карчык ук түгел иде әле ул. Көяз генә киенгән: чәчәкле-чуклы яулык, ялтыр-йолтыр күлмәге өстеннән бәрхет камзул, ефәк озын ыштаннан, аягында чигүле читек-кәвеш, кулын көмеш йөзек-беләзек бизәп тора, симез, шәмгә охшаган

бармаклары гәрәбә дисбе тарта, йөзе-кыяфәтеннән илле белән алтмыш арасында гына икәнлеген чамалап була иде.

Гадәттәгечә, исереп кайткан әткәсенең битәрләвен ишетмәс өчен Мәдинә Галимә әбисенә керде.

«Менә шушы була инде күрше кызы, – дип, сүз башлады Галимә, – таныш бул, Наһар түтиең, бергә уйнап үстек, бик хөрмәтле кеше ул авылда».

«Хәзер яшәгән җирдә дә», – дип өстәде Наһар, алтын тешләре күренерлек итеп киң елмаеп.

Китте сорашу, Мәдинәнең хәленә керү, ир-атны сүгү.

– Мондый чибәрлегең белән нигә әрәм булып ятасың бу бүрәнә тишегендә? Яхшы эшкә урнашырга кирәк сиңа, затлы киемнәр кирәк. Шәмнең яме – шәмдәл белән, диләр. Чутка да башың эшли, диләр синең, бездә яхшы сатучылар алтын бәһасе йөри. Мин яшәгән җирдә ханбикә булырлык бит син!

Бер атна үгетләделәр Мәдинәне, ниһаять, ул көнде, сумкага әйберләрен тутырды да, Наһарга ияреп, юлга кузгалды. Киткәндә, Наһар Галимә карчыкка көмеш беләзеген кидерде.

Яңа җирләр матур иде. Наһарның җыйнак кына өе бакча уртасында. Төрле-төрле җимеш агачлары астында аллы-гөлле бизәкле палас җәелгән сәке өстендә нигъмәтләр белән тулган дастархан әзерләнгән. Олы гына Надирә исемле хатын йөгерә-йөгерә табын әзерли. Үзе ярарга тырышып, нидер сөйли, яңалыклар җиткерә. Ул бу өйдә хезмәтче исәбендә яшәгән хатын иде.

Наһар Мәдинәгә ялт-йолт итеп торган ефәк күлмәк, озын ыштан, кәвеш бирде. Мәдинә каршы килеп караса да, монда гадәтләрнең шундый икәнен аңлатты. Эшкә урнашу өчен паспорт сораячакларын сәбәп итеп, Мәдинәнең паспортын алды. Өч көннән Наһар Надирәне ниндидер гаебе өчен эшеннән куып чыгарды. Ялынып-ялварып гафу сораса да, өйдә чирле улы ятканын, аны тәрбияләү өчен акча кирәклеген елый-елый сөйләсә дә, Наһар үз сүзеннән кайтмады. «Кылган явыз гамәлләрең өчен Ходай суксын!» – дип каргады аны Надирә. Киткәндә, Мәдинә сиздерми генә Надирәнең учына биш сум акча тыкты. Шулай итеп, өй эшләре бөтенләе белән Мәдинә өстенә калды. Вакыт үтә торды, өйгә еш кына җирле хатыннар килде, кызыксынып, Мәдинәне күзәттеләр, ул чәй әзерләде, соңыннан алар Мәдинәсез генә Наһар белән ни хактадыр кызып-кызып бәхәсләштеләр. «Эш кайчанрак табылыр икән?» – дип сорашса да, Наһар ашыкмаска, түземле булырга, табышлы булырдай эш килеп чыгу ягын карарга кирәклеген тәкрарлады. Бу яклар җылы, матур булса да, йөрәгенә ятмады яшь хатынның. Туган якның кырларын-болыннарын, урманнарын, чишмәләрен, авылдашларын сагынды ул.

Бер көнне Наһарларга еш йөри торган бер хатын урта яшьләрдәге бер ирне ияртеп килде. «Таныш бул, кызым, бу Гадәр әбиеңнең улы була, бик акыллы егет», – дип таныштырды Наһар Мәдинәне. «Без дога кылганчы, өйдән нигъмәтләрне алып чыгыгыз, балалар, улым, ярдәм ит кызыма», – дип, хатыннар дога кылырга утырыштылар. Егет нәрсәдер сөйләде, ул Мәдинәне ачыктан-ачык, үтәдән-үтә күзәтә, бәяли иде. Кайбер сүзләрен аңласа да, Мәдинә аны аңламаганга сабышты, күңеле белән ятышсыз, шом,

хәвеф-хәтәр барлыгын тоя иде ул. Кич Наһар Мәдинәне янына утыртып, сүз башлады: «Мәдинә, кызым, син миңа кызым кебек якын, бик яраттым үзеңне. Шуңа да сине бик бәхетле итәсем килә. Дөньяның әчесен-төчесен күргәнсең, бу чибәрлегең белән нигә сиңа эшкә кереп, үз-үзеңне җәфалап, өч тиенлек акчага яшәргә? Бер тәкъдимем бар сиңа: бик бай, бик тәртипле, бик хөрмәтле гаилә асыл, акыллы улларына кәләш эзли. Сине ул егетнең анасы да, егет үзе дә бик ошатты. Бүген күрдең аларны. Егетнең беренче генә никахы түгел-түгелен, тик аерылышуда ул гаепле түгел, хатыны юньсез булган, аннары һәркем үз буена карап, тун тегә дигәндәй, синең дә беренче никах түгел».

Көтелмәгән тәкъдимнән Мәдинә аптырап китте.

– Мин кияүгә чыгар өчен килмәдем бу якларга, Наһар түти.

– Хатын-кызның бурычы гаилә кору, бала үстерү, кызым.

– Яратмаган кешегә кияүгә чыгып буламы соң? Без бит борынгы заманда яшәмибез!

– Яратып чыгып карагансың бит инде, бер түгел, ике тапкыр.

Бу инде түбәнсетү иде.

Икенче көнне алар базарга чыкты. Ит базары таңнан эшләсә дә, чират зур иде. Чиратта торганда, кемдер Мәдинәнең җиңеннән тартты. Борылып караса – Надирә. Ул Наһарга күренмәскә тырышып, Мәдинәне читкәрәк, ышыккарак алып китте.

– Кач, кит бу карчыктан, сата ул сине, аның һөнәре шул, читтән кызлар алып килә дә калым түли алмаган яки яман аты чыккан ирләргә кияүгә озата. Синең хакта озаграк сатулашалар, чөнки купләрнең синдә өмете бар, син кыйммәтрәк торасың.

Мәдинәнең башы әйләнеп китте. Күңелендә туган шик-шөһбәнең урынлы булуын аңлады ул.

– Хәзерге замандамы? Мин милициягә барам.

– Милициядә барысы да аның кешеләре.

– Паспортым анда.

– Паспортың комодның аскы тартмасында, ачкычы сандык өстенә өелеп куелган юрганнар астында. Мине сатма, яман кеше ул, син яхшы күңелле бала, хуш бул! – дип, Надирә юкка да чыкты.

Бу хәлдән көн буе миңгерәп йөрде Мәдинә. Егерменче гасырда, совет чорында мондый хәлләр булыр дип башына да китермәгән иде ул. Тизрәк китәргә, качарга кирәк иде моннан. Тәвәккәлләп, юлга чыкты, ярый бераз мая акчасын эчке күлмәгенә тегеп куйган иде. Ун көн кайтты үз иленә, күп уйланды, күп кичерде: беркайчан да кешегә, бигрәк тә ир-атка ышанмаска кирәк икәнен миенә салып куйды ул. Ак атка атланып алып китүче әкият егете юк икәнен аңлады инде Мәдинә.

Ул кайтуга әткәсе авыр чиргә тарыган, ябыккан, картайган иде. «Терсәк якын да, тешләп булмый, исән булса, әнкәңнең кадерен белер идем», – дип елый-елый гафу сорады. Колхоз рәисе Мәдинәне завсклад итеп эшкә чакырды. Әткәсен күмгәннән соң, япа-ялгыз калды ул.

Ишеген кагучылар булмады түгел, тик югалтулар, хыянәтләр белән җәрәхәтләнеп беткән күңеле таш кебек каткан иде аның. Ир-атка шикле караш күңел түренә кереп оялаган кара кошның хәвефле күләгәсе шикелле

яктылыкны каплап торды. Ирдән аерылган хатыннарның, бигрәк тә чибәр һәм яшь булсалар, авылдагы урыннары ике төрле: ирле хатыннар аларга көндәш, азгын ир-атлар – сөяркә итеп карый. Мәдинә, бер гаебе булмаса да, шундыйрак итеп кабул ителә иде.

Шуңа да ул усаллашты, ир-атны дошман итеп күрде. Тик көннәрнең берсендә Мәдинәнең күңелен бетмәс-төкәнмәс яңгырдан соң күкне болытлардан аралап төшкән алтын кояш нурлары шикелле гаҗәп хис биләп алды. Колхозга яшь агроном Булат килде. Ир-ат ягына әйләнеп тә карамам дигән усал Мәдинә Булатны күрсә, балавыз кебек эри дә төшә, күзләре йолдыз кебек нур чәчә, ирен читләреннән серле елмаю бөркелә, күңеле күкләргә аша иде. Булат та Мәдинәне бер күрүдә ошатты. Ил өстендә йөргән имеш-мимешләргә дә ышанмады. Күңел сизгерлеге белән Мәдинәнең намуслы, эчкерсез кеше икәнен сиземләде егет. Алар арасына икесе генә тоя торган тылсымлы җеп сузылды.

Ә Шакир һаман аңламады, һаман Мәдинә дип авыз суын корытты. Булатның: «Үзем сөйләшимме ирләрчә?» –дигәненә Мәдинә: «Кирәкми, үзем!» – дип җавап бирде. Һәм Шакирны акылга утыртырга план корды.

Җәй канат җәйде, бодай башак җибәрә, басу өстендә талгын томан булып, арыш серкә очырган көннәр җитте. Көнбагышның «тиздән ачылам» дигәндәй көләчләнергә әзер торган уч төбе кебек йөзе кояш артыннан йөгереп китәрдәй булып талпына. Кукуруз чәкәннәре дә тулыша бара, бу матур музыкага аккорд биргән шикелле, биләү кебек кочкан яфрагын чырт итеп ярып, алтын түбә чәчен нурда чайкый.

Ә чөгендер басуын, өченче ел корылык булу аркасында, колхоз малларына Белоруссиядән ташыган саламга ияреп кайткан бик әрсез чүп үләне – кара солы каплый башлаган иде. Шул сәбәптән колхоз идарәсенең гадәттән тыш утырышында кичекмәстән чөгендер басуына бөтен мир белән десант төшерергә дигән карар кабул ителде. Хәтта колхозның партком секретаре мәктәпнең рәсем укытучысына «Бөтен көчне – чөгендергә!» дигән лозунг язып, басу капкасына элеп куярга боерык бирде.

– Чөгендер – стратегик план, аны коткару – колхоз намусы, ә җанында колхоз нумусы булган һәр кеше: укучылар, укытучылар, почта, клуб, китапханә эшчеләре, сатучылар, җыештыручылар, шул исәптән колхозчылар да (сыер савучылар, фельдшер Әкълимә, колхоз бухгалтериясе, силсәвит эшчеләре генә эштән азат ителә) – һәммәгез дә–басуга! Төшкә итле аш кырда әзерләнәчәк.

Бу белдерүне колхоз радиосыннан кичтән һәм иртә берничә тапкыр кабатладылар. Ике көн элек тоягына зыян килеп, бүген таңнан суелган сыер итен алып килеп, склад үлчәвенең өстәл зурлыгы тактасына бушатырга Шакир үзе ярдәм итте.

«Зур казанны пешекчеләр алып бара, итне минем ат арбасына салабыз, – диде ул Мәдинәгә, башына кигән салам эшләпәсен кәттә генә маңгаена төшереп, – син дә утырырсың, чөгендер басуы ерак кына».

– Җитте, Шакир абый, уен түгел бу, Әкълимә апага әйтәм, тукта, бәйләнмә миңа.

– Ул бүген эштә, бер генә булса да очрашыйк инде, аулакта сөйләшик, аңлашыйк, бер генә…

– Ялкыттың син мине. Ярый, сөйләшик, тик бүтән бәйләнмисең.

– Кайда?

– Утау вакытында, чөгендер басуы кырындагы кукуруз арасында.

– Түгәрәк күл буендамы, кайчан?

– Шартлы сигнал бирерсең.

– Ничек итеп?

– Вакыт-вакыт кукуруз арасыннан эт булып өреп алырсың, мин кешегә сиздерми генә үз җаем белән килермен.

– Ярый, көтәм, сый алып барам, табын әзерлим.

Басу тулы халык, эш кыза бара.

«Овсюгны тамыры белән йолыкмасаң, тагын да көчлерәк котырып үсәчәк, китмән кулланмаска, кул белән йолкырга», – дигән фәрман җиткерделәр. Халык туңкаеп, тезләнеп, үрмәләп, чүп үләнен йолку эшенәябышты. Кояш күтәрелә барган саен, маңгайдан аккан тир күзгә, биткә, муенга агып төшә, изү аша күкрәккә чаклы үтә, күлмәккә кунган тузан белән кушылып, тәнне кытыклый, чеметә, әчеттерә иде. Җитмәсә, кукуруз басуы артындагы сыер фермасыннан килгән ис тынга каплана.

Рәт-рәт булып тезелешеп утаган халык сусынын басу өчен шешә белән алган суларын уртлап куялар да тагын эшкә ябышалар. Төш вакытында зур казанда пешкән ашны көлешә-шаярыша, төртмә телләнеп ашап, бераз ял иткәч, тагын эш башладылар. Кояш түзеп булалмас дәрәҗәдә кыздыра иде. Шактый ялкытты һәм арытты бу утау. Шул вакыт ерак түгел кукуруз арасыннан: «Уау-уау-уау», – дип, эт өреп куйды.

«Их, су коенып чыгарга иде», – диде Мәдинәнең уң ягыннан утаган Шакир хатыны фельдшер Әкълимә.

«Сезне парткум килмәсә дә ярый, дигән иде бит, Әкълимә апа», – диде Мәдинә. «Иртән карт-корыга уколларны кадап, эшне бетердем дә килергә булдым». «Азгын ирен көнләшә ул, еракка җибәрми, тегесе барыбер кеше бакчасына төшә, – дип пышылдап алды авыл хәбәрләрен иң беренче белүче Фәүзия Мәдинәгә. – Сиңа сыланмыймы әле? Сак бул, Әкълимә җаныңны алыр».

«Бераз күләгәдә ятып ял итеп алсаң да, шәп булыр иде», – диде сул яктан утаган Нәҗибә. Кукуруз арасыннан нәзакәтле генә «уау… уай» дигән тавыш тагын кабатланды. Әкълимәдән ары рәт алып барган Рәсимә сүзгә кушылды:

– Көчек бугай!

Арыткан иде. Кәеф юк. Ул арада эт тавышы тагын ишетелде:

– Уау-уау-уау!

Иренә усал булса да, җанварларны җаны-тәне белән яраткан, жәлләгән, ихатасында биш песи, эт асраган Әкълимә борчылып, кукуруз басуына борылды:

– Кемнең эте икән?

– Адашкан бугай, бахыр, – диде Рәсимә.

Кукуруз басуыннан тагын «уау, уау, уау, уау» дигән таләпчән өрү ишетелде.

– Ачыккан эт тавышы килә, – диде Нәҗибә.

– Кансыз хуҗалар була, –дип, ут өстәде Мәдинә.

– Карый алмагач, нигә эт асрыйлардыр инде, – дип, сүзне дәвам итте Нәҗибә.

Беразга тынлык урнашты. Көн кичкә авышып килә икән инде.

«Агроном Булат утаган җирне принимать итәргә килергә тиеш иде, күренми әле. Көтү кайтыр вакыт та җитә», – диештеләр хатыннар. Ул арада кукуруз арасыннан тагын – бу юлы инде ялваруга охшаган: «Уау… уау… уау…» дигән үзәк өзгеч тавыш ишетелде.

– Койрыгы капкынга эләккәнгә охшаган, тавышы түгәрәк күл буеннан килә кебек бахырның, күлгә аучылар кондызга дип, ау салмадылар микән, тавышы сезнең эткә дә охшап тора, Әкълимә апа, – диде Мәдинә.

Бу сүзләр Әкълимәнең йөрәгенә ук булып кадалды, аңа эт тавышы чыннан да аларныкы кебек тоелды. «Әйттем Шакиргә: бәйлә этеңне яхшылап, уңайлы муенса кидер, чылбырын рәтлә, дип. Пешмәгән, – дип кызды Әкълимә. – Кайда бүген үзе? Көн буе күренмәде. Мине утауда дип белми инде. Доярка Гөлшатка күзен майландыра иде, дөрес икән, яталардыр су буенда. Үтерәм тотсам! Барып карамый булмый... Эт булса да, җан иясе, кайбер кешеләрдән тугрырак әле алар». Әкълимә кукуруз арасына кереп китте. Бераз ял итеп алу теләге белән берничә хатын аңа иярде.

Ул арада кукуруз арасында давыл купты: сары башлы чәкәннәр арасыннан чөгендер басуына иң беренче Шакирның салам эшләпәсе, аннары пинҗәге, аның артыннан чиләк, кабымлыклар, талчыбыктан үрелгән кәрзиндә тәлинкә-кашыклар, соңыннан «Портвейн» дип язылган шешә һәм иң соңыннан чәче-башы тузган, битләре тырналган, эчке майкасы ертылган Шакир килеп төште. Ул арада матай тавышы ишетелде: «Утыр тизрәк, тайдык моннан», – диде Мәдинәгә эшнең нидә икәнен аңлап алган Булат.

Мәдинә ялт итеп матайның арткы урындыгына кунды. Ак ат булмаса да, шәпле «Восход» матаенда әкият егете Булат Мәдинәне бәхет иленә алып чапты.

Ә шул көннән башлап, Шакирның кушаматы «Уау-уау Шакир» булып, аны очратканда, авыл халкы көлемсерәп, үзара «уау-уау» дигән позывной-сигнал белән аралашып алалар иде.



*Хабырыыс Ондороос – алар да, безнең ише, исем-атын мир кәгазьләрендә урысчалаштырып язарга мәҗбүр: Гаврил Андросов! – хәзерге саха әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән, мөгаен. Бүген аның иҗаты, Саха киңлекләрен тарсынып, федерацияне тулаем яулау белән мәшгуль.*

*Кызык кеше ул. Сәерлеге дә җитәрлек. Шагыйрь инде.*

*Үз халкын, мәдәниятен, ана телен, милли гореф-гадәтләрен ярата. Аларны санлый, саклый. Алар өчен борчыла, яна. Шагыйрь инде.*

*Уртак төрки тарихыбыз турындагы белемнәре дә хәттин ашкан. Берсендә җитдидән-җитди рәвештә:*

*– Атилла – һәрвакыт чороннан эчкән! – дип таң калдырды.*

*Чорон – өч аяклы саха чынаягы.*

*Кунакта чагым туры килгәнгә, мин аңа берсүзсез ышандым, билгеле...*

*Саха җире киң – саха күңеле кебек.*

*Хабырыыс шуның Татта олысыннан. Милли әдәбиятларына нигез салган Алексей Кулаковскийларны, Платон Ойунскийларны, Алампаларны биргән данлыклы төбәк бу. Элгәреләренең эшен дәвам итәр өчен карендәш – үзе дә аңышып бетмичә! – 1985 елның 6 маенда хәлиткеч гамәл кылган. Һәм, һичшиксез, яхшы иткән.*

*Мин аның шигырьләрен татарча менә болай күрәм.*

**Тәрҗемәче**

Гаврил
Андросов

# КЫРЫЫМПА МОҢНАРЫНА ТОТАШ КҮМЕЛҮЕБЕЗ...

## Сәргаскәр рухы

*(реинкарнация)*

Алдымда –
Караңгы томандай, куп-куе,
Офыккача җиткән дошманнар чирүе.
Артымда – гаскәрем.
Хисапсыз баш куеп,
Бүгенге орышның тарихка керүе.

Уң канат –
Данлыклы абыйлар, агалар,
Күпме яу кичелгән бергә бу киңлектә!
Сул канат – дусларым, ишләрем...

Һәм алар
Һәммәсе дә миннән
Сыңар сүз,
Ым көтә.

Өстемдә –
Кояшның мәңгелек балкышы!
Астымда –
Туган җир.
Коткыга сабышып,
Чит кавем керешер чигәргә...

Җиңәргә!
Җиңәргә!
Җиңәргә!

Чигәдән тир сыман –
Шуыша бу вакыт...
Сабырлык кереше, бармактан ычкынып,
Ук сыман атылыр – хәтерне канатып! –
Һәм дөнья, әрнүгә түзмичә,
Кычкырыр!

Мизгелләр, ай-көннәр, дәверләр буталыр,
Чыңгызның[1] шәүләсе яшендәй ялтырар!
Кемнәрдер кот бирер,
Кемнәрдер кот алыр,
Уйнатып кылычын
Кызурак,
Катырак!

Без – Билге әүлады[2]!
Без – иман, тугрылык!
Йөрәктә кайнаган үч белән, гамь белән,
Өксөкү[3] кошлары шикелле ыргылып,
Кап-кара томанны таратыйк
Мәңгегә.

Мәңгегә!
Мәңгегә!..

Ияләр!
Өч дөнья рухлары!
Чарасыз,
Ялварып, яңадан мин сезгә сыгынам...
Илаһи тынычлык һәм мәхшәр арасы –
Бары кул изәве...
Сыңар сүз.
Ым гына.

---

[1] Тарихи шәхесләр булудан тыш, Чыңгыз (Чыңыз Хаан) һәм Билге (Билге Хаан) – сахаларда тәкъдир илаһлары да.
[2] Әүлад – дәвам, торыннар.
[3] Өксөкү – саха мифологиясендә: бөркет һәм аждаһа кушылмасыннан гыйбарәт кош.

## Читтә очрашу

*(«Үдә дәфтәре» циклыннан)*

Ерак Үдә[4] ярларында кысан ызба.
Карт сунарчы, саха телен боза-боза,
Сөйли безгә белгән-күргәнен.
Күпме дөнья мәшәкате сыйган башын
Әле сыйпый, әле муен артын кашый,
Дымсу күзе – сагыш күлләре.

– Якут! – ди ул үзен, өзеп, горуранә.
Ямау салган кием төсле, төренә дә
Тунгус кушкан шушы исемгә[5],
Салкынны да сизми, белми хәтта,
Яши бирә: киек аулый, болан көтә,
Ияләрне тотып исендә.

Туган теле аксый, анысы; әмма үзе,
Чын сахача, капкын куеп, ятьмә тезеп,
Һәр көн саен яңа баб ача;
Яшьләр Париж, Шанхай яулап, залдан-залга
Көйләп олонхоны[6], шөһрәт даулаганда, –
Тормыш кора ата-бабача.

Ерак Үдә ярларында тар алачык.
Сахалыгын оныта барган карт сунарчы
Туар таңга төбәп карашын
Яши (җанда – ата-баба васыяте!),
Юмарт Байанайның[7] барча сый-нигъмәтен
Кайнар күз яшенә алмашып.

## Нишләтерсең...

*(Ватандашлар сугышы[8] кайтавазы)*

Нишләтим соң, әнкәй,
Нишләтим соң? –
Күрәчәгем, ахры, шушыдыр:
Ап-ак атта алсу таңны ертып
«Ак банда»га барып кушылдым.

Нишләтерсең, әнкәй?..
Ачуланма,
Кирәгеннән артык кайгырма,
Корал тотып, ревком[9] сафларыннан
Дошман сафларына күчтем, әйе,
Тирә-юнем – тоташ байгура.

Нишләтерсең, әнкәй,
Нишләтерсең:
Тәкъдир шундый сынау китерде:
ЧОН[10] егете... Кызылавыз әнчек!
Борын төбе дә кипмәгән иде...
Әрәмәдә атып үтердем.

Нишләтерсең, әнкәй...
Зинһар өчен,
Нәфрәтләнеп, борма карашың! –
Каен тузын тунап каек кордым
Һәм томанга кереп адаштым...

---

[4] Үдә – Хабаров төбәгендә ага торган елга.
[5] «Якут» сүзе тунгусча «йако» («саха») сүзеннән хасил булган.
[6] Олонхо – сахаларның борынгы эпик сәнгате.
[7] Байанай – саха мифологиясендә: сунарчыларны һәм балыкчыларны яклаучы, саклаучы тайга иясе.
[8] Саха җирендә Ватандашлар сугышы 1921 елда башланып 1930 елда тәмамлана.
[9] Ревком – революцион комитет.
[10] ЧОН – «фетнәче»ләргә, «кулак»ларга каршы көрәшкән махсус отряд бүлекләре (урысча: части особого назначения).

Нишләтим соң, әнкәй,
Нишләтим соң? –
Котылырга теләп коллыктан,
Кайнар яуга томырылдым, әйе! –
Хәзер менә салкын бәдәнемне
Туган җирнең туңы җылыта...

***

Көз. Сайсары[11]. Гүзәл вакыт!
Күктә – кояш. Саумы, көз!
Кырыымпа[12] моңнарына
Тоташ күмелүебез.

Сукмак. Усаклар серләшә.
Кыр тычканы – зыр килә.
Басма. Чүрәкәй тавышы.
Ишкәк чупырдый. Көймә.

Яңгыр сибәли, юешләп
Канат очын, иңбашым.
Кытах бирегез, утлы су
Йотыйм да күккә ашыйм!

Иртә. Томан. Туймаада[13].
Дулкын-дулкын – су өсте.
Кырпак карга да күп калмый...
Көз үтеп бара. Үтте...

***

Авыр уйлар баскан чакта боекмасын кеше,
Җиңеләя, җилли алар – тынчу һава ише.
Һәм ireккә, иркенлеккә омтылуың, шашып,
Тавышланып алгач, уза – гүя язгы ташу.
Һәм яшәргә теләк хәтта, һәм бәхеткә өмет
Капыл тоныклана – күзгә моңсу көннәр кебек.
Акрын гына бата кеше, аңышмый да, белми:
Суырып ала тормыш аны – төпсез сазлыкмыни...

***

Беренче кар яуган болынлыкта
Синсез калдым... Өнсез. Ил белән
Шәбәрешкән, шиңгән каен төсле,
Сыкы сара, ахры, мине дә.

Эзләреңне җилләр ялап алды,
Шәрә һәм буш хәзер иңкүлек.
Җаным урман сыман шаулый иде,
Куырылды – яфрак шикелле.

Әрнүемә гүя чыдамыйча,
Улый дөнья, шаша, чалара.
Агачлардан йолкып минем җанны,
Таратмакчы әллә кайларга...

## Бир фатиха...

Газиз атам,
Бир фатиха миңа:
Җитлегәмен, кавырсыным ныгый,
Кан-кардәшне, нәсел-нәсәбемне
Зилзиләдән ышыкларлык булыйм!

Газиз атам,
Бир фатиха миңа! –
Элгәреләр сыман, шөһрәт яулап,
Гаярь чабышкыма ут капканчы,
Офыкларны таптап чабыйм алга!

И учагым,
Бир фатиха миңа,
Синнән яшәү алган балаң ла мин! –
Мең ялкынны кичсәм дә, җаныма
Корым кундырмыйча калдыр.
Амин.

**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН** *тәрҗемәләре*

[11] Сайсары – хәзерге Якутск шәһәре эчендә калган һәм саха халкы өчен изге саналган күл.
[12] Кырыымпа – скрипкага охшаган ике кыллы музыка уен коралы.
[13] Туймаада – Якутск шәһәре урнашкан үзәнлек.



Фәгыйлә
Шакирова

# ГӨЛЧӘЧӘКНЕҢ ЯҢА ТОРМЫШЫ

хикәя

Гөлчәчәк – математика укытучысы, өстәмә рәвештә банк мәктәбен дә тәмамлады. Шуннан соң мәктәптә ун ел балалар укытты. Укытучы эше җиңелләрдән түгел, хәзерге заманда бигрәк тә. Указкадан дер калтырап торган заманнар узды. Хәзер ата-аналар гына түгел, балалар да хокукларын бик әйбәт беләлә.

Мәктәп эше дип чабып, Гөлчәчәк үзенең кырыкка җиткәнен сизми дә калды. «Бу эш белән мин кияүгә дә чыкмый калачакмын икән», – дип уйланган чаклары ешайды. Көзгегә караган саен агара башлаган чәчләренә күзе төшә дә уфтанып куя. Әллә танышу сайтларына кереп карарга микән дип тә уйлый, ләкин шундук сүрелә: укытучы башы беләнме?! Нинди түбәнлек, нинди ахмак уй дип, соңыннан үзен битәрли. Танырлар. Укытучылар, укучылар арасында гайбәт таралыр... Ләкин бу бертөрлелектән дә качарга кирәк иде. Гөлчәчәк тормышын яңабаштан корырга булды. Иң элек ул үз теләге белән мәктәптән китәргә гариза язып, директор бүлмәсенә керде. Кадрия Муллануровна гаризаны күргәч аптырап калды. Күзлеген бер салды, бер киде. Кесәсеннән кулъяулыгын тартып чыгарып, тирен сөртеп алды. «Гөлчәчәк Рәшитовна, ни өчен китәргә уйлыйсыз? Ничә еллар бергә бер гаилә булып яшибез, коллективыбыз әйбәт. Бәлки, без белмәгән проблемаларыгыз бардыр?» – дип, Гөлчәчәккә төбәлде ул.

Гөлчәчәк директорның карашыннан уңайсызланып китте, үзен кемгәдер хыянәт иткәндәй итеп тойды. Дөресе шул, ни дип әйтәсен алдан уйламаган иде ул. «Мин яңа эш таптым. Хезмәт хакы күпкә югары, торган җиремнән дә ерак түгел», – дип алдашты.

Кадрия Муллануровна гаризага имза салды да кызга сузды. «Ярар, яңа эш тапкансың икән, эшләп кара. Барып чыкмый икән, яңадан кайт. Без сине кочак җәеп каршы алачакбыз», – диде.

Гөлчәчәк икенче көнне үк документларын биржага илтеп бирде. Ике атна саен килеп билгеләнеп китте, яңа эш көтте. Нинди эш тә ярый, укытучы гына түгел... Аралаша торган, уңай хисләр тудыра торган эш кирәк иде аңа. Биржа хезмәткәре байтак вакансияләр тәкъдим итеп карады: архив хезмәткәре, колл-үзәк, медицина үзәкләрендә менеджер... Гөлчәчәк атна саен оешмаларга очрашуларга йөрде. Кайсын үзе ошатмады, кайсына аның кандидатурасы туры килмәде. «Бер дә булмаса, курсларга йөреп, риэлторлык хезмәтен үзләштерермен», – дип йөргәндә, бер банктан эш урыны тәкъдим иттеләр. Хезмәт хакы да югары. Кадрлар бүлегендә Гөлчәчәк белән бик озак сөйләштеләр, өч ай сынау вакыты белән аналитика бүлегенә алдылар. Шатлыгыннан нишләргә дә белмәде инде, менә ул яңа тормыш дип, хыялларга бирелде. Күз алдыннан эшлекле костюмлы, галстуклы җитди егетләр узды. «Бәлки, бәхетемне дә шунда табармын», – дип өметләнде. Үзе дә махы бирмәде: кибеттән затлы кием сатып алды. Хуш исле ислемайларын сибеп, бизәнеп-төзәнеп, билгеләнгән көнне эшкә чыкты.

Бүлек җитәкчесе бик горур кыяфәтле, затлы киенгән, кырык яшьләрдәге ханым икән. «Венера Нәгыймовна булам», – дип, үзе белән таныштырды да Гөлчәчәкне эш урынын күрсәтергә икенче катка алып менеп китте. Гөлчәчәк бинаның матурлыгына, яхшы ремонтка карап сокланып барды. Аларның эш кабинетында дүрт хатын-кыз утыра икән. Икесе институтны яңа бетереп килгән яшь кыз, икесе бик һавалы ханымнар булып чыкты.

Бүлек җитәкчесе Гөлчәчәккә танышырга дип, бер кочак норматив документлар калдырды. Компьютерны көн дәвамында урнаштырачакларын әйтеп, кабинеттан чыгып китте.

Җитәкче кабинеттан чыгып китүгә үк, каршы өстәлдә утыручы Рания Әмировна кызның каршысына килеп басты да:

– Духиларга аллергия миндә! Арзан хушбуйлар исенә бигрәк тә. Эшкә килгәндә ислемай сөртәсе булмагыз! – диде. Аннары, бүтән сүзем юк дигәндәй, урынына барып утырды.

Гөлчәчәкне аяз көнне яшен суктымыни, тәмам коелып төште. Төксе хезмәттәшенә каршы бер сүз дәшмичә, өстәленә өелгән документларга чумды. Ләкин күпме генә укырга тырышса да, Рания Әмировнаның: «Арзан хушбуйларга аллергия», – дигән сүзләре колагыннан китмәде. «Ун меңлек духины ярты бәясенә генә алган идем, ни өчен арзан диде икән? Әллә срогы чыкканны сатканнар инде? Бу ханым министр хатыны, ахрысы, бигрәк күркә кыяфәтле...» – дигән уйлар бөтерелде башында.

Бераздан Рания Әмировна, ах-ух килеп, кондиционерны кабызып җибәрде. Гөлчәчәккә якын гына утырган Сания Гаязовна дигәне кисәк кенә урыныннан сикереп торды да Рания Әмировна өстәлендә яткан пультны алып, кондиционерны сүндереп тә куйды. «Минем хондроз! Кичә дә көне буе кондиционер астында утырып билем кузгалды. Төне буе борыч пластыре ябыштырып чыктым!» – дип сукранды ул.

Ләкин Рания Әмировна бирешергә уйламады. Пультны хезмәттәше кулыннан тартып алып, кондиционерны яңадан кабызды. «Ничек бу эсседә

чыдап утырмак кирәк! Һава булмаса, мин буыла башлыйм!» – диде. Ике ханым сүз көрәштерүгә күчте. Калган хезмәткәрләр бәхәскә кушылырга курыктылар булса кирәк, компьютер экранына кадалып утыруларында булдылыр.

Ул арада компьютер урнаштыручылар килде. Чит кешеләр барында бәхәс тынып торды. Бүлек җитәкчесе кереп, яңа биремнәр калдырды. Әбәт вакыты җитте. Рания Әмировна, кәс-кәс атлап, ашханәгә, кызлар урамга чыгып киттеләр. Гөлчәчәк бүлмәдә Сания Гаязовна белән генә калды. Ул үзе белән алып килгән винегрет белән ипине тиз-тиз генә капкалады да тагын эшенә чумды.

45 минуттан соң бүлмәгә хезмәттәшләре җыела башлады. Рания Әмировна ишектән килеп керүгә үк кычкырып җибәрде: «Бүлмәгә сарымсак исе чыккан! Сез нәрсә, кызлар, ашханәдә ашый алмыйсызмыни?! Минем аллергия, сез мине үтерәсез!»

Гөлчәчәк документларга караган килеш көне буе мәктәбен күз алдына китереп утырды. Шау килеп чабучы укучыларны, хезмәттәшләрен күз алдыннан үткәрде. Тиздән беренче сентябрь җитә, укулар башланыр. Мәктәптә ул гына булмас... Җиденчеләр, и, сагыныр инде укытучыларын...

Кич белән Кадрия Муллануровнаның кесә телефоны шалтырады.


– Исәнмесез, Кадрия ханым. Бу мин, Гөлчәчәк... Минем урынга кеше таптыгызмы? – дип сорады ул.

– Юк, Гөлчәчәк, әлегә табалмадык. Кайтырга уйламыйсыңмы соң?

– Кайтам, кайтам!.. – дип, Гөлчәчәк сөенечтән елап җибәрә язды. – Иртәгә үк кайтам!



*Язучы, әдәби тәнкыйтьче,
филология фәннәре докторы,
КДУ профессоры Ибраһим Нуруллин.
1980 нче еллар.*



*Параду мәктәбендә укыткан еллар. Ибраһим Нуруллин (уңда) сугыштан яраланып кайткач, мәктәптә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Парау (Боровка), 1944 ел.*




*Нуруллиннар гаиләсе. Сулдан беренче язучының әтисе Зиннәтулла, дүртенче – әнисе Нәваль. Уңнан икенче – Ибраһим. 1930 нчы еллар.*



*Язучылар белән. Нарәк шәһәре, Таҗикстан. 1969 ел.*



*Өлкәннәр. Салих Баттал, Ибраһим Нуруллин, Әмирхан Еники. Казан, 1994 ел.*



*Ибраһим Нуруллин Ташкент шәһәрендә. 1986 ел.*




*Казан дәүләт университетының журналистика бүлеге студентлары белән. Казан, 1984 ел.*

*Ибраһим Нуруллинның шәхси әйберләре һәм фотосурәтләрен 1996 елның октябрендә хатыны Розалина ханым Ульяновск өлкәсе, Димитровград шәһәренең туган якны өйрәнү музеена тапшыра. Фотосурәтләр Димитровград шәһәренең туган якны өйрәнү музее фондыннан алынды. Материалны әзерләүдә ярдәм күрсәткән өчен музей директоры Марина Ивлиевага рәхмәт белдерәбез.*

*Сәхифәне Татар китабы йорты директоры* **Айдар Шәйхин** *әзерләде.*

# ТАТАРДА ДАСТАН БАРМЫ?

Алыплар тормышын, пәһлеваннарның безгә аңлашылып та бетмәгән батырлыгын, ил батырларының басып алучыларга каршы яуларын, ханнарның тәхет өчен барган көрәшен, үзенә аталган кәләшне эзләп юлга чыккан геройларны тасвирлаган чәчмә, тезмә яки шигъри һәм чәчмә өлешләре аралашып килгән зур күләмле әсәрләрне татар фольклор фәнендә дастан дип атау кабул ителгән.

Соңгы вакытта хәтта галимнәр арасында да «Татарда дастан бармы?» дигән сорау ишетәм. Әйе, чынлап та, хәзерге вакытта гына түгел, әле узган гасырның 80–90 елларында да әби-бабайлардан дастан турында сорасаң, алар җавап бирә алмас иде. Шул ук вакытта «Таһир-Зөһрә», «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу», «Сәйфелмөлек», «Бүз егет» бар, «Түләк»нең кульязма вариантлары табыла тора, Алпамыш турындагы вакыйгалар әкият буларак бәян ителә, Йосыф белән Зөләйха мәхәббәте тарихын әби-бабаларыбыз яттан көйләп сөйли иде. Ягъни җиseme бар, исеме юк буламы, башка сере бармы?

Сере бик гади! Татарда дастан дигән төшенчә булмаган. Татар халкы әлеге жанрга караган әсәрләрне төрлечә атап йөртеп, дастан атамасы чагыштырмача соңрак һәм, нигездә, фәнни термин буларак кулланышка кергән. Бу жанрга караган әсәрләр татар телендә беренче чиратта «кыйсса» дип тә аталган. Октябрь революциясенә кадәр басылган китапларда да, нигездә, шушы термин еш очрый. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф галәйһиссәлам», «Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха» яки «Йосыф кыйссасы», «Кыйссаи Козы Көрпеш», «Кыйссаи Сәйфелмөлек», «Кыйссаи Җөмҗөмә Солтан», «Кыйссаи Бүз егет», «Кыйссаи Алпамыш». Болар барысы да – татар дастаннары.

Дастан термины сирәгрәк очрый, дөресрәге, ул фәкать бер әсәргә карата гына кулланылып, берничә тапкыр «Дастан Хатәм тай» дигән китап басылып чыга.

Татар халкына төрек яки азәрбайҗан фольклорыннан кергән дип фараз итәргә мөмкин булган «Күр углы» әсәре «Хикәят Көр углы Солтан» дигән исем белән басылып, хикәят термины да дастан жанрының бер атамасы булып тора. Ике очракта да терминнарның Казанда басылып чыгып, халык арасында басма формада таралган әсәрләр турында бара. Беренчесе төрки халыкларга Һиндстан фольклорыннан керсә, икенче әсәр татар халкына да, башка халыкларга да төрек фольклорыннан таралган.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы популярлашып, бу әсәрне китап термины белән аталган очраклары да бар. Бу очракта китаби яки китап термины да кыйсса мәгънәсенә дә якын. Мәсәлән, «Йосыф Китабы», «Китабел Йосыф» яки «Китаби Йосыф». Әмма ул бер яктан жанрны аңлатса, икенче яктан бу кыйссаның халык теленә дә китаптан керүенә ишарә ясый.

Башка төрки халыкларда да эпосның үз милли атамалары бар. Дастан термины үзбәк, төркмән, азәрбайҗан, таҗик халыклары фольклорында бар, башкорт эпосында кобайыр һәм хикәят, казакъ халкында жыр атамалары очрый.

Хәзер яңадан «Татарда дастан булганмы?» дигән сорауга әйләнеп кайтабыз. Булган, һәм ничек кенә булган. Халык аны кыйсса дип белгән. «Кыйсса» сүзе (قصق) гарәпчәдән кереп, хикәя, тарихи вакыйга, риваять мәгънәләрендә йөри. Гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә «кыйсса» атамасы белән хикәя, хикәят, повесть, әкият, риваять һ.б. жанрларны атыйлар. Кыйссаларда сюжетны барлыкка китерүдә геройның эчке кичерешләренә,

уй-хисләренә дә игътибар бирелә. Бу кыйссаларның бер хасияте. Чынлап та, тылсымлы әкиятләрдә дә, тормыш-көнкүреш әкиятләрендә дә төп герой үзенең дошманнарын үтереп, әрдәнәләп өеп куйганда да, бер кеше дә аларның үлемен кызганып елап утырмый. Кыйссаларга килсәк, бу әсәрләрдә бәян ителгән вакыйгалар бер генә буын әбиләрне күз яше түктермәгән. Г.Тукай да үзенең 1910 елның 15 апрелендә «Шәрекъ клубы»нда ясаган «Халык әдәбияты» дигән чыгышында дастаннарның нәкъ шул ягына игътибар итә. «Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер» дип, дастаннарның, бу очракта «Таһир-Зөһрә» турында сүз бара, кешенең эчке кичерешләренә йогынты ясау көчен искәртә.

Дастан яки кыйсса нинди жанр соң ул? Фольклорның бу төрен язма әдәбияттагы романнар белән чагыштырып булыр иде. Романнар кебек үк аларда аерым каһарманнар, аларның батырлыгы / сәяхәте / сәфәре / мәхәббәте һәм мәхәббәт өчпочмагы турында сүз бара. Кешене уйланырга мәҗбүр иткән, таныш хис-тойгыларны яңарткан тыңлаучы яки укучы өчен кызыклы эчтәлек, мавыктыргыч сюжет бу әсәрләрнең искиткеч популярлыгын тәэмин иткән.

Татар дастаннары – беренче чиратта, җырау яки чичәннәр иҗаты белән бәйле жанр. Тугандаш башкорт халкы дастаннарын кобайыр дип атап, аларны башкаручыларны кобайырчы дип атый. Татар халкында ике термин да мәгълүм булган дип уйлыйм. Җырау булу – Күкләр яки Тәңре тарафыннан бирелгән сәләт буларак бәяләнгән. Әлбәттә, аның иң беренче шарты – чичәнлек традицияләрен яхшы белү, импровизацияләү сәләтенә ия булу.

Дастаннарны башкаруның үзенең күп төрле шартлары һәм тыюлары булган. Көннең яки елның теләсә кайсы вакытында дастан сөйләмәгәннәр. Аның үз вакыты – ел фасылы, тәүлектәге аерым вакыты булган. Мәсәлән, татар халкы ышанулары буенча, әкиятләрне көндез һәм җәй көне сөйләргә ярамаган. Бу ышану дастаннарга да кагылырга мөмкин дип фараз итәбез. Татар халкының кичләрен көйләп китап уку/китап тыңлау яки кыйссаларны яттан көйләү традициясе, әкият сөйләү традициясе шушы чичәннәр иҗатының дәвамы булып, ул XX йөзнең беренче яртысына кадәр дәвам итә.

Татар халкының кыйссаларын яттан көйләвен өлкән буын әле хәтерлидер. Минем дәү әнием, Кама Тамагы районы Каратал авылында туып үскән кыз, «Йосыф кыйссасы»н баштан ахырга кадәр яттан белә, көйләп башкара иде. Кыйссаларны көйләп башкару, яхшы белү безнең як – Татарстанның Тау ягы өчен гадәти күренеш дип әйтергә дә мөмкин.

Дастаннар – күпчелек төрки халыкларда тезмә, ягъни шигъри формадагы әсәрләр. Татар текстларында, кагыйдә буларак, тезмә һәм чәчмә өлешләр аралашып бара. Тулысынча тезмә, ягъни шигъри өлештән торган «Бүз егет» бар, тезмә өлеш «Идегәй» дастанында яхшы сакланган. Күпчелек әсәрләр безнең көннәргә чәчмәдә килеп җиткән. Бу күренеш, беренче чиратта, җырау-чичән профессиясе югалу белән аңлатыла.

Үзләре дә шигъри осталыкка ия, импровизациягә сәләтле бу талант ияләре тезмә текстларны сәгатьләр буе башкара алган. Кыргыз манасчыларының «Манас» эпосын башкаруын тамаша кылганнан соң, чичән-җырау сәнгате табигатенең, чыннан да, гади башкару гына булмавы аңлашыла. Мәсәлән, Мәскәү шәһәрендә 2012 елда узган «Эпос «Манас» – Памятник мировой эпической культуры» дигән конференциядә дүрт яшьлек Умот Доолотовның «Манас» поэмасыннан өзекләр башкаруы бу күренешнең феномен булуын ачык күрсәтте. Умот «Манас»ны өч яшендә сөйли башлый. Аңа аны беркем дә өйрәтмәгән, бала эпостан өзекләрне транс хәлендә сөйли. Бу күренеш, дастаннарны транс хәлендә башкару чын чичәннәр, җыраулар өчен хас күренеш булган дип уйлыйбыз. Нәкъ шушы рәвешле бары шигъри әсәрләрне генә башкарырга мөмкин. Эпик әсәрләрнең шигъридән чәчмәгә күчә баруы да башкаручы традициясе югалу белән генә аңлатыла ала. Дастаннарның аерым фрагментлары яки текстлар тулысынча халык музыка коралларына (думбра, дутар, кубыз, саз) кушылып, көйләп

башкарылган. Җыраулар юкка чыкканнан соң, дастаннарны көйләп башкару аларның эчтәлеген сөйләү белән алышынган. Бу, әлбәттә, күпчелек әсәрләрнең югалуына, күләмнәре кимүгә китергән. Без язма текст аша укый торган дастаннарның бер өлеше борынгы эпосның кыскача эчтәлеге дип атау да дөреслектән ерак түгел.

Татар халкының дистә гасырлар элек ислам динен кабул итүе, язулы һәм китаплы булуы, аның фольклорына, бигрәк тә дастаннарына да тәэсир итми калмаган. Җырау-чичәннәр иҗатын китап уку традициясе алмаштыра. Шул ук вакытта ислам диненең әлеге иҗатны тыюы да әлеге иҗат ияләрен эзәрлекләүгә китергән. Дастаннарда сакланган мәгълүмат буенча, һәр җырау яки акын күпмедер дәрәҗәдә күрәзәче вазифасын да башкарган. Мәсәлән, «Идегәй» дастаны аша исеме безнең көннәргә килеп җиткән Субра җырауның башкалар белмәгәнне белүе, киләчәкне һәм үткәнне күрә алуы тасвирлана. Татар, башкорт, казакъ фольклорының уртак герое Җирән Чичән дә – үзенең зирәклеге, алдан күрүчәнлеге белән мәгълүм образ.

Җырау-чичәннәр өстенә дипломатик вазифалар да салынганлыгы, аларның авыр мәсьәләләрне хәл иткәндә ярдәмгә килүе аноним авторның «Шәдҗәрәт әл-әтрәк» хезмәтендә тасвирлана. Хезмәттә бәян ителгәнчә, Җучинең үлем хәбәрен беркем дә Чыңгыз ханга җиткерергә кыймый, авыр миссияне Олуг-Җырчы исеме белән тарихка кереп калган чичәнгә тапшыралар.

Дастан термины фарсы телендәге хикәя яки хикәятне белдергән «дестан» (داستان) сүзеннән алынган. Бу терминга «буыннан буынга күчеп сөйләнә торган тормыш турындагы хикәя» дигән аңлатма да бирелә. Дастан билгеләмәсе әлеге жанрның төп сыйфатлары белән тәңгәл килә: героик, фантастик һәм романтик эчтәлекле шигъри-поэтик, прозаик яки катнаш формадагы әсәрләрне әдәбиятта һәм фольклорда дастан дип атыйлар.

Фольклористика фәнендә дастаннарга карата эпос термины да кулланыла. Эпос яки дастан жанрын халыкның героик идеаллаштыру масштабындагы үткәне, халык хәтерендә сакланган узган тормышы, аерым вакыйгаларны героик планда тасвирлаган фундаменталь характердагы эпик яки лиро-эпик әсәрләр дип билгеләргә мөмкин. Татар фольклористикасында эпос жанрын тикшерүгә багышланган беренче фәнни хезмәт буларак, Г.Ибраһимовның «Әдәбият кануннары» китабына кергән «Каһарманнар поэмасы» дигән хезмәтен күрсәтергә мөмкин. Бу китап беренче тапкыр 1918 елда Казанда басыла. Ләкин анда, фольклорчы Ф.В. Әхмәтова үзенең 1984 елда дөнья күргән «Татар халык иҗаты. Дастаннар» томына керешендә билгеләп узганча, татар дастаннары хакында сүз бармый. Г.Ибраһимов эпос жанрын «бердән имламызга туры килми, икенчедән, телемезгә, аһәңемезгә ят» дип бәяләп, дөнья эпосы үрнәкләре турында сүз алып бара. Г.Ибраһимовның бу фикере татар дастаннарын инкарь итәргә теләүчеләргә этәргеч булып, аларны фәнни нигездә өйрәнү шактый тоткарлана.

Дастаннарның төп үзенчәлеге буларак күрсәтелергә тиеш бер күренеш бар. Бу – аларның, нигездә, берничә халыкның уртак мирасы булу. Нигездә дип күрсәтү шартлы, чөнки аерым текстлар бер генә халыкта саклануы аның башкаларда булмавын түгел, юкка чыгуын, онытылган булуын да күрсәтергә мөмкин.

Татар фольклорындагы күпчелек дастаннар үзләренең тамырлары белән гомумтөрки эпоска барып тоташа, ягъни бер үк сюжетка корылган эпик әсәрләрнең милли версияләре ике, өч һәм күбрәк тә халыкта очрарга мөмкин. Сюжет никадәр борынгырак булса, ул шулкадәр ныграк таралган була. Бөтен төрки халыкларның уртак мирасы булган дастаннарга мисал итеп «Алпамыш» дастанын күрсәтергә мөмкин. Ул татарлардан башка үзбәк, казакъ, алтай, башкорт һәм башка халыкларда бар. «Кузы-Көрпәч белән Баян Сылу» – шулай ук алтай халыкларында, казакъларда, башкортларда популяр әсәр. «Ак Күбек» дастаны себер татарларында һәм алтайларда гына, ә «Түләк» татар белән башкорт халыкларында гына сакланган.

Икенче яктан, борынгырак сюжетка корылган әсәрләр жанр трансформациясе

кичереп, башка жанрларга, мәсәлән, әкияткә әйләнеп китү очраклары да юк түгел. Дастаннарның эчтәлеге риваятьләрдә саклана, өзекләре җырга әйләнеп киткән дастаннар да юк түгел.

Аерым сюжетлар татар халкына тугандаш халыклардан кергән. Аларны уртак мирас дип карап булмый, әмма бу әсәрләр халыклар арасындагы рухи бәйләнешләрне, күчешләрне күрсәтү ягыннан әһәмиятле. Мәсәлән, казакъ халкының «Кыз Жибек» дастаны революциягә кадәр Казанда берничә тапкыр басылып чыгып, аны татарлар да укый һәм «Кыз Җефәк» исемендә татар халкы да белә. «Күр улы» дастаны да татар халкына төрек фольклорыннан кергән. Әмма һәр халык үз вариантында үзе белгән күренешләр, тарихына, көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә бәйле детальләр белән эш итә, үзенең йола-ышануларын сурәтли.

Эпос яки дастаннар барлыкка килә башлавы ягыннан ул ыруглык җәмгыяте һәм ыруглык мөнәсәбәтләре җимерелә башлаган чорларга карый. Әмма соңрак чорларга караучы текстларда да борынгы ышанулар белән үрелгән иң борынгы мотивлар – дөнья яратылу, күкләр, җир һәм җир асты дөньялары турындагы космогоник карашларның эзләрен очратырга мөмкин. Эпос формалашуда төп чыганак хезмәтен үтәгән иң борынгы катлам – мифлар. Бигрәк тә беренче булып аерым күренешләрне, предметларны булдырган геройлар, иң беренче кешеләр турындагы мифологик хикәятләрнең генетик роле зур булган. Эпос жанрының бер башлангыч чыганагы мифлар булса, икенче чыганагы, бигрәк тә соңрак чорда, тарихи риваятьләр булганлыгын да күрсәтү зарур.

Архаик эпоста эпик вакыт – мифик дәвер һәм шул ук вакытта ыру-кабиләләргә хас яшәеш нормалары, архаик йолалар, кабиләара бәрелешләр, табигатьнең кырыс стихиясен һәм төрле явызлыкларны гәүдәләндерүче мифик көчләргә каршы көрәш тасвирлана. Мондый көрәш-бәрелешләрдә, кагыйдә буларак, үзара дошманлашып яшәгән дуаль система сурәтләнә, ул «бу дөнья» яки «үз җире» белән «теге дөнья» яки «чит-ят җирләр» арасында хөкем сөргән каршылык рәвешендә күрсәтелә. Теге дөньяда яшәүче дошман көчләр, гадәттә, мифик-демоник ия яки куркыныч зат итеп бирелә. Эпос каһарманы шул көчләрне җиңү яки буйсындыру исәбенә тормышта тәртип, гармония урнаштыру өчен көрәш алып бара. Дошманын җиңәргә аңа батыр аты, куәтле коралы ярдәм итә.

Төрки фольклорда капма-каршылыкка корылган дуаль система күпчелек очракта никах белән бәйле сюжетларда чагылыш таба. Герой үзенең кәләшен икенче дөньядан – ятлар дөньясыннан ала, аны эзләп, параллель дөньяга барып чыга, төрле авыр сынауларны уза, «теге дөнья» вәкилләре белән көрәшә. Эпик герой өчен бары үзе яшәгән территория генә «үз» дөньясы булып, билгеле бер чикне узуга «ят» дөнья, икенче дөнья башлана. Ят дөнья – җир асты («Йиртөшлек»), су асты («Түләк») дөньялары булырга яки елга, дәрья аръягында («Алып Манаш») урнашырга мөмкин. Күрше территорияләр дә «ят» дөньяга карый, ул герой яшәгән территория белән янәшә, ыру агачы Байтирәкне яки Байкаенны узгач башланырга да мөмкин («Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу»). Мәсәлән, «Түләк» дастанында «ятлар» дөньясы – су асты, ягъни Чачдархан патшалыгы. Җир дөньясы Күк-Тәңре, көн-кояш яклавында булып, су асты дөньясына кояш яктысы һәлакәт китерә. Дастанда мондый эпизод бар, Түләк ярдәм сорап, хак Тәгаләгә мөрәҗәгать итә, су астына кояш эсселеге, кояш яктысы җибәрүен сорый. «Йиртөшлек» дастанында да кешеләр дөньясына җир асты дөньясы каршы куела. Әмма бу ике дөнья арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр Түләкнең дә, Йиртөшлекнең дә икенче стихия вәкилләренә өйләнүенә комачауламый. Галимнәр дастан геройларының башка дөнья вәкилләренә өйләнүен экзогам никахларның чагылышы буларак аңлаталар. Шул ук вакытта архаик эпоста бу – монысы инде аеруча мөһим – табигатьне яратуны табигатьнең кырыс көчләре өстеннән борынгы кешенең беренче җиңүләрен дә символик рәвештә чагылдыра.

Идеаллаштырылучы эпик герой еш кына могҗиза белән туа. Ул – ярым кеше, ярым илаһи зат. Герой, анадан тууы белән җир, кешеләр дөньясына караса да, тууына илаһи көчләр сәбәпче булуы, аның гади кеше булмавын да күрсәтә. Кагыйдә буларак, герой өлкән яшьтәге карт белән карчыктан туа. Әмма бу очракта да геройның дөньяга килүе гадәти түгел, чөнки бала йә берәр изге затның фатихасы белән туа, яки карчык кеше берәр ризык ашаганнан соң авырга кала. Бала тууда атаның катнашы аның илаһи затка бала сорап мөрәҗәгать итүгә, ягъни илаһият белән ике арада арадашчы булуга кайтып кала. Эпик геройның гадәти кеше булмавын күрсәткән билгеләре дә була: әйтик, башындагы алтын чәч толымы («Кузы-Көрпәч»), аркасындагы яки маңгаендагы мөһере («Алпамыш»). Аның үлемсезлеге яки гадәттән тыш үлеме дә геройны гади җир кешеләреннән аерып куя («Ак Күбәк»). Күпчелек геройларның дөньяга киләсе алдан билгеле була, алар билгеле бер миссия үтәү өчен җибәрелә. Мәсәлән, Гесер турындагы монгол эпосында герой дөньяның дүрт тарафын дошманнардан, явыз көчләрдән чистарту максатында җирдә тудырыла. Бу мотивның эзләре татар халкының каһарманнар эпосына якын тылсымлы әкиятләрендә дә саклана. Мәсәлән, Диюне үтерәсе геройның исеме алдан билгеле булу шушы мотивка ишарә итә («Таңбатыр» әкияте). Бу мотив әлеге төр әкиятләрнең дастаннардан әкияткә күчүен дә күрсәтергә мөмкин.

Архаик эпосның төп идеясен тәшкил иткән галәмне яклау һәм саклау, табигатькә һәм тормышта гармониягә ирешү өчен барган мифик көрәш вакыт узу белән эпосның классик төрендә «үз» җиреңне басып алучылардан саклау өчен көрәш белән алышына. Шуңа бәйле рәвештә тарихилык белән миф арасындагы нисбәт тә үзгәрә. Классик эпос мифлар белән бәйләнешен сакласа да, тарихилыкка да дәгъва итә башлый. Ул ерак тарихта булып узган вакыйгаларны тасвирлаганда, тарихи риваятьләргә таяна, чор атмосферасы җир тормышына бәйләп тасвирлана. Бу очракта тарихи яки квазитарихи вакыйгалар гомумиләштерелгән шартлы вакыйгалар рәвешендә гәүдәләндерелә, аерым очракларда чынбарлыкта булган хәл буларак бәян ителә. Героик эпос башта архаик эпос-әкият форматында булып, борынгыларның табигатьнең кырыс көчләрен гәүдәләндерүче мифик көчләр белән бәрелешен һәм ыру-кабилә мөнәсәбәтләрен яктырткан булса, соңрак төрки кабиләләр беренче дәүләтләргә оеша башлагач, эпоста да феодаль тормыш рәвеше чагыла башлый. Бу – хуҗалык итүдә аучылыкка караганда терлек асрау һәм игенчелекнең өстенлек алуы, һөнәрчелек формалашу, парлы гаилә һәм шәхси милек барлыкка килү, һәм, беренче чиратта, милеккә мөнәсәбәттә сыйныфлар һәм иң беренче дәүләтләр формалашу. Кайбер әсәрләрдә ил-йортны, үз халкын чит-ятлар басып алуыннан саклау темасы үзәккә чыга.

Феодализм дәверендә, фольклор эпосы үсешенең соңгы чорында, героик эпос тарихилык, документальлеккә мөнәсәбәте ягыннан яңа баскычка күтәрелә. Ачыклап әйткәндә, классик героик эпоска алмашка тарихи эпос килә. Реаль тарихи шәхесләр, тарихи вакыйгалар героик эпос кысаларында сурәтләнә башлый. Тарихи дастаннар географик атамалар, халык, кабилә һәм аерым шәхесләрнең исемнәрен, чынбарлыкта булган аерым вакыйгалар турында мәгълүмат саклавы белән архаик һәм классик эпостан аерылып торалар. Әсәрләрдә халыкның этник тарихы, тормыш-көнкүрешенә бәйле үзенчәлекләре, йолалары, гореф-гадәтләре чагылыш таба. Әмма, табигый, тарихи дастан тарих эзеннән генә бармый, сәнгатьчә эшкәртүгә дучар ителгән әлеге төр эпоста да, традицион эпик мотивлар, мифологемалар да урын ала. Тарихи прототиплары булган эпик геройларның шәҗәрәсе дә илаһи зат яки идеаллаштырылган хөкемдардан башлана. Эпик геройның ата-бабалары турында да легендар характерда мәгълүмат бирелә. Мәсәлән, Идегәй турындагы дастаннарда Идегәйнең шәҗәрәсе изге Баба Төкләскә, ягъни Хуҗа Әхмәт Ясәвигә барып тоташа. Икенче яктан анасы Пәри кызы булу да Идегәйнең гадәти булмавын исбатлый. Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин. «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең беренче дастанында Чыңгыз ханның тууы да Илаһи Күк белән бәйләнештә тасвирлана.

Төрки халыкларны борынгыдан янәшә территорияләрдә яшәү, тел уртаклыгы, үзара этник һәм мәдәни йогынтылар һәм бәйләнешләр, уртак тарихи шартлар бәйләп торган. Ә инде Алтын Урда чорында төрки халыклар арасындагы сәяси, икътисади мөнәсәбәтләр тагын да ныгый, үсеш ала. Мәдәни һәм рухи байлыкларны үзара алмашу һәм уртак мирас әлеге бәйләнешләрнең бер чагылышы булып тора. Бу фольклорда бигрәк тә ачык чагыла. Алтын Урда чорына нисбәттә каралган дастаннарның күп санлы милли версияләре һәм вариантлары булуы менә шундый бәйләнешләрне раслый. Шул ук вакытта бер үк персонажлар, уртак сюжет һәм фабула берләштергән милли версияләр аерым эпизодларны тасвирлауда, геройны сурәтләүдә, конфликтны бәян итүдә һәрбер халыкның тормыш рәвешенә бәйле үзенчәлекләргә дә ия.

Татар дастаннары арасында эпос жанры формалашуның һәм үсешенең бөтен этапларыннан мисалга китерерлек әсәрләр саклана. Атап әйткәндә, иң борынгы чорга яки төргә караучы әкияти-мифологик дастаннар да («Йиртөшлек», «Түләк»), архаик яки героик классик эпос та («Алып-Мәмшән», «Ак Күбәк»), тарихи эпос та («Гайсә улы Амәт», «Идегәй») һәм романтик, ягъни мәхәббәт дастаннары да («Кузы-Кәрпәч белән Баян-Сылу») бар.

«Алпамыш» дастанының VI-VIII гасырларга караган иң архаик алтай версиясе «Алып-Манаш». Эпосның әкияти-мифологик төренә яки «каһарманлык әкияте»нә караган бу сюжет алтайлардан башка төрки халыкларга да тарала. «Алып-Манаш» дастанының берничә татар варианты фольклор экспедицияләре вакытында Ф.В. Әхмәтова тарафыннан язып алынып, алар хәзер Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана.

Әсәр каһарманлык яки батырлар әкият эпосына хас архаик үзенчәлекләрне, уртак урыннарны саклавы белән дә игътибарга лаек. Бу – баш геройның алыплыгы, аның никах сынавы үтүе, магик йокысы, кыяфәтен үзгәртеп, хатынының туена кайтуы, Сандугачның каһарманлык сыйфатларына ия булуын саклаган сюжетлар. Дастанның татар версиясе шактый үзгәртүләргә дучар булып, аерым эпизодлар, мотивлар төшеп калган, кайберләре традицион функцияләрен, мәгънәләрен югалта. Аның борынгы героик нигезен күзалларга әлеге әсәрнең төрле милли версияләрен чагыштырып өйрәнү мөмкинлек бирә.

Барлыкка килүе белән Алтын Урда чорына нисбәттә өйрәнелә торган «Ак Күбәк» дастаны классик эпос үрнәге булып тора. Әсәрдә Себер җирендә төрле ыру-кабиләләр арасында барган бәрелешләр эпик батырларның көрәше аша тасвирлана. Тарихи эпос төренә караучы «Гайса улы Амәт» дастаны Алтын Урдада тәхет өчен барган көрәшнең бер эпизодын тасвирлый. Бу – Алтын Урда тарихының чыңгызиләр арасында тәхет өчен аяусыз көрәш барган иң катлаулы чоры, 1350–1380 еллар арасындагы вакыйгалар. Әсәрдә сурәтләнгән күпчелек геройларның прототиплары да мәгълүм шәхесләр – Алтын Урда ханнары.

Феодализм дәверендә эпосларның бер өлеше романтик төсмер ала, ягъни, героика кимеп, көнкүреш һәм мәхәббәт темасын тасвирлау беренче планга чыга. Романтик характердагы мәхәббәт дастаннарында егетнең өйләнергә читтән кыз яки үзенә аталган кәләшен эзләп юлга чыгуы, һәм төрле каршылыклар, авырлыклар белән бәйләнгән никах сынавы үтүе тасвирлана. Кагыйдә буларак, гашыйклар язмышы фаҗигале тәмамлана. Төрки халыкларның «Таһир-Зөһрә», «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаннары – моның ачык мисалы. Әлеге дастаннарда да өлешчә булса да, героик эпостан күчкән аерым мотивлар да сакланган (мәсәлән, геройның батырлык күрсәткән балачагы, геройның тәнендә һөҗүмгә бирешә торган урыны булуы).

Дастаннарны темаларына, конфликтның характерына һәм тарихи дәрәҗәсенә нигезләнеп, берничә төркемгә аералар.

1. Героик дастаннар. Аларны фәндә алыплар турындагы хикәятләр, каһарманлык дастаннары яки батырлар эпосы дип атау да кабул ителгән. Героик яки каһарманлык

дастаннарын үзләрен янә ике төркемгә аерып, героик-архаик һәм героик-классик (архаик һәм классик) дастаннар дип атап йөртү дә бар.

2. Мәхәббәт дастаннары. Икенче төрле романтик яки лироэпик дастаннар дип атау да очрый.

3. Тарихи дастаннар.

Татар фольклорында дастаннарны классификацияләүдә, алда әйтелгәннәргә өстәп, аларның төп ике төркемен аерып күрсәтү мөһим. Бу – китаби һәм традицион дастаннар. Китаби дастаннарга, язма рәвештә эшкәртелеп, китап булып басылып чыккан дастаннар да, шәкерт дәфтәрләренә күчерелеп, безнең көннәргә килеп җиткән әсәрләр дә, кулъязма китапларда сакланган кыйссалар да керә. Аларны берләштерүче төп билге – таралу һәм саклану рәвеше язмача-басмача булу, башкарылу рәвеше, кагыйдә буларак, – кич утырулар вакытында кычкырып уку, шәкертләр арасында башкарылу. Традицион дастаннар буыннан-буынга күчеп, аерым аудитория алдында телдән башкарылган һәм халык, дөресрәге аерым кешеләрнең чичән яки акыннарның хәтерендә сакланган. Дөрес, тагын бер искәрмә бар. Халыктан XVIII-XIX гасырларда язып алынган эпик әсәрләр – күпчелек очракта дастаннарның кыскарган эчтәлеге, аерым шигъри яки прозаик өзекләре генә. Арада чагыштырмача үзгәрешсез сакланган өлешләр дә юк түгел.

Югарыда карап үтелгән бүленеш дастаннарның иҗат ителү, саклану һәм башкарылу рәвешенә бәйле. Шул ук вакытта традицион дастаннарның да, язма дастаннарның да үз эчләрендә конфликтның характерына бәйле тематик бүленеш бар. Югарыда тәкъдим ителгән классификацияләр шундый бүленешнең үрнәкләре булып тора.

Дастаннарда дөнья сурәтенең чагылуы, бабаларыбызның йола, гореф-гадәтләре һәм төрле ышанулары, дөньяга карашының ни рәвешле гәүдәләнүе фольклорның чынбарлыкка мөнәсәбәтенә бәйле. Билгеле булганча, фольклор халык көнкүрешенең мөһим элементы гына түгел, ә тарих һәм этнография буенча мөһим чыганак та. Анда халыкның иҗтимагый мөнәсәбәтләре, ышану һәм йола эзләре, көнкүрешенә кагылышлы күп мәгълүматлар сакланган. Дөрес, фольклор әсәрләрендә вакыйганың төгәл чагылышы түгел, бәлки әлеге вакыйгаларга карата халыкның мөнәсәбәте тасвирланганын да онытырга ярамый. Ягъни фольклор һәрвакыт субъектив кыйммәт. Фольклор текстларында теркәлгән теләсә кайсы фактның мәгънәсен һәм чынбарлыкны ни дәрәҗәдә төгәл чагылдыруын аның жанр үзенчәлекләрен, художество системасын исәпкә алганда да төгәл ачыклау кыен. Фактның никадәр дөреслеге яки дөреслекнең деформацияләнүе, аның реаль яки идеаллаштырылган булуы, тарихилыгы яки фантазиягә корылган булуы жанрдан һәм конкрет әсәрдәге вакыйга-күренешләрнең тормыш белән бәйләнеш рәвешеннән дә тора. Шулай ук бер үк әсәрнең вариантларына мөрәҗәгать итү дә кайсы фактларның традицион һәм тотрыклы, кайсыларының очраклы яки инновацион характерда булуын аерырга мөмкинлек бирә.

**Илсөяр ЗАКИРОВА,**
*филология фәннәре докторы,*
*Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.*

# ЙОЛДЫЗЛАРГА ГАШЫЙК ШАГЫЙРӘ

## РӘСИМӘ ГАРИФУЛЛИНА ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Халкыбызның алдынгы вәкилләре «азатлык» сүзен яңгыратып, тулышып, мәйданнарга чыккан 90 нчы елларда әдәбиятка килгән төркемнең бер вәкиле – Рәсимә Гарифуллина – хәзер публицистик яңгырашлы, нечкә хисле лирикасы, тарихи һәм мифологик поэмалары, прозасы, эсселары белән тормыш-яшәеш агышында эчке мәгънә, милли рух эзләүче, «җирдәге» һәм «күктәге» йолдызларга гашыйк зыялы, тынгысыз каләм ияләребезнең берсе.

Иҗат кредосын якташы, халкыбызның язмышы, киләчәге турында борчылып, йөрәк әрнүләрен садә юлларда чагылдырып калдырган шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин намена багышланган «Гомер буе үзен эзли кеше» шигырендә «Кем ул бүгенгебезне зурлаган шагыйрь? Үз бурычын үти алдымы?» – дип калкытып куйган Рәсимә Гарифуллина күпләребезгә кагылган төртмәле соравына үзе үк гомере буена җавап эзли:

*Әйтеләсе... әйтелмәгән китте*
*Бу гөнаһлы җирне калдырып.*
*Сүнә белми торган ялкын төсле*
*Бәгырьләрне тора яндырып.*

«Гомер буе үзен эзли кеше...»

Әдәбият белән сәнгатьнең төрле жанр вә юнәлешләрендә иҗат итүчеләре белән данлыклы Балык Бистәсе вилаятенең Балтач (Юлсубино) авылында тәүге сулышын, Югары Тегермәнлектә урта белемне алган үсмер күбебез шикелле югары уку йортына юл тотмый. Пермь шәһәрендә урнашып, ике елын хәрби завод станогы артында уздыра. Аның холкына хас тәвәккәллек, максатчанлык киләчәктә иҗатында чагылыш табуы табигый иде.

Казан дәрелфөнүненең журналистика бүлегендә югары белем алып, туган районының «Авыл офыклары» газетасында төрле вазифаларны үтәп, каләмен чарлаган яшь язучыны Саратовның Идел буе иҗтимагый-сәяси институтына белем эстәргә җибәрәләр. Аннан күпчелек талиб-талибәләр «ата коммунист», һич югында «тел бистәсе» булып чыксалар, затлы нәсел дәвамчысы әбисе йогынтысында яшьли Аллаһның барлыгына, берлегенә ышанып, балачагыннан намазга баскан Рәсимә Әхмәтзакир кызы шунда укучы бер төркем төрки кардәшләрен оештырып, мәчеткә йөри һәм укуын да уңышлы тәмамлый. Тиздән аны Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге мөдире итеп куялар. Шуңа хәтле берничә җыентыгын чыгарып өлгергән каләм иясе Р.Мостафин, М.Вәли-Барҗылы, А.Юнысова, Н.Гамбәр кебек тәнкыйтьчеләрнең, күпсанлы укучыларының уңай бәяләрен алган Рәсимә Гарифуллина Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Бәллүр каләм» иясе була.

2001 елда Идел-Пресс нәшриятында якташы, шагыйрь В.Фатыйховның сүз башы белән «Бүген ярат!» шигырьләр тупланмасын һәм олы жанрда беренче тәҗрибәсен – нәсел мөнәсәбәтләренә багышланган «Чулпы җыры» поэма-хатирәсен тәкъдим итә. Мәҗмуганы тәнкыйтьче «туган якны, дусларны, тугрылыкны, чын мәхәббәтне үз итәргә чакыру», дип бәяли[1].

Тәүге олы лиро-эпик тәҗрибәсендә иҗатчы бик күп тырыш, хәлле кешеләр тормышын пыран-заран китергән 1917 ел түнтәрелешен рәнҗеп искә ала. Алар

[1] Рәсимә Гарифуллина. Бүген ярат! Казан, 2001. – Б. 3-5.

ыруының бөлгенлеккә төшерелгән бер вәкиле Бибихәсәнә сигез баласы белән урамда калса да, үзен раслау һәм яшәү өчен тартышуны дәвам итеп, каенатасы Нәҗметдин ярдәмендә кул көче белән иске, ташландык тегермәнне аякка бастыра, аның мал-мөлкәтен юкка чыгарып, элеккеге хәерче хәлләренә кайтып төшкәннәргә дә ярдәм кулын суза. Ул чордагы илдә хөкем сөргән башбаштаклыкка бәя биргән ике юллыгы тәгәллеге белән «әхлак дәресе» кебек кабул ителә.

*Манаралар кисеп, кеше талап,*
*Бәхетләрне табып булмый ул.*
«Чулпы җыры».

Р.Гарифуллина чал тарихлы татар шигъриятенә «Чулпы җыры» поэмасы, «Әниемә», «Әткәйгә», «Фәрвазга», «Гөлнурым – күз нурым» кебек йөрәгеннән ургылып чыккан самими аһәңле, хисси гадилекләре илә әсир иткән багышлаулары, «Гашыйклар күзе», «Хыянәт нишләтә», «Ярата алу өчен дә», «Битарафка теләкләр» кебек сөю-сәгадәт, мәхәббәт парчалары белән килеп керә. Тәүге шигырьләр китабының кискен, каршы әйтерлекне калдырмаган «Бүген ярат!» дигән «әмере» икенче җыентыкның исемендә үк «чишелешен» таба. «Минем куллар синең кулда» дигән (2005) җыентыгының туган якка, хатын-кызга, сөю-сәгадәткә багышланган шигырьләрендә үзен иҗатка алып кергән ихласлыгын, табигыйлеген, «тәмле телен» саклау өстенә яшәешне, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кабул итү юнәлешенең үзәк бер тенденция буларак үстерелеше сизелә. «Әрәм узган гомер», «Фикер», «Көчсезлектә – көч» кебек фәлсәфи рухлы шигырьләрендә ул тормышның кыскалыгын искә төшерү аша хатын-кызның җан сафлыгын саклавын мәхәббәткә тугрылыгында һәм, шул хис уянганда, көчсезлегендә күрә. «Фикер» газәлендә ул «көч-көчсезлек» мәүзугын психологик тирәнлек һәм нечкә шигъри күзәтү аша ачуга ирешә. «Бинибая сөюдер хатын-кызның көчлелеге» дигән фикерен калкыта да, «акылына килеп», «Сүнми торган сөюдәдер хатын-кызның көчсезлеге», дип, дөньяны түгәрәкләп куя.

Үз шәхесен ул әүвәл каршылыклы хисләр бердәмлегеннән тукылган зат итеп сурәтли:

*Мин күп төрле була алам:*
*Кояш сыман якты янам,*
*Йә иркәлим, ачуланам,*
*Гөләп төсле чәнчеп алам.*
«Мин».

Укучы нишләп әле ошбу зат үзенең төрле булуы белән масая дип, нәтиҗә ясап өлгергәнче, «була алмыйм икейөзле» дип, асылына кайта.

*Кадеремне белмәсәләр,*
*Карчыгадай усалланам.*
*...Нинди халәт кичерсәм дә,*
*Һәрчак үзем булып калам.*
«Мин».

Шагыйрә кеше халәтенең рухи асылының төрле күренеш-чагылышларын күзәтә һәм нәтиҗәсен шигъри тел белән әйтеп бирү сәләтенә ия. «Сөю», «Мәхәббәт илендә», «Билгесезлек» тезмәләре иң олы хисне нечкә тоемлау белән сурәт үзәгенә алулары илә күңелне җәлеп итәләр. Әмма әдибә саф лирик әсәрләрендә дә интим мөнәсәбәтләрне, шатлыклы вә сагышлы мизгелләрне сурәтләү чикләрендә генә калмый. Милләт гамен үзәккә алган, аның югалтуларын гарьләнеп, хәтта «үпкә» белдереп язган шигырьләре дә публицистик рухы белән «бөтереп» ала.

*И сез, минем газиз татарларым,*
*Үз телендә сөйли алмаган,*
*Көен җуйган сандугач хәлендә*
*Башка кош көенә сайраган.*
«Татарларым».

Әлеге шигырь урнаштырылган мәҗмуга Татарстанның халык шагыйре Р.Гаташның «Дөнья йөге – нәфис иңнәрдә» исемле тәкъдимнамәсе белән ачыла. Рәсимә Гарифуллина китабының исемен юкка гына «Дөнья йөге» дип атамаган: таныш аңа, бик таныш аңа бу заманнарның үзгәрешле, афәтле чорларыбызның йөкләре»[2]. «Күңел дулкыннары», «Халәт» кебек бүлекләре һәркайсыбыз үзе генә тоеп яшәгән рухи дөнья нечкәлекләре турында уйланырга чакыралар. «Сөю шаяру түгел» дигән кисәтүгә «Бәхет серле төшенчә»гә кергән шигырьләре ачыкламыш бирәләр. «Дөнья» сүзен үзәккә алган публицистик гөманны милләт хәсрәтен уртаклашкан, һәр кешенең кыйммәте, хокукы турындагы фәлсәфи уйланулар тулыландыралар. «Дөнья йөге» җыентыгында күп мәгънәле «дөнья» сүзе дистәгә якын шигырьнең атамасына ук чыгарыла: «Якла, дөнья», «Дөнья йөзе», «Дөнья, син нинди?», «Дөнья шундый» кебек фәлсәфи әхлакый рухлы сөземтәләрендә хакыйкатьне автор каршылыклар бердәмлегендә эзли. «Дөнья шундый» шигыренең сөземтәсе тәшвишкә салырлык:

*Байлык, куанычлар кирәк түгел,*
*Үлем тарткан чакта чабудан.*

«Дөнья шундый».

«Умарта күчедәй дөнья» шигыре исә кешегә яшәү мәгънәсен аңлатып, тынычландырып, тигезләп куя.

Тормыш тәҗрибәсе ифрат бай Р.Гарифуллина каләмен төрле жанрларда чыныктырса да, ул – табигате, булмышы белән лирик шагыйрә. Ул нечкә хисләрне үзәккә алган әсәрләрендә дә сак телле, төгәл һәм кителмәгән сынландыруларга мөкиббән киткән иҗатчы булып кала. Гаҗәеп кызыклы, үзенчәлекле чишелешне тәкъдим иткән «Кайтавазы үткәннән» тезмәсен игътибарсыз калдыра алмыйм. Ни сәбәпле Чулман суда «дулкын уйный» кебек сорауга күбебез «җил купкандыр», яисә «көймә узгандыр» дигәнрәк җаваплар идек. Ялгышабыз икән шул: дулкын «Акчарлаклар үпкәннән» шулай «хафалана» икән. Ә акчарлакның шулай дәртләнеп үбүенең сере тирәндәрәк ятканы ачыклана.

*Сагышлары – җан авазы,*
*Кайтавазы – үткәннән.*

«Кайтавазы – үткәннән»

Шагыйрь мәхәббәт, сөю-сәгадәт, шәхес язмышы, табигать яме турында моңсу уйланулар даирәсендә генә калса да, абруйлы лирикларыбызның берсе булыр иде. Тынгысыз каләм иясе эзләнүләрдән туктамый. Әүвәл ул көчен сюжетлы, эпик оеткылы шигырьләрдә сынап карый. «Дөнья йөге» җыентыгындагы «Семинар», «Утырыш», «Отчёт җыелышы», «Яманнан яхшы көчле», «Авыллар картая» кебек күләмле шигырьләрендә вакыйгалы манзара өстенлек итә. Каләмен сюжетлы шигырьләрдә чыныктырганнан соң, тезмәдә әйтеп бетермәгән уй-фикерләрен прозаик әсәрләренә ышанып тапшыра. Аның сугыш һәм аннан соңгы чорны үзенчә бәяләгән «Кызыл капкалы йорт» документаль бәяны, чын сөюгә, мәхәббәт маҗараларына, хәтер һәм хыянәткә, мәңгелек хисләрне сурәтләүгә багышланган «Адашкан», «Ялкын ярлыкамый», «Мәхәббәт кичерәме?», «Ник кайтмыйсың?», «Пароходлар елаганда», «Зәңгәр дуга» бәяннары, «Туган ягым – Балык Бистәсе» бәйләмәнә тупланган әдәби-сәяси уйланулары махсус сөйләшүгә лаеклы тәҗрибәләр.

Соңгы елларда әдәбиятның чәчмә төренә игътибарны арттыруыңны хуплаган хәлдә, иҗатчыны үпкәләтмичә генә, «прозаң әлегә шигъриятең, бигрәк тә лирикаң белән бил алышырлык сыйфат дәрәҗәсендә тормый» дип, әмма бу төрдә дә өслүбеңне эзләп, үз әдәби-иҗтимагый мохитеңне тудыруыңны һәм чәчмә төрдә дә шигъри җанлы булып калуыңны телим.

«Әдипләребез» (2009) белешмәлеге Р.Гарифуллинаның «Шәҗәрәсе буенча элек тә җир-сулар биләп торган, мал-мөлкәтле нәселдән булуын» искә төшерә.

[2] Рәсимә Гарифуллина. «Дөнья йөге» – Казан, Тат. кит. нәшр. 2010. – Б. 3.

Шагыйрә үзенең дә бу хакта хәбәрдар булуын искәртә: «Нәсел шәҗәрәсенең Чыңгыз, Үзбәк, Бирдебәк ханнарга бәйле булуы турында мин дәү әнием Бибимәрьям һәм бабам Гарифулладан ишеттем»[3].

Табигый ки, аның төрле жанрлардагы иҗади эзләнүләрен берләштергән үзәк – халык, милләт язмышларына барып тоташкан ыру, нәсел, туганлык җепләре, шул изге төшенчәләргә мөнәсәбәте ята. Аның күңел сызлануының нигезен иҗтимагый вазгыятьләр, беренче чиратта халкының киләчәге турында борчулы уйланулар били.

Яңа гасыр татар әдәбиятына кешене иң кадерле байлык итеп күтәргән лирик шигырьләре, җырлары, журналистлык хезмәте белән бәйле публицистикасы белән килеп керсә дә, Р.Гарифуллинаның таланты бер-бер артлы диярлек басылып чыккан, дөнья барышының сикәлтәле булуын искәртеп, нәсел-нәсәбенең олы язмышлы кешеләрен – йолдызларын һәм тарихи вакыйгаларны үзәккә алган «Чулпы җыры», «Гомер белән гомер арасы», «Ак Сарайда серләр бар» һәм аеруча «Чаллы җире – шанлы җир», «Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» поэма-кыйссаларында тирәнрәк ачыла.

«Ак Сарайда серләр бар» – җиденче буын бабасы Юлдаш хәзрәтнең «Хан ярлыгы Ак Сарайда, саклагыз!» дигән васыятен үтәү рухы белән язылган һәм эчкерсезлеге, үткәннәребезне олылавы һәм медитатив өслүбе белән күңелләрне үсендерә торган кыйсса.

Татар тарихының иң хәвефле бер чорын үзәккә алган, сәнгатьчә эшләнеше җәһәтеннән дә игътибарга лаеклы күләмле шигъри әсәрләренең берсе, һичсүзсез, «Чаллы җире – шанлы җир» поэмасы. Әсәрдә сүз хәзерге Балык Бистәсе урнашкан төбәктә «яшәп» алган Чаллы ханлыгы язмышы турында бара. Берләшмәнең ханы итеп Мәскәүгә коллыкка озатылган Сөембикә ханбикәнең энесе Гали Әкрамны сайлап куялар. «Серле риваять» бүлегендәге юллар шул хакта.

*Бер риваять яши югалмыйча:*
*«Ханлык булган монда, шәһәрлек*
*Гали Әкрам булган соңгы ханы»*
*Асыл тарих яши*
*Яшәрлек...!*

«Чаллы җире – шанлы җир».

Кодрәтле чакларында Казан ханлыгы хакимнәре, биләре оеша гына килгән Чаллы кирмәнендә үзләренә көндәш күреп, аны төрлечә кыерсытканнар. Казан ханлыгы көл-күмергә әйләндерелгәч, аның исән калган сугышчылары, дин әһелләре, зыялылары Чаллы ханлыгына килеп сыенганнар.

Гаскәр башында кыю, курку белмәс, оештыру сәләтенә ия Мәмешбирде торган. Иҗатчы аны һәрьяктан килгән, халкыбызга хас иң җете сыйфатларга ия җитәкче итеп тасвирлый.

1556 елга чаклы Казанны кайтару, Болгарны торгызу рухы белән яшәгән Чаллы ханлыгы Явыз Иван гаскәрен күп тапкырлар куып җибәрә. Дошман ханлыкны буйсындыра алмаячагын аңлагач, мәкер юлына барып, Мәмәшбирдене сөйләшүгә, хәтта кунакка чакыра. Татар – ышанучан, ихлас халык. Нибары 200 сакчысы белән юлга чыккан Мәмәшбирдене Ослан тауларында, урманда качып торып, «Суй татарны, юкка чыксын, юк татар дигән милләт» кебек сүзләр белән барысын да кылыч аша уздыралар. Мәмәшбирдене Мәскәүгә алып барып җәзалыйлар. Поэма авторы әлеге югалтуны тарихи фаҗига итеп бәяли. Төп таянычы Мәмәшбирдесез калган хан Гали Әкрәм үзен «Җәтмәгә эләккән балык күк, чыгу чарасын күрми», ә Мәскәү тагын яу чаба. Менә шул тарихи-хәрби, милли-дини вакыйгалар, берәүләрне рәнҗетү, сыту исәбенә икенчеләренең баюы, киләчәген тәэмин итүе «Чаллы җире – шанлы җир» поэмасының тәнкыйди юнәлешен һәм композицион үзенчәлеген билгели. Төбәк тарихчысы Н.Гариф «бу әсәрдә борынгы Чаллы төбәге һәм аның үзәге булган Чаллы шәһәрлегенең шанлы вә данлы тарихы эпик югарылыкка күтәрелгән» дигән бәян-фикере белән уртаклаша[4].

[3] Р. Гарифуллина. Яшәү мәңгелек – Казан, «Идел-пресс» нәшрияты, 2004. – Б. 65.
[4] К.Гыйләҗ, Р.Гарифуллина. Йолдызлар юл күрсәтер. – Казан: «Школа», 2009. – Б. 42.

Кыйссаның төп үзенчәлеге югалтулар тудырган экзистенциаль сагыш, мөстәкыйльлек өчен көрәштә берләшә алмаган бабаларыбызга үпкә белдергәндә дә, гаепне аерым шәхесләргә кайтарып калдырмау рухы – авторның киң күңеллелеге касәфәте. Иҗатчы төрле чыганаклардан тупланган сәхифә-истәлекләрне хыял көче, лирик чигенешләр белән тулыландыра. Аерым алганда, Чаллы ханлыгы турындагы бәянын тәфсилләүгә керешкәнче, ул «чын риваять» сөйләүче җилләрне тыңлап, нәсел шәҗәрәсенең чишмә башын эзли.

Тарихыбыздагы иң олы югалтуларның берсен үзәккә алган «Чаллы җире – шанлы җир» кыйссасы белән авторны котлап, лирик чигенешләр, гомуми уйланулар исәбенә әсәрнең күләмлерәк чыгуын искәртеп, бер «глобаль» фикере белән килешмәвемне әйтми калдыра алмыйм.

*Хакимнәр тагын алмашты,*
*Үткәнгә кадер арта.*
*Гаделлек урнаштырыла,*
*Тарих халыкка кайта.*

«Чаллы җире – шанлы җир».

Мондый «кыю – тәвәккәл» хөкемгә-нәтиҗәгә иҗатчы кайсы чорны күздә тотып килгәндер, мәгәр аның белән килешә дә, соклануына кушыла да алмыйм. Их, аз булса да, телебез кысылмаган, милләтебез иркен яшәгән, «гаделлек урнаштырылган» илдә яшәп каласы иде дигән теләк күңелне тырный.

Р.Гарифуллинаның эчтәлеге, жанрлык хасиятләре тарафыннан «вакыт» вә «яра» белән санашмаган «Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» әсәре[5] турында гәп корганчы бер аңлатма-чигенеш ишеккә кага. Һәр шәйнең нәзари асылы булган шикелле Мөнәҗҗим образының татар шигъриятенә үтеп керүенең дә сере бар. 2009 елда «Школа» нәшриятында басылып чыккан «Йолдызлар юл күрсәтер» җыентыгының авторлары Р.Гарифуллина һәм аның ире, шулай ук Балык Бистәсе районының Яңа Сала авылы егете Кыям Гыйләҗ – язмышларны, киләчәкне йолдызлар хәрәкәте буенча өйрәнүче үзешчән астролог. Әлеге җыентыкта аның «Мөнәҗҗим – сарай астрологы», «Җөзе яки тамгалар телендә сөйләшәбез» кебек фәнни-популяр мәкаләләре урнаштырылган.

Р.Гарифуллина «Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт» әсәрен чәчен тараучы Су кызын һәм Казаныбызның символы Сөембикә манарасын искә алу белән башлап җибәрә. Мәҗүси аң төпкелендә бөреләнеп, игътибар көтеп яткан һәм Тукайның «җиңел кулы» белән шигъри кодлар дәрәҗәсенә күтәрелгән Су анасы, Шүрәле, Кисекбаш кебек мифик затларны иҗатында әйләнеп узган татар шагыйре юктыр.

*Сөембикә, манараңның*
*Ае суларга карый.*
*Ай нурында йөзә-йөзә*
*Су кызы чәчен тарый.*

«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт».

Шул идиллик, күңелләргә талгын тынычлык, рухи таяныч бөркеп торган юллар, татар шигъриятенә мифик образны алып керергә һәм шуңа бәйле рәвештә татар тарихының иң фаҗигале бер чорын – дәүләтчелегебезне югалтуны һәм Сөембикәне коллыкка төшерүне сурәт үзәгенә алырга мөмкинлек бирә. «Сугышны булдырмас өчен Бәкләр солых төзегән», «Сөембикә – ханбикәгә илдә ризык өзелгән», дигән авыр соравын лирик зат Мөнәҗҗимгә мөрәҗәгать алымында әйтә:

*Мөнәҗҗимгә сорау бирәм*
*Моны аңлап буламы?*
*Патшасын саклый алмаган*
*Халык милләт буламы?*

Яклаучысыз калган Казан ханлыгының егылачагын, гүзәллек, кыюлык, халкына

[5] К.Гыйләҗ, Р.Гарифуллина. Йолдызлар юл күрсәтер. – Казан: «Школа», 2009. Б – 23.

бирелгәнлек үрнәге булган Сөембикәне үз илендә калдыру кирәклеге турында кисәтмәгән өчен авторның Мөнәҗҗимгә дәгъвасы зур. Чөнки ул «кыпчак, болгар-татарларның алда ни күрәчәген» һәм бигрәк тә 1552 елда булачак фаҗигане сизенгән, әмма чаң сукмаган.

Поэманың үзәк композицион алымы – шартлылык, ягъни вакыйгаларны төрлечә бәяләргә мөмкинлек биргән икеләтелгән проекция. «Ваемсызлыгы» өчен әүвәл автор Мөнәҗҗимгә үпкәсен белдерсә дә, таркала барган илнең язмышын үзгәртеп булмаячагын аңлап чаң сукмагандыр дип, аны аклап та куя.

Мөнәҗҗимнең милләт язмышына битарафлыгына ватанпәрвәр «олан» ярсый, тузына, әмма ахыр чиктә, ошбу халәттә үзенең чарасызлыгын аңлап, аны акларга мәҗбүр була. Ул да явызлыктан җәфа, низаг күргән икән ләбаса.

*Мөнәҗҗимнең кисек башы*
*Миңа җавап бирмәде.*
*Бөтен серен үзе белән*
*Мәңгелеккә җирләде.*
«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт».

Күләмле яисә вакыйгалы эчтәлекле әсәрләрендә сюжет өлгесе тормышчан яисә хыялый булып, Р.Гарифуллина ни нәрсә турында язса да, үз-үзенә уйланса да, эчке мантыйкъ тәгәрмәче милләт язмышына, мөстәкыйльлекне югалту фаҗигасенә алып чыга. Шунда публицистика һәм беркадәр кызылга буялган оптимизм ярдәмгә килә:

*Бу җиһанга килүеңнең*
*Мәгънәсе аныкмы соң?*
*Син шушы өметне аклар,*
*Ватаның горурлыгына*
*Тиң булыр халыкмы соң?*
«Мөнәҗҗимгә – мөнәҗәт».

Автор әсәрләренең мантыйкый өлгерешенә һәм сәнгати үсешенә күз салсаң, даими эзлекле рәвештә караш-бәяләренең камилләшә килүен күрәсең. Белем, төрле фәннәрдән хәбәрдарлык, күп еллык журналистлык тәҗрибәсе шәхеснең зиһенен генә түгел, холкын-фигылен дә үзгәртә, баета.

Туган телебезнең мөмкинлекләрен иҗади үстерү юнәлешендә дә шагыйрә үзенә гаять таләпчән. Аның каләменнән төшкән «Ир сынатса, ил сынала», «Әйтер сүзе булса да, тешен кысып тын калган», «Без бурычлы горур халык булып, Горур Татар булып яшәргә» кебек мәкаль-әйтемнәргә якын яисә шулар рухындагы төгәл гыйбарәләр шактый аның иҗатында.

Агымдагы елның апрель аенда гомеренең бер өлешенә йомгак ясарга җыенган Рәсимә Гарифуллина туган халкының рухи дөньясын, данлы вә фаҗигале тарихын, четерекле хәзергесен, киләчәккә юнәлгән өмет-хыялларын сүз-образларга төреп бирү рухы белән яши. Аның тезмә һәм чәчмә әсәрләрендәге уңышларын табигый талант, белем, шәхес буларак җитлеккәнлек өстенә йөрәге, җаны, бөтен барлыгы милли нигезгә тоташкан булуы һәм фикерләү киңлеге, фәлсәфи тирәнлеккә омтылыш бизи. Җырга, моңга һәвәс шәхесебезнең шигърият чишмәсе саекмасын, рухи дөньясының яңадан-яңа кыйтгаларын ачып, укучыларын сөендерүне дәвам итсен! Йөрәгеннән ургылып чыккан «Сәгать суккан саен берләш, татар! Илгә иңсен бәхет, сәгадәт», дип нәзер әйтеп язылган әсәрләре милләтебезгә яшәү дәрте иңдереп торсыннар! Иншалла!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы*

# АЗӘРБАЙҖАНДАГЫ ТУКАЙЧЫ-ГАЛИМ

Көтмәгәндә таныштык без. 2018 елны Бакуга, Азәрбайҗан милли фәннәр академиясенең Низами Ганҗәви исемендәге Әдәбият институты юбилеена багышланган халыкара фәнни конференциягә килгән идек. Иртән пленар утырышка дип, Академиягә аяк басуга, элекке танышлар белән күрешү, яңа дуслар табу, белешү-сөйләшү башланды. Башта – бер галимә, аннары – икенчесе, аннары өченчесе зур горурлык белән үзләрендә татар галиме эшләгәнлекне әйттеләр. Бөтенесе белә, димәк, татар булуын яшерми; бөтенесе белә, димәк, ихтирам итәләр, дигән уй сызып үтте.



*ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Исмехан Госманлы белән Тукай һәйкәле янында.*

Рәсми котлаулар өлеше төгәлләнеп, тәнәфескә туктауга, үзе дә безне эзләп тапты. Татардан бигрәк, азәри кыяфәтле, чыннан да, тамырларында төрле милләтләр каны ага икән. Исмехан Госманлы – филология буенча философия фәннәре докторы (Азәрбайҗан Европа атамаларына күчкән), диссертацияләр яклау советының гыйльми сәркатибе, Әдәбият институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, урта гасырлар төрки әдәбиятлар белгече...

Әбием татар, әбиемнең әтисе Шәрип Хәлилов зур гаиләсе белән Казаннан (бәлки, Казан тирәсеннән) шушында килеп төпләнгән булган, дип ачыклап алды. Озын буйлы, мәһабәт Шәрипне «Казан татары» дип йөртәләр. Әбисе Фатыйманың гаиләдә гыйлемгә, тәртипкә, тәүфыйкка юнәлтеп яшәвен дә әйтергә онытмады. Шунда ук урта гасырлар татар мәдәнияте, Тукай иҗаты турында сөйләшергә кереште. Бу кешенең тирән белемле, гаять мәгълүматлы булуы гаҗәпкә калдырды.

Татарның бәхетне читтән эзләве – гаҗәеп бер күренеш бит. Ни өчен Казаннан – Кавказга киткәннәр, дигән сорауга да ул бик гади аңлатма бирде: әбиемнең әтисе бай һәм көчле нәселдән. Әмма бертуганнар арасында мирас низагы чыккач, ул үз гаиләсен алып, читкә киткән, диде. Димәк, эзләгәндә, нәсел тармагын табарга да буладыр.

Аның биографиясендә гаҗәпләнер урыннар күп булып чыкты. Исмехан әфәнде – гомеренең шактый өлеше узгач кына, гуманитар фәнгә килгән, әмма тиз арада төрки дөньяда абруйлы белгеч булып җитешкән.

Исмехан Мөхәммәт углы 1959 елның 1 июнендә Әрмәнстандагы Спитак районы Сарал авылында туган. Азәрбайҗан политехника институтын «5» легә генә тәмамлап, нефть чыгару һәм эшкәртү юнәлешен сайлый. Озак еллар инженер, цех башлыгы, бүлек җитәкчесе булып эшли, бу өлкәдә уңыш казана: аның 48 рационализаторлык тәкъдиме сәнәгатьтә кулланылышка керә.

Әмма кечкенәдән төрки халыкларның тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынган егет буш вакыт булуга, китапханәләргә барып, үзлектән борынгы төрки телләрне, урта гасырлар төрки мәдәниятен өйрәнү белән шөгыльләнә.

1991 елның 18 октябрендә Азәрбайҗан мөстәкыйльлек ала, бу вакытта, бик күпләрнеке кебек, Исмехан әфәнденең дә тормышы тамырдан үзгәрә. Ул үзен кызыксындырган филология фәне белән шөгыльләнергә дигән карар кабул итә.

Беренче хезмәтләре мәдәни-тарихи чыганак буларак, угыз-намәләрне өйрәнү белән бәйле була. Башлап, ул Җучи нәселе дәвамчысы булган Хива ханы Әбелгази Баһадур ханның (1603–1664) төркиләр тарихына караган хезмәтенә мөрәҗәгать итә. Мәгълүм ки, хан ике зур хезмәт яза: «Шәҗәрә-и теракиме» («Төрекмән тарихы», 1659–1661) һәм «Шәҗәрә-и төрки» («Төркиләр тарихы», 1663-1664). Аларда Үзәк Азия һәм Якын Көнчыгыш җирләрендә XIII–XVII гасырларда, Чыңгыз яуларына кадәр һәм аннан соң булган вакыйгалар тасвирлана, төркиләрнең борынгы ыру-кабиләләре, көнкүреше, мәдәнияте турында сөйләнә. Татарларга бу китапларның икенчесе яхшы билгеле: 1905 елны Казан университеты типографиясендә Г.С.Саблуков әзерләгән вариантта басылганнан соң, фәнни әйләнешкә керә.

Исмехан әфәнде Әбелгази Баһадур ханның беренче китабының төп нөсхәсеннән өзекләрне һәм А.Н.Кононов 1958 елны рус теленә тәрҗемә иткән версияне чагыштырып, төрекмән халкына үзләренең дастаннарда, мифологик аңда сакланган борынгы тарихын кайтарып бирә. Хезмәт «Абелгази Баһадур хан. «Шәҗәрә-и-теракиме»» исеме белән Бакуның «AME» NPB нәшриятында 2002 елны басылып чыга, тәрҗемәче, кереш сүз авторы, шәрехләү-комментарийларны һәм библиографияне төзүче И.М.Госманлы була.

Галим аннары өйрәнү объекты итеп сайлаган хезмәт тагын да борынгырак: Фазлуллах Рәшид әд-Диннең (1247–1318) «Җәмигъ әт-таварих» («Тарихлар җыентыгы») китабында XIII–XIV гасырларда төрки-угызлар тарихы дөнья барышы контекстына бәян ителә. Әлеге тарихларның берсе угыз кабиләләре тармагының үткәнен тергезгән «Угыз-намә» шәҗәрәсен сөйли. Төрек теленнән тәрҗемә итеп, шәрехләү-комментарийлар язып һәм библиография әзерләп, И.Госманлы 2003 елны Бакуның «AME» NPB нәшриятында «Рәшид әд-Дин. Угыз-намә» дигән хезмәт бастырып чыгара.

Аны басмага әзерләгәндә, И.Госманлы Зәки Вәлидинең фарсы теленнән төрек теленә тәрҗемәсеннән (1972) файдалана, китапның тышлыгына да З.Вәлидинең якты истәлегенә багышлана дигән сүзләр урнаштыра. Зур тиражлар белән үз хисабына нәшер иткән бу китабын галим барлык китапханәләргә һәм уку йортлары кафедраларына бүләк итеп тарата.

И.Госманлының әлеге хезмәтләре гаять зур иҗтимагый-мәдәни әһәмияткә ия була. Чөнки алар СССРдан аерылып чыккан ике зур төрки халыкка үз тарихларының дастани нигезен кайтара, узган юлларының бик борынгы чорларына реконструкция ясарга юл ача. Галимнең шәхси һөнәри сыйфаты – дөнья буйлап архив һәм китапханәләрдә төрки кульязмаларны барлау, үзендә булдыру, чыганакларны үзе кулга тотып, һәр сүзен укып һәм аңлатып, тирән анализ ясап эшләү борынгы тарихи хезмәтләрне заман югарылыгында фәнни әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирә.

Аннан соң да галим бу теманы читкә куймый. 2005 елны Бакуның «Ulu» нәшриятында «Угыз-намә» текстының шигъри версиясен бастырып чыгара. 2016 елны академик Теймур Кәримле (бүген Академиянең М.Физули исемендәге Кульязмалар институты генераль директоры) җитәкчелегендә «Төрки халыклар әдәбиятлары» белгечлеге буенча ««Угыз-каһан турында хикәят»тә әдәби-мифологик мотивлар» дигән темага диссертация яклый. Угыз-намәләрнең 6 кульязмасын нәшер иткән галим бүген борынгы уйгыр әлифбасында язылган, бердәнбер нөсхәсе Париж Милли китапханәсендә саклана торган «Угыз каһан дастаны»н басмага әзерли.

Төрки әдәбиятларда дастани традицияләрнең ничек дәвам иткәнлеге турында эзләнүләр галимне мәшһүр төрекмән шагыйре, тарихчы, философ, тәрҗемәче Нурмөхәммәд-Гариб Гандәлиб (1710/1711 – 1770/1780) иҗатына алып керә. Төрекмән шигъриятенең беренче шагыйре иҗат иткән «Угыз-намә» текстын азәрбайҗан теленә

тәрҗемә итеп, И.Госманлы аны 2010 елны Бакуда, «Ulu» нәшриятында дөньяга чыгара. Бер ел узуга, «Мөтәрҗим» нәшриятында Нурмөхәммәд Гандәлибнең сайланма әсәрләре – лирик шигырьләре, поэмалары 1 нче том буларак, 2 нче томда исә «Йосыф белән Зөләйха», «Ләйлә һәм Мәҗнүн» әсәрләре азәрбайҗан телендә дөнья күрә. Бу хезмәте Азәрбайҗан Журналистлар берлегенең «Алтын каләм» бүләгенә лаек була.

Шул ук елны Исмехан әфәнде тагын бер шагыйрь – Баяти Гасан Мәхмүд оглының әсәрләрен азәрбайҗан теленә тәрҗемәдә укучыга җиткерә. 2014 елны исә Бакудагы «Элм и Тахсил» нәшриятында Мәхтумкули Фрагиның (1724–1807) азәрбайҗан телендә сайланма әсәрләре (400 шигырь һәм берничә поэма), 2014 елны Азәрбайҗан кулъязмалар институтында табылган, бердәнбер нөсхәдәге «Диван»ы тулысынча әзерләнеп һәм комментарийлар белән бастырыла (бу урында М.Фрагиның кулъязмалары татарлар арасында, бигрәк тә Әстерхан якларында экспедицияләрдә йөргәндә еш очрауны, әсәрләренең иң тулы репертуары Казанда саклануны әйтеп үтү И.Госманлы хезмәтләренең бүгенге татар фәне өчен дә кызыклы һәм файдалы булуын искәртер).

Әлбәттә, төрекмән һәм азәрбайҗан мәдәниятләренең уртак тирән тамырларын, мәдәни бәйләнешләрне барлауга багышланган мондый хезмәтләр һәр ике як тарафыннан да җылы кабул ителә. Әйтик, 2014 елның маенда, бөек төрекмән шагыйре һәм философ М.Фрагиның 290 еллыгын бәйрәм итү кысаларында, И.Госманлы әзерләп бастырган китаплар уникаль басмалар дип зурлана, Төрекмәнстан Президенты Указы белән галимгә «Мәхтумкули Фраги» медале тапшырыла.

Галимнең төрки дөньяда шау-шу тудырган ачышы хакында без 2018 елны «Казан утлары» журналы укучыларына хәбәр иткән идек. Фәнни мәкалә булып ул «Казакъстанның Ыссык курганында табылган көмеш касәдәге сак-прототөрки рун язуы» исеме белән дөнья күрә. Анда 1970 елда табылган, безнең эрага кадәр VI–IV гасырларга карый дип исәпләнгән көмеш касәдәге язу укып күрсәтелә. Әлеге мәсьәлә 2014 елны Олжас Сөләйманов тырышлыгы белән ЮНЕСКОда фикерләшүгә чыгарыла һәм дөрес укылыш дип таныла. Бу зур уңыш Исмехан әфәндене язманың калган 2 юлын укып бирергә илһамландырсын иде.

Борынгы әдәбият белән шөгыльләнүдән тыш, И.Госманлы татар мәдәнияте белән профессиональ дәрәҗәдә кызыксына. Ул борынгы төрки-татар теленә, татар халык авыз иҗаты һәм тарихи-мифологик күзаллауларына, дастаннарына кагылышлы аерым темаларны күтәрә. Әмма иң зур, еллар буе максатчан эшләп килгән темасы – төрки мәдәниятләр янәшәлеге контекстында Габдулла Тукай иҗаты. Аның бу юнәлештә эзләнүләре шагыйрьнең тууына 135 ел тулуга багышлап, Азәрбайҗан Милли гыйлемнәр академиясе Бакуда нәшер иткән, Азәрбайҗан академиясенең президенты И.Габиббәйле һәм И.Госманлы тарафыннан язылган «Тукай һәм Азәрбайҗан» (Баку: Гыйлем вә тәхсил, 2021. 536 б.) китабында чагылыш таба.

Ике телдә – азәрбайҗан һәм рус телләрендә язылган китапта Габдулла Тукайның Азәрбайҗан вакытлы матбугаты, әдәбияты, аерым шәхесләр белән мөнәсәбәтләре, шулай ук Тукай әсәрләренең һәм мирасының тугандаш илдә ничек өйрәнелүе, саклануы мәсьәләләре күтәрелә. Хезмәт өр-яңа тарихи, мәдәни мәгълүматларга бай, ул Татарстандагы Тукайны өйрәнү фәнендә моңа кадәр аз билгеле чыганакларны фәнни әйләнешкә кертә.

Чыганаклар дигәннән, китапта кулланылган әдәбият исемлегендә азәрбайҗан телендә – 140, русча – 77 һәм татарча 38 хезмәт китерелгән. Шулардан, бигрәк тә, азәрбайҗан телендә нәшер ителгәннәренең татар укучысына бөтенләй диярлек мәгълүм түгеллеген әйтергә кирәк. Анда Тукайга кагылышлы махсус эзләнүләр алып барган профессорлар Пәнах Хәлилов, Азиз Шәриф, Азиз Мирәхмәдов, Мәмәд Араз, Манзар Ибраһимова, Вилаят Гулиев, Манзар Хәсәнова, Паша Кәримов, Низами Тагисой, Алмаз Үлви, Ариф Мәмәдов, Эшканә Бабаева, шагыйрь һәм тәрҗемәчеләр Хәлил Рза Олытөрк, Анар, Рәмиз Әскәр, Хураман Һүммәтова, Сабир Рөстәмханлы,

Мәмәд Казыйм һ.б. бик күп зыялыларның шушы олы эшкә керткән өлеше җентекләп анализлана һәм бәяләнә. Бу материал Азәрбайҗанда Тукайны өйрәнү фәненең барлыгын, зурлыгын дәлилли.

XX гасыр башы матбугатын күзәткәндә, китапта көтелмәгән нәтиҗәләр хасил була. Тукайның төрки дөньяда мәшһүр вакытлы матбугат басмалары («Тәрҗеман» (Бакчасарай), «Җөмһүрият» (Париж), «Төрек» (Каһирә), «Төрек йорды» һәм «Каракүз» (Истанбул) һ.б.) белән бәйләнешләре, иҗади фикерләвенә, мәдәни мохиткә Азәрбайҗанда нәшер ителгән «Иршад», «Фиюзат», «Икъбал», «Тәкаммел» һ.б.ның тәэсире мәсьәләсе, татар галимнәре тарафыннан кагылып-кагылып үтелсә дә, бүген әле үз тикшеренүчесен көтә. Әйтик, Уральскидан Казанга килгәндә, Тукай «Молла Насретдин»нең укылган саннарын үзеннән калдырмаган. Яки «Молла Насретдин», «Хаят» традицияләре 1905 елдан соң кинәт күтәрелгән татар сатирик басмалары «Уклар», «Ялт-йолт», «Яшен» һ.б. эчтәлегендә, бизәлешендә һ.б. аермачык сизелеп тора. Тукай иҗатында төрки дөньяның мәгълүм каләм әһелләре, бигрәк тә Мирза Алиәкбәр Сабир, Җәлил Мамедгулузадә кебек шәхесләр фикерләре белән «сөйләшү»-диалог та үзара багланышларның без күзаллаганнан тирәнрәк, куәтлерәк булганлыгы турында сөйли. Яшь Габдулланы «Шәркый рус», «Хәят», «Тәкаммел» һ.б. басмалар белән танышу әдәбиятка, журналистикага тартты, диюләре белән хаклы булган хезмәт авторларының «Молла Насретдин» журналы татар шагыйренең сатирик фикерләү осталыгын формалаштырды дигән сүзләре белән дә килешмәү мөмкин түгел. Мондый сәхифәләр, гомумән, татар һәм азәрбайҗан багланышларын яңадан өйрәнергә, XX йөз башындагы тарихи-мәдәни яңарышка төрки дөнья киңлегендә әйләнеп кайтырга кирәклеген искәртә.

Шушы материал тагын да тирәнрәк эзләнүләргә юл ача: авторлар И.Габиббәйле һәм И.Госманлы шагыйрьнең 137 еллыгына «Габдулла Тукай һәм «Молла Насретдин»» монографиясен басмага әзерлиләр. Ул басылып чыккач, татар укучысына аерым сөйләрбез әле.

И.Госманлы Тукайны өйрәнү фәнендә татар галимнәре өзек-төтек кенә фикерләр әйткән, беренчел чыганакларны системалы өйрәнеп бәя бирү һаман да кичектерелеп торган тагын бер зур эшкә алына: ул төрек телендә нәшер ителгән сирәк китапларны, «Казан», «Кардәш каләмнәр» кебек журналларның барлык саннарын анализлап, Габдулла Тукайның төрек һәм төрки әдәбият белемендә урынын аңлатып-шәрехләп, «Габдулла Тукай һәм Төркия» дип аталган зур хезмәт-монография әзерли. Аның бер өлеше «Чагыштырма әдәбият белеме» халыкара журналның 2022 елгы 2 нче санында (44–52 бб.) ««Казан» журналында (1970–1980) Г.Тукай әдәби мирасын бастыру һәм өйрәнү» дигән исем белән дөнья күрде.

Бүген И.Госманлы Г.Тукайның поэмаларын азәрбайҗан теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Шагыйрьнең тууына 140 ел тулуга багышлап, аларны өч телдә, бик киң шәрехләүләр белән нәшер итәргә исәпли.

Шулай итеп, Азәрбайҗанда яшәп иҗат итүче Исмехан Госманлы, алар үзләре олылап әйткәнчә, Исмехан-мөгаллим эшчәнлеге татарны өйрәнү фәненең Татарстан, Казан белән чикләнмәвен, бөтен төрки дөньяда мондый гыйльми эзләнүләр алып барылуны тагын бер кат дәлилли.

2019 елдан И.Госманлы Тукай темасын академик эзләнүләренең төп темасы итеп тәгаенли. Күрәсең, аның өчен «туган җир» һәм «халык» төшенчәләре үзе беренче тапкыр 2019 елда килеп күргән Татарстан белән дә бәйледер: юкка гына тукайчы булып китмәгән бит! Без дә мондый галимнәрне күрә, аларның татар халкына бүләк иткән олы хезмәтләрен бәяли алсак иде.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# ЯҢАРЫШ ЧОРЫ ТӨРЕК ӘДӘБИЯТЫНЫҢ 1860–1917 ЕЛЛАР АРАСЫНДА ИДЕЛ-УРАЛ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА ЙОГЫНТЫСЫ

2015 елда Истанбул университетының әдәбият факультетында безнең тарафтан «Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860–1917 еллар арасында Идел-Урал татар әдәбиятына йогынтысы» темасына 439 битлек докторлык диссертациясе якланды. Төркия галимнәренең татар язучылары турында моннан алдарак әзерләнгән аерым монографик хезмәтләре булса да, бу дәрәҗәдә колачлы һәм җентекле үрнәкләрне чагыштырулар белән әдәби бәйләнешләр темасы беренче тапкыр әлеге докторлык диссертациясендә генә тикшерелде. Шушы фәнни эшебез, татар галимнәре, әдипләренең игътибарын җәлеп итәр, алар арасында кызыксыну уятыр дип өметләнеп, хезмәтебезнең эчтәлеге белән таныштырырга булдык.

Диссертациянең кереш бүлегендә Идел-Урал төбәгенең патша Россиясе тарафыннан 1552 елда яулап алынуы, татарларның Россиядә беренче рәсми оешмасы булган мөфтият, татар зыялыларының тамырлары, яңа ысулдагы татар мәдрәсәләре, 1905 елгы революция алып килгән хөррият атмосферасы, Исмәгыйль Гаспралының Кырымда башлаган һәм иң күбе Идел-Уралда таралган ысулы җәдит мәктәпләренең татар җәмгыятенә керткән өлеше аңлатыла.

1552 елдан алып 1690 елга кадәр Идел-Уралда йөз дә кырык ел эчендә, түгел әдәби бер әсәрнең, хәтта исеме телгә алынган бер генә укымышлы шәхеснең дә булмавы бу чорны «кара чор» буларак бәяләргә сәбәп була ала.

1755–1790 еллар арасындагы күтәрелешләр Россия дәүләтенең мөселманнарга карата сәясәтен үзгәртүгә юл ача. 1770 елда Казанда беренче таш мәчет («Мәрҗани» мәчете) ачыла. 1787 елда Петербургта беренче тапкыр Россия дәүләте тарафыннан Коръәни Кәрим бастырыла. 1789 елның 2 гыйнварында Екатерина II тарафыннан дәүләт контролендә булган Оренбург мөселман диния нәзарәте оештырыла. XVII һәм XVIII гасырларда Россиядәге чуалышларда мәчет-мәдрәсәләренә зарар китерелмәгән Эстәрлебаш, Кышкар һәм Каргалы авылларындагы Бохара ысулындагы мәдрәсәләр үзләре тәрбияләп чыгарган дин әһелләре һәм шагыйрьләре белән татар мәдәни тормышының мөһим мәгариф һәм мәдәният үзәкләренә әверелә.

1855–1889 елларда татар җәмгыятенең түл җыйган, милли рухы ныгыган чорны *Мәрҗани чоры* дип атарга да мөмкин. Бохарада укыган Шиһабетдин Мәрҗани кебек «мөҗәддит»тән соң Мәскәүдә белем алган, татарларга һәм бөтен Урта Азиягә йогынты ясаган Исмәгыйль Гаспралы кебек «реализатор» мәйданга чыга. 1884 елдан 1905 елга кадәрге чорны татар иҗтимагый хәрәкәтен *Гаспралы чоры* дип атарга була. 1905–1917 елларны исә *хөррият еллары* дип атарга мөмкин. Бу чор – яңа татар әдәбиятының алтын гасыры. Бу чорда татар тарихында беркайчан да булмаган кадәр бөек язучылар үсеп чыга.

Татар яңарыш хәрәкәте Идел-Урал татарларының XIX гасырның соңгы чирегеннән алып, 1917 елның Октябрь революциясенә кадәр кырык еллык дәвердә Бохарада җитешкән Шиһабетдин Мәрҗани кебек могтәбәр ил агасы, аксакалларыннан белем бирү системасын формалаштыручы капитал иясе татар сәүдәгәрләренә, авыл имамнарыннан мәдрәсә шәкертләренә, Истанбул һәм Мисырда белем алган Фатих

Кәрими һәм Габдрахман Сәгъди кебек язучы-журналистлардан татар мөгаллимнәренә, Зәйнулла Рәсүли һәм Галимҗан Баруди кебек дин галимнәреннән үз туган җирләрендә үсеп чыккан Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан кебек яңартучы зыялыларына кадәр бик киң бер җирлектә социаль һәм төптән килгән, төп кысасы мәгърифәтчелек булган татар җәдит хәрәкәте моңарчы социологик мисалы булмаган, үзенең эчке динамизмы сәбәпле барлыкка килгән бер интеллектуаль хәрәкәтнең бердәнбер һәм уникаль үрнәге буларак уртага чыга. Идел-Урал төбәгендә формалашкан бу хәрәкәтнең казакъ далаларыннан Себергә кадәр, үзбәк җирләреннән уйгур өлкәсенә кадәр киң туфракларда региональ җәдит хәрәкәтләрнең һәм әдәбиятларның формалашуына кадәр йогынты ясавы хәрәкәтнең мотивация көчен күрсәтүе ягыннан бик мөһим.

Беренче бүлек «Татарларның белем бирү һәм мәдәни тормышында Госманлы дәүләтенең һәм «Солтан шәһәре» Истанбулның йогынты сфералары (1860–1905)» дип атала. Бу бүлектә 1860 елдан алып 1905 елга кадәрге чорда татарларның Истанбулга йөз тотуларының күрсәткечләре булган сәяхәтнамәләр һәм хаҗнамәләр, сәяхәт иткән Истанбул китаплары, госманлычадан тәрҗемәләр, татар яңарышының көчле ихтыярлы алдынгылары Шиһабетдин Мәрҗани, Зәйнулла Рәсүли һәм Исмәгыйль Гаспралы кебек зыялыларның бу юнәлештәге рольләре, Идел-Урал төбәгендәге мәгариф учреждениеләре һәм, Җамал Вәлиди сүзләре белән әйткәндә, «истанбуллылаштырылган» яңа татар мәдрәсәләре, Истанбулда укыган татар студентларына кагылышлы мәсьәләләр җентекләп каралган.

Татар әдәбиятында әдәби жанр буларак, сәяхәтнамәләрнең тәүге үрнәкләре хаҗ сәяхәтләре була. Татар хаҗиларының хаҗга барышлый иң беренче ирешкән ислам үзәкләре Истанбул булганлыктан, алар анда күргән яңа нәрсәләр, сатып алган китаплар һәм күрешкән кешеләр белән фикер алышулар аларга яңара башлауга этәргеч була. Бик күп хаҗнамәләр арасыннан Гали Чокрый белән Шиһабетдин Мәрҗанинекеләр аеруча мөһим. 1880 елда хаҗга барган Мәрҗани Истанбулда иң югары дәрәҗәдә каршы алына. Мәрҗани шәйхелислам Әхмәт Әсат әфәнде, юстиция министры Җәүдәт паша, тышкы эшләр министры Саффәт паша һәм элекке мәгариф министры Мөниф пашалар белән очраша. Юл уңаеннан Истанбулга тукталган дәрәҗәле татар имамнарына һәм сәүдәгәрләренә Госманлы дәүләте төрле бүләкләр бирә. Шундыйлардан Мөхәммәдьяр Солтанов, Гатаулла Баязитов, Исмәгыйль Гаспралы, Хәсән Акчурин, Галимҗан Баруди, Нургали Хәсәнов һәм Хәсәнгата Габәши кебекләрне билгеләп үтәргә мөмкин. Татар хаҗилар, Госманлы классик әсәрләрен алып, аларны Идел-Урал якларына алып китәләр. Бохарага укырга барган татар шәкерләре шулай ук чыгтайча китапларны Идел-Уралга алып кайталар. Миркасыйм Госманов бу китапларны «сәяхәтче китаплар» дип атый. Рәхмәтулла Әмирхан, Каюм Насыйри, Габделгалләм Фәезханов һәм Фатих Халиди кебек татар зыялылары «Әбүгалисина», «Ләтаифе Хуҗа Насретдин», «Хикмәтле тутый хикәяте», «Тарикаты Мөхәммәдия», «Мәгърифәтнамә», «Кырык вәзир», «Кабуснамә», «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә» һәм «Мең һәм бер көн» кебек әсәрләрне алар госманлы теленнән татар теленә тәрҗемә итеп бастырганнар.

Татар яңарышында Истанбул белән бәйләнешләрне мөһим дип санаган көчле ихтыярлы лидер зыялыларның башында Шиһабетдин Мәрҗани килә. 1861–1876 еллар арасында Мәрҗани унлап укучысын Истанбулга укырга җибәрә. Үзенең улы Борһанетдин 1875 елда Истанбулга килә һәм анда сигез ел укый. 1872 елларда Истанбулдагы укучылары «Җәридәи хәвадис», «Басыйрәт» һәм «Әл-Җәваиб» кебек Истанбул газеталарын Мәрҗанигә җибәреп торалар. Идел-Уралның мөһим мәсьәләләрендә Зәйнулла Рәсүлинең дә Истанбул белән элемтәсе көчле. Ул да укучыларын, шул исәптән үз улын да, Истанбулга укырга җибәрә. Бу ике бөек шәхеснең икесе дә Исмәгыйль Гаспралы һәм аның карашлары яклы булалар.

Бохара ысулындагы Эстәрлебаш, Кышкар һәм Каргалы мәдрәсәләре татар

үзаңының мәдәни учаклары булса, яңа чорда укучыларының күбесе Истанбул һәм Каһирәдә белем алган Казандагы «Мөхәммәдия», Уфадагы «Галия» һәм Оренбургтагы «Хөсәения» кебек яңа ысуллы мәдрәсәләр татар терелешенең милли үзәкләренә әверелә. Яңа татар әдәбиятының күренекле язучылары барысы да болардан чыккан. Казакъ һәм үзбәк якларыннан бу уку йортларына шактый күп укучы белем алырга килгән.

Татар әдәбиятының алдынгы язучылары Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Мөхәммәд Садыйк, Муса Акъегетзадә, Фатих Кәрими, Габдрахман Сәгъди, Шәриф Камал, Йосыф Акчура, Нәҗип Гасри, Зыя Насыйри, Габдулла Шинаси, Хәлим Сабит, Мәхмүт Алмаев, Габдрахман Кәрәм, Гобәйдулла Буби, Харис Фәйзи һәм Һади Максуди Истанбулда укыйлар. Табылган мәгълүматка караганда, 1907 елда Истанбулда укучы татар студентларының саны – 25, 1908 елда – 54, 1909 елда 67 гә җитә.

Икенче бүлек «1905–1917 елларда яңа татар әдәбияты язучыларына яңа төрек әдәбиятының йогынтысы яссылыгында Истанбул матбугаты» дип атала.

Яңа татар мәдрәсәләрендә һәм Истанбулда җитешкән яңа буынның таянырлык үз ресурсларыннан мәхрүм булулары аларга, Истанбулдагы кардәшләреннән әдәби әсәрләр алып, үз китапханәләрен булдырырга юл ача. Татар мәдрәсәләрендәге шәкертләр потенциалы китап сәүдәсенең җанлануына сәбәп була.

1905 елгы революциядән соң Истанбулда басылган китаплар Казан, Уфа, Оренбург, Эстәрлетамак, Троицк һәм Орск кебек шәһәрләрдә ачылган татар китап ширкәтләре тарафыннан Идел-Урал төбәгендә күпләп таратыла. Яңарыш чоры төрек язучыларының бөтен әсәрләренең бу дәвердә Идел-Урал төбәгендә укылганын бу ширкәтләрнең «Әсами көтүб» дип аталган реклама брошюраларында күрергә мөмкин. Төрек язучылары Зия Паша, Намык Кәмаль, Әхмәт Митхәт әфәнде, Шәмсеттин Сами, Мөаллим Наҗи, Абдүлхак Хәмит, Әхмәт Расим, Хөсәен Рәхми, Хөсәен Җахит, Мәһмәт Рауф, Җәнап Шаһабеттин һәм Халит Зия Ушаклыгил кебек язучыларның культ әсәрләре «Әсами көтүб»ләрдә урын алган. Истанбулда укыган татар язучылары Йосыф Акчура, Закир Рәмиев, Фатих Кәрими, Шәриф Камал һәм Габдрахман Сәгъдиләрнең төрек әдәбиятына карашлары, аларның төрек әдәбиятыннан тәрҗемәләре һәм алар тәэсирләнгән төрек язучылары, Истанбулда укымасалар да, Истанбулга йөз токткан татар язучылары Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал һәм Фатих Әмирханнарга төрек әдәбиятының йогынтысы аерым-аерым тикшерелә.

Цензура басымына карамастан, Истанбул газеталары һәм журналлары Идел-Урал төбәгенә барып җитә тора. Шулай ук төрек әдәбиятыннан татар теленә тәрҗемәләр дә ясала. Намык Кәмальнең «Zavallı Çocuk» («Бичара бала») һәм «Vatan Yahut Silistre» («Ватан, яхуд Силистра») драмалары «Кызганыч бала» (1900) һәм «Ватан» (1918) исеме белән, Теодор Касабның «Pinti Hamid» («Саран Хәмид») әсәре «Саран» (1914), Абдүлхак Хәмитнең «Duhter-i Hindu» («Һинд кызы») пьесасын «Һинд кызы» исеме белән Галиәсгар Камал тарафыннан тәрҗемә ителә.

Төрек әдәбиятының беренче романы Шәмсетдин Саминың «Taaşşuk-ı Talat ve Fitnat» дип аталган әсәре «Мөгашәка, яхуд Тәлгать бәк илә Фитнат ханым» (1904) исеме белән Гыйнаятулла Әхмәт тарафыннан тәрҗемә ителә. Әхмәт Мидхәт әфәнденең «Gençlik» («Яшьлек») исемле әсәре Садри Максуди тарафыннан «Яшьлек – юләрлек» (1897) исеме белән тәрҗемә ителгән кебек, тагын бик күп әсәрләр татарчага аударыла. Мәһмәт Җәлалның «Җәмилә» романы (1907) татарча нәшер ителә. Халит Зия Ушаклыгилнең «Mezardan Sesler» әсәре Габдрахман Сәгъди тарафыннан «Кабердән тавышлар» (1912) исеме белән татарчага тәрҗемә ителә. Янә Халит Зияның ике хикәясе Габдрахман Кәрәм тарафыннан «Аң» журналында, татарча бер хикәясе «Шура»да басылып чыга. Тагын Хөсәен Рәхми Гүрпынарның «Mürebbiye» («Тәрбияче ханым») романы А.Авыргази тарафыннан «Аң»да нәшер ителә.

Йосыф Акчураның Казандагы эшчәнлеге, «Вакыт» газетасына Истанбул турында

язган мәкаләләре, төрек әдәбияты турындагы фикерләре, «Türk Yurdu» («Төрек йорты») журналы, Истанбулдагы эшчәнлеге һәм бу татар милли фәлсәфәчесе хакында җентекле тикшеренүләр дә хезмәттә урын алган. Янә шагыйрь Дәрдемәнднең тормышы, Истанбул белән мөнәсәбәтләре, Зия Пашага ияреп язган шигырьләре, аның төрек теленнән тәрҗемәләре карала. Фатих Кәримигә багышланган бүлек утыз биттән гыйбарәт. Фатих Кәриминең Истанбулдагы тормышы, анда Җамалетдин Әфгани һәм Вамбери белән күрешүләре, Әхмәт Митхәт әфәнде белән мөнәсәбәтләре, әсәрләре һәм өслүбендәге Әхмәт Митхәтнең йогынтысы «Gönül» («Күңел») һәм «Мирза кызы Фатыйма» романнарын чагыштыру аша тасвирлана. Шәриф Камал һәм Халит Зия Ушаклыгил арасындагы йогынтылар аларның хикәяләреннән мисаллар белән күрсәтелә. Истанбул дарелфөнүнендә укыган Габдрахман Сәгъдинең риторик китаплары анализланып госманлы риторик китаплары белән чагыштырыла. Шулай ук Фатих Әмирханның «Тәгъзия» шигыренең Халит Зия Ушаклыгилнең «Mezardan Sesler» («Кабердән тавышлар») мәшһүр шигыренә охшаш яклары уртага салып күрсәтелә.

Өченче бүлектә татар әдәбиятында яңа төрек әдәбиятчыларына карашлар, мөнәсәбәтләр карала. Яңарыш чоры төрек язучыларыннан Ибраһим Шинаси, Намык Кәмаль, Шәмсетдин Сами, Рәҗаизадә Мәхмүт Әкрәм, Абдүлхак Хәмит, Әхмәт Митхәт әфәнде, Халит Зия Ушаклыгил һәм Тәүфикъ Фикрәт кебек алдынгы язучы һәм шагыйрьләрнең аерым баш исемнәр астында татар язучыларына йогынтылары өйрәнелгән.

Яңарыш чоры төрек әдәбиятының 1860 елдан 1917 елгы революциягә кадәрге арада Идел-Урал татар мәдәнияте һәм әдәбиятына булган тәэсире, чорның әдәби казанышлары шул вакыттагы газета-журналларны өйрәнеп ачыкланды. Шушы темага бәйле тупланган мәгълүмат диссертациябезнең актуальлеген һәм оригинальлеген билгеләүгә нигез булды. Хезмәтебезнең илле битлек библиографиясенең яртысыннан артыгын гарәп хәрефләре белән язылган татар әсәрләре, шул чорның татар газета-журналлары тәшкил итә. Татар галимнәре һәм язучыларының китапларында урын алмаган мәгълүмат һәм документларны кертү диссертациянең кыйммәтен тагын да арттыра. Хезмәтебезне әзерләр өчен 2013 елда Казанга килеп, архивларда һәм китапханәләрдә дә эшләгән идек. Шул вакытта ачык йөз белән каршы алып ярдәм иткәннәре өчен татар зыялылары һәм галимнәреннән Разил Вәлиев, Хатыйп Миңнегулов һәм Мәсгуд Гайнетдингә (урыны җәннәттә булсын) рәхмәтләремне җиткерәм.

**Һүсәйин БАРГАН,**
*фән кандидаты*[1].
*Төрекчәдән* **Ринат СӘФӘРОВ** *тәрҗемәсе*

[1] Һүсәйин Барган – төрек галиме. Истанбулда яши.

*Мәхмүт Хөсәеннең тууына – 100 ел*

# ТҮБӘТӘЙЛЕ ӘДИП



Күренекле шагыйрь, утлар-сулар кичкән фронтовик, күпсанлы җырлар авторы Мәхмүт Хөсәеннең тууына 100 ел тулды.

Мәхмүт Хөсәен (Мәхмүт Хафиз улы Хөсәенов) 1923 елның 15 апрелендә хәзерге Казакъстан Республикасының Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Җаңакала районы Урда авылында туган. 1941 елда Кызылъяр шәһәрендә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, пионервожатый, газета хезмәткәре, культмассовик булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Мәхмүт Хөсәен үзе теләп, армия сафларына баса. Фронтның алгы сызыгында сугыша, берничә тапкыр яралана, «Кызыл Байрак», «Кызыл Йолдыз» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. 1945 елда Ленинградта Югары Артиллерия мәктәбендә укый, аннары 1947 елның июненә кадәр Ленинградта һәм Казанда командир булып хезмәт итә.

1947–1952 елларда Мәхмүт Хөсәен Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, озак еллар Татарстан китап нәшриятында башта редактор, аннары матур әдәбият редакциясе мөдире булып эшли. 1976 елдан – язучы-профессионал, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.


Мәхмүт Хөсәеннең җырчы-шагыйрь буларак та үз урыны бар. Аның шигырьләренә татар, башкорт һәм казакъ композиторлары, яшь һәм үзешчән музыкантлар тарафыннан 150 дән артык җыр язылган. Шагыйрьнең аерым шигъри әсәрләре украин, үзбәк, литва, таҗик, кыргыз, удмурт, мари, чуваш, каракалпак һәм монгол телләрендә басылып чыккан. Рус һәм казакъ телләрендә исә өч мөстәкыйль җыентыгы бар. Мәхмүт Хөсәеннең үзе исән чагында ук кырыкка якын китабы дөнья күрде.

Өлкәнрәк тыңлаучыларыбыз хәтерлидер, Мәхмүт Хөсәен сәхнәләрдән чыгыш ясарга ярата иде. Халыкның Горький паркына аның шигырь сөйләгәнен тыңларга йөргән чаклары бар иде. Бәлки шуңадыр, аерым әдәби даирәләр тарафыннан аны кечерәйтебрәк күрсәтү, эстрада шагыйре итеп кенә бәяләү галәмәте сизелде. Ләкин күңел биреп укып карасаң, Мәхмүт Хөсәен зур һәм тирән иҗат иясе икәнлеге аңлашыла. Бу – халыкчан шигърият.

Совет елларында Казанда татар зыялылары арасында милли киемнән ваз кичмәгән ике генә шәхес бар иде кебек. Аларның берсе ак калфаклы сандугачыбыз Сара Садыйкова булса, икенчесе – Мәхмүт Хөсәен. Аның бизәкле түбәтәе беркайчан да башыннан төшмәде, шул рәвешчә ул үз халкына ахыргача тугрылыклы булуын ачыктан-ачык күрсәтә белде. Бу ул заманнарда үзенә күрә бер батырлык иде.

QR-код ярдәмендә сайтыбызга кергәч, Мәхмүт Хөсәеннең атаклы музыкантларыбызга һәм композиторларыбызга багышланган шигырьләреннән төзелгән радиокомпозиция ачылып китәчәк. Мәхмүт Хөсәен укуындагы шигырьләр 1980 еллар ахырында язып алынган. Программа дәвамында сез шулай ук Салих Сәйдәшев, Заһидулла Яруллин, Сара Садыйкова, Исмәгыйль Һилалов һәм Рөстәм Яхин әсәрләрен республикабызның танылган музыкантлары һәм авторларның үз башкаруында ишетерсез.

# ШИГЫРЬЛӘРЕ КӨЙГӘ ЯТЫП ТОРА...



Татарстан Республикасы Дәүләт Гимны сүзләре авторы, фронтовик шагыйрь Рамазан Муллагали улы Байтимеровның (1923–1989) тууына 100 ел.

Бу исем ишетелүгә, Татарстан радиосы коллективының үз эчендә генә якты хатирә итеп саклана һәм буыннан-буынга күчеп сөйләнә торган бер мәзәк хәл искә төшә. Элек радиода Сәнгать советы бар иде. Шушы советның таләпчән «җиз иләге» аша үтеп чыга алган җырлар гына эфирга бирелә иде. Бервакыт Рөстәм Яхин радиога Рамазан Байтимеров шигырьләренә язылган яңа җырлар алып килә башлый. Алар әлеге дә баягы Сәнгать советында тикшерелә, кабул ителә. Мондый җырлар күбәеп киткәч, шушы советта әгъза булып утыручы бер зур шагыйрьнең эче поша башлый һәм ул: «Ник язасың аның сүзләренә, беткәнмени башка шагыйрьләр?» – дип, композиторга дәгъва белдерә. Казаннан читтә яшәүче иҗатчыларга үгисетеп карау бар иде бит элек, бу шагыйрь дә шундыйрак фикер тарафдары булган, күрәсең. Шуннан композитор бөтен халык алдында аңа җайлап кына болай дип җавап бирә: «Сезнекеләргә дә язып карадым, фәлән ага, интегеп беттем, ә менә Рамазанның шигыре үзе җырлап, көйгә ятып тора», – дигән...

Чыннан да, безнең радионың музыкаль архивында Рөстәм Яхин белән Рамазан Байтимеров язган дистәләгән җырлар саклана, һәм гаҗәбе тагын шул: алар әле бүген дә халык тарафыннан соралып, эфирда яңгырап тора. Шушы ике олуг шәхеснең иҗат җимеше булган «Туган ягым» җыры 1993 елда, зур конкурс аша үтеп, республикабызның Дәүләт Гимны итеп кабул ителде.

Рамазан Байтимеровның шигырьләрендәге ритм һәм рифма төгәллеге, хис һәм фикер тирәнлеге башка композиторларның да игътибарын җәлеп иткән. Җәүдәт Фәйзи, Сара Садыйкова, Бату Мөлеков, Рәшит Абдуллин кебек күренекле аһәңсазлар тарафыннан иҗат ителгән җырлар безнең көннәрдә дә яшь буын башкаручыларның репертуарында урын ала, радио һәм телевидение эфирында яңгырый.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтында бирелгән мәгълүматларга караганда, Рамазан Муллагали улы Байтимеров 1923 елның 5 апрелендә Башкортстанның Авыргазы районы Исмәгыйль авылында туган. 1941 елның көзеннән сугышның соңгы көннәренә хәтле фронтта хәрәкәттәге армия сафларында була. Ике тапкыр контузия ала, яралана. Батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә. Туган ягына гомерлек инвалид булып кайта. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. «Чаян» журналы, республика радио-телевидение редакцияләрендә, мәктәптә укытучы булып эшли. 1958 елдан Лениногорск шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

Рамазан Байтимеров – бик күп шигырьләр, поэмалар авторы. Шагыйрьнең «Туган ягым», «Канатларым», «Мәңгелек яшьлек», «Җырларым – солдатларым» дигән җыентыклары басылып чыккан.

Хәзер инде, әйдәгез, QR-код ярдәмендә сайтка керик. Биредә игътибарыгызга журналист Ирек Нигъмәти тарафыннан әзерләнгән «Җырга күчкән язмыш» дип исемләнгән радиотапшыру тәкъдим ителә. Анда язучы Рәмзия Габделхакова һәм шагыйрь Гәрәй Рәхимнең Рамазан Байтимеровның иҗатына һәм тормыш юлына кагылышлы фикерләре, шагыйрьнең кызы Гөлшат Кушелькова-Байтимерованың әтисе турында язган истәлекләре урын алган.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## Рамазан Байтимеров

### Каен суы

Каен суы нигә ага икән,
Кышлар үтеп, ямьле яз җиткәч?
Күз-яшь булып әллә тама микән,
Яшь гомерләр үткәч, наз киткәч?

Ямьле язлар җитсә, кешеләр дә,
Табигать тә күркәм киенә.
Кошлар да шул чакта сузып-сузып
Җыр җырлыйлар бәхет көенә.

Күңелләрнең китек урыннары
Искә төшә бәйрәм көннәрдә.
Тел булмагач, эчке моң-зарларын
Сөйләсен соң каен кемнәргә?

Каеннарны яз утырткан ирләр
Кайталмады туган җирләргә.
Шуңа, ахры, каен күз-яшь түгә,
Яфраклары шаулый җилләрдә.

### Сагыш

Язмыш илтте яшьли еракларга,
Йөрәк ничек ярсып типмәсен?!
Читтә яшәп, читтә картаерга
Беркемгә дә насыйп итмәсен.

Тезелешеп кошлар кайткан чакта,
Карый идем күккә каерылып.
Кошларның да калмый бәхетлесе
Туып үскән җирдән аерылып.

Туган җирне кайтып бер күрсәм дә,
Мин үкенмәс идем, үлсәм дә,
Баш очына салып калдырырга
Туфраккаен йөрттем кесәмдә.

### Игенче

Игенче син, бәхет игүче син,
Йөрәгеңдә бетмәс ярсу бар.
Күңелеңне тарта киң басулар,
Эрү белән язгы кар-сулар.

Карашларың күктә, үзең җирдә,
Җырың белән кырлар уяна.
Игенче син, бәхет игүче син,
Данлы кеше бөтен дөньяда.

Синең тырыш хезмәт көчең белән
Мул булалар сыйлар табында.
Маңгай тирең тамган болын-кырлар
Шатлыгың да синең, кайгың да.

Игенкәйләр күкрәп үссен диеп
Йөрисең гел янып-көеп син.
Байлык-муллык өчен көрәшүче,
Үзең гади, үзең бөек син.

### Үзем турында

Татып үстем ачы-төчеләрне,
Җәүһәр күрсәм, туктап ымсынмыйм.
Кеше булып җирдә яшәгәндә
Ни эшләдем, үзем кем соң мин?

Дусларыма керсез сөюем бар,
Дошманнарга нәфрәт, үчле мин.
Кеше булуымны Ватаныма
Мәхәббәтем аша үлчимен.

Изге антым саклап йөрәгемдә,
Давыл кичкән гади солдат мин.
Үз халкымның үлмәс күзәнәге,
Киләчәккә яшим карап мин.

Туган илем – бөек язлар иле,
Бар дөньяга нурын бөркеде.
Җиргә җылы биргән шушы язның
Мин кечкенә бер нур бөртеге.

# ҖИЛӘКЛЕ ГОМЕР



Кешенең гомер озынлыгы аның кылган гамәлләре, изге эшләре белән бәяләнә. Нинди генә һөнәр сайласа да, кешелеккә, җәмгыятькә файда китерергә омтылучы кеше үзе дә бәхетле була. Бүгенге героебыз да шулай ди.

Асия Гомәр кызы Шаһабетдинова тумышы белән хәзерге Чирмешән районы Кармыш авылыннан.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк хәрби хезмәткә алынып, илебез Бөек Җиңү таңын каршылаганнан соң гына кайткан Гомәр ага һәм аның тормыш иптәше Нәкыя апаның уртак мәхәббәтенең тәүге җимешләре бу дөньяга аваз салганга да инде җиде дистә елдан артык вакыт узган.

– Әтием фронтта күргәннәре хакында сөйләргә яратмый иде. Аның теләге бер генә булды: «Без кичергәнне балаларга, оныкларга күрергә язмасын!» – дип кабатлый иде ул хискә бирелгән чакларында. – Асия апа балачагы турында сөйләүне шундый истәлекләрдән башлады.

Бер-бер артлы туган сигез баланың иң өлкәне булган кызга исемне әтисе сайлый. Асия яңа гаилә башлангычы, шундый авыр заманда яшәргә көч бирүче җан булып дөньяга аваз сала.

– Әти-әниемнең көн буе эштә булуын исәпкә алсак, йорт-җирдәге шактый эшне миңа башкарырга туры килде. Шулай да ул чакларны бик сагынып искә алам. Иңгә чиләк-көянтә элеп, ерак чишмәдән тәмле су алырга баруларым читкә киткәч тә төшкә кереп йөдәтте әле, – ди ул, елмаеп.

Эне-сеңелләренә – күз-колак, әти-әнисенең уң кулы булып җитешә Асия. Әтисенең ал дими, ял дими эштә булуы өстенә, әниләре дә кырга беренчеләрдән булып чыга. Председатель хатыны башкаларга үрнәк күрсәтергә тиеш! Шуңа күрә колхозчыларга ипи басып пешерүгә кадәр барлык эш өлкән җилкәсенә төшә. «Өйдә һәркемнең үз вазифасы бар иде. Кечкенәдән эш белеп үскәнгә, һәрберебез тормышта үз юлын тапты. Укуда да, эштә дә сынатмадык», – ди Асия апа бертуганнары турында сөйләгәндә.

Уку дигәннән, бар нәрсәне алдан уйлап куярга, планлаштырырга өйрәнгән Гомәр ага балаларының киләчәген дә алдан кайгырта. Олы кызлары җиденчене тәмамлаганнан соң, балалар русчага өйрәнсеннәр дип, гаиләсе белән Бөгелмәгә күчәргә карар кыла. Баштарак моңа кадәр авылдан чыгып йөрмәгән кызга авырга туры килә, әлбәттә. Әмма үҗәтлеге үзенекен итә, тора-бара рус телен дә су урынына эчә башлый ул.

Ә менә кечкенәдән табиб булырга хыяллануы әтисенең үрнәге белән бераз башка юнәлеш ала – мәктәпне тәмамлар вакыт җиткәч, Асия авыл хуҗалыгы институтына барырга карар кыла. Тик беренче омтылыш бик үк уңышлы булмый – конкурстан уза алмый ул. «Тик мин бирешә торганнардан түгел. Бөгелмәнең җиләк-җимеш питомнигыннан юллама алдым да Кама Тамагы районының Теньки авылындагы авыл һөнәри-техник училищесына агрономлыкка укырга кердем». Вакытны сузмас өчен параллель рәвештә читтән торып институтка да барып керә ул. Аның тизрәк белгеч буласы, әтисенең эшен дәвам итәсе, киңәйтәсе килә. Әмма язмыш дигәнең башкачарак язылган икән шул.

Училищены тәмамлап, үз якларына эшкә кайткан чая, чибәр кыз әтисенең эшен дәвам итәргә, җиләк-җимеш үстереп, башкаларны шатландырырга уйлый. Тик менә

илленче еллар башында эти-әнисе бәхет эзләп, Урта Азия якларына чыгып киткән Миннефәритнең планнары башкачарак булып чыга – ул, кыз кулын сорарга дип, кодалар җибәрә. Бер көрешүдә үк бер-берсен ошаткан яшь йөрәкләргә, олылар баштарак каршы килсәләр дә, кавышу насыйп булган икән. Егетнең әтисе белән әнисе янына алар кияү-кәләш булып кайталар. Көн арты көн уза. Асия баштарак инкубатор станциясендә, соңрак мамык заводында эшли. Институтта имтихан бирү сылтавы белән елга ике мәртәбә туган якларга да кайтып килә ул. Тормышларын тулыландырып, бер-бер артлы өч малай туа. Өс-баш бөтен, тамак тук, дөнья түгәрәк кебек.

Әмма халыкның «җан тартмаса да, кан тарта» дигәне хакка чыга. Икенче баласын тапканнан соң, Асия апа бик каты авырып китә. Гади генә тамак шешүе аяныч хәлләргә китерә яза. «Гомерең булса, яшисең икән әле, – ди ул хәзер, елмаеп. – Бер зәхмәтнең бер хикмәте дигәндәй, бу сынау туган якларга кайтуга сәбәп булды». Үзләре яшәгән Шәһрисабз шәһәре хастаханәсеннән гариза язып чыга да Казанга оча ул. Табиблар кулы гына түгел, һавасы да шифалы була – күп тә үтми, Асия апа аягына баса. Элемтә юк заманнар, нинди хәбәр ишетергә дә белми юлга чыккан Миннефәритен ул диплом якларга әзерләнгән килеш каршы ала. Эчкән суының, сулаган һавасының да тормыш иптәшенә уңай тәэсир итүен күргән ир Татарстанга кайту турында уйлый башлый. Уртага салып сөйләшәләр дә Бөгелмәгә кайтып төпләнәләр.

Миннефәрит тракторга утыра, ә Асия кайчандыр укырга юллама алган җиләк-җимеш питомнигына урнаша. «Шәһәр халкын эшле дә, җиләкле дә иттек», – ди ул, горурланып. Шуның янына өйле дә дип өстәргә кирәк. Чөнки моңа кадәр баракларда яшәгән эшчеләр өчен унсигез фатирлы ике йорт төзетүгә ирешә җитәкче кеше. Башкалар өчен тырышкан җитәкченең сүзен эшчеләр дә аяк астына салмый. Бер утырткан агач үсә инде ул. Ә менә җиләк гел игътибар сорый. 15 гектар җиргә утыртылган татлы җимешне эшкәртергә, вакытында суын сибәргә, җыеп алырга да кирәк. Шөкер, ярдәм кирәк чакта районның башка оешмалары да Асия апа командасына өстәмә көч юллап тора. Өйдә сагынып көтүче ирең, балаларың, эштә шундый ярдәмчеләрең булганда, җир җимертеп эшлисе дә эшлисе генә дә бит. Әмма аларга кабат сынау килә – гаилә башлыгы, көтмәгәндә авырып китеп, мәңгелеккә күзен йома.

Ир кеше үз гомерендә өч эшне башкарырга тиеш дигән әйтем йөри халыкта: агач утыртырга, өй салырга һәм малай үстерергә. Ә бу эшләрне бит хатын-кыз да булдыра икән. 45 яшендә тол калган Асия апа өч ир баланы аякка бастырган, өй җиткезеп чыккан. Утырткан агачларның исәбе дә юк.

Әтиләрен озатканда, әле олы уллары Ринат – студент, Салават белән Руслан мәктәп укучылары булып кала. Бүген абыйлы-энеле өч ир туганның да үз гаиләсе бар, балалары буйга җиткән. Үзләре дә ир уртасы яшенә җитсәләр дә, канат ныгыткан ояларын онытмый алар. «Әни безгә ана назы бирү белән бергә, авыр чакта таянырлык ата җилкәсен дә алыштырды. Хәзер дә киңәш кирәк булса да, шатлыкларыбызны уртаклашырга да әни янына ашыгабыз. Һич югы шалтыратабыз. Үзе дә тик торырга яратмый. Ерак ара дип тормый, җыена да Казанга килеп җитә. Оныклары да «әби» диеп үлеп тора, киңәшчеләре генә түгел, сердәшчеләре дә булды шул ул аларга», – ди Ринат әфәнде, сүз алып.

– Бу тормышта бер генә үкенечем бар – улларыма игътибарым азрак булды, – дип көрсенеп куя Асия апа. – Шулай да алар үпкәләми, дөнья кууның шактый кыен булуын үзләре дә аңлый инде хәзер. Шөкер, бүгенге көндә иң зур таянычым алар.

– Тылсымлы таяк бирсәләр, нишләр идегез? – дип кызыксынам Асия ападан.

– Бакчачылык эшен яңартыр, кешеләр өчен күбрәк тырышыр идем, – ди ул.

– Ә үзегез өчен? – дип, төпченүемне дәвам итәм.

– Башкалар хакына күңелеңә яткан эш белән шөгыльләнү үзең өчен тырышу белән бер инде ул, – дип җавап бирә героем.

**Ландыш НӘСЫЙХОВА**

### РӘИС КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов рус әдәбияты классигы Александр Пушкинның тууына – 225, татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү турында карар имзалады.

### «ТУКАЙ ХӘЯТЫНА ЧУМЫП...»

Казандагы Г.Тукай әдәби музеенда шагыйрь, драматург, публицист, әдәби тәнкыйтьче, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхмәт Фәйзинең тууына 120 ел тулуга багышланган «Тукай хәятына чумып...» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты Газинур Морат, әдәбият галимнәре Хатыйп Миңнегулов, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Нурфия Йосыпова, нәфис сүз остасы Әлфия Хәбибуллина, җырчы Айдар Габдинов, Г.Камал театры артисты Илнур Закиров, И.Әүхәдиев исемендәге музыка көллияте студенты Азалия Хафизова, концертмейстер Алсу Сөнгатуллина һ.б. чыгыш ясады. Кичәне музей мөдире Гүзәл Төхвәтова алып барды.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

ТР Милли китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Юзеевның тууына 90 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды. Кичәдә язучылар Рәдиф Гаташ, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, Камил Кәримов, Газинур Морат, Рафис Корбан, Вакыйф Нуриев, галим Габдуллаҗан Җәләлов белән аның хатыны, ветеран-укытучы Гөлфәния ханым чыгыш ясады. Казан театр көллияте студентлары шагыйрьнең шигырьләрен укыды, Азат Тимершәех, Хәбир Ибраһим җырларын (баянда Рафаэль Сафин) җырлады.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирзага (Илфак Ибраһимовка) 70 яшь тулуга багышланган «Мәңгелек юлында» дип аталган әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы Илсөяр Иксанова, режиссёр Илдар Хәйруллин) булып узды. Ул Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге La Primavera оркестры һәм И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең татар хоры башкаруында Роза Мөхетдинованың Мөхәммәт Мирза сүзләренә язган «Идел-йорт» кантатасы белән башланды. ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин юбилярга ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев котлавын тапшырды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла котлады. Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Нурфия Йосыпова Мөхәммәт Мирзаның иҗаты турында сөйләде. Шагыйрьнең шигырьләрен Искәндәр Хәйруллин, Фәннүр Мөхәммәтҗанов (алар тамашачыларга бөек артист Мохтар Мутинга багышланган «Мохтар. XX гасыр трагедиясе» поэмасыннан өзек тә ирештерделәр), Илнур Закиров, Ришат Әхмәдуллин, Ирек Хафизов укыды. Шигырьләрне яшь шагыйрьләр Эльмира Җәлилова, Лилия Гыйбадуллина, Ралиф Гыйздәтуллин да сөйләделәр. М.Мирза сүзләренә язылган җырларны Илүсә Хуҗина, Гөлнара Мурзиева, Айрат Ганиев, Лилия Муллагалиева, Алинә Кәримова, Лилия Хөсәенова, Сөмбел Билалова җырлады. Юбилярны котларга Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов, Актаныш муниципаль якташлар җәмгыяте рәисе Вәсим Вахитов, «Благодарение» фонды җитәкчесе Фәрит Салихов та килгән иде. Бәйрәм «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышы белән тәмамланды. Кичәне Фәнис Җиһанша белән Айзилә Батырханова алып барды.

***

Мөхәммәт Мирзаның юбилеен туган ягы Актанышта да зурлап билгеләп үттеләр. Районга Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендәге делегация килде. Аның составында Газинур Морат, Факил Сафин, Рөстәм Галиуллин, Нурфия Йосыпова, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Фәттахова, Айгөл Әхмәтгалиева, Лилия Гыйбадуллина, Айзирә Имамова кебек каләм әһелләре бар иде. Актаныштагы «Адымнар» мәктәбендә Мөхәммәт Мирза исемендәге шигърият һәм татар теле бүлмәсе ачылды, педагогик конференция, укучылар белән очрашулар үткәрелде.

Әдәбият бәйрәме Актаныштагы Ә.Авзалова исемендәге Мәдәният сараенда Мөхәммәт Мирзаның зур иҗат кичәсе белән дәвам итте.

* * *

Башкортстанның Эстәрлебаш районы үзәгендә Турмай авылында яшәп иҗат итүче Хисаметдин Исмәгыйлевнең 70 яшьлек юбилее уңаеннан чаралар узды. Татарстан һәм Башкортстан кунаклары түгәрәк өстәлдә катнашты, китапханәдә, музейда булды. Район мәдәният йортында «Әйтер сүзем бар» дип аталган кичә узды. Юбилярны Татарстан һәм Башкортстан Язучылар берлекләре рәисләре Ркаил Зәйдулла белән Айгиз Баймөхәммәтов, каләмдәшләре Марсель Галиев, Газинур Морат, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан, Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары Руслан Сөләйманов, Дилбәр Булатова, Илдус Фазлетдинов, Мөнир Вафин, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшин һ.б. котлады.

## РӘФИКЪ ЮНЫСНЫ ИСКӘ АЛУ

Якташ язучылар – шагыйрьләр, популяр җырлар авторлары Сания Әхмәтҗанова, Наил Касыймов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, аның урынбасары Вакыйф Нуриев Арча районына кайтып, шагыйрь, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты, байтак еллар басмабызның баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән Рәфикъ Юнысны искә алдылар. Сәфәр әдипнең туган авылы Кәче зиратында хезмәттәшебезнең каберен зиярәт кылудан башланды. Монда Рәфикъ Юныс улы рухына дога багышланды. Аннары Кәче мәктәбендә Р.Юнысның тууына 80 ел тулу уңаеннан «Яшәү дәвам итә» дип аталган кичә булды. Анда укучылар якташ шагыйрьнең шигырьләрен укыдылар, Казаннан кайткан кунаклар Рәфикъ ага белән бәйле җылы хатирәләрен, якты истәлекләрен уртаклаштылар.

## КОНФЕРЕНЦИЯ

Кукмара районы Олыяз мәктәбендә «Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел» дип аталган фәнни-гамәли конференция булып узды. Анда жюри әгъзалары буларак әдәбият галиме Фоат Галимуллин, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат һәм шагыйрь Фәнил Гыйләҗев катнашты.

## УНСИГЕЗЕНЧЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы Рәдиф Сәгъдинең «Бер гаилә сурәте» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан унсигезенче китап. Анда авторның ике детектив әсәре тәкъдим ителгән. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте медиа директоры Алсу Исмәгыйлева, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, авторның каләмдәшләре Зиннур Мансуров, Камил Кәримов, Фирдәвес Зариф, әдәбият галимнәре Хатыйп Миңнегулов, Зөфәр Мөхәммәтшин, җырчы Базарбай Бикчәнтәев һ.б. чыгыш ясады. Чараны Г.Кариев исемендәге Казан яшь тамашачы театры артисты Илфат Камалиев алып барды.

## «АУЛАК ӨЙ»

ТРның Мәгариф һәм фән, Мәдәният, Яшьләр эшләре министрлыклары, Бөтендөнья татар конгрессы, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән оештырылган төбәкара «Аулак өй – көрәш» проектының (җитәкчесе – журналист Сәрия Закирова) финал ярышлары булып узды. Анда Балык Бистәсе районы Олы Елга, Лаеш районы Имәнкискә, Чувашия Республикасының Комсомол районы Урмай мәктәпләре, Казандагы 5 нче гимназия укучылары көч сынашты. Финалда Олы Елга мәктәбе җиңеп чыкты һәм «Сәләт» лагерена юллама белән бүләкләнде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

15 апрель – журналист-публицист, нашир, тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Ислам Әхмәтҗанов**ка 75 яшь.

***

22 апрель – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты **Марат Әмирханов**ка 90 яшь.

***

25 апрель – Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, прозаик, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты **Халисә Мөдәррисова**га 70 яшь.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман М.АМИРХАНОВА «Воительница», роман Х.ИСМАГИЛОВА «Заколдованный круг», рассказы Х.МУДАРИСОВОЙ; поэма Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ; стихи С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, Р.ШАГЕЕВА.*
*«Литература родственных народов»: стихи Г.АНДРОСОВА в переводе Р.МУХАМЕТШИНА.*
*«Литературный конкурс «Учитель – самый прекрасный человек на земле!»: рассказ Ф.ШАКИРОВОЙ «Новая жизнь Гульчачак».*
*Фотоархив посвящённый 100-летию И.Нуруллина. Рубрику подготовил А.ШАЙХИН.*
*«2023 год – год дастанов»: статья И.ЗАКИРОВОЙ.*
*«Литературная критика»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА.*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 100-летию М.Хусаинова и 100-летию Р.Байтимерова. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Стихи Р.БАЙТИМЕРОВА.*
*«Соплеменник»: статья Л.НАСЫХОВОЙ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На нашей обложке: здание Национальной библиотеки РТ. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by M.AMIRKHANOV «The Warrior Girl», novel by H.ISMAGILOV «The Enchanted Circle», stories by H.MUDARISOVA; poem by F.GIZZATULLINA; poems by S.AKHMETZYANOVA, R.SHAGEEV.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by G.ANDROSOV translated by R.MUKHAMETSHIN.*
*«Literary competition «Teacher is the most beautiful person on earth!»: story by F.SHAKIROVA «Gulchachak’s New life»*
*Photo archive dedicated to the 100th anniversary of I.Nurullin. The rubric is prepared by A.SHAYKHIN.*
*«2023 is the year of dastans»: article by I.ZAKIROVA.*
*«Literary critics»: article by T.GALIULLIN.*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Priceless voices»: articles for the 100th anniversary of M.Khusainov and the 100th anniversary of R.Baytimerov. The rubric is led by N.AKMAL.*
*Poems by R.BAYTIMEROV.*
*«Tribeman»: article by L.NASIKHOVA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our cover: building of the National Library of the Republic of Tatarstan. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* ТРның Милли китапханәсе бинасы.
*И.Абрамова фотосы.*